ISSN 0206–4189
Индекс 73210

# КАЗАН УТЛАРЫ

11.2011





**Габдрахман Әпсәләмов**
**(1911—1979 )**

**Казан утлары**

**Qazan utları**

2011

**11**

**(1069)**

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:
**«ТАТМЕДИА»**
*ачык акционерлык җәмгыяте*

татмедиа

*БАШ МӨХӘРРИР*

**Равил Габдрахман улы Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Рабит Батулла**
**Зилә Вәлиева**
**Разил Вәлиев**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Илфак Ибраһимов**
**Дамир Исхаков**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Розалина Шаһиева**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

---

*Мөхәррирләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Рөстәм Галиуллин, Марат Закир, Камил Кәримов, Алмаз Хәмзин.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Флера Сабирова.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Гөлнара Галиева** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

---

*420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
*Баш мөхәррир—562-10-62.*
*Баш мөхәррир урынбасары—292-93-16.*
*Җаваплы сәркәтип, компьютер үзәге—562-11-28.*
*Шигърият, публицистика, фән һәм сәнгать бүлеге—292-39-63.*
*Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге—292-39-63.*
*Гамәли хезмәткәрләр—562-11-28.*
*Исәп-хисап бүлеге—222-09-80.*
**Факс**—*(843) 562-11-28.*
**E-mail:** *kazanutlari@yandex.ru*

КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ–НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ–СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

Бу санда


**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Марсель ГАЛИЕВ. Тәхет җуйган халык—бәхет җуя... *Шигырьләр.* ........ 5
Марат ӘМИРХАНОВ. Әлвидаг. *Тарихи бәян.* ........ 10
Нәҗибә САФИНА. Яңа җыр алып киләм. *Шигырьләр.* ........ 112
Лилия СӘГЫЙДУЛЛИНА. Чиксезлек чикләрендә. *Шигырьләр.* ........ 120

**ТАТАР ХИКӘЯЛӘРЕ ХӘЗИНӘСЕННӘН**

Габдрахман ӘПСӘЛӘМОВ. Онытырлык түгел. ........ 116

**ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ**

Рәмилә МАЙОРОВА. Шуны тели йөрәк. *Шигырьләр.* ........ 123

**САТИРИК ӘСӘРЛӘР КОНКУРСЫ**

Рөстәм ГАЛИУЛЛИН. Дан. *Хикәя.* ........ 125

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Алсу ШӘМСУТОВА. «Алдымда—чикле чиксезлек...» *(Рәмис Аймәтнең иҗат портретына штрихлар).* ........ 127

**ФӘН**

Лилия МӨХӘММӘТҖАНОВА. Казан татарлары иҗатында китаби дастан. ... 137
Фирдәвес ГАРИПОВА. Авылларыбыз тарихы. ........ 158
«Татар энциклопедиясе» битләреннән. ........ 161

**ХӘТЕР**

Таһир ГЫЙЛАҖЕВ,Әлфәт ЗАКИРҖАНОВ. Музыкаль драма жанрына нигез салучы *(Мирхәйдәр Фәйзинең тууына 120 ел).* ........ 142
Фәнис ЯРУЛЛИН. Хәтер төпләрендә утлы күмер. *Көндәлекләр.* ........ 177

**ЮБИЛЕЙЛАР**

«Мин Казаннан китмәдем» *(Р. Галиуллинның Равил Бохарай белән әңгәмәсе).* . 148
Рәйсә ЮСУПОВА. Бөеклек һәм күңелдәге яралар *(София Гобәйдуллинага 80 яшь).* ........ 152
Марат ЗАКИР. Канатлы Ләбиб *(Ләбиб Леронга 50 яшь).* ........ 155

**АК ҖИЛКӘН**

Рөстәм МИНГАЛИМ. Бәләкәй Рөстәм. ........ 166
Флүзә НӘҖМИЕВА. Әниләрдә—әниләр дә. *Шигырьләр.* ........ 169
«Хикәя яза аласызмы?». ........ 170
Ким ШАКИРОВ. Бер планета—ике кояш. ........ 175

«Казан утлары» архивыннан. ........ 164

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ........ 188

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: историческая повесть М. АМИРХАНОВА «Разлука»; рассказ Г. АБСАЛЯМОВА «Никогда не забыть!»; стихи М. ГАЛИЕВА, Н. САФИНОЙ, Л. САГИДУЛЛИНОЙ.
«Творчество молодых»: стихи Р. МАЙОРОВОЙ.
«Сенной базар»: Конкурс сатирических произведений. Рассказ Р. ГАЛИУЛЛИНА «Слава».
«Литературная критика»: А. ШАМСУТОВА. «Творческий портрет поэта Р. Аймата».
«Память»: Т. ГИЛЯЗОВ, А. ЗАКИРЗЯНОВ. «Основатель жанра музыкальной драмы»; дневниковые записи Ф. ЯРУЛЛИНА.
«Наука»: Л. МУХАМЕТЗЯНОВА. «Книжный эпос в творчестве казанских татар»; Ф. ГАРИПОВА. «История наших деревень».
Страницы из «Татарской энциклопедии».
«Наши юбиляры»: Интервью Р. ГАЛИУЛЛИНА с Р. БУХАРАЕВЫМ; статьи Р. ЮСУПОВОЙ и М. ЗАКИРА, посвященные 80-летию композитора С. ГУБАЙДУЛЛИНОЙ, 50-летию поэта Л. ЛЕРОНА.
«Белый парус»: Р. МИНГАЛИМ. «Маленький Рустем»; стихи Ф. НАЗМИЕВОЙ.
Из фотоархива журнала.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: «Последние дни осени»; поэтесса Ляйсан ЮНУСОВА.

## IN THIS ISSUE:

«Prose and poetry»: historical novel by M. AMIRKHANOV «Separation»; story by G. ABSALYAMOV «Never forget!»; poems by M. GALIEV, N. SAFINA, L. SAGIDULLINA.
«Youth's creation»: poems by R. MAYOROVA.
«Hay market»: Competition of satires.Story by R. GALIULLIN «Glory».
«Literary criticism»: A. SHAMSUTOVA. «Creative portrait of poet R. Aymat».
«Memory»: T. GILYAZOV, A. ZAKIRZYANOV. «Founder of musical drama genre»; diaries by F. YARULLUN.
«Science»: L. MUKHAMETZYANOVA. «Book epic in creativity of Kazan Tatars»; F. GARIPOVA. «History of our villages».
Pages from «Tatar Encyclopedia».
«Our jubileers»: Interview of R. GALIULLIN with R. BUKHARAEV; articles by R. YUSUPOVA and M. ZAKIR, dedicated to 80th anniversary of composer S. GUBAYDULLINA, 50th anniversary of poet L. LERON.
«White Sail»: R. MINGALIM. «Little Rustem»; poems by F. NAZMIEVA.
From photo archives of magazine.
Diary of social-cultural life.
On our covers: «Last Days of Autumn», poet Laysan YUNUSOVA.

*The magazine edits monthly*

★ Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★ Редакциягә килгән кульъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★ Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 01.11.2011, график буенча 01.11.2011.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108 $^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ Р–1690. Тираж 4019.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча Федераль хезмәтнең Татарстан буенча идарәсендә, 2010 елның 1 апрелендә теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ №ТУ 16-00337
Индекс 73210 (физик затлар өчен), 16262 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

«ПИК «Идел-Пресс» ААҖ «ТАТМЕДИА» филиалы типографиясендә басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2011 ел.



Марсель
Галиев

# ТӘХЕТ ҖУЙГАН ХАЛЫК—БӘХЕТ ҖУЯ

## Бөек дала—Ана-Ил

**Алтын Урда.**
**Дөнья хозурында**
**Кайда синең сөрмә-алтыннарың?**
**Хач имезгән күпме гөмбәзләрдә**
**Күрәм аның зәһәр ялтыравын.**

**Алтын Урда.**
**Дала күкрәгендә**
**Кайда синең мәшһүр калаларың?**
**Тәхет җуйган халык—бәхет җуя,**
**Ятим даны иңрәп кала бары.**

**Алтын Урда.**
**Зиннәт-байлыгыңа**
**Көндәш булган, тиңдәш булалмаган.**
**Хан казнасы—җан казасы булса,**
**Мәңгелек рух илдә туалмаган.**

**Алтын Урда.**
**Кемнәр котырткандыр**
**Өч туганны[1] канга-кан килергә?**
**Була икән Ана-Илнең билен**
**Сындырырлык итеп тилертергә.**

**Алтын Урда.**
**Күкрәп янган дала,**
**Хан таҗлары янган—асылташлы.**
**Байраклары янган—бүре башлы,**
**Еланнары янган ысылдашып.**

[1] Аксак Тимер, Туктамыш хан, Идегәй

Марсель ГАЛИЕВ (1946) – *шагыйрь, прозаик, публицист; «Су буеннан әнкәй кайтып килә», «Догалы еллар», «Рух», «Талисман» һ.б. утызлап китап, алты томлык сайланма әсәрләр авторы. Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты.*

Алтын Урда.
Үзен-үзе җиңеп
Җиңелгәнне ничек аклап булсын?!
Иярдәге Илхан иелгәндә,
Илне халык ничек саклап калсын.

Алтын Урда.
Сабак алмас халык:
Таралганы күпме, таркалганы?
Әрсез кавемнәрне үрчетергә
Җитәр микән Җирдә татар каны?

Алтын Урда.
Гаярь улларыңның
Дәвамнары кайсы халыкларда?
Таныйм йөздән, әмма рухы бизгән,
Теле-дене—бүтән калыпларда.

Алтын Урда.
Дала ләхетенә
Иңгән атлы дәвер җәсәденнән
Өннәр килсә, тояклардан кубып,
Моң сирпелә хәтта җил күзеннән.

Алтын Урда.
Нинди кодрәт сүнгән!
Ни үкенеч, ела оятыңнан.
Бүре булып улый җанда Хәтер,
Ә хәтергә елан оя корган...

## Ат билендә туган поэма

Дала атлары, дәртләнеп,
Горур уйнаклап алса,
«Кыз куу» ярышларында
Парга парын табышса...

Ил җырлый, бишек аса.

Дала атлары, айгылдап,
Тояклар тупырдатса,
Ак болыттан ак лачыннар
Ялына төшеп кунса...

Ил яши, казан аса.

Дала атлары шомланса,
Кешнәшеп аваз салса,
Яу чыгарга хәбәр биреп,
Көмеш чаңнар чыңласа...

Ил иңгә корал аса.

Дала атлары егылса,
Данын таптап, хан ауса,
Дала атлары еласа...
Юатыр тел калмаса...

Илең үлгән ләбаса.

## Җан гүләве

Без бит шушы чиксез кыйтгаларның
Төп хуҗасы булган кавемнән.
Гасыр упкыннарын сикергәндә,
Егылганбыз атлар биленнән.

Бөркетләргә тансык биеклектән
Елдам карап, язмыш көлгәндер.

Күңелдәге чал кыраулы хисләр
Учаклары сүнгән көлдәндер.

Әле һаман сүнеп бетми канда
Бөек мәмләкәтләр гүләве.
Уч кызышса кылыч сабын эзләп,
Йодрык яный заман өрәге.
«Юлбарыс булдың, барыс булып кара!»—
Язмышның бу шулай түләве.

Дәүләтле чор, шанлы дәверләрнең
Һич тә онтыласы юк аның.
Сиңа рәхәт, моңсыз яшь замандаш,
Суык күзле
манкорт туганым.

## Иделнең ялган ярында

Су каргышы—сары камышларда.
Таныш ярда,
Тынын кысып, эссе ташлар ята.
Кеше акылыннан әрнеп,
Җыерылган маңгайлары.

Хәвефле кыя кирәк ташларга да,
Ташланырга биеклектән.

Кыя керфегендә тәкатен җуйган
Ташлар торса,
Кеше дә бит күккә бага,
Алла кодрәтен тоеп,
Күңеленнән эзли дога,
Белмәгәнен яшермәкче үз-үзеннән.

Дулкын тетрәвеннән биеклеген җуйган
Ташлар ята,
Әлсерәгән сарык сыман.

Иделкәйнең бакый ярларында
Чарланган үз телен
Оныткан мы яшь дулкыннар?—
Сулышына кабып килә-килә,
Ярга ятып улә.
Пышылдап сүнә ташта җирән күбек,
Сырхау заман түкергән кебек.

Су күзгесе күзге түгел инде,
Камыш кытыкламый күк йөзен.
Үз-үзенә кул салырга теләп,
Кайда үрсәләнә
Замананың яман өрәге?

Әгәр ташлар чишенсәләр беркөн,
Тетрәнүдән
Ярылмасмы акыл йөрәге?..

## Санлый заман, сынап-сынап

*Адлер Тимергалинга*

Исәнбәтләр исәптә юк димә,
Әллә каян калка кыюлар.
Кыю җанны сугарырга диеп
Тибеп чыга изге коелар.

Инде бетте дигән чакта кинәт
Халкым бирә шундый улларын,—
Аягүрә басып кешнәп куя
Йокымсырап яткан тулпарың.

Энә белән кое казый алган
Фидакярләр сирәк туганын
Онытма син, Заман: санлый белеп,
Адлер атлы Шаһи зат барын.

## Каләме барның—әләме бар

*Наис Гамбәргә*

Вөҗданына сәҗдә кыла белде,
Җитәкләде кырыс язмышын.
Көтмәгәндә, иҗат галәменнән
Күк иелеп алды җан кошын.

Оста мәргән кебек, Сүз авында
Тулы иде һәрчак садагы.
Туган телне күңел мәркәзендә
Дәүләтле тел итеп санлады.

Әһле каләм... Керсез кәгазь кыры...
Үксез калды даны—соңлады...

* * *

Мең яшә, тарихларны кич,
Мең рәхәт чик, мең михнәт;
Җирдә бөек юаныч бер:
Бәллүр билле Мәхәббәт.

## Таныр идең микән

Яратуны үзем уйлап таптым,
Укып өйрәнмәдем китаптан.
Тәрәзәңә синең, төнлә килеп,
Тәүге хисен төреп кар аткан—
Мин идемме?
Аннан тәрәз бозын
Кайнар тының белән эретеп,
Күз аттың да...
Елмаюың белән
Төн тынлыгын дәррәү терелтеп,
Йөгереп чыктың, капка шыгырдатып,
Их, безнеңчә иде дөньясы!..

Кайсы Тубай агачына кунды
Мәхәббәтнең парлы оясы?..

Нинди хыял, нинди ашкынулар!
Җиһан җәйгән безгә канатын.
Алла бирсә, дигән тик бер сүзне
Язмыш көткән икән җан атып.

Әйтмәгәнбез. Җилкенүле күңел
Яшьлек бәхетеннән исергән.
Безгә кадәр, бездән соң да шулай:
Яратылу серен кем белгән.

Әйлән-бәйлән карлар яуган төндә
Мең әйләндек җирне.
Аннары...
Төн пәрдәсен ашыктырып ачты
Әтәчләнеп аткан таңнары.
Яратуны Ходай иңдергәндер.
Без бит моны соңлап аңладык.

Яратуны уйлап таптым диеп,
Кемнәр килә яшьлек үреннән.
Хисләр кыйбласына маяклар юк,
Безнең эзләр инде күмелгән.
Кайсы тәрәзгә кар ыргытыйм?—
Карлар ява хәтер күгеннән.

Таныр идең микән үзеңне син,
Кайтып алсаң минем күңелдән?

## Төштән—төшкә

Син кояшка кадәр тугансыңдыр,
Син кояштан соң да каласыңдыр,
Мәңге Сөю Таҗым.

Мин төшемдә синең төшкә кердем,
Дөнья буйлап сине эзләп йөрдем,
Төнге Илаһ Назым.

Яңгырады аһым, чөйде таулар,
Кайтты, сулгып, нәүмиз кайтавазлар,
Сине табалмадым.

Инде тәмам өмет өзгән хәлдә,
Төштән өнгә чыгып барган мәлдә,
Кинәт пышылдадың:

—Шулай эзләрсең дип белгән идем,
Мин бит синең төшкә кергән идем...
Синең Төнге Назың.



Марат
Әмирханов

# ӘЛВИДАГ

ТАРИХИ БӘЯН

—Сафагәрәй, Сафа-гә-ә-рәй...

Сөенбикәнең хафалы тавышы йомылып калды. Һөҗүмче кемсә аны ятагында яткан хәлдә юрганына төреп бәйләде дә иненә күтәрде. Аякларыннан эләктерде, чәбәләнү, ярдәмгә чакыру түгел, тын алулары да авырлашты.

Ни-нәрсә бу? Фетнәме? Хыянәтме? Ничек сарай эченә үтеп кергән алар? Төнлә сак-фарраш икеләтә ишләрәк ләбаса. Хан кая? Улым, Үтәмешгәрәем...

Чарасызлыктан, күңел әрнүеннән Сөенбикәнең йөрәге өзелеп төшәр дәрәҗәгә җитте.

И, бер Аллам, рәхмәтеңнән ташлама сана, Мәрьям ана зирәклекләре бир. Үземнән битәр, ханым, Сафагәрәем, маликзадә улым Үтәмешгәрәем өчен җан атам. Ул хаким затларны мәмләкәтебез хакына ошбу бәла-казалардан арындыр. И, бер Аллам.

Кинәт кенә шау-шу купты, кылыч чыңлата башладылар. Китте кычкырыш, китте ыңгыраш. Ләкин ыгы-зыгы озакка сузылмады, аны кадерледән-кадерле, якыннан-якын Сафагәрәйнең көр әмере туктатты.

—Ханбикәне азат итегез!

Сөенбикә аңын югалтты. Ә күзләрен ачканда җәмәгате кочагында иде.

—Хәерле иртә, ханбикәм,—диде Сафагәрәй хатынының кулларын сыйпаштыра-сыйпаштыра.

—Мин бик яман төш күрдем...

—Тынычлан, ханбикәм, тынычлан,—диде Сафагәрәй,—өн иде ул, түгел төш. Һәм ул өнне мин үзем оештырдым, зинһар, гафу ит.

Сөенбикә сәерсенеп иренә бакты.

—Шаяртма, ханым-солтаным, чын дөресен сөйлә. Өн икән, димәк...

—Дошманның дустан яралуын бик белеп әйткәннәр, ханбикәм,—дип

---

Марат ӘМИРХАНОВ (1933)—*прозаик, публицист; «Чулманның ак йолдызы», «Таш һәйкәл», «Сөн моңы», «Тәкъдир» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

ялгап китте Сафагәрәй,—сарайда монафыйклар пәйда булды. Иван белән мин яу кырында ачыктан-ачык көч сынаша алам. Ә болар куркынычрак, чөнки дә әйбәт булып кылана беләләр. Шуңа күрә алардан вакытында арынырга кирәк иде. Турылыклы яугирларым белән үткәргән төнге тикшерү хәтта синең сакчыларның да ышанычсыз икәнен күрсәтте. Сине урлап китү бернигә дә тормый икән ләбаса. Бу бик куркыныч фал.

Сөенбикә ире исән чакта әлеге «тамаша» өчен аңа үпкәләп тә йөргән иде. Әмма Сафагәрәй мең мәртәбә хак булган икән. Бүген инде монафыйклар йөз яшерүне кирәк тә санамый. Хан булып ханга тел тигезүдән тайчанмыйлар. Башка сыймаслык хәл.

Ходаем, әллә соң бу бөек Алтын Урда дәүләтен гүргә керткән Чуалыш Газраилнең Каза капкасын да кагуымы?

## БЕРЕНЧЕ КЫЙССА

### Кәшһәк углан

Татлиның аяклары үзеннән-үзе туктап калды. Шул ук мизгелдә күңел хөҗрәсендә оеп яткан аңлаешсыз хисләр өермәсе кузгалып, тамагына кайнар төер булып утырды, тәнен ашкынулы дулкын сызып узды...

Көн кичкә авышып килә иде. Офык киштәсенә эленгән болыт челтәрләренә инде алсу төс йөгергән. Казансу өстендә иренеп кенә тук акчарлаклар очып йөри. Яр буенда куактан куакка сикерешеп, сары түшле йомгактай йомры песнәкләр куаныша. Дымык. Ара-тирә генә адашкан урын җил агач яфракларын кыбырсытып уза.

Аһ, нинди хозур икән Сөенбикә ханбикәнең манарасы! Күр, шушы сихри манзара эчендә ничек балкып утыра. Ул аны бу кадәр үк күркәм итеп күз алдына китермәгән иде. Баксаң, мәшһүр Эйфель манарасы белән дә, данлыклы Пиза манарасы белән дә тиңләшә алырлык икән ич. Мәһабәт, чибәр, горур, эчендә җаны да бардыр, шәт.

Татли әлегәчә Парижга табынып яшәде. Хәер, бу гаҗәп тә түгел, чөнки Париж аның туган шәһәре. Шушында канат чыгарды, шушында үз урынын тапты. Аннан соң, Париж Париж инде ул, калалар каласы! Юкка гына: «Парижны күр дә—үл»,—димәгәннәр.

Шуның белән бергә, Казан шәһәре дә, әлеге манара да күңеленә бик якын тоелды, хәтта, әнә, йөрәге дә сулкылдый башлады...

—Сез үзегезне начар хис итәсез ахры, ярдәм кирәкмиме?—дип мөрәҗәгать итте ана бер ир-ат.

—Юк, юк, рәхмәт, зинһар борчылмагыз,—диде Татли кабалана-кабалана,—болай гына ... ни ... хәзер...

—Чишмәгез тулганга охшый,—диде узгынчы уены-чыны белән.

Әллә чыннан да күзләре җепшегән инде—Татли кульъяулыгын кулына алды.

—Сөенбикә манарасы күңелемне кузгатты,—диде ул аклангандай. Шул арада җилкенчәк бикәчләргә генә хас өлгерлек белән сүз кушучының сурәтен тәгаенләп алырга да җитеште.

Очлы күзе иң элек шырпыдай төз-буй сынын шәйләп узды. Югыйсә Рәсәйгә аяк басуга, кочак җитмәстәй юан гәүдәле, капкорсаклы ир-атларның ишлелегенә шаккаткан иде. Кая карама, шундыйларга төртеләсең. Бу әфәнде бөтенләй үзгә. Дөрес, йөзе искитәрлек түгел, армут[1] җимешенә тартымрак: маңгае тар, ияге калын, иреннәре салынкы. Әйтерсең лә, гәүдәсен аерым, башын аерым юнып ясаганнар. Ләкин үзеннән көч-кодрәт, чын азаматларга гына хас нindидер дәрт бөркелеп тора.

[1] Армут—груша.

—Әйдәгез, танышыйк, мин Марсель атлы булам,—дип, яңа белеше инсафлылык белән башын иде.

—О-о, мьсё француз исемен йөртә,—дип елмайды ханым,—ә минем тулы исемем Татьяна, үзара Татли дип йөртәләр, үземә дә Татли ошыйрак төшә.

—Мадемуазель...

Татли шук кына күзләрен уйнатып алды.

—Мадам, мсьё, мадам Юсупова...

Марсельнең чәчләре кашы белән кушылды.

—Сез Сөембикә нәселеннәнме әллә?

—Әйе, мин княгиня...

—Хәзер менә төшендем. Сез княгиня Ксения Юсупова—Сфири—Шереметьеваның кызы буласыз. Княгиня күптән түгел генә Казанда «Кенәз Юсуповлар нәселе тарихы: Казан—Петербург—Париж» күргәзмәсен ачу тантанасында катнашкан иде. Искиткеч самими, зыялы, укымышлы һәм чибәр ханым. «Үз нәселем белән горурлык һәм шатлык хисләре генә кичерәм, мин Казанга гашыйк», дип, үзенең ыру тамырларына турылыклы булуын ачыктан-ачык әйтеп бирде, шуның аркасында татарларның күнеленә мәңгелеккә кереп урнашты. Чын интеллигент, чын милләтпәрвәр княгиня. Сез дә, мадам...

Татли әңгәмәдәшенең ярсулы озын нотыгын азагына кадәр тыңлап бетермәде.

—Мин әле бернәрсәгә дә ирешмәдем, мьсё,—дип үзе ялгап китте.—Ә Казанга нәсел җепләрен яңарту максатыннан килдем. Талисманым—«Сөембикә» муенсасының оригиналы кебек үк затлы муенса.

Ул озын нәфис бармаклары белән муенсасына кагылып алды.

—Мин сезгә ярдәм итәргә әзер, княгиня,—диде Марсель,—татар тарихыннан мәгълүматым бар, археолог, казыну-эзләнү эшләре белән шөгыльләнәм. Казанның 1000 еллыгы проектында да якыннан торып катнаштым...

—Юк, юк, зинһар, кирәкми,—дип ярдәмнән баш тартты Татли,—мин монда үз асылымны эзләп килдем. Ә бу ифрат та шәхси тойгы. Шуңа күрә ялгызым гына сәяхәт итәм. Инкогнито, аңлыйсызмы? Юлым озын: Казан, Әстерхан, Мәскәү, Касыйм, Петербург...

—Дөнья хәлен белеп булмый, алай-болай кирәгем чыкса, хәбәр салыгыз,—диде Марсель.—Шулай да бер киңәшем бар, «Сөембикә» исемен йөрткән журнал редакциясенә сугылмый китмәгез.

—Андый журнал да бармыни?

—Татар милли басмаларының йөзек кашы, чын халык журналы,—дип тезеп китте Марсель,—гомумән, җөмһүриятебездә ханбикәнең исемен пропагандалау юнәлешендә соңгы вакытта аерым чаралар күрелә, әйтик, бер калада хәтта Сөембикә исемендәге кызлар футбол командасы да бар...

—Татар бик мәрхәмәтле, бик хәтерле халык икән, бу минем иң зур ачышым,—диде Татли,—гафу итегез, туганнарым дип әйтергә теләгән идем, һич күнегә алмыйм...

—Зыян юк, күнегерсез,—диде Марсель,—Сөембикә алдында безнең бурычларыбыз әле бихисап. Ханбикәгә кайчаннан бирле һәйкәл куя алганыбыз юк.

—Мин, мәсәлән, һәйкәл кирәкми дип саныйм,—диде Татли ниндидер сабырсызлык белән, гүя кемдер аның фикерен кире кагарга тели иде.—Сөембикәгә иң зур һәйкәл—аның манарасы! Ханбикәне таш сынга әверелдерсәң, ул азатлык символы булудан туктаячак, хәтер ядкәре булып кына калачак. Ә тарих аңа искиткеч зур вазифа йөкләгән. Сөембикә

Клеопатра, Жанна Д Арк, Маргарет Тетчер, Беназир Бхутто, Индира Гандиларга тиң шәхес. Аның үрнәге татарларга мөстәкыйль дәүләтчелекләрен торгызырга булышачак. Мин моңа ышанам.

Марсель княгиняны исе китеп, әсәрләнгән хәлдә тынлады. Кадими милләтчеләр авызыннан да чыкмый торган сүзләр ич бу. Крамола. Рәсәйдә, әнә, суверенлык дигән билгеләмәне дә кулланылыштан алып ташладылар. Ә бу мадам дәүләтчелеккә кизәнә. Тәвәккәл.

—Дәүләтчелекне торгызу мө-ө-ө-мкин алайса,—диде Марсель сузыбрак,—мин сезне дөрес аңладыммы, княгиня?

—Дөньяда мөмкин булмаган нәрсә юк.

—Редакция мөнәсәбәтендә фикерегез ничегрәк?

—Монысы, мсьё, чыннан да сезнең ярдәмнән башка барып чыкмастыр, мөгаен.

Марсель очрашу матур үтсенгә бөтен тырышлыгын салды. Редакциядә дә бик шатландылар.

—Княгиня Ксенияне редакциягә китерү өчен президент аппаратына кадәр барып життем,—диде журналның баш мөхәррире,—тыңларга да теләмәделәр, протоколга кертелмәгән, имеш. Ә син, сабакташ, күктән көткәнне жирдән китердең. Рәхмәт. Йөзеңә кызыллык килмәс, ышандырам.

Адәм сөйли, язмыш көйли, ди. Очрашу мөхәррир тәгаенләгәнчә генә оешмады. Иң әүвәл Матбугат йортының чытык йөзле уяу сакчысы кәефне җибәрде. Уздырмый гына бит, дүкәмит таләп итә. Гөнаһ шомлыгына, Марсель яңа костюмын кигән иде, дулкынлану белән һәммә кәгазь-катыргыларын искесендә онытып калдырган. Редакциягә шалтыратып хәлне аңлатканчы, аннан кеше төшкәләнгәнче ярты картайды. Чүп өстенә чүмәлә, менеп життек кенә дигәндә, лифт туктап калды. Монысы инде пычаксыз сую дигән сүз иде. Хәер, каршы алучы ханымның артык исе китмәде, күрәсең, монда табигый хәл иде бу. Котылу ысулы да гадәти икән.

—Әй, кем бар анда, лифтерга әйтегез, бу калтырча тагын туктап калды бит,—дип аваз салды.

Танышына юлыкты ахры, җавап та килеп ирешә.

—Шул кирәк сиңа, чәчби, бераз җиллән әле, кичә миннән көлгәнеңне онытма, һи-һи-һи...

—Фатуш, ярар инде, Фатуш... Кунаклар белән мин...

Марсель читләтеп кенә Татлига күз салып алды. Ханымның иреннәре кысылган, йөзе ап-ак, ә күзләрендә—аптыраш. Ярый әле, чәбәләнми, дип сөенеп куйды, француженкаларны бик чәүчәләк диләр ич.

Тыныч бул, барысы да рәтләнер дигәндәй, ул җиңелчә генә юлдашына орынып алды. Лифт ачылганчы Татли аның кулларын җибәрмәде.

Редакциядә княгиняга, милли гореф-гадәтләргә туры китереп, чәкчәк авыз иттерделәр. Шуннан соң баш мөхәррир княгиняның «Сөембикә беләзеге» белән бүләкләнүе турында редколлегия карарын укып, диплом тапшырды.

—Беләзегебез бик дәрәҗәле, ул бөтендөнья татар хатын-кызларының мәртәбәле бүләге санала,—дип мактанып алырга да онытмады.

Табын да мулдан иде. Милли ризыкларның ниндиләре генә юк: төплекәй, бәлеш, өчпочмак, кыстыбый, тутырылган тавык.. Аларны тәм-томнар алыштырды.

—Шушы кадәр аш-су эчендә кайнап, сез ничек шулай күркәм буй-сынлы булып каласыз соң?—дип белеште Татли.

Дөрестән дә, журналист ханымнарның барысы да, сайлап алынгандай, бал кашыгына салып йотардай нәфис иде.

—Аш ашка—урыны башка,—дип шаяртты мөхәррир.

—«Аз кап—май кап» дигән бик мәгънәле әйтемебез дә бар әле безнең,—диде су сөлегедәй ыспай буй-сынлы Гөлнара исемле журналист ханым.

—Моның сере бик гади,—дип әлеге темага нокта куйды мөхәррир,—без Сөембикә варислары, княгиня, матурлык безнең вазифабыз.

Журналист халкы кызыксынучан бит ул, төпченепме-төпченәләр. Әйтик, Йосыф бәк нәселендә икенче булып туган ир бала ни өчен егерме алты яшендә дөнья куя?

—Моны дин алыштыруга бәйләп аңлаталар,—диде Татли,—минем сәяхәтем дә беренче чиратта әнә шул сакаллы гөнаһны ярлыкауга мөнәсәбәтле.

Вакыт үткәне сизелми дә калды. Гәпләштеләр дә, җырлаштылар да, биештеләр дә.

—Миңа бик оят, ханымнар, сез белгәннәрнең чиреген дә белмим икән, Кәшһәк углан турында, мәсәлән, мәгълүматым юк дәрәҗәсендә иде,—диде княгиня саубуллашканда.—Танышуыма бик шатмын. Ә мьсё Марсель бу искиткеч очрашуны оештырганы өчен бер үбүгә лаек.

Кул чабуларга ияреп, Татли үзенең учын үбеп алды да, ишарәсен Марсель тарафына очыртты.

—Барысына да рәхмәт, әмма лифтыгызга утырмыйм, гафу итегез,—диде ул.

Алар тугызынчы каттан җәяүләп төштеләр.

***

Өермә җиледәй ыжгырып, бүлмәгә ниндидер гаугалы чит-ят тавышлар инде.

Сөенбикә дерт итеп китте. Җә, Аллам, тагын кемнәр тузына инде анда, бу арада һич тынгы бирмиләр. Гасәбәләрен[2]* әйтер иде, тәмам кулдан ычкынып баралар. Тәрәзәләрне шыран-яран ачып калдырмагыз, дип күпме тукырга була инде, һаман үзләренчә эшлиләр. Имеш, саф һава зарур, имеш мин саулыгым турында уйламыйм.

Нишләмәк кирәк, язмыш давылы Багы Ирәм[3] бишегедәй көйле тормышын төбе-тамыры белән куптарып ташлады бит. Сафагәрәй бәхетен дә, шатлык-куанычларын да, якты, тыныч көннәрен дә үзе белән кара гүргә алып китте. Ул хәзер канатсыз кош халәтендә. Бердәнбер юанычы—улы Үтәмешгәрәй. Һәм дә ханлыгы. Яшәвенең мәгънәсе бербөтен булып укмашкан шушы ике кыйбла-кыйтгадан гыйбарәт. Шуны күпсенә көнчел адәмнәр. Саулык турында, матурлык турында кайгыртумы, ул тыныч вә назлы көннәр үтте шул инде, үтте...

Бүлмәгә тыны-көне беткән баш сакчы килеп керде.

—Галиҗәнап, Юлбарыс бәк кабул итүенне таләп итә, тавыш куптара, ни боерасыз?—дип ханбикәгә текәлде.

Сөенбикәнең ак маңгаенда әле моңарчы күрелмәгән вак сырлар хасил булды. Әүвәл ул кемсә көчекләр башларын капка астыннан чыгарып кына, таш белән бәрмәсеннәр дип, кача-поса гына өрәләр иде. Хәзер, әнә, сарайга килеп гауга куптарудан да тайчанмыйлар.

—Бәкне хан катына үткәрегез, мин аны шунда кабул итәрмен,—диде.

Сакбаш аптырабрак калды. Сөенбикә аның ни уйлаганын бер күз сирпүдә төшенеп алды. Тут яфрагы да, әнә, сабырлык аркасында гына ефәккә әверелә, диләр ич. Тәхет иминлеге хакына ташламаларга да бармыйча булмый.

—Хәер, бәкне шушында, эш бүлмәмдә генә кабул итәрмен ахры,—диде

[2] Гасәбә—хезмәтче.
[3] Багы Ирәм—җир оҗмахы.

Сөенбикә кәнәфиенә җайлап утырган арада. Аннан көлемсерәбрәк өстәп куйды: «Борчылма, фарраш[4] монарчы Юлбарыс бәк кешегә тия икән дигән хәбәрнең колакка элενгәне юк иде әле.»

—Юлбарыс бәкне ханәкә катына!—дигән әмер яңгырады.

Бәк кагыйдә таләп иткәнчә, ханбикәне бил бөгеп сәламләде. Әмма ярсуы йөзенә бәреп чыккан иде, күзләре дә очкынланып яна.

Сөенбикә бәкне җентекле күзеннән кичерде. Ул аның белән якыннан таныш түгел, шулай да каршы якның телгә кергән вәкиле икәнен белә. Ишетүенә караганда, бәк ханга аяк чалучыларның иң тәвәккәле. Сүзен бәреп әйтүе, гамәлләрен ачыктан-ачык кылуы, ышыренеп, боргаланып маташмавы өчен хәтта сарай әһелләре дә ихтирам итә икән үзен. Карап-багуга камыт аяклы, тукмак кадәре генә бәндә.

—Рәхим ит, бәк, утыр, кымызыннан авыз ит,—диде Сөенбикә тыныч кына,—йомышыңны тыңларга әзермен.

Сөенбикәнең дустанә вә ачык мөнәсәбәте Юлбарысның төксе йөзен үзгәртмәде. Җәясе тартылган халәттә:

—Ханбикә, мин сиңа бик зур дәгъва белән килдем,—диде.

—Синең тоташ чәнечкедән торганың күптәннән мәгълүм,—диде Сөенбикә,—Сафагәрәйне дошман күргәнеңне бөтен халык белә иде.

Юлбарыс ризалашмыйча:

—Ялгышасың, ханбикә, мин Сафагәрәйне түгел, ханны өнәми идем,—диде. Аннан соң, елъязмачы ягына борылып кисәтте,—менә болар ни язып калдырыр, әйтә алмыйм, әмма да ләкин Сафагәрәйнең тарихка эчү-исерүдән бәрелеп үлгән дигән тамга белән кереп калуына һич тә кул куймыйм. Бу дөреслеккә туры килми. Хәлбуки, андый гаделсез гайбәт йөри.

—Рәхмәт бәк, сөендердең...

—Мөхтәрәм ханбикә, әйтеп бетерергә рөхсәт ит. Ә менә шәхсән син мине дошман күрергә хаклы. Дөрес, ул ният гамәлгә ашмады, шулай да нигез бар. Син хәбәрдардыр, билгеле, Сафагәрәйнең вафатыннан соң без, бер төркем югары кат зыялылары, тәхеткә аның олы улы Бүләкгәрәйне утыртырга карар иттек. Шул максат белән мин Кырымга юл тоттым. Ләкин Тын елгасын кичкәндә урыс яугирлары һөҗүм итте, иллалла белән генә качып котылдым. Икенче тапкырында да уңышсызлыкка дучар булдык.

Тарихка бу вакыйга иң пычрак тәхет чуалышларының берсе булып кереп калырдыр, мөгаен. Әлеге хәбәр килеп ирешүгә, Кырым ханы Сәхибгәрәй Бүләкгәрәйне өтермәгә үк ябып куя. Ник дигәндә, Казан тәхетенә Төркиядә яшәүче Дәүләтгәрәйне тәгаенләү исәбендә була ул. Төрек солтаны Сөләйман пашаны да үз ягына аудара. Чын нияте исә Казанга барышлый Дәүләтгәрәйне теге дөньяга озату, шуның белән Кырым тәхетенә иң көчле дәгъва итүчедән арыну була.

Юлбарыс бәк, сүзем озынгарак китте ахры дип булса кирәк, ханбикәгә күз төшереп алды.

—Сабак алырлык вакыйга,—дип, Сөенбикә фатихасын бирде.

Бәк тамагын кырып алды да, ялгап китте:

—Сөләйман паша ризалыгын бирә бирүен, әмма ханның хәйләсен бик тиз тоемлап ала. Үтә тырышлыкның төбендә ниндидер усал максат ятарга тиеш дип уйлый. Һәм үз тозагын кора. Ә аның тозагы күпкә мәкерлерәк. Бу Җанә черкес кабиләсенең баш күтәргән чагы. Сәхибгәрәйдән шуларны бастыруны үтенә.

Ул яу чапканда Дәүләтгәрәй Бакчасарайга килеп, Кырым тәхетенә утыра. Аңлашыла булыр, Бүләкгәрәйне дә өтермәдән азат итә. Бүләкгәрәй исә саклап торып, агасы Сәхибгәрәйне үз куллары белән буып үтерә, үчен

[4] Фарраш—сакчы.

кайтара. Дәүләтгәрәйгә дә дәгъваче кирәкми. Тиздән Бүләкгәрәйнең үле гәүдәсен табып алалар.

Шушы фаҗигале вакыйга, өч яшьлек Үтәмешгәрәйне, дөресрәк әйтсәк, сине, ханбикә, тәхеткә күтәрде.

Бүлмә эче тынып калды. Тыштагы тавышлар да ишетелми, тәрәзәләрне ябуның файдасы тиде, күрәсең.

—Бүләкгәрәй отышлырак булган булыр иде дип саныйсыңмы, бәк?—дип сорады Сөенбикә.

—Бу хакта сүз куертуның мәгънәсе юк инде, ханбикә,—диде бәк.—Хәзергесе борчый безне. Әйтик, ханлыгыбыз Мәскәү белән бер ялгызы йөзгә-йөз калды. Һәм үзебез турында без үзебез кайгыртырга бурычлы. Үтә дә җаваплы чор.

—Шушы хакта гәпләшергә килгән идеңме, бәк, тыңлыйм,—диде Сөенбикә,—ирештер фикереңне.

Юлбарыс күзләрен түшәмгә терәп торды да, уйларын пичәтләде.

—Ханбикә, турысын әйткәнгә үпкәләмә,—диде,—вәзгыять шундый, тел яшереп тора торган чак түгел. Имеш, син Кәшһәк углан белән ханыбыз Үтәмешгәрәйне үтереп, тәхеткә сөяркәңне утыртмакчы икәнсең. Бел, бу барып чыкмаячак!

Сөенбикәнең капылт кына сулар һавасы бетте. Күз аллары караңгыланып, бүлмәдәге нәрсәләр берара биешеп алды. Ул үзенең гәүдәсен дә тоймый башлады.

Нәкъ шушы вакытта бүлмәгә Үтәмешне алып керделәр. Гадәттәгечә, малай йөгереп килеп әнисенең итәгенә уралды.

—Анаем, минем колыным белән уй-ный-сым килә,—дип, әнисенең кулыннан тарткаларга тотынды.

Сөенбикә айнып китте. Һәм дә әйтте:

—Күреп торасың, бәк, хан үз урынында, атасына охшап, ул әле Казан тәхетендә бик озак утырачак...

Үзе генә калгач, ярсу аңа янә килде.

Сөяркә! Нинди килешсез сүз! Килешсез генәме—әшәкенең әшәкесе! Уйнашчы, зиначы, азгын... Үзенә шундый шакшы гайбәт ягарлар дип башына да китереп караган зат түгел ләбаса ул. Сүз утыз теш арасыннан чыкса, утыз кешегә җитә, диләр. Димәк, гайбәт таралып өлгергән инде. Ә гайбәт идәнгә чәчелгән ярма кебек—чүпләп тә бетерә алмассың.

Сөенбикәнең күзенә йокы кермәде, төне буе шушы хакта уйланып ятты.

Кәшһәк углан белән алар бик еш очрашалар. Шулай булмыйча, ул хөкүмәт башлыгы. Хәл итәсе мәсьәләләр бихисап. Ханлык искиткеч авыр чор кичерә. Эттән дә күбәйде дошманнары. Бер яктан Мәскәү кыса, икенче яктан казанлылар. Ә Кәшһәк бердәнбер таянычы, терәге, киңәшчесе. Сафагәрәй вакытыннан бирле сафтан-саф эчкерсезлек белән хезмәт итеп килә. Булдыклы, гадел, вәгъдәле.

Ир кеше сыйфатында да күрекле углан. Озын буйлы, киң җилкәле, нык, таза. Килеш-килбәтеннән, бөтен торышыннан олпатлылык ташып тора. Сакал-мыегын кыска итеп йөртә. Ихтимал, шуңа күрәдер тәскә-биткә дә яшь күренә. Кыскасы, кыз-хатынның йөрәген чуалтырдай ир-егет. Бу җәһәттән алар Сафагәрәй белән охшашканнар иде. Ни әйтсәң дә, чыбык очлары бит. Сафагәрәй аны шуңа күрә Кырымнан чакыртып китерде дә инде.

Шунын белән бергә, соңгы вакытта Кәшһәкнең үз-үзен тотышында нindидер сәер ашкыну чаткылары да тоела башлады. Кайчан гына башын күтәрмәсен, күзенә тәгәрәп кереп тора.

Әнә, әле дә үзе Арча арлары чуалышын ничек бастыруы турында хисап тота, ә сүзләре авыз эчендә үк эреп бетә, һич анларлык түгел. Сөенбикә ачы катык шикелле кабарып чыкты.

—Углан, син әнгәмәгә әзер түгел, бар, чыгып фикерләреңне туплап кер,—дип, Кәшһәкне куып ук чыгарды. Югыйсә бик мөһим мәсьәлә турында гәпләшәләр иде. Узган атна азагында Арча арлары сарай каршына килеп, өч көн буе гауга күтәреп йөрде.

—Без Мәскәүне хуп күрәбез!

—Хан олуг кенәз Иоаннга баш исен!

—Кырым, үкчәңне күтәр!

Сөенбикә әлеге низагны хәл итүне хөкүмәт башлыгы Кәшһәк угланга йөкләде. Инде оран салучы күренми, димәк, ул бурычын үтәгән. Ишетүенчә, бер-ике бунтарьның башы да җиргә тәгәрәгән. Куркак арларга шул җиткән, артларына да борылып карамыйча элдерткәннәр, имеш. Тик арлар барыбер тибенәчәк әле. Чөнки урыска таяналар. Ә урыслар, Иоанн патша кушуы буенча, борын төбендә генә, Казаннан нибары утыз чакрымда, Идел-Зөя тамагында егерме сигез көн эчендә хәрби кирмән төзеп куйдылар. Анда хәзер урыс әләме җилферди. Алар чынлыкта Тау ягын яулап алдылар. Ханлык зур калҗа югалтты.

Сөенбикә ике араны җайларга тырышып карады каравын, тырышлыгы көткән нәтиҗәне генә бирмәде. Үтәмешгәрәй хан исеменнән җибәргән рәсми илчене Иоанн хәтта кабул да итмичә: «Безнең илә барышлыкта булырга теләсә, хан яхшы илчеләр җибәрсен»,—дип, казанлыларны кире борып җибәрде. Бу бит күрәләтә санга сукмау дигән сүз.

Мәскәүнең яу чабарга җыенуы шул чакта ук мәгълүм иде инде. Хәзер исә Кремль мәкерле ниятләрен яшерүне дә кирәк санамый.

Кәшһәк углан урап кергәч тә шул турыда гәпләштеләр. Сөенбикәнең борчылуына ул үтә бер тәвәккәллек белән:

—Җаннары ике булса, килеп карасыннар, ник туганнарына үкенерлек итәрбез.

Сизелеп-тоелып тора, Кәшһәк ханбикәгә ярарга тырыша, чама хисен югалтканын да сизми ахры. Бер кулына ике карбыз тоткан кешене хәтерләтә.

—Иоанн Арча арлары ише генә түгел,—дип кисәтте аны Сөенбикә,—Мәскәүнең атлы гаскәре генә йөз мең кылычка җитә. Ә синең кырымлы вә нугайларың егерме меңгә дә тартмый. Казанлыларның мәсләге исә бөтенләй башка...

—Минем бер яугирым мең урыска тора, ханбикә...

—Углан, сөзеп каравыңны ташла әле,—дип кисәтүне кирәк тапты Сөенбикә,—болай да гайбәт таралган ди калада, наһакка керсез исемемне болгатуларына күңелем бик рәнҗи.

—Син күз өстендәге кара каш, ханбикә...

—Углан, җитәр...

Кәшһәк урыныннан сикереп торды да озак кына нәүмизләнеп карап торганнан соң ачынып әйтте:

—Әгәр Чыңгыз ыруыннан булсам, мин сиңа яучы җибәрер идем, ни кызганыч, Ходай андый бәхетне насыйп итмәгән...

Аллаһым ныклык вә түземлекләреннән аерма, гыйшыкны гыйшык тудыра диләр бит.

—Углан...

Кәшһәкне туктату мөмкин түгел иде инде, таш йотар тәвәккәллек белән тәкъдимен ирештерде.

—Син наз өчен яратылган зат, Сөенбикә,—диде,—шакшы вә гаделсез

идарә шөгыле сиңа тәс түгел. Әйдә, качыйк бу Алла каргаган җирдән. Мин сине атаең Йосыф би кулына тапшырырмын, калганын үзең хәл итәрсең.

Әлеге сүзләр Сөенбикәнең күңелен кузгатмады, киресенчә, халәтенә катгыйлык кына өстәде.

—Мин Казан ханбикәсе, углан, бу минем гомерлек йортым, авызыңны үлчәп ач,—диде.

—Әйттем исә кайттым, бу минем бурычым иде.

Хәл ителәсе мәсьәләләр хәл ителмичә, хөкүмәт эшенә кагылышлы җөмләләр яңгырамыйча калды.

—Ханга минем ихтирамым вә сәламемне ирештерсәң, бик шат булыр идем,—дип хушлашты Кәшһәк ханбикә белән.

—Чираттагы очрашуны иртәгә нәкъ шушы вакытта билгелим, хөкүмәт эшчәнлеге буенча эшлекле тәкъдимнәр көтәм, җентекләп хәзерлән,—диде Сөенбикә,—ә сәламеңне Үтәмешгәрәй ханга һичшиксез җиткерермен.— Бераз уйланып торганнан соң янә өстәде: «Улың Хәйдәр бәкне сарайга китерсеннәр, Үтәмеш белән алар ахириләр ич.»

***

Марсель кунак ханымны ресторанга чакырды.

—Аһ, рәхмәт, мсьё, минем бик тә татар милли ризыкларын авыз итәсем килә,—дип, шатлыгыннан кулларын чәбәкләде Татли,—түләү хакында борчылмагыз, үз өлешемне үз кесәмнән чыгарырмын.

Марсель көлемсерәп башын чайкап куйды.

—Егет—егетнең көзгесе, княгиня, татар сатулашып вакланмый.

—Ә нәрсә, ресторанда без ирем белән аерым-аерым түлибез. Көнбатышта бу гайре табигый хәл саналмый,—диде Татли,—мөстәкыйльлек барысыннан да өстен.

Мадам төлкенең төлкесе икән, күр, ничек җиңел генә ике арага пәрдә элеп куйды, янәсе, күңелеңне ымсындырма, бернинди уен-муен да булмаячак.

Иртә кычкырган күкенең башы тазга әйләнер, ди. Марсель дә шул хәлгә кала язды. Татар халык ашлары дип борын чөеп шапырынсак та, Казанда затлы кешегә күрсәтерлек югары дәрәҗәдәге рестораныбыз да юк икән ләбаса! Оят, валлаһи. Япон рестораны бар, Кытайныкы, Француз, Италия ... тагын әллә кемнәрнеке, ә татарныкы юк. Дөрес, һәммәсендә дә диярлек милли ризыклардан бер-ике блүдә хәзерлиләр хәзерләвен. Ләкин алар өйдәш хатын хокукында гына.

Әле ул урынның күркәм җирдә булуы да шарт. Тимер-томыр алачыклары арасындагы «Тимерхан» ресторанына алып бармассың бит инде. Рәхмәт, Кремльдә эшләүче дуслары ярдәм кулы суздылар. «Корстон» дигән заманча ресторанда алар өчен милли ризыклардан торган табын әзерләделәр.

Бер айлык хезмәт хакым да җәл түгел, йөзгә кызыллык кына китерерлек булмасын дип хәл итеп куйды Марсель. Кунакның күңелен күрергә теләп, французларның мәшһүр эстрада җырчысы Патрисия Каасның кассеталарын да хәстәрләп куйды. Ләкин мадам аның бу тырышлыгын ул көткәнчә бәяләмәде. Тавышы яңгырауга:

—Фу, каян казып чыгардыгыз бу Алман бетен,—дип, ватандашын бөтенләй бетереп ташлады.

Француженканың кыланышлары моның белән генә тәгәлләнмәде, билгеле. Марсельнең, мәсәлән, бию-танцыларга һәвәслеге юк дәрәҗәсендә. Чибәркәй, әнә, һич үзенә урын таба алмый, биергә чакыручыны көтә...

Озак көттермәделәр, күрше өстәлдәге бер шома егет эләктереп тә алды. Рәхәтләнделәр генә. Марсель көнләшүеннән шартлый язды. Тәкате беткәч,

туалетка кереп бикләнде.

Урап килгәндә Татли күренми иде инде, официант аңа язу китереп тоттырды. Анда түбәндәгеләр язылган иде: «Мьсё Марсель! Бу мавыктыргыч күнелле кичә өчен бик рәхмәтлемен. Ихлас. Әле күрешербез, тәэсирләрем турында шунда тәфсилләп сөйләрмен. Инглизләрчә китүем өчен гафу үтенәм. Сезнен Татли. 17.07.09. 22 сәг. 33 минут.»

Марсель ике тулы рюмканы бер ыргымда бушатып куйды да, официантны чакырды.

—Счёт!

—Мадам үзе өчен түләде,—диде официант калын иреннәрен лепердәтеп. Күрәсең, чәйлек мулдан эләккән иде.

Сезнең Татли, имеш, чикерткә—төп башына утыртты тәки, җилбәзәк.

Татли бу вакытта бүлмәсендә иде инде. Гадәттәгечә, кайтып керүгә краннарны тулы көченә ачып җибәрде. Ул шыбырдый-шыбырдый ургылып аккан су тавышын ярата, гүя ашкынулы музыка: ярсыта, тузгыта, дулкынландыра...

Тормышта да каршылыклар, киртәләр аша йөрергә күнеккән ул, җилгә каршы барырга, тәвәккәлләргә, җиңәргә! Сөенбикә ханбикә эзләре буйлап сәяхәткә чыгып китүе дә шул үҗәтлекнең бер чагылышы иде.

Татли шәрә сынын зур көзге шәрәфенә ышанып тапшырды. Нәфис буй-сын, шикәрдәй ак тән, озынча күркәм йөз, күгәрчен күкәе шикелле генә икесе бер учка сыярлык күкрәк алмалары...

Татли үз-үзе белән хозурланып торган арада телефон шалтырады. Аннан: «Княгиня, сез кая югалдыгыз, нигә тавыш-тыныгыз юк?»—дигән шелтәле тавыш ишетелде.

—Маман! Мең тапкыр гафу үтенәм,—диде Татли ихластан,—шалтырата алмадым шул, әле генә рестораннан кайттым. Аннан соң, сез бу вакытта йокларга ята идегез бит. Үзегез беләсез, сезнең тынычлыгыгыз минем өчен барысыннан да өстен. Балалар ничек анда, бик йөдәтмиләрме?

—Рәхмәт, безнең хәлләр окей. Бәлки, рәсми органнар белән элемтәгә керергә кирәктер?

—Юк, маман, бу хакта килештек ич инде, минем инкогнито рәвешендә йөрисем килә. Ярдәмчеләрем дә артканнан-арта. Иртәгә менә бер хатын-кыз сынчы остаханәсенә алып барачаклар. Сөембикә ханбикә тематикасы буенча эшли икән. Монда миңа бик ошый, зинһар борчылмагыз.

Килешенгән вакытта, нәкъ иртәнге ун сәгатьтә, ишек кактылар. Бу «Сөембикә» журналы хәбәрчесе иде. Озынча гәүдәле, көләч йөзле Гөлнара исемле бу ханымны редакциядә очрашу вакытында ук ошаткан иде. Әле дә балаларныкы кебек эчкерсез елмаю аша французчалатып:

—Бонжур, мадемуазель,—диде.

—Әйе, мадемуазель,—дип көлде Татли.

—Үзегез әйтмәсәгез, сезне бераү дә ике бала анасы дип әйтергә базмас иде,—диде Гөлнара.

—Комплиментка комплимент, Гөлнара,—диде Татли,—чибәрлегегез өстенә сәгать дөресләрлек төгәллеккә дә ия икәнсез.

—Төгәллек аристократлар белән журналистларның алтын кагыйдәсе ич инде,—диде Гөлнара,—әйдә, кузгалыйк, княгиня, Нигъмәти ханым унбергә килеп җитәргә кушты, токмачларым куермасын, ди.

—Барасы еракмы?

—Утыз-кырык чакрымнар тирәсе.

Шофер егет туры юлдан алып китте. Туры юл дигәне дачниклар гына йөри торган комлы юл иде. Бормалы, сикәлтәле. Ләкин юл катканагы сизелми дә. Чөнки манзарасы матур. Ике яктан да ябалдашларын җәеп,

шырпыдай төз биек чыршылар сәламли. Ара-тирә шул кызгылт-сары кәүсәләр арасыннан мәгърур Идел дә йөзен ачкалап ала. Шунда ук корыган агачлар да, чүп-чар да күзгә чалына. Гөлнара шулар өчен көенде, чит ил кунагына күрсәтә торган урыннар түгел бит инде болар, дип эченнән генә машина йөртүчене сүгеп барды.

Кинәт күк гөмбәзе шартлап ярылгандай булды. Баксаң, урман артында яңгыр болыты сагалап торган икән. Күп тә үтми, эре тамчыларын машина түбәсенә коя ук башлады.

Дөп-дөп-дөп...

—Люблю грозу в начале мая...

Татли Тютчёвның мәгълүм шигъри юлларын исенә төшереп алды.

—Ә мин яшеннән бик куркам,—диде Гөлнара,—зинһар, акрынрак барыйк.

Шофер егет көлде генә:

—Яшен машинага тими ул, аны тәгәрмәчләре саклый,—диде.

Тиз-тиз генә суын сыгып бетерде дә, болыт шунда ук эреп юкка чыкты. Ә бистәдә кояш хуҗа иде, анда бөртек тә яңгыр төшмәгән.

—Әссәламегаләйкем, хуш киләсез,—дип ачык чырай белән каршы алды Нигъмәти. Аннан соң Татьянага мөрәҗәгать итеп:

—Княгиня, без шулай яшибез инде,—диде ни өчендер аклангандай—авылчарак.

—Искиткеч матур табигать кочагында яшисез,—дип элеп алды Татли,—ландшафт бик ошады, һәммәсе табигый. Мондый борынгы хаос Африкада да юк хәзер. Европа турында әйтеп тә тормыйк, һәр агач ботагына кадәр исәптә анда. Юллар тигез, сукмаклар туры, үләннәр кыркылган, куаклар номерлы. Барысы да шома, күз төртелерлек тә урын таба алмыйсың. Эчне пошырырлык бертөрлелек.

Гөлнараның авызы ерылды, ул шул княгиня мактаган хаос өчен оялып барган иде ләбаса!

—Әйдәгез, узыгыз, сез кулларыгызны чайкалаганчы токмачым да кабарып чыгар,—дип хуҗабикә алъяпкычын киеп куйды.

—Мин иртән кофе эчтем инде,—диде Татли,—рәхмәт тәкъдимегез өчен.

—Княгиня, татар бусагасын атлап кергән кунак тавык шулпасында пешкән токмачтан авыз итәргә бурычлы,—дип Гөлнара хуҗабикәгә ярдәмгә килде,—йоласы шундый, югыйсә, яманатың чыгуы бар.

—Юк, юк, минем һич тә яманатымны чыгарасым килми,—дип, Татли өстәл янына килеп утырды,—фигурам бозылса бозылыр, болай да көмәнле хатындай тулдым инде...

Аштан соң остаханәгә уздылар. Нигъмәти скульптурасын алдан ук әзерләп куйган иде. Бүлмәнең нәкъ уртасындагы кызгылт-карасу япма ябылган түгәрәк өстәл өстендә фил сөягедәй ап-ак ханбикә сыны балкып утыра.

Скульптор ханбикәне горур кыяфәттә җилкәнле көймә эчендә басып торган халәтендә сурәтләгән. Сөембикәнең үтә дә хәвефле мизгеле. Аны шушы көймәдә тоткын сыйфатында Мәскәүгә алып китәчәкләр...

Татли өстәлне берничә тапкыр әйләнеп чыкты, статуяны озаклап-җентекләп тикшерде. Башкалар комачауламады, тын гына читтән күзәтеп тордылар.

—Бу иҗади җимешегезнең киләчәк язмышын ничек тәгаенлисез?—дип, Татли тәүге соравын юллады.

—Конкурста җиңеп чыкты, һәйкәл булып Идел өстенә утыртачаклармы-юкмы, монысы хөкүмәт вәкаләтендә. Әлегә берниндә дә карар кабул

ителмәгән,—дип анлатма бирде Нигъмәти.

Татли янә өстәл тирәли йөренде.

—Кремльдәге Сөембикә манарасын манзара кылгач, ханбикәгә аннан да уңышлырак һәйкәлнең булуы мөмкин түгел дигән фикергә килгән идем,—диде,—хәзер дә фикерем үзгәрмәде. Сезнең эшегез дә бик уңышлы. Тәэсирләндерә, уйландыра, дулкынландыра. Әйткәнемчә, уңышлы образ. Бик уңышлы. Котлыйм. Ул, һичшиксез, һәйкәл дә була алыр иде. Янә бер нюанс: белүемчә, мөселманнарда сынга табыну зур гөнаһ санала. Һәйкәл шул ук пот ич инде ул.

—Рәхмәт, княгиня, фикерләрегез бөтенләй үзгә,—диде скульптор. Инде әңгәмәбезне чәй табынында дәрләтик.

—Әллә чәй дә милли ризыкмы?—дип белеште Татли.

—Чәй миллинең дә миллие, княгиня,—диде Гөлнара,—соравым да әзер. Белүебезчә, Юсуповлар ыруы тәхет иясе Романовларга караганда да баерак булган, зиннәтле сарайлар, эре-эре җир биләмәләре, алтын-көмеш, асыл таш, сәнгать әсәрләре—исәбенә дә чыгармын димә. Шул байлыклардан колак кагу сездә нинди хисләр уята?

—Шәхсән миндә бернинди хисләр дә уятмый, чөнки мин ул байлыклар арасында үсмәдем,—дип көлде Татли,—мәсьәләгә сез теләгән мәгънә биргәндә исә, өлкән Феликс Феликсович 1900 елда ук бу бай мирасның язмышын хәл итеп куйган. Мин аның васыятен хәтта яттан беләм. Менә, тыңлагыз: «Завещаем в собственность государства в видах сохранения сих коллекций в пределах империи для удовлетворения эстетических и научных потребностей Отечества». Васыять үтәлә, шуңа күрә бернинди дәгъваның дә булуы мөмкин түгел, дип саныйм.

—Сөембикә ханбикә дә, образлы итеп әйткәндә, сарайдан ике кулын селтәп чыгып китәргә мәҗбүр ителә. Берничә гасырдан соң бу хәл янә кабатлана,—диде Гөлнара,—әмма тарих Юсуповлар нәселенә барыбер мәрхәмәтлелек күрсәтә. Бүген дә алар каш өстендә.

***

Ослан таулары артында энгер-менгер пәрдәсен урталай ярып, җиргә яшен уты сызылып төште. Озак кына, кайтавазларын дулкынландыра-дулкынландыра күк күкрәде, гүя болытлар өстеннән кыргый атлар көтүе чабышып узды. Җиһан караңгылыкка чумды. Еш-еш атылган яшен ташлары да бу караңгылык эченә үтеп керә алмый, киресенчә, аңа хәвеф кенә өсти иде.

Кәшһәк тәрәзәдән күзен алмыйча гына ясавылга әмер бирде:

—Барбулсын углан белән Турчы бәкне дәш, тиз,—диде,—күләгәң дә күренмәсен.

Тегеләр, әйтерсең лә ишек катында гына сагалап торганнар, килеп тә керделәр.

—Ходай догаларыбызны ишетте, менә нинди төн җибәрде, иншаллаһ, юлыбыз уңар, җыеныгыз, мин яугирларны күтәрергә боердым,—диде Кәшһәк,—алай да саклык зарур, урман колаксыз, кыр күзсез булмас, ди.

—Гаиләләребезне кисәтүне мәгъкуль саныйм мин үзем,—диде Турчы бәк,—дөнья хәлен белеп булмый...

—Яшь кәләшенне арттыра алмыйсың инде, бәк,—дип көлде Барбулсын углан.

—Борчылмагыз, Кырым үзебезнеке, гаскәр туплауга әйләнеп кайтачакбыз, сагынырга да өлгермәсләр,—диде Кәшһәк,—мин үз гаиләмә дә серне тишмәдем.

—Бирсен Ходай!

Кәшһәк угланның янгырлы кара төндә өч йөзле атлы гаскәре белән Казаннан чыгып китүен эт тә сизмәде. Барысы да уңай килеп торды. Атлар шәп, таң атканчы шактый ыргым ясадылар.

Хәлбуки, юл катлаулы да, куркыныч та. Идел ягы инде тулысы белән урыслар кулында. Адым саен диярлек сыргавыл. Гөмбәләр сыман бер-бер артлы калкып кына торалар. Анда борын төртмәле түгел. Шуңа күрә ураугыч булса да, Чулман юнәлешен сайладылар. Хәер, ничек кенә авыр булмасын, исән-имин аръякка чыгуны тәэмин итәргә кирәк. Ә бу ярты уныш дигән сүз.

—Намаз вакыты җитте,—дип кисәтте угланны хәзрәт.

—Рөхсәтемне бирәм,—диде Кәшһәк,—бераз хәл җыеп, тамак ялгап алу да зыян итмәс.

Иртәнге тынлыкны ярып, хәзрәтнең азанлы тавышы янгырады:

—Намаз! Намаз! Намаз!

Кәшһәк хөр булып күренергә тырышса да, барыбер йөрәге урынында түгел иде. Һич көтмәгәндә чыгырыннан чыгып, үзе янында тәгамләп утыручы Әхмәт яугирга камчысын күтәрде.

—Дуңгыз түгелсең, нигә шул кадәр тыгынасың, әкүл[5],—дип кычкырды.

—Яугир башлыгына сөзеп карап алды да , читкәрәк шуышты. Калганнар да шым калды. Хупламадылар. Кәшһәк үзе дә кыенсынып китте. Бу яхшыга түгел, дип ачынып куйды. Югыйсә, бу тотнаксызлыкны аңларга да була. Монарчы аның куркакларча яу кырын ташлап киткәне юк иде. Бу юлы менә качты. Әйе, әйе, качты! Дөрес, без Казанга кире әйләнеп кайтачакбыз, ханлыкны элеккечә үз кулыбызга алачакбыз дигән татлы хыялга төреп шәрехләде көрәштәшләренә бу гамәленең асылын. Шик тумасын өченгә, гаиләләрне дә алдырмады. Хәер, ышану-ышанмауның әллә ни әһәмияте дә юк. Алда—Кырым! Алда—туган-үскән ил!

Кәшһәкнең, ни гаҗәп, ханбикә җәһәтеннән күңеле тыныч иде. Аның гыйшкы Сөенбикәнең җанын эретә алмады. Моңа, билгеле, үпкәләргә дә ярамый. Ханбикәнең дәрәҗә-абруе чагыштыргысыз дәрәҗәдә зур. Ул мөмтаз[6] зат. Асыл кош. Нинди генә шартларда да дәрәҗәсе төшмәячәк. Казан җинелгән сурәттә дә үзенә тиң пар табачаклар. Бары хан—хәләл җефетнең аты гына үзгәрәчәк. Әүвәл Җангали булган, аннан—Сафагәрәй. Хәзер, әнә, Шаехгали дигән сүз чыкты. Ә Кәшһәк? Кәшһәк тә мөхтәрәм кеше, әмма җәнабе гали түгел.

***

Сөенбикә башын учларына салып, ни тере, ни үле кыяфәттә шактый озак утырды. Якыннарының аны мондый чарасыз хәлдә күргәннәре юк иде әле. Күр инде, элекке чибәр, мөлаем ханбикәнең шәүләсе генә ләбаса. Җә Ходай, ник болгана бу дөнья. Сарай булып сарайда да тынгы юк.

Сөенбикә кипшенгән иреннәренә ширбәт тигезеп алды да янә Кәшһәк угланның хатына күз төшерде. Хәер, хат дисәң, исең китәр, нибары берничә җөмлә: «Ханбикә! Кырымлыларның Казанга хаҗәте бетте. Без китәргә мәҗбүр. Бигайбә.»

Адәм ышанмастай хәбәр ич бу. Хәбәр генәме, хыянәт! Бер таяныр кешесе бар иде, инде анысы да ташлап качты.

Нишләргә?

Сөенбикә әлеге сорауга җавап эзләп өзгәләнгән бер мәлдә каравылбаш килеп керде. Йөзе киткән иде.

[5] Әкүл—убыр.
[6] Мөмтаз—өстен.

—Ни бар?—диде Сөенбикә.

—Тагын җыелганнар, сине күрәселәре килә.

—Чакыр соң?

—Алар күп, аннан соң...

—Нәрсә аннан соң?—диде Сөенбикә түземсезләнеп.

—Алар синең үзләре янына чыгуыңны таләп итәләр...

—Инде таләп тә куя башладылармы?—дип, Сөенбикә урыныннан торып басты. Хәдимә туташ җәт кенә җилкәсенә чапанын китереп япты.—Ярар соң, аларча булсын, барыбер коелырдай укасы калмады, коеласы коелып бетте.

—Ханбикә, без аларга узынырга ирек бирмәбез, мин сакны кисәттем,—дип, ханбикәне тынычландырырга ашыкты каравылбаш.

—Анда күренәсе булмагыз!

—Синең иминлегең өчен без җаваплы, ханбикә!

—Хәзер барысы да Аллаһ иркендә.

Сарай мәйданы гөлт итеп тора иде. Әйтерсең лә, зәм-зәм чишмәсенә манып алганнар: якты, чиста, пакь. Бу матур дөньяга матур гамәлләр генә фарыз. Дуслык, ихтирам, гаделлек, сабырлык, ярдәмчеллек—менә аның канатлары. Ләкин ул канатлар каерылган. Усаллык, дорфалык баш калкытты, шулар хакимендә калды бәндә. Шуңа күрә фәрештәләр дә качып бетте. Ә фәрештә юк җирдә яхшылыкка өмет итмә.

Сөенбикәнең гөманы рас килде. Эченнән энә үтәрлек бер ябык адәм күтәрелеп чыкты да, чәрелдек тавыш белән алдан әзерләнгән кырлы-мырлы нотыгын укый башлады:

—Бикә, без хәзер ни кылырга да белмибез. Синең һәм безнең үз өебездә хуҗа булуның чигенә җиттек бугай инде. Үз җиребездә кала салып, зур туплы гаскәр белән безгә каршы сугышырга җыенган урысларга без ничек каршы торыйк? Моның өчен гаскәребез дә, көчебез дә җитми. Кәшһәк угланга без үзебезнең ханга ышанган кебек ышана идек. Ә ул ил өчен иң авыр вакытта Казаннан качып китте. Шушындый шартларга куелгач, без хәзер Шаехгали хан янына барып, аңардан гафу үтенеп, безгә патша булып килергә, сине үзенә хатынлыкка алырга ризалык бирүен үтенергә тиешбез...

Сөенбикәнең аяклары тотмас хәлгә җитеп хәлсезләнде. Хәдимәләре култыгыннан эләктереп алмаса, шәт, егылып та киткән булыр иде.

Бу Үтәмешгәрәйне тәхеттән мәхрүм итү ләбаса! Өстәвенә, юк, юк... Аллам сакласын... Сафагәрәенең кара дошманы Шаехгали куенына керергәме?

Бу шартларны ул кире кага. Шулай да җыелган халыкка тәгаен сүзен әйтмәде, очрашуны: «Ходай ни язса—шул булыр»,—дип кенә төгәлләде.

Сарайда аны корылтайдан килгән морза көтеп тора иде.

—Әле генә корылтай вакытлы хөкүмәт төзү турында карар чыгарды,—дип ул соңгы хәбәрне җиткерде.

Сөенбикәгә үзенең артык кашык икәнен тою соң дәрәҗәдә авыр иде, шуңа күрә берара ни әйтергә белми аптырап калды.

Тынлык озаккарак сузылды, күрәсең, морза тамак кырып куйды. Сөенбикә дә айнып китте. Сүз булсын өченгә генә:

—Баш карачыбыз кем инде?—дип белеште.

—Ходайкол углан белән Нурали бәк.

Сөенбикә: «Баш карачы берәү генә була ич»,—дип төзәтмәсен ирештермәкче иде дә үзен борчыган җөмлә алданрак очты:

—Беләсезме соң, хан билгеләмәгән хөкүмәт вәкаләтле була алмый бит!

—Вакытлы хөкүмәт тәхет мәсьәләсен хәл итү өчен оештырылды да инде, бичә,—дип аңлатмасын бирде морза.—Зөягә мөхтәрәм сәетебез Колшәриф мөфти җитәкчелегендә илчеләр чыгып китте. Алла кушып, Шаехгали

галиҗәнаплары ханлыкны үз кулына алыр дип өметләнәбез. Хөкүмәткә вәкаләтен дә бирер. Тормышыбыз җайланыр, шәт, тәмам сүтелгән иде бит.

—Кануни тәхет иясе Үтәмешгәрәй ханны кая куясыз?

—Үтә-меш-гәрәй...

Морза тотлыгып калды. Ул шәхсән үзе, башка бәк-морзалар кебек үк, ханлыкның бөлгенлеккә төшүен Сөенбикәнең булдыксызлыгыннан күрә иде. Хатын баш булган ил уңмас, дип кисәткән ич бабаларыбыз да. Үтәмешгәрәй бала булу сәбәпле, дәүләт белән ханбикә идарә итте. Һәм менә нәтиҗәсе. Бу ялгышны элегрәк төзәтәсе калган да бит, нишлисең, соң булса да, уң булсын. Колшәриф сәет Зөя кирмәнендә олуг кенәз вәкиленә корылтайның бертавыштан кабул ителгән карарын җиткерәчәк. Әлеге карар Казан ханлыгының мөстәкыйльлеген саклап калу мәнфәгатьләрен күз уңында тота. Ә урман екканда йомычка оча инде ул. Бу очракта йомычка ролен Үтәмешгәрәй хан белән Сөенбикә ханбикә үтиячәк.

—Ходай Үтәмешгәрәй ханга озын гомер насыйп итсен,—диде морза,—әмма корылтайның аларны әсир сыйфатында Мәскәүгә тотып бирү турындагы карарын әйтергә кыймады.

***

Иртә белән унлыкбашы Әхмәт яугирның югалуы турында хәбәр итте.

—Бушана булыр, кичә ач бүре урынына тыгынган иде,—дип сүзне уенга бормак итте Кәшһәк,—юкка хәсрәтләнмә, йә йокы бүсәдер.

—Гафиллеге түбәсеннән ашкан инде анысы...

Кәшһәк гаскәринең сүзен ошатмады.

—Телеңне озайтма, булдыклы яугирым ул минем,—диде,—тәгам вакытындагы кызып китүем якын итү галәмәте генә.

—Шулай да...

—Әллә хыянәт димәкче буласыңмы?

Мизгел эчендә Кәшһәкнең йөзе кара янып чыкты, карашы зәһәрләнде. Әхмәт аның еллар дәвамында иләктән үткәреп туплаган иң ышанычлы яугирларының берсе ләбаса. Бу катлаулы озын юлның тәүге чакрымнары ук хыянәттән башлана икән, аның уңышлы төгәлләнәсенә өмет тә итә алмыйсың.

—Җирнең астын өскә китерегез,—диде Кәшһәк төйнәлгән йодрыкларын кысып,—тереме-үлеме, алдыма китереп бастырыгыз!

Әхмәтне озак эзләмәделәр. Табылды. Ләкин аркасында хәнҗәр иде. Табигый хаҗәтенә утырган вакытында һөҗүм иткәннәр.

Кәшһәк кайгырды да, шатланды да. Яугирын югалту аңа чиктән тыш авыр иде. Шул ук вакытта, хыянәт фаразының акланмавы олы юаныч та китерде.

Әлеге фаҗига хәрби хәлгә ачыклык кертте. Урысның озын кулы Чулман буена кадәр үк сузылган икән инде.

—Безгә урыслар белән һич тә йөзгә-йөз очрашырга ярамый,—диде Кәшһәк,—элеккечә төп бурычыбыз югалтусыз-нисез аръякка чыгу. Анда күз күрер. Кузгалабыз!

—Атларны авызлыкларга!

Әхмәткә ясалган һөҗүм алдан корылган планнарны чәлпәрәмә китереп ташлады. Хәтта ки, кичү урынын тәгаенләүне дә, ат өстендә генә хәл иттеләр.

—Идел буенда—урыс, Чулман буенда—урыс,—дип зарланды Барбулсын углан,—кая барып төртелергә дә урын тапмассың.

—Ишмөхәммәд мирза, син шушы як кешесе, бөтен өмет синдә,—диде Кәшһәк,—мизгелләребез дә санаулы, башыңны эшләт, мирза!

—Башны эшләтеп торасы юк, бердәнбер ышаныч—Нократ кичүе,—диде Ишмөхәммәд,—ерак жир, урыслар да юктыр.

—Халык ничек анда, кулга ияләшкәнме?—дип белеште Турчы бәк.

—Халык ул кайда да сарык, бәк, көтүче кай тарафка чыбыркы шартлатса, шул якка теркелде...

—Житәрен, сүз куертуның мәгънәсе калмады,—дип өзде Кәшһәк бу икенең әңгәмәсен,—мине хәзерен елганы ничек итеп кичү мәсьәләсе борчый. Саллары, каекары бар микән? Үзебезгә әмәлләргә туры килсә күп вакыт югалтачакбыз. Монысы безнең файдага түгел.

—Әлеге хажәттән кичүгә тиз йөрешле бер чирү жибәрергә кирәк, төп гаскәр килеп житкәләгәнче барысын да рәтләп куйсыннар. Урында яхшырак күренә ул,—дип киңәшен бирде мирза.

—Дөрес,—дип күтәреп алды аны Барбулсын углан,—бу оештыруны мин үз өстемә алам.

Кәшһәк фатихасын ирештерде:

—Әй, Аллаһы! Без Синнән ошбу сәфәребезгә изгелек, тәкъвалек һәм Син риза була торган гамәлләр насыйп итүенне сорыйбыз. Әй, Аллаһы! Безнең ошбу сәфәребезне жиңеләйтсәң вә ераклыгын кыскартсаң икән. Әй, Аллаһы! Без Сина сыенабыз.

***

Нократ кырымлыларны якты чырай, ачык йөз белән каршы алды. Көн туып кына килә иде әле. Әнә, кызарып-яшәреп бишегеннән кояш күтәрелеп килә. Аның тәүге нурлары иң элек офык читендәге челтәр болытларны яктыртып узды, шунда ук агач яфракларында уйнаклап алды да, үлән өстендәге чык бөртекләрендә асылташ булып жемелдәде.

Бераздан барча жиһан кояш хозурында иде инде.

Кәшһәк бу манзарага игътибар да итмәде, килә-килешкә атыннан сикереп төште дә елга читендә кайнашучы Барбулсын углан төркеме янына ашыкты.

—Барысы да әзер, карачы, төялә башларга да була, сүземдә тордым!

—Рәхмәт, углан, сөендерден.

Сөенерлек тә иде шул. Аның әмерен көтеп, әнә, бер жепкә теркәлгәндәй салмак дулкын өстендә саллар тибрәлә. Рәт-рәт тезелешеп торалар. Бернича каек та күренә.

—Урындагы халыкның ярдәме зур булды,—дип ачыклык кертте углан,—барысын да Бәхтияр хаким оештырды. Яраннары бик уңган икән, эшне сытып эшлиләр, безгә кул да тигертмәделәр. Әнә үзе дә килә, ул сиңа ихтирам вә хөрмәтен күрсәтергә тели, каршы килмәссеңме?

—Рәхим итсен. Тиз. Безнең озын-озак юанып торырга вакыт тар,—диде Кәшһәк.

Бәхтияр хаким тубалдай зур башлы, карсак гәүдәле кеше икән. Хәрәкәтләре жиңел, күзләре үткен. Тәвәккәллеге менә мин дип тора.

—Әссәламегаләйкүм, Барча Казан жиренең баш карачысы Кәшһәк угланга олуг сәламнәребезне житкерәбез,—дип каршылады ул башлыкны,—иншаллаһ, сәфәрегез уңышлы булыр.

—Амин!—диде Кәшһәк.

Хакимнең бүләге дә бар икән. Бу—чит-читләренә Коръән аятьләре уелып, уртасына адәм йөзле кояш рәсеме төшерелгән һәм дә кош вә хайван сурәтләре белән бизәлгән корыч калкан иде.

—Ниятләребез гамәлгә ашсын,—дип тоттырды ул аны Кәшһәкнең кулына.

Ярдәмчеләре зур агач табакка салып, кыздырылган сарык боты, касә

белән кымыз китерделәр.

—Көн ялы—ризык ялы, карачы, авыз ит, аш—олы хөрмәт билгесе.

—Хөрмәтегезне кабул итәм, хаким, барчагызга да Ходай бәрәкәтле гомер насыйп итсен,—диде Кәшһәк кулын күкрәгенә куеп,—ифрат та ярдәмчел кеше икәнсез. Рәхмәт!

Кәшһәк иреннәрен кымыз чәркәсенә тигезеп алды да әмер бирде:

—Атларны авызлыкларга!

Ике каекның өсте каплаулы иде. Берсенә Кәшһәк белән Турчы бәкне урнаштырдылар, Ишмөхәммәд мирза икенчесендә урын алды. Ишкәкләргә, ышанычлырак булсын дип, үз кешеләре утырды. Саллар тулышын да шул максат белән көтеп тордылар. Дәррәү кузгалу хәерлерәк, ваемсызлык яхшыга китерми.

Тирә-як хозурлыкка, ямьлелеккә тиенеп утыра. Үз ибенә ятып кына ялкау дулкыннар чупылдаша, су өстендә вак балыклар сикерешә, күктә кояш балкый.

—Их, яшь кәләшем Рабига бикәч тә күрсен иде бу матурлыкны,—дип, Турчы бәк кырын-кырын гына Кәшһәккә карап алды.

Кәшһәк моны сизмәде дә. Ул сәҗдәгә авышкан диндардай оеп каткан иде. Иреннәре генә кыймылдый: «Аллаһым, нинди дә зур кодрәткә ия Син. Мин Синең кодрәтең белән генә хәрәкәт кылам. Раббым, безгә дус бул, мәрхәмәтеңне күрсәт...»

Тагын нәмә мыгырдана инде бу ялган мулла, дип чыраен сытты бәк,—эшләребез көйле ләбаса. Барбулсын угланга рәхмәт.

Кәшһәкнең исә мәрткә киткән кыяфәттә йомылуының сәбәбе кеше ышанмастай гади дә, садә дә иде: ул судан курка.

Углан ишле гаиләдә үсте. Атасы Тау ягы кирмәненең кәтавылы[7] Җәббар гаскәри үтә дә таләпчән, үтә дә каты куллы кеше булып, үз якыннарын гына түгел, бөтен бистәне учында тота иде.

Шулай бервакыт, бала чагында, Кәшһәк елгага мәтәлеп төште. Гаскәриләрнең берәве суга сикереп, малайны коткармак итсә дә, Җәббар аңа:

—Яшисе килсә, үзен-үзе коткарсын, катнашасы булма,—дип бакырды.

Елганың гарасатлы яңгырдан соң котырынган вакыты иде. Мондый чакта ул мәрхәмәтне белми, йомычка урынына талкый. Кәшһәк берничә мәртәбә су йотарга да өлгерде инде. Үзе кул-аяклары белән чәбәләнә, читкә чыгарга омтыла. Берсендә теләгенә иреште дә. Ләкин чытырмандай ябышкан таш кына түзмәде, ишелеп төште. Ә көче кимегәннән- кими. Шулай да бирешергә исәбе юк, үлем белән үҗәтләнеп тарткалаша. Борылышта тәки яр читендәге агач ботагын эләктереп алды бит. Шуңа еландай уралды...

—Без, улым, аксөякләр нәселеннән түгел, үз көчебезгә генә таяна алабыз,—диде атасы,—бу хакыйкатьне һәрвакыт исеңдә тот.

Атасы васыятен үтәп, Кәшһәк Бакчасарайда иң күренекле углан булып танылды. Әмма судан куркуы барыбер калды.

Сәхибгәрәй хан аңа тирән ышаныч белән карый иде. Көннәрдән-бер көнне үзе янына чакырып алды да:

—Сине яңа яшерен бурыч көтә, углан,—диде.

—Баш өсте, мөхтәрәм галиҗәнап, мин аны үтәргә әзер,—диде Кәшһәк.

—Бүген төнлә берәүгә дә сиздерми төмәнең белән Идел тарафларына чыгып китәсең,—дип әмерен шәрехләде хан,—менә бу ярлыгымны якын туганым, Казан ханы Сафагәрәйгә тапшырасын. Аңлашыла булыр, бурыч үтәлергә тиеш!

—Һичшиксез үтәләчәк, хан!

[7] Кәтавыл—комендант.

Һәр уңышның үз хәйләсе була. Бу очракта да ул хәйләне уйлап табарга кирәк иде.

Тапты аны Кәшһәк. Кансызлыклары аркасында телгә кергән бер урыс төркеменең Нугай чигендә башбаштаклык итүе аңа мәгълүм иде. Бигрәк тә сәүдәгәрләр зарлана. Күп калым бирергә туры килә икән. Ул шуннан файдаланмак итте. Сәүдәгәр киеме кигезеп, берничә орышчысын урысларга озатты. Тегеләр сөйләшү сонында уртага берничә мичкә шәраб та тәгәрәттеләр. Бу кадәр шәраб эчәргә генә түгел, коенырга да житәр иде, шәт. Рәхәтләнде хәмергә маһир урыс.

Мичкәләр бушап, егыласылары егылып беткәч, Кәшһәк түмәнен күтәрде. Берничә бөртек аек сакчы алар өчен чүп кенә иде инде.

Иртәгәсен ул юлбасарларның башларын колга очына элеп, юл буенча тезеп чыгарга боерды.

Кырым башкисәрләре турындагы хәбәр самум жиле тизлеге белән далага таралды.

Казанга бернинди хәвеф-хәтәрсез барып життеләр. Ярлыкны Сафагәрәй хан даирәсе алдында үзе укып чыкты.

—Таныш булыгыз, бу Кәшһәк углан булыр, туганым Сәхибгәрәй хан түмәне белән бүләк итеп жибәргән,—без мондый саллы ярдәмгә бик мохтаж идек.

Үзләре генә калгач, Сафагәрәй угланны базарда мал сайлагандай тоткалап та карады, суккалап та алды. Ошатты ул бу мәһабәт гәүдәле, үткен карашлы ватандашын.

—Мин сине шушы кыяфәттә күз алдына китергән идем,—диде.

—Белүемчә, безнең ыргым яшерен иде...

—Хәбәр толпардан да алданрак йөри ул, углан, урыслар хәзер синнән уттан курыккандай куркалар, ди. Афәрин!

—Сәхибгәрәй ханга ничек турылыклы хезмәт иткән булсам, сиңа да үземне шул бирелгәнлек белән багышлармын,—диде Кәшһәк.

—Кырымдагы гаиләнне кузгатмыйсың,—диде Сафагәрәй саубуллашканда,—монда үзенә тиң кәләш табып бирермен. Минем үземнең дә тәүге гаиләм Кырымда яши.

Вакыт үтә. Сәхибгәрәй хан да, Сафагәрәй хан да инде гүр ияләре, урыннары ожмахта булсын.

Алар аның бу адымына нинди бәя бирерләр иде икән? Мөгаен...

Кәшһәкнең уйлары киселде, чөнки күзләре текә борылышта пәйда булган көймәләрне шәйләп алган иде. Карга көтүе диярсең. Ашкынып-ыжгырып киләләр.

Ул үзен-үзе белештермичә урыныннан сикереп торды, куркуы да юкка чыкты.

Хыянәт?

Юк, бу хыянәт түгел, ваемсызлык китергән бәхетсезлек. Үз хыянәтенең котылгысыз кайтавазы.

Әхмәт яугирны үтереп, әүвәл аны сынап караганнар: куа чыгармы—юкмы? Чыкмады. Кәшһәкнең төп ниятен төшенеп алгач исә кичүдә тозак корганнар. Барбулсын угланга үзләрен жирле халык дип тәкъдим иткәннәр. Тегесе ышанган. Аңа иярөп, Кәшһәк тә сукыр тавыктай шул кибәккә алданды. Югыйсә һәр гамәлен кырык кат үлчәп караганнан соң гына башкарырга күнеккән кеше иде ләбаса!

—Һөжүмгә әзерләнергә!—дип кычкырды ул.

—Коткарыгыз, яшь кәләшем хакына коткарыгыз!—дип суккаланды Турчы бәк.

Кәшһәк ачуыннан аны көймә кырыена төртеп екты. Хәер, үзе дә шундый

ук чарасыз хәлдә иде. Әмере дә тузганак мамыгыдай һавада асылынып калды. Салларда шау-шу, кычкырыш-бакырыш...

Атаман Федор Павлов белән Северга житәкчелегендәге кара мөһерле җәза отряды иде бу. Утта янмас, суда батмас. Үзара да «Иблис котырыгы» дип йөртәләр иде. Кәшһәкнең ишеткәне бар иде әлеге ушкуйнак юлбасарлар турында, әмма тап булганы юк иде. Менә очраштылар...

Көймәләр килә-килешкә төркемнәргә бүленеп, салларны камап алды. Хәрәкәтләре төгәл, уйланылган, тавыш-тыннары да юк, фәкать көймәбашларның гына өзек-өзек чыккан боерыклары ишетелеп киткәли.

Шунда ук бер-бер артлы элмәкле арканнар оча башлады. Ә дигәнче салларны бүрәнәсен-бүрәнәгә аерып, ботарлап ташладылар. Бу эш аларга уен кебек кенә иде. Чөнки Бәхтияр адәмнәре сал бүрәнәләрен, таратырга уңай булсынга, бер кагылуда өзелерлек ярымчерек кайрылар белән генә теркәгәннәр иде.

Яугирлар, атлар белән бергә көзге яфраклар кебек уптым илаһи елгага коелып бетте. Өсләренә туктаусыз уклар, сөңгеләр оча. Көмештәй саф вә пакь су алсу төскә керде, Нократ кан, үләксә белән тулды.

Кәшһәк суга сикереп, яугирларының ачы язмышын уртаклашырга омтылып карамак итенсә дә, ирек бирмәделәр.

—Бу кара сакалны саклагыз, ул аларның атаманы,—дип кисәтте көймәбаш,—төшемле әсир.

Кәшһәк белән Турчы бәкнең аяк-кулларын бәйләп, әрдәнә урынына көймә төбенә сузып салдылар.

Яр буенда үзенә бер мәхшәр. Йөзлекбашы сатлык Бәхтиярның урман ышыгында посып яткан орышчылары тәүге чиратка эләкмәгән кырымлыларны канга батыра-батыра кырып бетерде. Барбулсын угланга гына тимәделәр.

—Бу ачык авызны Зөягә җибәреләсе төркемгә кушыгыз, җавапны шунда тотар,—диде Бәхтияр.

Нократның козгыннары, ерткыч җанварлары атна буе мәет, ат үләксәсе белән туенды.

***

Кәшһәккә аш-су керттеләр. Югыйсә, иртәнгесе дә шул килеш тора иде әле.

—Мин мөселман өммәтеннән, тәгамне дә мөселман кулыннан гына ашыйм,—диде ул,—күпме кабатларга мөмкин инде?

Йомышчы кара бүрек аның сүзләрен артына да элмәде, ирен читләре белән генә көлемсерәгәндәй итте. Гүя, көннәрең санаулы гына калды, басурман, тиздән муеныңа тавык тәпие тагачаклар, дип әйтергә тели иде.

Дөресе дә шулай, аны монастырь төрмәсендә шуның өчен тоталар да. Бик күп мөселман әсирләренең йөрәк бәгыре өзелгән каһәрле урын бу.

Ә Кәшһәкнең ризык мөнәсәбәтеннән бигрәк, кимсенүдән җаны әрни. Урам карагын тоткандай китереп яптылар да, оныттылар. Казан ханлыгының баш карачысы лабаса ул! Күренекле яугир, гаскәрбаш. Ясавылы, йомышчысы да юк хәтта. Ул үзе дә бик күп дәрәҗәле әсирләр тотты, әмма берсен дә мондый кысынкылыкка дучар итмәде.

Зарын ишеттеләр, күрәсең, көннәрдән бер көнне бөтенләй башка бүлмәгә алып керделәр. Ул кара бүрекләрнең кысан вә сасы хөҗрәләреннән аермалы буларак, ат утарыдай зур, зиннәтле җиһазлар белән җиһазландырылган затлы бүлмә иде. Идәндә—келәм, диварларда—аю тиреләре. Якты, гөлт итеп тора. Берара Кәшһәкнең күзләре камашты.

Бүлмәнең нәкъ уртасында төрле-төрле ризыклардан сыгылып торган

биниһая олы өстәл. Анда көрәк сакаллы, мичкәдәй юан бояр сыйланып утыра иде.

—Әйдә, карачы, түрдән уз, ризыгымны бүлеш, бик разый-бәхил булырмын,—дип дустанә мөнәсәбәттә каршы алды аны бояр кырым-татар телендә, әйтерсен лә, күптәнге әшнәләр.

Кәшһәкнең йөрәгенә җылы йөгерде, күңелендә өмет кабынды: бәлки, үз дәрәҗәсендәге әсир белән алыштырып, Ак кирмәнгә кайтып китәргә рөхсәт бирерләр? Бу дәүләтара багланышта бик тә гадәти хәл.

—Тартынма, җитеш, дуңгыз итен мин үзем дә өнәмим,—диде бояр калҗаларны бер-бер артлы шудырган арада,—башта Казанда, соңыннан Бакчасарайда илче вазифаларын башкардым. Тора-бара мөселман ризыкларына да күнегелде.

Ул бермәл кызып-кызып татар милли аш-суын мактап алды. Аннан соң кисәк кенә туктап, керфексез күзләрен Кәшһәккә төбәде:

—Мәгәр канны бездыгыз, кара йөрәкләр...

—Без үз вазифабызны гына башкардык,—диде Кәшһәк,—мөстәкыйльлеген яклый алмаган дәүләт дәүләт түгел ул.

—Олуг кенәз шул үҗәтлекләреңне, хәрби уңышларыңны исәпкә алып, сиңа зур мөмкинлекләр бирә,—диде бояр,—инде аның таләпләрен тыңла.

Бояр бер ыргымда хәмер касәсен авызына каплап куйды, чыраен да сытмады, кабымлыкка да үрелмәде.

Кәшһәк игътибарын җыеп, тураебрак утырды.

—Атна-ун көндә православиене кабул итәсең,—диде бояр өздереп,—бу—бер. Икенчедән, патшабызга турылыклы хезмәт итәргә каның белән ант эчәсең. Җәмәгатең, балаларың белән бары шуннан соң гына кавыша алачаксың.

—Аллага шөкер, алар Казанда,—дип, җиңел сулап куйды Кәшһәк,—ерактa...

Боярның чепи күзләре бүселеп чыкты, йөзен сәерсенү шәүләсе каплады. Ә бераздан ютәлли-ютәлли хихылдарга тотынды.

—Күрәм, си-и-н, карачы-ы-ы, далада качып йөри-йөри кы-ы-ргыйланып беткәнсең икән бит,—диде тыела алмыйча,—дө-дөньяда-ан артта ка-а-лгансың...

—Моның белән ни әйтмәкче буласың?—диде Кәшһәк шомланып.

—Казанның аек акыллы даирәсе, ниһаять, бөек патшабыз Иоанн Васильевичның гадел таләпләренә колак салды, Үтәмешгәрәй ханны һәм Сөенбикә ханбикәне Мәскәүгә тотып бирде. Этапланган әсирләр арасында синең хатының белән балаларың да бар. Мин сиңа менә шушы хакта әйтмәкче идем.

Кәшһәк аягүрә торып басмак иде дә, тез асты тотмыйча кире урындыгына лыпылдады.

—Юкка борчыласың, карачы,—диде бояр исе китмичә генә,—тамаклары тук, синең белән бер үк көнне митрополит аларны да туры юлга бастырыр. Янәча яши башларсыз. Дәрәҗәң дә бермә-бер артыр.

Ишек алдында буылып-буылып өргән эт тавышы ишетелде. Сакчы тәрәзәне ябып куйды.

—Патшабызның мәрхәмәте бәһасез, кадерен бел,—дип, бояр соңгы калҗага үрелде.

Кәшһәк маңгаен кулына терәп, сүзсез калды.

—Җә, ни әйтәсең?—дип сорады бояр,—олуг кенәзгә нинди җавап җиткерергә боерасың?

—Бояр, мине Ходай мөселман өммәтеннән яраткан, үз динемнән үлем ачысында да баш тартмаячакмын. Олуг кенәзгә менә шуны җиткер.

—Ә балаларын, җәмәгатен?

—Булачак булмый калмас.

—Туң йөрәк икәнсең, карачы. Бел, бу соңгы очрашу, үкенергә туры килмәсен.

—Сүз озайтуның мәгънәсе юк, бояр, бер тырмага ике мәртәбә басмыйлар.

Әңгәмә шуның белән төгәлләнде. Тагын ике көннән Кәшһәк угланны таң атканда җәзалап үтерделәр: әүвәл кулларын гәүдәсеннән турап алдылар, аякларын. Аннан соң башын чабып, исәп-хисап базына, түмгәк-гәүдәсен ерткыч җанварлар өненә ыргыттылар.

Кәшһәкнең җәмәгате Нәсыйха бикәне дә, балаларын да чукындырдылар, яңа исем бирделәр. Иоанн мәрхәмәт иясе икәнен янә дәлилләде. Балаларын монастырь мәктәбенә, Наталья-Нәсыйханы исә бер бөлгән карт боярга кияүгә биреп, бөек княгиня Анастасиягә гасәбә хезмәтенә тәгаенләде.

Кәшһәк угланның мөселман ыруы акрынлап төкәнде.

## ИКЕНЧЕ КЫЙССА

### Йосыф би

Татли Әстерханга су юлы белән барырга ният итте. «Идел татар тарихының җуелмас шаһиты, сәяхәтең үз ыруыңның колачын күзалларга да ярдәм итәчәк»,—дип, моны Марсель дә хуп күрде. Тик китәргә бер көн кала теплоход билетын кире тапшырырга туры килде. Чөнки анасы княгиня Александра шалтыратып, йөрәгенә ут салды, төпчеге авырып киткән, имеш, тамагына салкын тигезгән. Татли кабалана-кабалана кайтып китәргә җыена башлады. Марсель аптырап калды.

—Мин сезне, княгиня, Декабрист бичәләредәй нык характерлы, куйган максаты хакына теләсә-нинди кыенлыкларга да барырга әзер көчле зат дип кабул иткән идем, ялгышканмын икән,—диде.—Борчылмагыз, мин сезне озатып куячакмын.

Татли сүзсез генә төенчек-сумкаларын кулына алды да, чемоданына ишарәләп:—«Монысы сезгә»,—диде.

Такси машинасы көтеп тора иде инде.

—Аэропортка,—диде Марсель,—тизрәк, әле безнең билет та аласы бар.

—Тимер юл вокзалына,—дип төзәтте аны Татли.

—Ничек?—дип әйләнеп бакты Марсель.

—Әстерханга поезд тимер юл вокзалыннан китәдер бит,—дип көлемсерәде Татли,—алдан ук поезд муафыйграк булыр дип килешкән идек түгелме?

Ә поезд дигәне ахырзаман калтырчасы булып чыкты: уңайсыз, килбәтсез, пычрак: док та дык, талкый гына, рельстан чыгып китәр дә, мәтәлеп төшәр төсле.

Татли төнне керфек тә какмыйча үткәрде. Йончыганын күрсәтәсе килмичә вагоннан да иң соңгы кеше булып чыкты. Казандагы дуслары үтенече белән аны Әстерхан төрки-татар хатын-кызларының «Сөембикә» берләшмәсе рәисе Наилә ханым каршы алырга тиеш иде.

Яз кояшы сыман көлеп-елмаеп, тамбур төбендә басып торучы мөлаем һәм чибәр ханымны ул шундук абайлап алды. Шулай яратып, ихлас күңелдән мөкиббән булып карап тора, бәгырь, аны кем беләндер бутау мөмкин түгел иде. Поезд мәрәкәләре дә, арыганлыгы да су белән юып төшергәндәй юкка чыкты.

—Хуш киләсез, княгиня Татьяна, ата-бабаларыгызның кендек каны тамган изге җиргә рәхим итегез,—дип, хуҗабикә аны төшә-төшешкә

кочаклап алды. Кемнәрдер кулына чәчәкләр китереп тоттырды.

—Мине бик кыен хәлдә калдырдыгыз, болай мәшәкатьләнергә кирәкми иде,—диде Татли каушавын яшерә алмыйча.

—Сез безнен иң кадерле кунагыбыз,—диде Наилә сәхнәдән нотык сөйләгән телмәрдәй,—ханбикәбез нәселеннән!

Вокзалдан туп-туры табын мәҗлесенә алып киттеләр. Ул ике катлы җыйнак кына йортның җимеш бакчасында оештырылган иде. Искиткеч матур бакча. Рәт-рәт өрек, абрикос, шәфтал[8] куаклары тезелешеп утыра. Инде әнә, айва, алма өлгереп килә. Ә койманың буеннан-буена йөзем тәлгәшләре тибрәлә.

Ишек алды тоташ аллы-гөлле чәчәкләргә күмелгән, гүя бинидая зур келәм җәеп куйганнар.

Хуҗа, киң җилкәле, тулы битле көләч ир-егет, карбыз телеме тәкъдим итте:

—Рәхим ит, княгиня, карбыз нугайларның ихтирам билгесе,—диде. Үзе авызын да җыя алмый. Сөенече түбәдән ашкан.

Татли тешләп кенә алмак иткән иде дә. Наиләнең баш чайкавыннан карбыз кисентесен ашап бетерергә кирәк икәнен төшенеп алды.

Утырасы кеше утырып беткәч, өстәлгә учакта кыздырып пешерелгән куй чыгарып салдылар. Симездер үзе, чит-читләреннән майлары тамып тора. Татлиның борыннары җыерылды, ничек авызга капмак кирәк бу май тутырмасын?

Хуҗа түшкәне кискәләргә тотынды. Иң әүвәл бер кабыргасын аерып алды да кунакка сузды.

—Аш-суга фатиханы бир, княгиня,—диде.

—Ата-бабадан килгән гореф-гадәт,—дип өстәде Наилә чигенергә урын калдырмыйча.—Экология мөнәсәбәтендә иң саф, иң пакь ит, табиб буларак, тулы гарантия бирәм.

Дөрестән дә, ит кабуга эреп кенә китте. Монарчы Татлиның табигый ит авыз иткәне булмаган икән ләбаса. Кәтлит, гуляш, антрекот, тефтели... тагын әллә нинди йөзләгән исем астында сүле беткәнче эшкәртелгән, төрледән-төрле соус, консервант ише нәмәстәкәйләр өстәп, чын тәме тәмам җуелган цивилизацияле блюдалар белән бу куй итенең бернинди уртаклыгы да юк иде.

Табында сүз-багышламалар күп булды, бик күп сорау яудырдылар, Татлиның болай да шайтан төкергән телен тәмам яздылар, үзе дә шаккатты.

—Княгиня телбистәсе булырга тиеш түгел ул, дуслар,—диде уены-чыны белән,—бу һич тә яхшыга китермәс.

—Соңгы сорау,—диде Наилә,—әлеге хокукны бу йортның хуҗасы, абруйлы эшмәкәр-меценатыбыз Хәсән әфәндегә бирсәк дөресрәк булыр.

—Гадел карар,—дип, рәисне һәммәсе дә хуплады.

—Хәсәннең соравы алдан ук килештерелгән гомуми сорау иде булса кирәк, томырылып ана төбәлделәр.

—Княгиня, әйтегез әле, сез үзегезне нинди милләт кешесе итеп саныйсыз?

Татлины әлеге сорау кыенрак хәлгә куйды. Чөнки күреп-сизеп тора, мондагылар өчен сорау символик мәгънәгә ия. Шуңа күрә җавап бирергә ашыкмады, аның һич тә бу мөлаем, үз ыру-нәселен ихластан яраткан яна дусларын рәнҗетәсе, хәтерләрен калдырасы килми иде. Шуның белән бергә, дөреслеккә дә хилафлык кылырга тиеш түгел.

—Минем тамырларда татар, урыс, грек каннарының кушылмасы

[8] Шәфтал—персик.

ага,—диде ул,—шулай да үземне күбрәк француз буларак хис итәм. Әнием, мәсәлән, үзен урыс милләтеннән дип саный. Монда безнең гаеп юк, бу язмыш уены. Барыбызга да мәгълүм, Йосыф бинең Мәскәү патшасы хезмәтенә багышланган өченче буыны вәкиле генә Православиене кабул иткән, аңа кадәр Аллаһка табынганнар. Бу—бинең туруны Габдулла мирза. Аңа пост вакытында зур руханины каз ите белән сыйлагансың дигән гаеп ташлыйлар. Шуны сәбәп итеп, барча мал-мөлкәтен, җирләрен тартып алу белән яныйлар. Шарт бер генә: чукыну. Һәм Габдулла чукынырга мәҗбүр була. Нәселнең яңа тарихы менә шулай башлана.

—Белүебезчә, княгиня Ксения Казанга визиты вакытында Колшәриф мәчетендә нәсел-ыруы рухына дога кылган,—дип сүзен кыстырды Наилә.

—Алай гынамы, Санкт-Петербургта Шереметьевлар сараенда үткәрелгән очрашуда җыелышучыларны: «Мин татар кызы» дип таңга калдырган,—дип тә өстәде Татли.

Табындагылар гөрләшеп кул чапты, җавабын ошаттылар.

Мондый очрашулардан соң үзгәрмәс җирдән үзгәрерсең, дип уйлап куйды Татли.

Икенче көнне кунакка иркенләп шәһәр күрсәттеләр. Татли бигрәк тә Татар базарын ошатты. Бер сатучы аңа искиткеч матур нәни мичкәгә салып, кара уылдык бүләк итте. Тере балыклар сатучы агай иң зур җәенне сайларга кушты.

—Рәхмәт,—диде Татли көлемсерәп,—мин аны кая куярмын икән соң?

—Борчылма,—диде ут чаткысыдай өлгер Наилә,—сезнең исемнән без ул балыкны ятим балалар йортына тапшырырбыз.

—Татар сәүдәгәрләре бик юмарт икән,—диде Татли,—мәрхәмәтлек йөзләренә язылган.

—Татар бакчада туа, базарда үлә,—диләр монда.

***

Күрегезче, нинди матур сарык. Аклыгына күзләр чагыла, әйтерсең лә, яңа сауган дөя сөтенә манып алганнар. Далада йөзгә-меңгә берәү генә туа мондый сылукай. Бәрәне дә үзе кебек үк күркәм, учта гына йөртерлек.

Каян килеп чыкканнар соң алар бу чәнечкеле котсыз атауга? Су эчәргә барган җирдән адашканнар күрәсең, көтүдән аерылып калганнар булса кирәк. Бәлкем, бүреләр куркыткандыр? Мөгаен. Әнә ич сарыкның колаклары ширпыдай тырпайган. Үзе туктаусыз як-якка карана, тынгысызлана. Бәләкәче дә сыланып кына тора, кая ул уйнаклау, сикергәләү, гүя кендеге өзелмәгән.

Хак. Бүреләр камалышында икән ич бәгырьләр. Посып кына корбаннарын күзәтәләр. Кансызлар. Ни йөрәгең белән шушы гүзәл затларга теш батырмак кирәк? Хәер, бүре шуның өчен яратылган да инде ул. Корсак колы.

Сарык-ана фәкать бәрәне хакында гына мазалана иде. Бу аның бөтен тырышлыгыннан, нишләргә белмичә өзгәләнүеннән сизелеп тора. Бүреләр якынайганнан-якыная, аралары—күп дисәң бер ыргым калгандыр...

Йосыфның төше шушы урында өзелде. Дөресрәге, өзделәр. Ул хадим егетнең җилкәсен каккалавыннан уянып китте. Ә күз алдында әле һаман нарасыен бүреләрдән сакларга тырышып үрсәләнгән ак сарык иде. Саклый гына алмады, үзен дә, бәрәнен дә умырып кына ыргыттылар...

—Нәмә бар, ник таң тишегеннән бимазалыйсың?—дип ризасызлыгын белдерде би,—соң ятканны беләсең ләбаса.

—Илчеләр кайтты, бик ашыкканнар, Байбахты мирзаның аты ишек алдында егылып, кабыгудан җан тәслим кылды,—диде хадим, сүзебез

житди, уят диделәр.

Йосыф авызын иләктәй ачып, иснәп куйды.

—Керсеннәрме?—дип ашыктырды хадим хуҗасын.

—Чебендәй ябышты тәки,—дип чыраен сытты би,—бар инде алайса, чакыр, барыбер күзне йокы алмас хәзер, Байбахты үзе генә керсен, ничу өер белән йөрергә. Тозлы чәй әмәлләгез, кымыз да ярый.

Байбахты илче бүлмәгә дала әвәрәседәй тәгәрәп кенә инде. Ине-буе бер булса да, йөгерек чаптардай житез хәрәкәтле иде ул.

—Иван бер-бер затлы бүләк җибәргән ахрысы,—дип каршы алды аны Йосыф,—җә, күрсәт, ни-нәрсә алып кайттың?

—Хәлләр яман, би...

—Соң, сөйлә!—дип кычкырды Йосыф. Ул йокысыннан тәмам арынды.

—Сөенбикә ханбикә белән Үтәмешгәрәй ханны казанлылар Иванга әсир итеп биргәннәр...

—Һоһ...

Йосыфның чүлмәктәй зур башы күкрәгенә салынып төште. Хадим егет тиз генә кесәсеннән ачы таш алып, бинең иреннәрен, борын тишекләрен сыйпаштырырга тотынды. Күрәсең, мондый хәл булгалап тора. Дөрестән дә, Йосыфка җан керде, берничә йотым чәй эчергәннән соң илчегә соравын юллады:

—Үз күзләрең белән күрдеңме, кеше сүзе генәме?

—Мәскәүнең бик ышанычлы бояры җиткерде. Иван казанлыларга әйткән, хан белән ханбикәне үз теләгегез белән тотып бирмәсәгез, дәүләтегезне юк итәм, дигән.

—Шыр җибәргән инде тегеләр, шулаймы?

—Казан йомшарды, би, бик тә мескен хәлгә калды,—диде илче.

Төшем рас килде, ак бәрәнкәйләремнең, бәгырькәйләремнең башларын ашаганнар икән, дип Йосыф эченнән генә ачынып куйды.

—Би-мирза, бераз хәл җыеп алыр идең,—диде Байбахты борчылып,—кәефеңне боздым...

—Бүген-иртәгә далага чыгып китәм, атна-ун көн үз уйларым белән икәүдән-икәү генә калырга ниятлим,—диде Йосыф үзалдына сөйләнгәндәй.

Илче артык иде инде. Һәм ул тавышсыз-тынсыз гына бүлмәдән чыгып китте.

Дала да кәефсез иде. Офык баудагы кер шикелле чайкала. Кояшның да гадәти рәвеше үзгәргән, ул куәс чиләгеннән бүселеп чыккан камырны хәтерләтә, асылынып-ялманып тора.

Нугайларга таныш манзара бу—самум кузгалачак.

—Дөяләрне җил-аркан яткырыгыз!

Әмер гүләп килгән җил эчендә югалып калды. Мизгел дә үтмәде, ком өермәсе кояшны йотты, җиһан караңгылыкка чумды. Кешеләр дөяләргә ышыкланып, баштан-аяк япма белән бөркәнделәр. Ләкин комнан котылырмын димә, ул барыбер керер тишек таба, тешләргә сылана, күзләрне кыра. Чамасыз дәрәҗәдә эссе, әйтерсең лә учак өстендә утырасың.

Йосыф би генә боларны сизми, дөресрәге, жаны-тәне эсселектән дә битәррәк халәт—сагыш вә үкенеч халәте белән тулышкан иде.

Сөенбикәне ошбу бәлаләрдән йолып кала ала иде бит?! Ала иде! Бердәнбер кызына карата нигә шулай каты бәгырьле булды соң әле ул? Күз өстендәге кара каш иде ләбаса үскәндә.

Бүтән хатыннары һаман ир бала алып кайткан бер вакытта, яшь кәләше Бибинур аңа кыз бүләк итте. Сөенбикә дистәдән артык агалары арасында

күкәй эчендәге сары кебек иде, иркә вә сөекле сенел булып үсте. Купшы чәчәк—чибәрнең чибәре. Ходай сылукайга акылны да, зирәклекне дә өеп биргән иде. Гыйлемгә-мәгърифәткә омтылышы ягыннан да дала кызларына охшамыйча, башкалардан бик нык аерылып тора иде.

Йосыф кызын өзелеп ярата иде, әлбәттә. Тик аксөяк нәселнең ыруы каршында, җәмгыять-гавам алдында катгыйдан-катгый йөкләмәләре барын да истән чыгарырга ярамый. Күп очракта әлеге даирәдә җәмгыяви вазифа ярату, туганлык хисеннән алданрак йөри.

Сөенбикәнең тәүге ире Җангали хан белән ничектер хисләре беркеп җитмәде. Кадер-хөрмәткә күнеккән иркә туташ моны бик авыр кичерде, атасына шикаятьле хатлар язды, аннан яклау көтте. Ул исә: «Төшкән җирендә таш бул»,—дип бәхәссез карарын җиткерде. Кызы аны аңлады.

Иван ни-нәрсә уйлап казанлыларның бу яман гамәлен кабул итте икән, һич аңлашылмый. Шәехгалине тәхеткә утыртасың килә икән утырт, сиңа берәү дә комачау тудырмый. Сөенбикәне дә Мәскәүгә алып китәргә кирәкми, тот та Шәехгали ханга кияүгә бир. Тигез җирдә түмгәк чыгару гына ич инде бу. Хәер...

Кырымлылар аркасында бозылды Казан—Мәскәү арасы. Сафагәрәй хан олуг кенәзне санга сукмады, Мәскәү, үз чиратында, Сафагәрәйнең ханлык вәкаләтен танымады. Егерме елдан артык этле-мәчеле яшәделәр, әле берсе өскә чыкты, әле икенчесе. Сафагәрәйнең вафаты Иванның кулларын чиште.

Йосыфка кызы белән оныгының баш очында болытлар куеруы турында электән үк хәбәр итеп тордылар анысы. Әйтергә кирәк, ул чарасын да күрергә тырышып карады. Шул ук вакытта, Мәскәү белән дә бозылышасы килмәде. Ә инде Иванның Казан өстенә йөрергә ниятен белүгә, олуг кенәзгә ярлык юллады. «Минем 300 мең явым бар,—дип үпкәсен белдерде ул,—сигез углым бүленеп боларның һәрберсенең унар мең яулары бар. Шуларның һичбер вакыт синең кешеләр өстенә барганы юк.»

Бинең өлкән улы Юныс мирза да 1551 елның көзендә яраткан сеңлесе өчен борчылып Мәскәүгә илчеләр җибәрде. «Казан сиңа дошман булдыгы кеби, безгә дә дошман,—дип хакыйкатьне ачып салды ярлыгында,—син аны алсаң да, мин синең белән бозылышмамын...»

Йосыф бигә далага чыгар алдыннан гына Иванның ярлыгын китереп тоттырдылар. Байбахты илченең хәбәре тулысынча расланды. Ярлык төче телләнеп язылган иде. Тире ябынып кына бүредән сарык булмаган кеби, гамәлләренә матур төс бирергә тырышып язылган әлеге хат та атай кешене һич тә тынычландырмады. Имеш, Сафагәрәй ханның углы Үтәмешгәрәйне атасының начарлыклары өчен Мәскәүгә алып килгәннәр. Әмма олуг кенәз үч сакламый икән, Сөенбикәне дә, Үтәмешгәрәйне дә үзе зур багышлаулар белән багышлаган, аларны төрлечә куандырган. Имеш, Шәехгали хан аларны үзендә тотасы килмәгәнгә генә һәр икесен дә Мәскәүгә китерергә мәҗбүр булган.

Чеп-чи ялган! Шәехгалинең тотасы килмәгән, имеш. Аны акылга утыртырга Иванның ярты сүзе җитә ләбаса!

Юк, акламады Иван тугрылыклы дустының ышанычын, акламады!

... Самум мәңге туктамастай булып ыжгырынса да, гомере кыска үзенең. Кисәктән башлана, кисәктән бетә.

Адәмнең юшкын утырган күңелен самум җиле дә юып алып китә алмый шул. Йосыф мирза, әнә, даланы аркылыга-буйга иңләсә дә үз-үзенә урын таба алмыйча изалана. Ахыры сәяхәтенең унҗиденче көнендә дөяләрне утар ягына борырга боерды.

***

Машина жыйнак кына каралты-куралы бер йорт алдына килеп туктады. Чүлмәк тышыннан билгеле дигәндәй, хуҗасының пөхтәлек яратуы әллә каян күренеп тора. Гадәти дала авылларыннан үзгә буларак, ул яшеллеккә төренгән, җимеш куаклары эчендә балкып утыра иде.

Капкадан башына җинелчә ак яулык бөркәгән кечерәк кенә гәүдәле бер өлкән ханым килеп чыкты. Ул якты елмаю белән кулларын кош канатыдай як-якка җәеп, кунакларга таба атлады.

—Хуш киләсез, кадерлеләрем, өемнең түренә узыгыз,—диде,—сезне күрүемә бик шатмын, Ходай барыбызга да иминлек, сабырлык вә гыйлемлек бирсен.

—Сөенбикә ханбикәнең ерак туганы, хөрмәтле агабиебез Зөлхәбирә тәнәкә дип таныштырды Наилә.

Татли тәнәкәне кочаклап алды. Ә Наилә тын гына елады да елады.

Чәй табынында да парлап утырдылар. Татли җитмешнең аръягына чыккан бу мамыктай йомшак мөлаем ханымның яшь чагын күзалларга тырышты. Бу сурәт Сөенбикә ханбикә сурәтләре белән тәнгәл килеп бетми иде. Хәер, гаҗәп тә түгел, ник дисәң, рәссам үз хыялындагы образны тудыра, ханбикәнең исә чын сурәте бервакытта да булмаган. Истәлек-хатирәләр бар, ә сурәте юк. Зөлхәбирәдә үз ыруының сыйфатлары, мөгаен, күбрәк саклангандыр.

Зөлхәбирә кулына кабал алды. Өй эченә сагышлы аһәң таралды. Аңа илаһи бизәк булып, уенчының бераз калтыраулы, әмма йөрәкне чеметтерердәй самими тавышы кушылды.

Йосыф мырза кызы Сөембикә
Муса ханның сөекле оныгы.
Мин дә Исхак мырзаның ин олы—
Беренче кадерле оныгы...

Җырчы сулышын өзеп, тукталып калмакчы итенсә дә, Татли аңа ялынулы мөлдерәмә карашын юнәлтте. Бу сүзсез караш, зинһар өчен, тагын бер генә куплет, дигәнне аңлата иде. Зөлхәбирә карышмады, җыруын дәвам итте.

Гасырлар арасыннан
Син карыйсың елмаеп,
Күзләреңдә тулы
Кардәшлек нуры.

—Нугай көйләре соң дәрәҗәдә примитив булып тоелырга мөмкин,—дип аңлатма бирде ул кабалын читкә алып куйгач,—тик бу беренче карашка гына, аларның тәэсир көче дә шунда, гадилектә, халыкчан булуында.

—Миңа калса, төп сыйфат миллилектә,—дип Татли да үз фикерен җиткерде,—миллилек халыкның җаны ул.

—Ай-һай, халыкның җаны миллилек калыбына гына сыешып бетәр микән?

—Безнең Наиләне ышандыруы авыр,—диде Зөлхәбирә яшь дустының аркасыннан сөя-сөя,—мин исә шәхсән княгиня белән килешәм.

—Мин бит, тәнәкә, миллилекне инкарь итмим,—диде Наилә,—әйтик, княгиня Йосыф би нәселенең дәвамчысы. Ә син, тәнәкә, Исмәгыйл ыруы вәкиле. Йосыф белән Исмәгыйл бертуган. Тик алар бер-берсен күрә алмый. Тәхет хакына Исмәгыйл бәк агасына кул күтәрә. Сөембикә яклаучысыз кала. Шуннан соң ханбикәнең тарихта эзе дә югала. Логика фәне буенча

сез килешә алмастай дошманнар лабаса. Житмәсә, диннәрегез дә үзгә. Чынлыкта алай түгел. Сез Сөембикә варислары. Бу—рухи бөтенлек.

Наиләнең күзләре яна, йөзе балкый. Бәхәсләшү ошый иде аңа. Зөлхәбирә дә бик гыйлем зат икән, чынбарлыкны ассызыкларга бер җөмләсе житте.

—Бу язмыш, Наилә сеңлем,—диде,—миллилеккә аның бер катнашы да юк.

Әңгәмә әле озак дәвам итте. Бер самовар чәй генә эчеп бетерделәр.

—Мин, тәнәкә, сезнең белән очрашуыма чиктән тыш шатмын,—диде Татли хушлашканда,—икенче шатлыгым да бар. Нинди зур икән минем Ватаным: Франция, Россия, Татарстан, Нугай иле.

—Син үзең дә айбар[9] зат икәнсең, княгиня.

***

Юныс мирза, ачыктан-ачык белдермәсә дә, атасының Сөенбикә хакында ут йотып йөргән һич тә хупламый иде. Шуңа күрә, юк сәбәбен бар итеп, дала жыенына да бармаска хәл итте. Ачулы иде ул ханбикәгә. Чөнки сеңлесе агасының омтылыш-теләкләренә юл ачуда булышмады. Ә Юнысның бик тә Казан бәге буласы килә иде. Карачы, корылтай әгъзасы сыйфатында ханлыкның иң дәрәҗәле адәмнәре гаиләсенә керү иде максаты. Әлеге максаты хакына тәгаен гамәлләр кылудан да тартынмады. Жизнәсе Сафагәрәй хан каршында:

—Мин Идегәй ыруының бер асыл заты, һәм минем Казан бәге булырга тулы хокукым бар,—дип, мәсьәләне кабыргасы белән куйды.

Сафагәрәй зур вәгъдәләр бирмәде, уйлап карарбыз гына, диде. Эш шул уйлап караудан узмады. Сафагәрәйнең үлеме бу җәһәттән яңа мөмкинлекләр ачты. Мирза янә Казанга йөрде. Тик уңышсызлыкка очрады. Бәклек саны бирү түгел, калага да кертмәделәр, куып җибәрделәр. Байтак кына яугирларын да югалтты.

Юныс мирза үҗәт кеше иде, ишекне япсалар, тәрәзәдән, тәрәзәне япсалар ишектән керә торганнардан. Әлеге уңышсызлыктан соң да уеннан кайтмады, фәкать максатына ирешү ысулын гына үзгәртте. Иң әүвәл ул кызлары житеп килә торган Казан бәкләрен ачыклады. Шулар арасыннан матди хәлләре мөшкел затларны сайлап алды. Алар өч кеше булып, Хәйдәр бәк аеруча авырлык кичерә иде. Озын телләрнең әйтүенә караганда, калым акчасына зур өметләр баглый, имеш. Кызы Хәдичә исә дала курасыдай зифа буйлы, карап туймаслык чибәр, имеш. Бер бите ай, икенчесе—кояш, нугайларча әйтсәң, «кызыл туңлы» кәләш.

Дала жыенын инкарь итүенең иң зур сәбәбе дә шушы Хәдичә сылу белән бәйле—бүген-иртәгә Казаннан яучылар җавап алып кайтырга тиеш. Ул түземсезлек белән шуларны көтә.

Яучылар, ниһаять, ат тезгеннәрен утартоткылга китереп бәйләделәр. Тик баш яучы Шаһбаз мирзаның йөзе һич тә litaяшлы якты көн белән тәңгәл килми иде. Юныс бер күз сирпеп, бу күләгәле кыяфәтне шәйләп алды. Озын юл галәмәтедер, талчыккандыр, яше дә бар, дип үзен юатып караса да эчендә ниләрдер өзелеп төшкәндәй булды.

—Җә, нинди хәбәр белән кайттыгыз?—дип түземсезләнеп сорады ул бусагада яучы күренүгә.

Шаһбаз итәк чабуы белән юеш маңгаен корытып куйды да, өстәлдәге кымыз чәркәсен кулына алды.

—Кызы шәп иде, каһәр,—диде калын иреннәрен чәпелдәтеп.

—Өздереп әйттеләрме?

—Өздереп, морза, «Мин кызымны бишенче хатынлыкка бирү өчен үстермәдем»,—дип кырт өзде.

[9] Айбар—матур.

—Карт хатынын аера дип әйттенме соң?

Шаһбаз кабыккан иде күрәсен, ияк читләренә агыза-агыза янә бер чәркәне бушатты.

—Әйтмәгән кая, бу никах Юныс морзага Казан бәге кәнәфиенә юл ачачак, дидем, бергә-бергә яшәрсез дидем.

—Ишкәнсең ишәк чумарын, ангыра,—дип ачусыз гына кулын селтәде морза.

—Синең урынында булсам, ул Казан дигәннәрен җир белән тигезләр идем,—дип, яучы тагын берне каплап куйды.

—Һәм булачак та!

Юныс бар көченә хәнҗәрен тәрәзә янындагы түмәргә китереп кадады. Түмәр шартлап икегә ярылды.

Шуннан соң тиз-тиз генә җыенды да, атасы Йосыф би утарына чыгып китте.

Җыенның кызган чагы иде. Ярсыганнар. Кымыз касәләре дә кулдан-кулга әйләнгәләп кенә тора, тутырырга гына өлгер. Бәхәснең Казан турында барганын абайлавы да кыен түгел. Бу сүз бик еш колакка керә. Ә Нугай аксөякләре, әйтерсең лә, Иванга ярау мәсләгендә ярышка чыкканнар. Хәер, көчле койрыгына ябышу куштаннарның яраткан гамәле ләбаса. Исмәгыйл бәк, әнә, чираттагы ярлыгында: «Яу булган Казанны тар-мар итәбез, син дә яу чапсаң иде»,—дип мөрәҗәгать итте. Белек-Булат: «Синең өчен Казан белән орыштым, син дә минем өчен Казан белән орыш»,—дигән үтенеч юллады. Арыслан морза да алардан калышмады. «Казан сезгә яу булдыгы кеби, безгә дә яу. Мин хәзәрендә Казанны яуларга барамын»,—дип ышандырды.

***

1552 елның июнь-июль айларында Нугай илчеләре Мәскәү юлына тузан кундырмады. Югары даирәгә мөнәсәбәтле һәр белекле морза олуг кенәзгә ярлык җибәрүне үзенең асыл бурычы сыйфатында кабул кылды. Чөнки җыен шулай хәл итте. Теләкләре Сөенбикә ханбикәгә тиз арада азатлык бирү, туган-үскән иле Нугайга кайтару иде. Ярлыклар үтә дә катгый төстә язылып, чәчләр үрә торырлык кискен сүзләр белән тулы иде.

Иоанн әлеге ярлыкларны укып, вакытын әрәм итмәде, Нугай иле белән элемтә тотучы дьякка тапшырды.

—Кыска тот,—дип күрсәтмә бирде,—ул елак адәмнәрнең зарын ишетәсе килеп тормый, каймагын гына житкер.

—Каймагы шул, галиҗәнап, һәммәсе Сөенбикә ханбикәне азат итүне...

Дьяк тотлыгып калды. Чөнки «таләп итә» дип дөресен әйтсә, олуг кенәз буза куптарачак, йодрыкларын уйнатудан да тартынмаячак. Шуңа күрә ул «үтенәләр» дип котылмакчы итте.

Иоанн шаркылдап көлеп җибәрде.

—Җан кадерле, ә?

—Дык...

—Ярар, ярар, аларның стилистикасын бик яхшы беләм,—диде Иоанн дустанә кыяфәттә,—искәрмәләрендә ни-нәрсә бар, шулар күбрәк кызыксындыра мине, хәлбуки, монда да яңалык юктыр дип уйлыйм.

Дьяк бушанып калды, Алланың рәхмәте, буран булмыйча калды.

—Гали мирза,—дип көр тавыш белән тезеп китте түрә,—Гали мирза кеш туны җибәр дигән...

—Тотсын капчыгын, башы яшь, аңа киелгән сусар туны да бик җиткән.

—Белек-Булат морза ас туны, янә дә көбә сораган, Арыслан мирза алтын йөгертелгән кылыч, балык теше кәтә. Касай морза: «Кызымны хан углына кияүгә бирәчәк идем, ана кара бүрек, катифә тышлы кеш тун, ушак, көбә кирәк»,—дип тәкъбрарлый. Ә Исмәгыйл бәкнең кара төлке тиресеннән тегелгән бүрек киясе килә...

—Эт күңеле бер сөяк, ди, боларына сораган әйберләрен җибәр, хәзергә кирәк әле алар безгә. Исмәгыйл бәккә өстәсәң дә була. Өметем зур минем аңа. Кызым, дия-дия Йосыф би тәмам акылын җуя ахрысы, алмаш хәстәрен күрергә вакыт җитте булса кирәк.

—Би ярлыгында үзенә һич нәрсә сорамаган,—диде дьяк.

—Менә-менә, элек сорана иде, димәк, чын-чынлап дошманлашырга ният итә...

Әйе, Йосыф бинең Мәскәүгә дәгъвасе зур иде. Шуның белән бергә, ярлыклар язып кына Иоанның йөрәген йомшартып булмасын да төшенә башлады. Аяк терәп сөйләшү өчен беренче чиратта көч зарур. Көчең барда гына синең белән исәпләшәләр. Теш күрсәтү хәлеңнән килми икән, бигайбә, типкегә әйләнәсең.

Йосыфның әле, Аллага шөкер, теш күрсәтерлеге бар. Йөз меңлек атлы гаскәр җыю аңа берни тормый.

Килеп туган шушы яңа вәзгыять уңаеннан ул, олы башын кече итеп, киңәш-табыш итешергә дип, туганы Исмәгыйл бәк җәйләвенә чыгып китте. Инде күптәннән энесе белән күзгә-күз карашып сөйләшәсе, аңлашасы килә иде. Ник дигәндә, соңгы вакытта Исмәгыйл үзен дорфа тота, чәнечкеле сүзләр очырта, хәтта агалары Шәехмамай бинең вафатына мөнәсәбәтле рәвештә аның үз үлеме белән үлмәвенә ишарә итеп, төрле гайбәтләр тарата.

Исмәгыйл утарында зур бәйрәм иде. Төпчек улының кырыкламасын билгеләп үтү тантанасы икән. Кабал сугалар, җыр-бию. Якын-тирә осталарын гына түгел, Казах акыннарына кадәр чакырган. Ә мине урап узды, димәк, күңелендә нөктә саклый, дип эченә салып куйды Йосыф.

—Бүген улымның эт күлмәген салдырдылар,—диде бәхетле ата хәл-әхвәл алышкач,—Нугайның асыл ханы булачак ул минем төпчегем!

Йосыф туганының соңгы җөмләсен колагына да элмәде, чөнки хан бүреген киярдәй затлы малайлар аның үзендә дә бар. Шөкер, хан бүреге әле үзендә. Һәм ул тәхетне бирәүгә дә бирергә җыенмый.

—Исем-атын тәгаенләгәнсездер инде,—дип, Йосыф йомшак кына әңгәмә җебен бәхәсле темадан читкәрәк этәрде.

Исмәгыйл, кымыздан булса кирәк, кикерегенә төенде.

—Ап-ап-ап-тчи...

—Йәрхәмдиһаллаһ!—дип битен сыпырып куйды Йосыф.

—Исеме дөньяда бер,—диде Исмәгыйл төчкеренеп туйганнан соң.

—Кем атлы инде ул дала каһарманыбыз?

—Урус!

Йосыф аптырап калды.

—Урус?

—Әйе, Урус, олуг кенәз Иоанн галиҗәнаплары хөрмәтенә куштырдым.

Йосыфның кәефе тәмам бозылды. Исмәгыйл исә аның мәсләген төшенеп алуга үзе һөҗүмгә күчте.

—Юкны бушка әйләндереп йөрүең икән әле,—диде мыскыллырак кыяфәттә,—сеңлебезне мин Шәехгали ханның никахлы бичәсе дип беләм, мөхтәрәм ханбикә. Барыбыз да шуны теләдек ич, син үзең дә ул никахны хуп күрдең. Печтәннәнүеңне һич аңламыйм. Ни теләдек, шуны алдык. Рәхмәт Иванга, мең яшәсен!

Хак, Йосыф Сөенбикәнең Шәехгалигә ярәшелүен тели иде. Кызы моңа

үзе дә каршы түгел иде. Ирекле Казан ханлыгының ирекле ханбикәсе сыйфатында! Бүгенгесендә Мәскәү токтыны. Көчләп кияүгә бирелгән токтын. Ә токтын азат ителергә тиеш!

Исмәгыйлнең үз мәнфәгатьләре. Әнә, нәрсә ди бит: «Синең сәүдәгәрләрең Бохарага, минекеләр Мәскәүгә йөри. Әгәр дә мин Мәскәү илә орышсам, ул чагында ялангач калырга туры киләчәк»,—ди.

Йосыф Касай мирзадан да яклау тапмады, «Мин орышка бара алмыйм»,—дип аңлашудан да баш тартты.

Ул вакытта туганнары, уллары, һәм дә барча дәрәҗәле Нугай морзалары Иоанга Казанны тар-мар итүе унаеннан тәбрикләү ярлыклары җибәргәннәр иде инде. Йосыф бер ялгызы калды. Шулай да Мәскәүне тезләндерү уеннан кире кайтмады. Башкасы үзеннән-үзе хәл ителәчәк. Исмәгыйл дә, уллары да, морзалар да аның табанын ялаячак әле.

1553 елның сентябрь урталарында Йосыф би йөз меңгә якын атлы гаскәрен Мәскәү тарафына кузгатты. Бу ишле төмән белән җитәкчелек итү өчен, билгеле, хәрби әзерлек һәм гаскәри тәҗрибә зарур. Йосыф би исә бервакытта да җиһангир дәрәҗәсендә орышларга йөрмәде. Ул вазифаны уллары, туганнары башкара торган иде. Алар исә баш тартты.

Хәл бигрәк тә үз җәйләүләрен үткәннән соң авырлашты.

—Безнең иравыл[10]* йөзлеккә урыс черчеты[11] һөҗүм иткән, ике генә атчабар котылып калган,—дип, сәргаскәр беркөнне күңелсез хәбәр җиткерде.

—Монда нинди урыс булсын?—диде Йосыф ачу белән.

Сәргаскәр, ничарадан бичара гына булса да, хәлне төшенеп алган иде инде.

—Урысның хәзер аяк басмаган җире юк,—диде.

Тора-бара мондый урын бәрелешләр шактый ешайды. Һөҗүмчеләр һич көтмәгәндә җир астыннан калкып чыккандай капылт кына пәйда булалар да, канлы гамәлләрен кылып, шундук юкка да чыгалар. Шулай да бермәлне икесен эләктерделәр. Яралары комачаулады булса кирәк. Ә алар, гөнаһ шомлыгына, урыс киеменә төренгән нугай юлбасарлары булып чыкты. Куенга иләнгән еланнар. Бөтен серне алдан белеп торганнар, шуңа күрә тоттырмаганнар да.

—Сез ничек үз патшагызга кул күтәрергә җөрьәт иттегез?—дип тузынды Йосыф,—сез минем кавемем ләбаса!

—Патшабыз Исмәгыйл бәк,—диде арадан кыюрагы,—безгә аның сүзе генә сүз.

Ачуыннан Йосыфның йөзенә яшелле-зәңгәрле тимгелләр бәреп чыкты.

—Бу хыянәтчеләрне ат койрыгына тагып, далага җибәрегез!—дип кычкырды,—хәзер үк!

Һөҗүмнәр барыбер тукталмады. Бер яктан—урыслар, икенче яктан—исмәгыйлнекеләр. Бу инде бәкнең гадәти аяк чалуы гына түгел, чеп-чи дошманлыгы иде.

—Би галиҗәнапләре, без бер-ике атна эчендә бөтенләй гаскәрсез калачакбыз,—дип кисәтте сәргаскәр,—күреп торасың, яуыбыз эреп аккандай ага, ташлап китүчеләр дә бермә-бер арта.

—Кире борылырга дисеңме әллә?

—Шулай хәерлерәк булыр, һәрхәлдә, мин үз өстемнән җаваплылыкны төшерәм.

[10] Иравыл—алдан баручы.
[11] Черчет—дошман явы.

Йосыфның бәхәсләшергә дә, даулашырга да чамасы калмаган иде.

—Кызым, җаның изаланмасын, кара гүр тартып алганчыга кадәр мин синең өчен тартышудан туктамаячакмын,—дип үз-үзенә сүз бирде,—бәхет кошыңны кайтарачакбыз әле. Кайтарачакбыз!

***

Мәскәүдән Шәехгалигә түбәндәге эчтәлекле ярлык озатылды. «Барча Русьнең падишаһысы һәм олуг кенәзе булган Иван Васильевичтан туганыбыз Шәехгали ханга: Исмәгыйл, Касай, Юныс мирзалар безгә язу язганнар. Сез, туганыбыз, безнең кушуыбыз буенча, Сөенбикәнең борынын кискән, аңа төрлечә зур сыйсызлыклар кылып, аны үтергәнчегә кадәр кыйнаган, дип Йосыф бәккә сүз булды дигәннәр. Шуның өчен Йосыф бәк безгә ачулана, аннан илчеләр һәм сатучылар килми... Син аңа ярлык җибәр әле. Ярлыгыңның күчермәсен без дә күрик. Без Йосыф бәккә үзебездән ярлык җибәрдек. Кызын ничек багышлап, ничек саклаганыбызны, нинди зур сыйлар илә сыйлап сиңа биргәнлегебезне, шулай ук торынын үзебезнең углыбыз урынында тотуыбызны мин аңа яздым. Менә шуларның барысы хакында мин аңа язып, ул эшләрне эшләвем аның өчен булды, дидем. Киләчәккә Йосыф турында син туганымның уе ничек? Ярлыкны сиңа илтүче чапкын илә ул хакта миңа язсаң иде.»

Йосыф бинең киләчәгенә кагылышлы ишарә белән Нугайдагы урыс илчесе Петр Тургиневка да хат килеп төшкән иде инде. Олуг кенәзнең нияте, ачыктан-ачык тәгаенләмәсә дә, хатының һәр юлыннан сизелеп тора иде. Би, чыннан да, Мәскәү өчен сызлаган тешкә әверелде. Ул авыру тештән фәкать суырып ташлап кына котылырга мөмкин. Кызганыч, Йосыф би черек теш түгел, вәкаләтле хаким. Кануни тәхет иясе. Абруйлы зат. Ләкин митрополит Макарий әйтмешли, Тәңребез бу фани дөньяга Кешене хуҗа иткән. Кеше дигәнең исә үз мәсләгендә теләсә-нинди гөнаһ гамәлләр кыларга да сәләтле.

Тургиневның башында берсеннән-берсе хәтәррәк планнар туды. Әйтик, Нугайны яулап алу мәсьәләне тулысынча хәл итәргә юл ачар иде. Әмма әлегә тамакта Казан төер булып утыра. Иң әүвәл анда чын-чынлап ныгырга кирәк. Моңа вакыт зарур. Аннан соң әле чиратта Әстерхан тора...

Шушы мәшәкатьле вә борчулы көннәрдә Йосыфны энесе Исмәгыйл бәк тамаша кылырга чакырды. Ул төрледән-төрле бәйрәмнәр үткәрергә һәвәс иде. Юк сәбәпне бар итеп, әллә нинди бәйгеләр уйлап чыгара. Көнкүрештә бер тиен өчен кара тиргә төшеп сатулашучы «Саран Исмай», ни гаҗәп, уен чутында юмарт байга әверелә дә куя. Исмәгыйл әле дә кырык адым ераклыкта утыртылган баганага янчык элеп куйды да: «Кемнең дә кемнең угы шушы янчыкка тишек ясый, эчендәге алтын аныкы»,—диде.

Ярышның үз кагыйдәләре. Мәйданга ун мәргән чыкты. Өсләрендә ак җилән, билдә—кызыл пута. Чабулар шул путага кыстырып куелган. Садакта нибары бер ук. Шуннан артык бирелми. Берсенең дә угы янчыкны тишмәсә, бәйге сызыгына башкалар чакырыла. Әлегә мондый хәлнең булганы юк икән. Чөнки утарга даланың иң туры куллы мәргәннәре җыелган. Бу юлы да ярыш озак бармады. Өченче булып чыгыш ясаучы какча гәүдәле озын егетнең угы күн янчыкка еру салды.

Кешеләр дәррәү купты. Ә Исмәгыйл алтын иясенә үз куллары белән бер таш чүлмәк кымыз тоттырды. Җинүче аны ирен читләреннән агыза-агыза сол белән генә озаклап эчте.

—Бүгеннән сине йөзлекбаш итеп билгелим, яугирларыңны да төз атарга өйрәт,—дип шатландырды бәк мәргәнне.

Бу әле тамашаның башы гына иде. Йодрык сугышын нугайлар, ат чабышыннан кала, барча көч сынашулардан да өстенрәк саный.

Менә мәйданга былтыр җиңү яулаган каһарман чыгып басты. Төптән юан, нык бәдәнле яшь адәм. Табактай йомры башы гәүдәсенә турыдан-туры тоташкан, муены беленми дә. Дүрт-биш адым ара калдырып, янә ун алпамша тезелеште. Асау айгыр кебек таптанышып торалар. Күзләрен кан баскан, йодрыклар төйнәлгән, һәрберсенең өстен чыгасы килә, билгеле.

Каһарман һәр дәгъваче белән чиратлашып көч сынашырга тиеш. Биреләрдә икән, тагын—батыр!

Йосыф узган елгы батырны таныды, ул аның җәйләвеннән иде. Үзенә дә ниндидер илаһи күтәренкелек өстәлгәндәй булды, җилкәләре киңәеп, сулышлары җинеләеп китте. «Әйдә, туганым, арт сабакларын укыт әле Исмәгыйл иярченнәренең»,—дип көч биреп утырды, җаны-тәне белән җинеп чыгуын теләде. Әлегә борчылыр нәрсә юк. Батыр беренче дәгъваче янында озак юанмады, икенчесен дә җинелдән хәл итте. Өченчесе, әнә, сыртын кабартып маташкан була, мокыт. Түмәрдәй адәм, ине-буе бер. Йодрыгы да каты булса кирәк, шәп суккалый, көндәше чайкалып-чайкалып китә.

—Касыгына сыла, касыгына,—дип түземсезләнеп кычкырды Йосыф.

Шуны гына көткән диярсең, батыр, чыннан да шәпләп кенә түмәрнең корсак астына тартты. Шуннан соң мантымады да инде.

—Бәрәкалла!

Йосыф учларын угалап алды. Ләкин шатлыгы озакка бармады, дүртенче дәгъваче, һич көтмәгәндә, батырны бөтәрләп ыргытты. Кем диген әле, сакал-мыегы да юньле-башлы чыгарга өлгермәгән бер егет кәмәше.

Тамашачылар яңа батырны хуплап гөж килде.

Йосыфның гаме төкәнде. Аны инде бернәрсә дә кызыксындырмый иде, тамаша да, кешеләр дә. Сакчыларына ым какты да, шау-шудан файдаланып, беркемгә берни әйтмичә шыпан-шыпан гына утарны ташлап чыгып китте.

Бинең юклыгын иң беренче Тургинев абайлады.

—Илбашы белән киңәш-табыш итешәсе бар иде, кызганыч, мәшәкатьләре чыккан, күрәсең,—дип сөйләнеп алды илчеләргә хас итагатьлек белән. Мәҗлес корсак гамәле илә мәшгуль иде, аңа җавап бирүче табылмады. Һи, бирәннәр, дип эченнән генә сүгенеп куйды Тургинев. Ләкин ул хаталана иде. Исмәгыйлнең колаклары уяу. Гадәттәгечә, ул хәтта Мәскәүдән нидер теләнү турында да баш ватмый, кайчан Йосыф темасы кузгалыр икән дип көтеп утыра иде. Чөнки әлеге мәсьәләнең Мәскәүне кызыксындырганын бик яхшы белә. Шуңа күрә илче аны һич тә читләтеп узмаячак. Ә аның үз гамәлләре инде кырыкмаса кырык мәртәбә уйланылган, әйтәсе сүзе әзер.

—Бинең гөрәңкәсе җинеләйгән ич инде, гуспадин, ана хәзерендә баш-аягы бер казан,—дип шаярткан атлы итте,—Мәскәүгә яу чабам дип көлкегә калуын гына күр. Җә, акыллы башлык эшеме инде бу?

Тургинев каш астыннан гына бәккә сынап карап алды.

Исмәгыйл җимне сибә генә.

—Олуг кенәздән Казанның Тау ягыннан өлеш чыгаруын сорап ярлык язган идем, һаман көтәм әле,—дип үпкәсен дә белдереп алды.

Илче исә әңгәмә җебенең очын чуалтмый гына алып бару ягында.

—Йосыф би бар ич әле монда, ул ни әйтер, аннан узып эш майтару кагыйдәгә хилафлык кылу булыр иде,—диде.

—Кысыр хәсрәт артыннан йөреп, саташып беткән инде ул, Йосыф биегез...

Тургинев тезгенен йомшартарак төште.

—Мин үзем дә изге Нугай иле тәхетендә акылы какшаган кешенең утыруын башыма сыйдыра алмыйм,—дип пышылдады бәкнең колагына.

—Нәмә, әллә...

—Тсс,—дип урта бармагын тырпайтты илче,—Шәехмамай хан да үз үлеме белән үлмәгән дисең ич...

***

Йосыф би җиңеләйгән икән, дигән гайбәт аның үзенә дә килеп иреште. Һәм бу гайбәт жиленен туганы җәйләүләре тарафыннан исүе дә аңа мәгълүм иде. Бик гарьләнде: тәмам чашты бу мокыт, үз урынына утыртырга вакыт житкәндер, мөгаен. Болай булса, башыңа менеп атланырга да күп сорамас.

Шул ук көнне Исмәгыйл утарына атчабар чыгып китте. Ул урап кайтмады. Әмма бераздан агасы катына мирза үзе килеп төште. Йосыф бик сөенде. Бәлки, акылына килгәндер. Сәер яклары бар инде аның, нишлисең, бәләкәйдән шундый иде. Сигез яшендә үк бөтен гавәмне шаккатырган малай ич ул.

Һәр елны, яз башланып үләннәр борын төртүгә, далада ат чабышлары уздырыла иде. Ата-бабадан килгән бу бәйге атна буена дәвам итә, анда барча җәйләүләрдән килгән чабышкылар катнаша. Ярышны малайлар башлап җибәрә. Билгеле, һәрберсенең беренче буласы, ил бабасы кулыннан исемле камчы аласы килә. Әлеге узышка Исмәгыйл аеруча тырышып әзерләнде, көне-төне ат өстеннән төшмәде.

Бер көн кала атларны тикшереп, утарга яптылар. Барысы да тәртиптә иде. Ярыш сызыгына басканда да ул-бу сизелмәде. Тик финишка Исмәгыйл берүзе генә килде. Авызы—колагында. Җиңүче бит, җиңүче! Ә башкалар? Аларда аның эше юк. Ул беренче, ул! Исмәгыйл!

Калган чабышкыларның яланда калганы ачыклангач, зур гауга купты. Ул атларның тояк астындагы йөрәк итләренә шырпы төрткәннәр булып чыкты. Һәм бу вәхшилекне Исмәгыйл уйлап тапкан. Җәзаны исә булышчысына бирделәр. Олы башы белән шушы яман җинаятькә юл куйган өчен адәмнең умырткасын ташка бәреп сындырдылар. Үлә алмыйча бер атна кычкырып ятты бичара.

—Вәгаләйкемәссәлам, бәк,—әйдә, түрдән уз, бик шатмын,—дип туганының сәламен кайтарды Йосыф,—табын катына чыкканчы хәбәрләшеп, эчне бушатып алыйк, ачуың килсә, борыныңны тешлә, ди, аңлашып яшәүгә ни житә?

Исмәгыйл астыртын гына бүлмәне күзәтеп чыкты. Моны агасы да сизде.

—Синең икәүдән-икәү генә каласың килә,—дип, Йосыф даирәсенә күз ымы белән генә бүлмәне бушатырга боерды.—Шикләнмичә теләсә-нинди сереңне чишә аласың хәзер, туганым.

—Бик мәгъкуль...

Исмәгыйл янә як-ягына каранып алды. Ул ничектер ачылып китә алмый иде. Шуңа күрә әңгәмәне Йосыф үзе башлап җибәрде.

—Кыр чирүе чаклы яугир белән килгәнсең икән,—диде.

—Үзең беләсең, заманалар катлауланды...

—Анысы хак, заманалар, чыннан да, катлауланды,—дип килешүен белдерде Йосыф,—менә минем турыда да синең биләмәләреңдә, зиһене чуалган икән ханнын, дигән гайбәт йөри икән. Бик рәнҗим мин сиңа, туганым...

Исмәгыйл артына типкәндәй капыл гына урыныннан купты да

Йосыфның билендәге хәнҗәрен суырып алды.

—Сак! Сак!!—дип кычкырып җибәрде Йосыф.

Ул хәнҗәрдән битәр (хәнҗәр, билгеле, дуамаллык кына!), энесенең пыялаланып тонган күзләреннән курыкты. Аларда ачу, дошманлык, күралмау, бәгырьсезлек—барысы бергә укмашып каткан иде. Камыт аякларын җәеп баскан, гәүдәсе гүя киерелгән җәя, угы ялгыш ычкынып китсә тыярмын димә.

—Юкка көчәнмә, агаем, без монда корыны бушка әйләндереп утырганда минем яугирларым сакчыларынны бәйләп ташлады инде, алар хәзер базда бака кимерә,—диде Исмәгыйл ямьсез көлемсерәү белән.

—Мин Нугай ханы, хакың юк!

—Синең сәгатең сукты инде, хан, Нугай иленә минем ише акыллы вә каты куллы хөкемдар кирәк, син аны таркатып бетердең, Рәсәйдән аердың.

Исмәгыйл хәнҗәрен болгап алды да, ике адым алга атлады. Йосыф ишеккә килеп бәрелде,—ләкин ул тыштан терәүле иде.

—Мин сине исән калдыра алмыйм, агай, яшисен яшәдең, дөнья белән бәхилләшер вакытың җитте...

—Исмәгыйл, туганым, Ходайдан курык...

Йосыфның сүзләре өзелде, аның күкрәгендә үзенең көмеш саплы хәнҗәре кадалып тора иде инде.

Йосыфны шул ук көнне җирләделәр.

—Әңгәмә вакытында бинең кисәк кенә зиһен өянәге кузгалды да, үз хәнҗәренә үзе кадалды, тотарга җитешә дә алмый калдым,—дип аңлатты Исмәгыйл агасының фаҗигале үлемен.

Аңа берәү дә ышанмады, һәм берәү дә хак дөреслекне ачарга батырчылык итмәде.

Дәүләти канун нигезендә Нугай тәхете бакыйга күчкән бинең кече ир туганына фарыз. Бу кече ир туган Исмәгыйл бәк иде.

***

Марсель вокзалга сәгать ярым алдан килде. Алтынчы вагонның тукталу урынын сорашып-белешеп, шунда сакка басты. Әйтерсең лә, сөйгән ярын каршылый. Югыйсә, ул княгиняга Үтәмешгәрәй хан белән Ходайкол бәкнең Архангел соборындагы табутларын күрсәтүне, алар турында мәгълүмат җыюны оештырырга гына ризалашкан иде. Хезмәте түләүле. Татли юл чыгымнарына кадәр үз җилкәсенә алды. Ә йөрәге бер сәбәпсез нигәдер кыбырсыпмы-кыбырсый.

Ниһаять, Әстерхан поезды Мәскәү вокзалына борын төртте. Каршы алучылар төркеме берара умарта күчедәй дулкынланып алды да, перрон буйлап сибелде. Марсель генә кузгалмады. Чөнки вагон туктыйсы урынны сантиметрына кадәр төгәл билгеләгән иде. Һәм вагон нәкъ шул ноктада тукталып та калды. Пассажирлар, әнә, коела да башлады. Татли гына күренми. Телеграмма текстын буташтырганнар, ахры, һич ышаныч юк бу почтага, дип тешләрен кысты Марсель. Нишләргә? Аңа Әстерхан булышчыларының адреслары да, исемнәре дә билгеле түгел иде. Иртәгәсе поездны көтәргә кала, күрәсең.

—Мьсё, мьсё Марсель, мьсё...

Марсель кеше агымын кирегә ера-ера таныш тавыш ишетелгән якка ыргылды.

—Мин алтынчы вагонны сагаладым.—диде Марсель,—гафу үтенәм...

—Ә мин тугызынчы вагонда идем,—диде мадам берни булмагандай,—аһ, нинди матур букет...

Татли үрелеп, Марсельне үбеп алды, ә ул аның кулларын эзләп тапты...

—Мьсё, мин душта юынып, үземне аз-маз рәткә китергәләгәнче ике-өч сәгать вакыт үтәр әле,—диде Татли кунакханәгә урнашкач,—сез ресторанда урын ала торыгыз...

Марсель бу сүзләрдән эреп ага язды. Шулай да шатлыгын эченнән чыгармады, киресенчә:

—Минем сезгә комачау тудырасым килми, княгиня, иртәгәсе очрашуларга да ныклабрак хәзерләнергә кирәк бит әле,—дип бәясен күтәрмәк итте.

—Мьсё, хәзер үк бу сүзләрегезне кире алыгыз,—диде Татли,—югыйсә, үпкәлим.

—Кичерегез, зинһар, мин бүген сезнең колыгыз!

Татли ресторанга әйткән вакытыннан бер сәгатькә соңарыбрак төште. Көтү газаплары шундук онытылды. Аны танырлык түгел иде. Менә нинди була икән ул чын княгиня! Баксаң, кинофильмнардагы ялган образлар курчак кына икән ич. Имитация. Сыланып торган кара күлмәге ифрат та килешле иде. Бер ачык җире юк, муенына кадәр каплаулы. Әмма аңа карап һични югалтмый, киресенчә, килеш-сынының һәр уемы, һәр сызыгы беленеп, ымсындырып тора.

Ачыклык мәсьәләсендә шулай да ашыккан икән Марсель. Башта үз күзләренә үзе ышанмады: княгиня күлмәгенең арка өлеше бөтендәй юк иде, шәп-шәрә тән. Ә нинди тән! Шикәрдәй ап-ак, ефәктәй ялтыравыклы, кош каурыедай шома. Вальс биегәндә аның куллары ирексездән княгиняның аркасына ятты. Лев Толстойның мәгълүм романындагы Анна белән Вронскийның тәүге тапкыр якыннан очрашуын сурәтләгән эпизод күз алдына килеп басты. Ялгыш кына Вронскийның кулы Аннага орынып китә. Кенәз өенә кайткач, әле бик озак кулының шул урынын үбә-үбә ләззәт кичерә. Мин үзем дә шул хәлгә калып барам, ахры, дип уйлап куйды Марсель.

Аны тәшвишле четрекле хәлдән телефон челтерәве коткарды. Татли телефонын бер генә секундка да кулыннан төшерми иде.

—Гафу үтендем, мьсё, ирем шалтырата,—дип, княгиня телефонын колагына терәде. Марсель әдәп саклап, читкәрәк китеп басты.

—Виктордан күп сәлам, мьсё,—диде Татли сөйләшүен тәмамлаганнан соң.

—Рәхмәт, тик без таныш түгел...

—Мин аңа үзем әйттем,—диде Татли Марсельнең аптыраулы халәтен күреп,—мине бик мәртәбәле бер татар галиме озатып йөри, дидем, борчылмаска мөмкинсең, бик оялчан, борылып күз атканы да юк, дидем.

—Сез инде бигрәк...

—Җә, әллә дөрес түгелме?

Татли хәйләкәр генә аңа карап алды да, урыныннан торып басты.

—Мин арыдым, зинһар өчен мине озатып куегыз,—диде.

Бүлмәдә княгиня Марсельдән күлмәгенең каптырмаларын ычкындырырга булышуын үтенде.

Мондый исерткеч ләззәтле якынлыктан Марсельнең башы әйләнде. Куллары калтырана, каптырмалар да буйсынырга теләми, каһәр...

—Мьсё, талчыктырмагыз мине, мьсё...

—Княгиня... каптырмаларның һич җаен таба алмыйм...

Татли бер селтәнүдә күлмәгеннән арынды да, матур ак куллары белән Марсельнең муенына сарылды.

—Француженкалар болай озак вакыт кавалерсыз тора алмый, мьсё,—дип пышылдады,—ә сез шуны һаман аңламыйсыз...

## ӨЧЕНЧЕ КЫЙССА

### Үтәмешгәрәй хан

—Йа, Раббым! Ошбу догаларымны кабул кылсана, минем йөрәк бәгъремне—улыкаемны үз янына алсана. Бу затлы нәсел кыйпылчыгы мондый ла хурлау-кимсетүләргә һич кенә дә лаек түгел ләбаса. Әсирлек белән килешкән хәлләрдә дә, ата-бабаларыбыздан килгән саф вә пакь динебез—Мөхәммәд өммәтеннән аерылудан үлемне мин мең өлеш өстенрәк күрәм. Раббым, үтенечемне читкә типмә, өз ул баланың гомерен...

Сөенбикә күз яшьләренә буыла-буыла Аллаһыга теләкләр күндергән бу минутта Үтәмешгәрәй Амвросий атакай белән Архирейлар бакчасында хозурланып йөри иде. Тирә-як илаһи яшеллеккә төренгән. Колакларны иркәләп, кошлар сайраша. Пумала койрыкларын җилфердәткәләп ботактан-ботакка тиеннәр сикергәли. Күктә нурлы кояш балкый. Сөенеп туймаслык көн.

—Туганым, бу матурлыкны Ходай бар иткән, моның өчен без, адәмнәр, Тәңрегә бик тә рәхмәтле,—дип, атакай ихласлык белән Үтәмешгәрәйнең какча аркасыннан сыйпаштырып алды.

Дини саны атакай мөрәҗәгатенә лаек итсә дә, Амвросий үзе тулышып кына килә иде әле, сакал-мыек урынында да бала йоннары гына кабарып тора. Гәүдәгә килешле: озын, төз. Аяк йөзенә төшеп торган кара чикмәне аны тагын да күркәмрәк күрсәтә иде. Ә теле? Бал да май. Тәмләп, җентекләп, җиренә җиткереп сөйли, авызына гына карап торасың.

—Адәмнәр арасында яманнары да күп, туганым,—дип дәвамлады атакай,—кызганыч, минем үземнең кавемем дә шул төркемгә керә иде. Аллага шөкер, митрополит Макарий мине туры юлга кертте, изге православие храмының ишекләрен ачты. Мең-мең рәхмәт бу изге җанга, ул минем коткаручым. Хәзер...

Атакайның җырдай тигез агышлы нотыгы өзелеп китте. Үтәмешгәрәй ни булды икән дип башын күтәрсә, алар янына болан колыны килеп туктаган икән. Муенын сузган, каен яфракларыдай түгәрәк күзләре мөлдерәмә...

—Ашарга сорый, чибәркәй, мин кесәмдә ипи телеме йөртәм, мә, сыйла үзен,—диде атакай,—саваплы булырсың.

Колын кулдан ашарга өйрәнгән иде инде, ризыкны бик тиз ялмап алды.

—Менә рәхмәт, туганым, чын христианнарча игелекле гамәл кылдың,—дип мактады атакай.—Үзеңә дә ошагандыр әле, шулаймы?

—Ошады, атакай,—диде Үтәмешгәрәй,—миңа синең яныңда бик тә рәхәт, сүзләрең дә аңлаешлы.

—Яхшылыгың өчен Ходай үзеңә дә хозурлыклар бирсен,—диде Амвросий,—сизәсеңме, сиңа гаделлек сыйфатлары инә башлады бит. Православие һәрвакыт гаделлекне алга сөрә. Тиздән синең үзеңә дә изге чиркәү ишекләрен ачып керү насыйп булыр. Син моңа әзер инде. Дөрес әйтәмме, туганым?

—Әйе, атакай, мин әзер...

Амвросий малайга текәлеп карап торды. Сүзләре хак-дөрес булса да төшенке халәттә иде әле Үтәмеш. Димәк, аны нидер борчый.

—Туганым, күрәм күңелеңә оялаган шайтани вәсвәсә әле һаман сиңа иркенләп сулыш алырга ирек бирми, атакаең белән уртаклаш, ни сәбәпле тәшвишләнәсең, яшермә, җиңеләеп китәрсең,—диде Амвросий әчке бер йомшак аваз белән.

Үтәмешгәрәйнең тулы иреннәре сизелер-сизелмәс кенә дерелдәп алды, тамагына кайнар төен килеп тыгылды.

Ул күзләренә бәреп чыккан яшен күрсәтергә теләмичә, башын читкә борды.

—Әйдә, менә бу эскәмиягә утырыйк әле, туганым, иркенләп аңлашыйк,—дип, Амвросий урын тәкъдим итте.

Берара тын гына бер-берсенә терәлешеп утырдылар. Атакай малайның кулларын үзенең какча учына йомды.

Амвросий малайны ашыктырмады. Бераз тынычлангач ул үзе күңелен бушатачак. Турылыклы, вәгъдәле җан, акыл иясе. Күпне күргән шул бичара. Ә алда иң зур имтихан. Мондый кискен үзгәреш җинел генә бирелми. Аның үзен бала вакытта ук чукындырганнар. Атасы—нугай мирзасы Белек бәк олуг кенәзгә үз теләге белән килеп сыенган. Гаиләсе белән православие динен кабул иткән.

—Атакай, анаем Сөенбикә ханбикә дә христиан динен кабул итсә, без бергә-бергә яшәр идек,—диде Үтәмешгәрәй,—мин анаемны бик тә сагынам...

Амвросий малайны кочагына кертте дә: «Оялма, җыла, туганым, җыла, күз яшьләре күңелгә җиңеллек китерә ул»,—диде. Ә үзе, корты тирәндә икән, чукындыруны тизләтү зарур, дигән карарга килде.

Мәскәүгә китерелгәннән соң, Үтәмешгәрәйне анасы катына кертмәделәр. Югары даирә өчен бу табигый хәл. Чөнки бояр, кенәз балалары башлыча ата-анадан аерым тәрбияләнә.

Сөенбикәгә ана шатлыгы шактый соң килде. Утыз яшьтә инде мөселман хатыннары оныкларын сөя. Бәлкем шуңадыр күкрәге шешеп җәфаланды. Ә аның бердәнбер газизен үзе имезеп үстерәсе килә иде. Дәваланып та карады, өшкертте дә, догаларын да калдырмады, хәер-сәдака өләшүен әйтеп тә торасы юк. Ләкин файдасы гына тимәде. Ә сөт анасын сайлау үзе бер җәфалы гамәл иде. Ул бу эшне берәүгә дә ышанып тапшырмады, үзе шөгыльләнде. Иң әүвәл сарайга иң сәламәт, иң чиста яшь аналарны чакыртып китертте. Билгеле, алар нәсел-нәсәпләре ягыннан да тел-теш тидермәле түгел иде. Сөенбикә һәрберсен энә күзеннән үткәргәндәй тикшереп чыкты. Сорау арты сорау: кайда туып-үстең, нинди хастәләр белән чирләдең, мунчада еш юынасыңмы, кайсы ризыкларны хуп күрәсең, ничә бала тудырдың, арада үлүчеләр бармы?

Болары әле тәүге танышу, мәгълүмат җыю гына иде. Иң кызыксындырганы—сөт! Сөт тәмле дә, туклыклы да булырга тиеш. Хан улы өчен ич ул сөт! Шуңа күрә аналарның сөтләрен саудырып үзе эчеп карады.

Шул рәвешле Рәхимә исемле бер яшь морза хатыны сайлап алынды. Аның белән ул-бу була калса дип, тагын өч дәрәҗәле ана исемлеккә кертелде. Калганнар яраксызга чыгарылды.

Имезүчесен күрүгә Үтәмешгәрәй көйсезләнергә тотынды, елый, тибенә.

—Улым-бәгърemнең карыны ачкан икән бит, карагыз, ничек түземсезләнә,—диде Сөенбикә,—тизрәк ач күкрәгеңне, наным, күрмисеңмени, хан ничек өзгәләнә.

Хан исә имидән баш тартты, каптырулары була, былт итеп төртеп чыгаруы була. Азапландылар.

—Ханбикә, баланы интектермәек әле, бүтән әнкәләргә дә төртеп караек,— диде өлкән абыстай,—җаны тартмаса, көчләүнең фәтвәсе юк аның.

Үтәмеш күрше бүлмәдә чират көтеп утыручы әлеге дәрәҗәле өч әнине дә беренче тәкъдимдә үк кире какты.

—Инде нишлибез!—диде еларга житешкән Сөенбикә,—башым катты, ни уйларга да белмим.

—Алай бетерешмә әле, ханбикә,—диде өлкән абыстай сабыр гына,—теге яраксызга чыгарылган әнкәләрне дә чакырып китерәек, хан берәрсен үз итмәсме?

Чыннан да, Үтәмешгәрәй пешкән алмадай йомры гәүдәле, алсу йөзле, Сөенбикә нәсел мөнәсәбәтендә яраксызга чыгарган биш бала анасының имиен каптыруга, чуп-чуп китереп имәргә дә тотынды.

Гөлсинә атлы бу сәүдәгәр бичәсе ханны өч яшькә кадәр имезде.

Сафагәрәй дә улы өчен җан атып тора иде. Башкалары инде буй җиткергән, барысы да Кырымда, туган җирләрендә яши. Төпчек бала һәрвакыт татлы була бит инде ул.

Атасы үлгәндә Үтәмешгәрәй имидән аерылмаган иде әле. Ул аны хәтерләми дә. Анасының сөйләвенә караганда, батырларның батыры, көчлеләрнең көчлесе: ат дагасын бер омтылышта аерган, кырык адымнан чебен күзенә ук аткан, бер яшьлек тайның астына кереп, аны күккә чөйгән, кыскасы, дошманнарын кан калтыратып торган азамат ир-егет булган ул.

Анасы янә атаеның төз гәүдәле, күркәм йөзле, Йосыф пәйгамбәрдәй чибәр булуын бик еш искә ала иде.

Соңгыларына малайның артык исе китми. Ник дисәк, угланны чибәрлек түгел, батырлык бизи. Остазы Ибраһим бәк адым саен шушы гыйбарәне кабатлый. Ә бер әңгәмә вакытында: «Атаем батыр каһарман булгач, нишләп Газраилга бирешкән соң ул?»—дип анасын шаккаттырган иде Үтәмешгәрәй.

Сөенбикәнең авызы йомылды.

—Яратуың миңа күбрәк тисенгә, әйеме, анаем?—дип малай үзе ярдәмгә килде.

—Нигә алай дисең, улым?

—Атаем исән булса, яратуыңны икегә бүләргә туры килер иде.

Сөенбикә улын күкрәгенә кысты. Иреннәре исә: «Сине тәхеткә утырту өчен»,—дип пышылдады.

Үтәмешгәрәйнең хан бүреге киюе кануни булса да, Юлбарыс бәк тасвирлаганча, очраклы рәвештә тигән бәхет кенә иде. Тарткалашның төп сәбәбе һич тә ханның яшенә мөнәсәбәтле түгел иде. Сабый ханнар, сабый патшалар, сабый корольләр булган, бар, булачак та. Урыс патшасы Иоанн үзе дә тәхеткә бала чакта утырды. Хикмәт кемнең сабый хаким исеменнән идарә итүендә. Кайчандар Нугайдан каза күргән даирә Сөенбикәне өнәми иде. Шуңа күрә бәхәс шактый кискен булды.

—Борчылмагыз, җәмәгать, ошбу җәһәттән ханлыгыбызның тәҗрибәсе бар,—дип тынычландырырга тырышты аларны Корылтай башлыгы Габдулла бәк,—хәтерегездәдер, Гәүһәршад тәнәкә васый сыйфатында Җангали ханның вазифаларын менә дигән итеп башкарды.

—Гәүһәршад тәнәкә башка чут,—диде Хафиз морза,—ул мәшһүр Олуг Мөхәммәд хан каныннан иде, урыны оҗмахта булсын, ә бу чикерткә, Сөенбикә ханбикәне әйтүем, мангыт ыруыннан. Мангыт кулына калмабызмы, менә нәмәстәкәй ашый безнең җанны, фаразан.

Морза түбәтәен салып, зур кулъяулыгы белән чәчсез башын корытып алды.

—Тәртәгә тибә башласа, яшь ханга икенче васый билгелибез, яхут шуның белән вәс...

Корылтайбаш җөмләсен төгәлли алмады, төчкереп җибәрде.

—Әп-п-те-е-чи!

Төчкерүне даирә яхшыга юрады.

—Йәрхәмдиһалла, бәк, сүзең хак икән.

Корылтай вәгъдәсендә торды. Сөенбикәне васыйлыктан ваз кичертү

генәме, хан белән бергә Мәскәүгә тотып бирде.

Тоткынлыкта Ана белән Бала тагын да ныграк якынлашты. Кайгы аларны бербөтен итте. Көрешкән араларда икәүдән-икәү генә калырга омтылалар иде. Үтәмешгәрәй әнисенең кочагына сыешып бетә. Иң бәхетле мизгелләре иде бу.

Мең дә биш йөз илле икенче ел, май аеның унжиденче көнендәге очрашу Сөенбикәнең күңелендә аеруча тирән эз калдырды. Бик матур язгы көн иде. Алмагачлар шау чәчәктә. Тирә-як хуш ис белән тулган. Шуңа ярашлы рәвештә күңелләре дә күтәренке иде. Ходайның рәхмәте киң, бәлкем әле аларның күгенә дә кояш иңәр. Олуг кенәз мәрхәмәтенә килеп, аларны Нугайга, туганнары иленә озатыр. «Йосыф би Иоанн патшага ярлык арты ярлык юллый, сезне әсирлектән коткару өчен җан атып тырыша»,—дип, Нугай илчесе әле шушы көннәрдә генә Сөенбикәнең йөрәгенә сары май тамызган иде.

Үтәмешгәрәй анасының чәчләреннән сыйпый, кулларын үбә.

—Атаең шикелле эре сөякле булып үсәсең, улым, инде алдыма да сыймыйсың,—диде Сөенбикә.

—Зур үскәч, мин сине ак атка атландырып, Казаныбызга алып кайтырмын, анаем,—диде Үтәмешгәрәй,—анда үзебезчә генә сөйләшер идек.

—Рәхмәт, улым, син Казан тәхетенең хак варисы...

—Әллә елыйсың инде,—диде Үтәмешгәрәй,—борчылма, анаем, мин тиз үсәм.

—Күземә керфегем керде ахры, кырыпмы-кыра...

—Анаем, минем синең белән бергә яшисем килә, мин сине бик яратам,—дип Үтәмешгәрәй анасына тагын да елышарак төште.

—Хөрмәтле җәнабе гали, хан каты куллы, кырыс табигатьле була, анае итәгенә тагылып йөрми,—дип инде Сөенбикә улын юатты,—үзең Казанга кайту турында хыялланасың.

Бүлмәгә ясавыл керде. Ул:

—Ханның көрешү вакыты чыкты, аны мөгаллиме көтә,—дип белдерде.

—Анаем...

Үтәмешгәрәй әнисенең кулларына ябышты.

—Анаем...

—Улым, сабырлыгыңны җуйма, сабыр иткән генә морадына җиткән, һәрвакыт Казаныңны исеңдә тот.

—Анаем, бирмә мине бу чит адәмнәргә, бирмә!

Анасының кулыннан аерып, малайны бүлмәдән алып чыгып киттеләр.

Әлеге авыр хушлашудан соң шактый вакыт узды. Бу чор эчендә Үтәмешгәрәйнең тормышында кискен үзгәрешләр булды. Хәзер аңа фәкать урыс гасәбәләре генә хезмәт күрсәтә. Алар барысы да карабүрекләр, көн-төн православие кануннарын тукыйлар. Үз телен ишетмәгәнгә дә бишбылтыр.

Анае янында булса, барысына да түзәр иде әле. Ә ул килми дә килми, онытты ахры. Юк, юк, Аллам сакласын, аның анае дөньяда бер. Матур да, ягымлы да, йомшак та. Улын бик-бик ярата. Яратмаса: «Үтәшем, Мамышгәрәем»,—дип иркәләп сөяр идемени? Төшенә дә кермәс иде. Бүген дә керде. Бик сәер төш керде аңа бүген.

—Анаем, син үзеңә бөтенләй охшамагансың, кем кыерсытты, әйт,—диде ул батыраеп,—мин аны...

—Улым, миңа хәзер ике дөнья—бер кәнди,—диде Сөенбикә төксе генә.

—Минем янга да килмисең...

—Менә килдем бит инде...

—Бу төш кенә ич, анаем!

—Төш ни, өн ни...

—Мин синең Үтәмешең түгелмени инде, анаем!

Сөенбикә улының бу йөрәк өзгеч сагышлы тавышын ишетмәде, күктә нindидер каракош пәйда булды. Анасы куркынып читкә тайпылды. Тик соң иде инде, каракош таш сыман җиргә атылды...

—Бәхил бул, улым, Үтәшем...

Анасы әлеге сүзләрне әйттеме, әйтмәдеме, Үтәмешгәрәй ачык кына хәтерләми, бу вакытта уянган иде инде ул. Төш юрау да бала шөгыле түгел, шулай да әлеге төш анын юксыну, сагыну хисенә яңа дулкын өстәде. Уйлары гел анае турында гына: нигә хәсрәтле иде ул, нинди каракош сагалый иде аны? Шуңа күрә атакайның вәгазьләре дә башында калмый.

...Амвросий алдында кичекмәстән малайның анасына булган шушы илаһи хис кыясын чатнату, аннан соң чәлпәрәмә китереп ваклау, тузанга әйләндерү, җилгә очыру бурычы тора. Митрополит каршысына басканда малайның җаны да, тәне дә элекке богаулардан азат булырга тиеш.

—Сизеп торам, синең анаеңны күрәсең килә, шулаймы?—дип, шәкертенең башыннан сыйпап алды ул,—белсәң икән, туганым, теләгеңне мин чын күңелемнән хуплыйм.

—Әйе, атакай, анаемны бик тә күрәсем килә,—диде Үтәмешгәрәй,—мин аны бик юксынам.

Амвросий учларын-учка йомарлап күкрәгенә куйды да күзләрен күккә терәп, догага талды.

—Ходайдан син туганыма түземлек вә сабырлык бирүен үтенеп ялвардым,—диде ул гыйбадәтен тәмамлагач,—ишетте, туганым, ишетте...

—Рәхмәт, атакай, төшемдә анаем да сабыр булырга өндәгән иде,—диде Үтәмешгәрәй,—мин сине бик хөрмәт итәм.

Бу сүзләр хак иде. Амвросий бервакытта да тавышын күтәрми, кимсетми, җаена гына килеп тора. Игътибар белән тыңлый, хаталарын түземлек белән төзәтә. Әле дә шифалы кулларын Үтәмешгәрәйнең җилкәсенә салды, аңа ничектер җиңел, рәхәт булып китте.

—Туганым,—диде Амвросий ана туп-туры карап,—үзең дә шаһит, әле генә Тәңредән фатиха алдым, күңелсез хәбәр җиткереп күрексез буласым килмәсә дә, мәҗбүрмен...

Ул тирәннән сулыш алып, тынып калды.

—Тыңлыйм, атакай,—диде Үтәмешгәрәй,—Тәнре фатихасы—изге фатиха.

—Синең анаең Сөенбикә ханбикә белән очрашып күрешү мөмкинлеген бетте, туганым...

Үтәмешгәрәй башта бу сүзләрнең асылына төшенми торды, ә икенче мизгелдә йөрәге сызланудан бөгелеп төште.

—Ничек бетте, атакай?

—Туганым, ханбикә үзе очрашуны теләми,—диде Амвросий,—Ходай сабырлыгыңнан аермасын...

Үтәмешгәрәй өзгәләнеп кычкырып җибәрде:

—Бу дөрес түгел, атакай!

—Сөенбикә ханбикә Касыйм ханы Шаехгалигә кияүгә чыкты, шуңа күрә син теләгәнчә христиан динен дә кабул итә алмый,—дип тыныч кына аңлатма бирде Амвросий,—ул синнән ваз кичте. Бер яманның бер яхшысы, ди, алай бик бетерешмә, олуг кенәз сине тулысы белән үз канаты астына ала...

—Атакай, син ялган сөйлисең, анаем мине ташламас, ул мине ярата... Мин дә аны яратам... Ялган...

Үтәмешгәрәй җиргә ятып, үлән тамырларын тырный-тырный үкереп еларга тотынды. Аннан соң кисәк кенә сикереп торды да бакчаның аргы очына таба йөгерде. Ерак китә алмады, карабүрекләр юлына аркылы төште. Аларга да тиз генә бирешмәде әле, яралы арысландай үзләренә ташланды: тешләде, тибенде, сукты, кычкырды...

***

Марсель өчен ак җәймәле көн туды. Аяклары җиргә дә тими, очып кына йөри. Шулай булмыйча, нинди ләззәтле төн насыйп итте бит аңа Ходай. Ә алда әле күпме бәхетле мизгелләр көтә.

Шундый ашкынулы, дәртле хисләр шаукымында ул Татлиның ишеген шакыды.

—Букетыгызны вазага куегыз, мин хәзер җитешәм,—диде княгиня битараф бер ваемсызлык белән.

Марсельнең кайнар хисләре бозга әйләнде. Кичәге гүзәлкәйдән тузан бөртеге дә калмаган иде, әйтерсең лә алыштырып куйганнар.

—Әллә бер-бер хәл булдымы?—дип сорады ул гаҗизләнеп,—мин...

—Сез сонладыгыз, мьсё,—диде Татли аны тынламыйча да,—без бу вакытта Василий Блаженный храмында булырга тиеш идек инде, белегез, минем һәр минутым исәптә.

Марсель югалып калды, чөнки храм турында да, экскурсия турында да оныткан иде, дөресрәге, ул үзен һаман җиде кат күк өстендәге кебек хис итә иде. Княгиняның катгый сүзләре аны җиргә төшерде.

—Хәзер, хәзер, барысын да рәтлим,—диде каушавын баса алмыйча.

—Зинһар өчен тизрәк кыймылдагыз, мьсё, мин төгәллекне яратам.

Эш машинага утыру белән үк башланды.

—Үтәмешгәрәйнең храмда җирләнүе аңлашыла,—диде Татли,—Ходайкол ни сәбәпле патшалар рәтендә урын алган, шуны шәрехләгез әле, мьсё.

—Ходайкол бәк хакында мин ... теге ... сезгә берникадәр мәгълүмат биргән идем инде, мадам,—дип тотлыга-тотлыга сөйләп китте Марсель,—Ибраһим ханның вафатыннан соң тәхеткә аның тәүге җәмәгатеннән туган баш баласы—Илһам шаһзадә утыра. Йомшак холыклы, булдыксызрак кеше була ул. Кәеф-сафа корырга ярата. Руслар шул халәтендә әсир дә итәләр үзен. Олуг кенәз Василий анасы Фатыйма—Солтанны, туган энесе Ходайколны, башка якыннарын сөргенгә сөрә. Күп тә үтми, Илһам хан фани дөнья белән хушлаша, ә Ходайкол бәк православиегә күчәргә теләк белдерә.

—Мине күбрәк бәкнең җәсәде ни сәбәпле храмга куелуы кызыксындыра,—диде Татли иреннәрен бүлтәйтеп,—бик буталчык сөйлисез.

Марсель төкереген йотып куйды.

—Василий патша Петр Ибрагимовичны кенәз дәрәҗәсенә күтәрә һәм аңа үзенең Евдокия исемле сеңлесен ярәшә,—диде ачу катыш,—туганлашалар. Шулай итеп, Петр Ибрагимович патша гаиләсенә керә, олуг кенәз вазифасын башкарган чаклары да булгалый...

—Менә хәзер бераз ачыклык керде, мьсё,—диде Татли,—моннан ары кәефемне бозмагыз, сезнең аркада бүген йөземдә ике өстәмә сыр хасил була язды.

—Сүз бирәм, княгиня.

Марсель юл уңаенда Кызыл мәйданны күрсәтеп, үзенең абруен акламакчы итте, машинаны ГУМ кибете янындагы бер тыкрыкта туктатты. Тик ярарсың мадамга, көт.

—Мьсё, без Мәскәү чүплекләре буйлап экскурсиягә чыктыкмы әллә?—дип борынын җыерды.

—Княгиня, без чынында да экскурсиягә чыктык, беренче обьект—Кызыл мәйдан,—диде Марсель тавышын күтәрә төшеп,—моннан кул гына сузмалы.

Татли керфек астыннан гына аңа күз төшереп алды.

—Шул үләксә оясы гына житми иде.

—Ихтыярыгыз, княгиня, тәкъдим—миннән, кире кагу—сездән.

—Храмга!

Василий Блаженный храмы Мәскәүнең бүгенге архитектурасына ябышып бетми, ямаулык сыманрак булып аерылып тора. Әмма затлы ямаулык, бизәкләре генә дә нинди, карап туймассың.

Ирексездән Татлиның күз алдына Notre—Dawe de Paris соборы килеп басты. Хәлбуки, алар арасында бернинди уртаклык та юк. Париждагы храм Француз готикасының башлангыч чорына карый, Мәскәүнеке аннан ике-өч гасыр соңрак төзелгән. Шулай да, охшашлык бар, бу охшашлык—тарих! Һәр икесе—тарихи һәйкәл.

—Мәскәү өчен Казанны буйсындыру яшәү белән үлем тарткалашына тиң булган көрәсең,—диде Татли,—югыйсә, шушындый Җинү символы корып куймаслар иде.

—Рәхмәт, княгиня, сез дә рус сәясәтенең асылына төшенә башладыгыз,—диде Марсель. Аның үпкә-ризасызлыклары да тоныкланып калгандай булды.—Мәскәү аннан соң да күп җинүләр яулаган, күп жирләрне, күп халыкларны басып алган, тик берсе хөрмәтенә дә башкалада храм төзелмәгән.

—Дөрестән дә,—дип гаҗәпләнде Татли,—монысына, мөгаен, минем башым житмәс иде, бик урынлы, һәм дә саллы дәлил.

Храмда аларны экскурсовод көтеп тора иде инде. Өлкән яшьтә булса да мөлаемлыгын җуймаган бу ыспай, төз гәүдәле ханымны Татли шундук үз итте. Марсельгә исә, киресенчә, ошамады, купшы күркә, дип бәясен чыгарып куйды. «Бу храмда безнең данлыклы олуг милләттәшләребез жирләнгән»,—дип әңгәмәне үз кулына алырга чамалап караса да, экскурсовод аны бер селтәнүдә өзде.

—Гафу, белүемчә сезнекеләрнең урыны Казанда, әфәндем, Покров соборы, ягъни дә Василий Блаженный храмы исә рус дәүләтенең иң күренекле шәхесләрен генә сыендырган,—диде ул сүзләренең хаклыгына тирән ышанган хәлдә,—Александр Сафакиреевич шуларның берсе. Иң яше.

—Мадам, ул серле үлемнең сәбәпләре сезгә мәгълүм түгелме?—дип, инде Татли әңгәмәгә кушылды.

Сорауны ошатты булса кирәк, экскурсоводның нәзек кашлары уйнаклап алды.

—Тәгаен генә әйтә алмыйм, княгиня, шулай да фаразлар бар,—диде ул күзләрен очлайтып,—сәламәтлеге ташып торган егерме яшьлек дәүләт әһеленең үлеме җә переворот, җә хатын-кыз белән бәйле булырга тиеш. Һәрхәлдә, ул чорда югары даирәдә бу гадәти хәл булган—безнең очракта переворот үзеннән-үзе төшеп кала, чөнки Иван патшаның иң көчле чагы. Шуңа күрә көн тәртибенә икенче вариант килеп баса...

—Миңа калса, сез проблеманы чамадан тыш гадиләштерәсез,—дип бәхәскә керде Марсель,—фаҗигане тормыш-көнкүреш кысаларына гына кертеп калдыру һич тә үзен акламый. Минемчә, бу сәяси үлем.

—Дәлилләрегезне китерегез, әфәндем,—диде ханым,—тарих фактларга нигезләнә, хисләргә түгел.

—Фактларга да җан җылысы өрергә кирәк шул.

Экскурсоводның йөзендә каһкаһәле елмаю чаткылары кузгалып алды.

—Әгәренки үзегез әйткән җан җылыгыз булса, әфәндем, сез Александр

Сафакиреевичның тормыш юлын, бернинди ак таплар калдырмастай итеп, инде әллә кайчан бөртекли-бөртекли өйрәнер идегез. «Храмда безнең данлыклы милләттәшләребез җирләнгән», дип күкрәк сугу ансат ул, эш күрсәтү авыр.

—Браво, мадам, сезнең белән тулысынча килешәм.—Татли кулларын чәбәкләде,—татар галимнәре ике генә өлкәдә уңышлы эшли: беренчесе—зарлану; икенчесе—Мәскәүне сугү.

Марсель телсез калды.

—Сөенбикә ханбикәнең тормышы да урыс тарихчыларының тасвирламасында гына яши, татар галимнәре Херасковка да, Глинкага да, Карамзинга да, Соловьевка да, бигрәк тә алар тәнкыйтькә тоткан монах Иоанн Глазатыйга да һичнинди яңалык өстәмәде. Аларның версияләре, мадам, сез дөрес билгеләп үткәнчә, нигездә гөманлауга, фаразлауга корылган.

Марсель телсез килеш тә таң калды. Күр, княгиня урыс-татар тарихыннан шактый хәбәрдар икән ләбаса, юри генә белмәмешкә салына икән.

Экскурсовод Татлиның фикерен тагын да үткенләндерде:

—Мисырлар, әнә, Клеопатраның, французлар Жанна Д, Аркның тәрҗемәи хәлләрен еллап, айлап кына түгел, көнләп-сәгатьләп тәгаенләгәннәр,—диде,—һәммә халыкның тарихы аның шәхесләренә бәйле. Татар халкын күтәрәсегез килсә әгәр, шәхесләрегезне барлагыз,—диде.

Храм белән танышу ике сәгатьтән артык дәвам итте. Экскурсовод йомшарып китеп, хәтта Үтәмешгәрәйнең табутын фотосурәткә төшерергә дә рөхсәт бирде.

—Мьсё, сез мадамга үпкәләргә тиеш түгел,—диде Татли музейдан чыккач,—миңа калса, ул тулысы белән хаклы.

—Акыл өйрәтергә сез барыгыз да ясап куйган кебек,—диде Марсель,—башта татар булып яшәп карагыз әле, княгиня, үпкәләргәме-үпкәләмәскәме икәнен менә шунда тоярсыз.

Татлины да бу сүзләр битараф калдырмады, иртәнге төкселегенең пәрдәсен ачып, киеренкелекне йомшартмак итте.

—Мьсё,—диде сөрмәле күзләрен майландырып,—барча татар ир-егетләре дә шаһиняләренә карата шулай битарафмы, әллә сез бердәнбере генәме?

Марсель исә уе белән һаман музейда иде. Музей хуҗабикәсенең уктай очлы репликалары аны тәмам чыгырдан чыгарган иде. Татар тарихының хәле дөрестән дә кызганыч. Ул әле һаман урыс тарихының койрыгында өстерәлә. Берәр чиге булырмы моның? Нәкъ шагыйрь әйткәнчә:

Татар юлы әйләнгеч,
Татар юлы болгавыр.
Татар юлы җиңел түгел,
Татар юлы бик авыр.

Тартып бара тарихын,
Тугарылып, җигелеп...
Җиңел булсын кайдан килеп,
Җинеп кара, җиңелеп!

—Гиннесс китабына кертергә лаеклы туң йөрәк сез, мьсё,—дип, Татли Марсельне үзе култыклап алды,—анда, мөгаен, мүк үскәндер.

***

Амвросий әлеге хәлләрдән соң шәкерте белән бер атнадан соң гына очрашты. Аңа кадәр Үтәмешгәрәйгә тулы ирек бирелде, аны берәү дә бимазаламады, кайгысы белән йөзгә-йөз калдырдылар.

Һаман игътибар үзәгендә кайнарга күнеккән зат өчен ялгызлык үзе бер җәза булса, шәхси борчылулар да килеп кушылгач, ул җәза түзә алмастай сагышка әйләнә икән. Үтәмешгәрәй сары йоккан кеше сыман төссезләнде, йөзендә борыны гына утырып калды. Амвросийны күргәч чак елап җибәрмәде.

—Атакай, мин сезнең алда бик гаеплемен, үз-үземне тота алмадым,—диде,—түбәнчелек белән гафу үтенәм...

—Үткәннәрне онытыйк, туганым,—диде Амвросий,—минем үземдә дә гаеп зур, хәбәремне ышандырырлык дәрәҗәдә житкерә алмадым. Сөенбикәнең яраткан кешесе белән никахлашуы һич тә гөнаһ түгел. Тәнре парлыларны хуп күрә. Бәхетнең күзе сукыр аның, туганым, үпкә тотмыйк ханбикәгә.

Үтәмешгәрәйнең бит сеңерләре оешып катты.

—Атакай, минем Сөенбикә ханбикә тоткан диндә бер генә көн дә каласым килми,—диде ул яман усаллык белән,—тизрәк чиркәүгә алып кер, мин әзер!

Амвросий күз очлары белән генә көлемсерәгәндәй итенде. Ул көлгәндә дә тавышын чыгармый, аяк очлары белән генә елмая белә. Йөргәндә дә аяк очы белән генә йөри, янына килеп басканын абайламыйча да каласың, еланнан да саграк кылана.

Шатланырга нигезе дә бар иде, билгеле. Өч-дүрт ай эчендә киребеткән кыргый хан аламасын тәмам үзенә каратты лабаса. Малай ана хәзер тулысынча ышана иде. Моңа кадәр үк муенына тәре тагарга ризалашкан иде анысы. Тик бу әле адымның яртысы гына. Сафагәрәй хан каны янә дөньяны бутамасынга Ана белән Баланы мәңге килештермәслек рәвештә дошманлаштырырга кирәк иде. Әлеге авыр бурыч та үтәлде дияргә була. Бу дәвамлы гамәл. Әмма орлык салынды, шытымы да көттермәс, шәт.

—Мин сине котлыйм, туганым, Тәнребез дога-үтенечләребезне ишетте, аңыбызны ачты,—дип, Амвросий малайның кулларын кысты,—Раштуа көннәрендә Иисус Христос гаиләсенә керү үзе бер изге гамәллер.

Үтәмешгәрәй 1553 елның сигезенче гыйнвар көнендә Үтәмешгәрәй булудан туктады. Бу көн аның күңелендә нииндидер хыялый төш кебек кенә уелып калды. Ул тоташ бәйрәм тамашасыннан гыйбарәт иде. Әкияти затлылык, әкияти купшылык. Һәммәсе алтын-көмешкә, асыл ташларга төренгән, киемнәр ялык-йолык килеп тора. Һәр тарафта шат авазлар: котлашу, кочаклашу, үбешү...

Урыс кәеф-сафа сөрүгә маһир халык, шаулы бәйрәм аның канында.

Беравык шушы зиннәтле мохиттә Үтәмешгәрәй нииндидер эчке бетерешү белән калтыранып китте: ул монда артык кашык түгелме? Әлеге ялтыравыклы адәмнәр аны мыскыллап көлмиләрме? Ул чак кына: «Анаем, коткар мине, анаем»,—дип кычкырып җибәрмәде.

Амвросий, гадәттәгечә, шешәдән генә чыккан җен шикелле нәкъ кирәк чакта шәкерте янында иде инде. Ул аны төркем эченнән читкәрәк алып чыкты.

—Туганым, тиздән, бик тиздән син дә изге православие агачының җимешләренә күркәм иш булырсың,—диде.

Алар татлы төтен исе аңкып торган шушындый ук затлы, әмма кечерәк гыйбадәтханәгә керделәр. Монда тыныч иде. Малай янә күндәм ялагай көчеккә әверелде. Сихере көчле иде атакайның.

Кемнәрдер Үтәмешгәрәйнең җилкәсенә озын җилән салды, очлы башлы бүрек кигезде. Митрополит Макарий каршысына китереп бастырганда аның урыс кавеме малайларыннан бер аермасы да юк иде.

—Гәүдәңне төз тот, бөкреңне чыгарма,—дип, атакай соңгы күрсәтмәләрен бирде.

Чиркәү хоры тынгач, митрополит вәгазь сөйләде. Аннан соң алтын савыттан Үтәмешгәрәйнең йөзенә кечкенә пумала белән догалы су чәчрәтте, колагына яна исемен пышылдады.

Үтәмешгәрәй уяулы-йокылы хәлдә иде, ни кушсалар, шуны үтәде: «бар» дисәләр барды, «тукта» дисәләр туктады. Күпме көч түкте шунын өчен урыс чиркәве! Жиде яше тулар-тулмас бала гына ич әле ул.

Зиһене Мәскәү елгасына чумдырып алгач та шактый вакыт ачылмый торды әле, хәтта чукындыру атасы архиерей Савва Крутицкийның сузылган кулын да күрми торды. Ә учында тәре иде. «Үп, үп»,—дип пышылдады Амвросий.

Рухани ул тәрене анын муенына элде.

—Раб божий, Александр, син хәзер хак христиан, православие чиркәвенең хакыйкый әгъзасы. Котлыйм,—диде митрополит—ошбу изге исемне аклавына өметем зур. С богом!

Александрны, жылы толыпка төреп, шәпле атлар жигелгән купшы чанада Кремльгә алып киттеләр. Аны анда олуг кенәз Иоанн Васильевич көтеп тора иде.

Иоанн патша Александрны тиң дәрәҗәдә кабул итте. Ул бу какча гәүдәле, житди йөзле, үз яшеннән күп зиһенле әсир малайны ярата иде. Язмышлары охшаш булгангадыр, мөгаен. Дөрестән дә, һәр икесе дә өч яшьтә атасыз калды. Өч яшьтә икесе дә тәхеткә утырды. Алар өчен ил белән васый сыйфатында аналары хакимлек итте. Сигез яшькә житкәч, аналарын да югалттылар. Ятимлек патшаларга да авыр яра.

—Әйдә, уз, хан, синең өчен бик шатмын,—дип тәхетеннән үк төште,— киләчәктә дәүләтебезнең иң батыр, иң турылыклы каһарманы булырсың дип ышанам. Бүләгем дә мәгънәле. Ул шушы эчкерсез теләкләремнең тутыкмас вә күгәрмәс көзгесе.

Воевода Воротынский тантаналы төстә Александрга кынысы алтын-көмеш, асыл ташлар белән бизәлгән кылыч китереп тоттырды.

Иоанн эчтән генә елмаеп куйды. Моның мәгънәсе тагын да тирәндәрәк. Казанның бу элекке ханы, хәтта сулар кирегә агып, риваятьләргә генә хас могжиза белән татар дәүләте торгызылган очракта да тәхеткә дәгъва итүчеләрнең исемлегенә дә кертелә алмый. Мөселман дәүләтендә Жучи династиясенә караган мөселман аксөяге генә идарә хокукына ия. Урыс патшалары әлеге хәлдән бик оста файдаланып килделәр, шул юл белән күп кенә дошманнарын тәхеттән читләштерделәр.

Шушы ук көнне Казан тәхетенә Сөенбикәнең атасы Йосыф би утырткан соңгы хан Ядкәр—Мөхәммәд галиҗәнаплары да гомерлеккә реаль ханлыктан ваз кичте. Митрополитның:

—Үз теләгең белән кабул итәсеңме христиан динен? дигән соравына чиркәү көткән җавапны бирде.

—Мин Христосны яратам, Мөхәммәд пәйгамбәрне күрә алмыйм,—диде. Ләкин үзе борчуда иде. Чөнки Иванны чик дәрәҗәдә мыскыл итеп, Шаехгалине төрле әшәке сүзләр белән сүгеп, христиан динен хурлап язган әшәке эчтәлекле язуы патша кулында саклана иде. Кичерерме-кичермәсме? Кичермәсә—сөрген!

Иоанн аны кичерде. Алай гынамы, бу унтугыз яшьлек егеткә бик дәрәҗәле бояр кызын ярәште, хан дигән исемен калдырды. Ядкәр—Симеон үз-үзеннән, тормышыннан канәгать хәлдә урыс җирендә кыска, әмма дә бәхетле гомер кичерде.

Кунак ашы кара-каршы, ихтирамга ихтирам белән җавап бирү фарыз.

—Хөрмәтле православный падишаһ. Тәңре сиңа һәрвакыт дошманнарынны җиңәргә ярдәм итеп килә,—диде Александр рәхмәт-сәламнәрен

ирештергәннән соң,—һаман шулай булсын. Кызганыч, бүләгем генә юк, чын күңелемнән тәкъдим иткән булыр идем.

—Син үзең бүләк, хан,—диде Иоанн,—мөмкинлекләр дә тудырырбыз, балигълык яшең җитүгә, берәр шәһәр багышлармын. Бүгенге көннән ин якын туганым хокукында даирәң белән Кремльдә яши башларсың.

Александр тезләнеп, патшаның чабуын үпте.

—Падишаһ, мин сина турылыклы хезмәт итәргә ант эчәм,—диде.

—Хан, дөресен генә әйт әле, син Казанны буйсындыруыма нинди мөнәсәбәттә торасың,—дип, Иоанн Александрга текәлде.

Патша үзенең шундый кармаклы сораулары белән еш кына якыннарын авыр хәлгә куя. Дөрес, шаяру, уен-көлке кабыгына төреп бирә ул аларны, сынап карау өченгә. Әмма анын акылы үзе белән, кайчан бу «шаяртулар» фаҗигага әверелә. Әнә, Афанасий атлы бояр белән булган хәлләрне әле булса искә алып сөйлиләр, хәлбуки ана инде ел ярым вакыт үткән.

Кемдер үчлек белән чаккан, имеш, Афанасий ураза вакытында итле ризык ашаган. Тәкъва зат буларак, Иоанн үзе дини йолаларны бөтен шартларын туры китереп тота. Анын ярты гомере гыйбадәтханәдә үтә. Бу яктан да күпләргә үрнәк. Иртәнге сәгать дүрттә ул инде догага оеган булыр. Казанга яу чапканда да үзе белән берничә күчмә чиркәү алып барды.

Афанасийга патша әйтә:

—Русьта шундый йола яшәгән: кешенең алдашу-алдашмавын белү өчен аны кайнап торган дәрьяга ташлаганнар. Бата икән, димәк, хаклы. Йөзеп чыкса—ялганчы. Сине дә хәзер сынап карыйбыз.

—Падишаһ, һәр ике очракта да үлем көтә ләбаса,—ди бояр,—мәгънәсе...

—Мәгънәсе шунда, бояр, баткан бәндә Ходай каршында да, патша каршында да саф исемен саклап кала,—дип туктата аны падишаһ,—чын христианнарча изге гамәл.

Афанасий дәрьядан йөзеп чыга, билгеле, егерме өч яшьлек егет күрәләтә батып үлмәс бит инде. Иоанн белән бергә уйнап үстек, әшнәләр идек, эш шаяртудан узмас дип уйлый, күрәсең. Ләкин сүзендә тормаган патша патша була димени. Кизәнгәнсең икән инде—сук!

Ялганы өчен боярны барлык кагыйдәләргә туры китереп җәзага тарталар.

Залдагылар ирексездән шушы гыйбрәтле вакыйганы хәтерләренә төшерделәр. Чөнки сорау искиткеч четерекле иде. Күзләр Александрга төбәлгән. Ә ул шаккаттыргыч җавап очырды.

—Рәхмәт, падишаһым, Мәскәүгә алып килеп, мине кимсетүле ярлыкларга кул куюдан коткардың,—диде.

Иоанн шаркылдап көлеп җибәрде. Аңа ияреп башкалар көлде.

—Акыл яшьтә түгел, акыл башта,—диде Иоанн кешеләр көлеп туйгач,—хан моны тагын бер мәртәбә раслады. Анын авызыннан чыккан сүзләрнең нигезендә тирән хаклык ята. Минем Казанга йөрүем һич тә басып алу максатыннан булмыйча, Тәңре тарафыннан анда хакимлек иткән адәм актыкларының начарлыгы өчен җибәрелдем. Начарлыкны фәкать христиан дине генә бетерә ала. Һәм христиан дине алдагы чорда барча кыйтгаларга да таралачак. Ошбу илаһи бурычымны мин җиренә җиткереп үтәячәкмен!

Зал әлеге ашкынулы нотыкны бердәм рәвештә күтәреп алды.

—Син Тәңренең җирдәге хак илчесе!

—Христиан дине өчен җаныбыз да җәл түгел.

—Үлем басурманнарга!

Иоанн тагын да әсәрләнеп китте. Ул яшьләргә хас булганча, максималист иде. Даирәсенә дә, үзенә дә күп очракта акланмаслык югары таләпләр куя. Мактауга да саран. Ә бу юлы теле элмәктән ычкынды.

—Сез Христос өчен фида булучы беренче кешеләребез,—дип мөрәҗәгать итте ул мөритләренә,—бу заманда сезнең кебек батырлык күрсәтүче һичкем юктыр. Сез икенче македониялеләр, борынгы җинүләрнең батыр гаскәрләре, бу эшегез белән Дон елгасы янында Тәнресез Мамайны җинүчеләргә охшыйсыз. Дан! Дан! Дан!

Иоанн Александрга элек тә ошый иде. Ә бу манзаралардан соң ул аңа башы-аягы белән гашыйк булды, һәр сүзен, һәр хәрәкәтен, һәр мимикасын күнеленә иңдереп калырга тырышты. Менә нинди кыю, тәвәккәл, юмарт вә үҗәт кеше ул бөек падишаһ!

***

Александр яңа халәтенә дә тиз күнекте. Хәзер ул Кремльдә яши, ашаганы-эчкәне патша өстәленнән. Иоанн аны еш кына үзе белән гыйбадәтханәгә дә алып йөри.

Акрынлап элекке тормыш, элекке кешеләр онытылды, хәтер җебе киселде.

Билгеле, аның сарай иерархийсендә биләгән урыны белән килешмәүчеләр дә хәтсез иде. Тик патшага ризасызлык күрсәтү җилгә каршы төкерү белән бер, шакшысы үзеңә төшә. Шуңа күрә авызыңны йозакта тоту хәерлерәк, һәрхәлдә, иелгән башны кылыч кисми. Шулай да, эшне астыртын саклык белән йөрткәндә элекке Казан ханының гына түгел, мөнәүәр затларның да ашларына таракан кояргa бик мөмкин.

Воевода Михаил Воротынский шундыйларның берсе иде. Ул үзенең хаклыгын бөртек тә шик астына куймый. Ник дигәндә, кенәз Казан кампаниясендә турыдан-туры катнашып танылу алган сәргаскәр. Шәһәрнең алынуы, күп байлыкларның кулга төшерелүе турында беренче булып патшага ул җиткерде. Иоанн шатлыгыннан аның күз алдында: «Тәңренең бу көне куана торган изге көн»,—дип елап җибәрде.

Патшага тантаналы шартларда Казан ханының таҗын, таягын, ялавын тапшырды.

—Бөркетләреңә әйт, каланы өч көнгә җинүчеләр кулына тапшырам,—диде Иоанн,—теләгәнегезне кылыгыз!

—Без, галиҗәнап, синең мәсләгеңне үтәп, жиде яшьтән өстен барлык ир-атларны да кырып бетерәчәкбез!—дип сүз бирде воевода.

—С богом!

Бу аяусыз орышта Воротынский бик күп коралдашларын югалтты. Ул каһарманнарның батырлыгы онытылырга тиеш түгел. Ә монда тар-мар ителгән дәүләтнең әсир ханына баш ияргә туры килә. Егылып үләрлек хәл.

Воеводаның татарны күралмавы шул дәрәҗәгә җиткән иде ки, үзенә фарыз түгелне улы кенәз Алексей җилкәсенә ташлаудан да тайчанмады. Бу иң фаҗигасез юл иде: бала ни кыланмас, аңа гаеп ташлау урынсыз гамәлдер. Хәер, атасына күрә баласы, Алексей үзе дә зурга омтылып яшәүче үҗәт зат, кулыннан килмәгәнне теше белән булса да өзә торганнардан.

Александр шулай ук үз бәясен бик яхшы белә, аңа кемгәдер ярау, яраклашуның һич тә хаҗәте юк.

Кремль мәктәбенең ике яшь талибы арасындагы көндәшлек бер-берсе белән ачыктан-ачык бәйләнешүгә кадәр барып җитә башлады. Ә җае чыгып кына тора. Әле бүген дә чәкәләшеп алдылар. Бәхәс җайдак осталыгы серләренә өйрәнү дәресендә кабынды.

—Ат ничә яшьтә ат була?—дигән сорау куйды мөгаллим.

Укучы малайлар: «Син әйт тә, син әйт»,—дип берара төрткәләшеп алдылар.

Сорау авыр иде. Александр да уйга калды.

Атае аны бишектән төшүгә ияргә меңгерде. Тәүге атландыруда ук, ханны шатландырып, тезгенгә чат ябышты ул. Еш кына ат өйрәтү манзарасын карарга алып баралар иде. Шаһзадәнең тәпи йөри башлауга ат арасында әвәрә килүен якыннары яхшыга юрый иде. Бүләк атлары да ишәйгәннән-ишәя барды.

Аның хатирәләрен бүлеп, кенәз Алексейның җавабы янгырады:

—Өч яшьтә,—диде ул ныклы ышаныч белән,—өч яшькә житкән атны гаскәргә бирергә ярый.

Нәкъ шушы мизгелдә Александрның хатирәләре дә шытым бирде. Ниндидер могҗиза белән күңел төбендә остазының: «Биле билтәк бишле айгыр, алтысында ат булыр»,—дигән такмагы уелып калган икән.

—Ат алты яшендә ат була!

Алексейның күзләренә мыскыллы очкын кунды.

—Өч яшьтәге ат ат булмыйча сыер булсынмыни?—дип хихылдады.

—Өч яшьлеге кунан,—диде Александр.

Әйтте дә үз сүзләренә үзе шаккатты. Белгән-кулланган сүзе түгел, димәк, остазы авызыннан колагына кереп калган.

—Әйе, өч яшьлек атны дала якларында кунан дип йөртәләр,—дип шәрехләде аның җавабын мөгаллим,—беләсең икән, малатчина.

—Белмичә, ул бит дала кыргые, басурман, хи-хи-хи...

Алексей учларын дуңгыз колакларына охшатып йомарлады да, чигәсе тирәсендә селкеткәләп торды. Бу ишарәнең мәгънәсе Александрга таныш иде. Урыслар татарларны мыскыл итәселәре килсә, шулай кылана. Ләкин әлеге ишарәнең аңа хәзер бернинди мөнәсәбәте дә юк. Ул—христиан. Йолалары да христианнарча. Жен ачулары чыкты.

—Мин басурман түгел, кенәз,—диде ул сүзләрен бастырып, рәхим итеп гафу үтенегез! Югыйсә, мин патша галиҗәнапларына рәсми үтенеч белән мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр булачакмын.

Алексейдан битәр, мөгаллим коелып төште. Бу күңелсез чәкәләшүнең зур низагка әверелүе дә ихтимал лабаса. Ә гаепне аның өстенә аударачаклар, карамагансың, юл куйгансың диячәкләр. Кенәзләргә, боярларга гына ул ни кылансалар, шул килешә.

—Кенәз, зинһар өчен гафу үтенегез, бу хәлнең шаукымы мөхтәрәм атагыз Михаил Тимофеевичка барып ирешсә, яхшы булмас,—диде мөгаллим ялварулы кыяфәттә.

Атасының исеме малайга салкын су койгандай тәэсир итте. Аның каты куллы икәнен ул кемгә караганда да яхшырак белә. Аннан соң, кирелегенең воеводага зыян салуы да ихтимал. Озынга сузмау хәерлерәк.

—Борчулы сүзем өчен гафу үтенәм, кенәз,—диде ул теш арасыннан гына.—Ялгышымны таныйм.

Йөрәге исә «үч», «үч» дип типте.

—Кенәз, падишаһыбыз Иоанн Васильевич гомерлеккә минем хан дәрәҗәмне калдырды, рәхим итеп, чын дөрес саным белән мөрәҗәгать итегез,—дип каныгуында булды Александр.

Алексей тирләп чыкты, әмма аның башка юлы юк иде.

Озак та үтми, алар янә әләгештеләр. Монысы су буенда, хәрби уеннан соң булды. Әлеге дәрескә алар бик теләп йөриләр. Чөнки һәрберсенең оста орышчы буласы килә. Билгеле, орышчының батыр булуы да зарур. Патша өчен, Ватан өчен, православие хакына баш салу үзе бер мәртәбә.

Әлегәчә бу уеннарда Алексейны уздыручы булмый иде. Ә бүген, һич уйламаганда, кылыч уенында да, ат өстеннән сөңге ыргытуда да Александрга тиңнәр табылмады. Сыйныфташлары аны котлап, баш киемнәрен күккә чөйделәр.

—Тырышлыгыгыз өчен рәхмәт, хәзер рәхәтләнеп су коенсагыз да була,—диде остаз,—миннән рөхсәт.

Шул ук мизгелдә бер-бер артлы киемнәр оча башлады, комаяк малайлар тавышы белән тулды. Чыр-чу. Кара халык балаларыннан берниндиаермалары юк, шулай ук кычкырышалар, сикерешәләр, тарткалашалар, бәргәләнәләр...

—Господа, әйдәгез, шәп-шәрә килеш коенабыз!

Алексейнын бу дуамал өндәмәсе байчураларнын күңеленә дә хуш килде.

—Ура-а-а!

Сабакташлар минут эчендә анадан тума килеш калдылар, бер Александр гына кыймыйча басып тора. Аның бервакытта да чит кеше алдында шәрә калганы юк: сөннәтеннән ояла. Сөннәте өчен ул кавем-ыруына, ата-анасына чиксез дәрәҗәдә ачулы иде.

Алексей исә үчен кайтара алуына куанып бетә алмый. Әнә, күзләре ничек яна.

—Кәлтә еланының киселгән койрыгы урынына яңасы үсә бит, хан, борчылма, синеке дә үсәр әле,—дип инде әче теле белән үтергеч һөҗүмгә күчте,—бәлкем үскәндер дә, күрсәт әле, ха-ха-ха!

Малайлар тыела алмыйча көләләр, кайсы эчен тоткан, кайсы комга егылган. Тамаша.

Александрның йөзенә тимгелләр бәреп чыкты. Ул, әлбәттә, түзәргә, котыртуларга бирешмәскә кирәклеген бик яхшы белә. Хакыйкатьне бу даирәдә йодрык белән исбат итмиләр. Тик үзен-үзе тотарлык хәлдә түгел иде инде ул. Бер мизгелдә икеле-микеле уйларын читкә куеп, кыерсытучысының өстенә сикерде. Алексей, билгеле, моны көтмәгән иде, шуңа күрә баштагы мәлне югалып калды. Ләкин аның мул гәүдә-сынында мускуллар да мул иде ахры. Малайлар кенәзне хуплап гөрләшәләр. Александрны исә ачу, кимсенү тота. Бу хисләр аерым очракта хәтта көчтән дә өстен чыга. Һәм ул җаен китереп, рәнҗетүчесен әйләндереп тә салды.

—Кенәз, моннан ары миңа карата мыскыллы гамәлләр кылмассыңмы?—диде Александр Алексейның кулларын каерып тоткан хәлдә,—үзем дә сиңа үч тотмам. Килештекме?

Алексей мыш-мыш килә.

—Көтәм, кенәз?

Александр тезе белән аның аркасына кадалды.

—Аһ... аһ... авырта...

—Сүзенне генә әйт,—диде Александр,—ә килешү-килешмәү синең эш.

—Килешәм,—диде Алексей.

***

Кунакханә вестюбилендә аларны заманча килбәттә киенгән, килешле буй-сынлы чибәр ханым каршы алды.

—Княгиня, мин сезне бер күз сирпүдә танып алдым,—дип ул озын тырнаклы кулларын сузды.—Алтынга корт төшми, ди халык, сезнең дә аристократ токымыгыз әллә каян кычкырып тора. Ә мин Нәфисә Кирамова булам, «Мәскәү татарлары» клубы җитәкчесе.

—Миңа карата әйткән сүзләрегез барыннан да элек үзегезгә кагыла,—диде Татли күптәнге танышын очраткандай,—ихлас.

—Рәхмәт, княгиня, кайсы гына хатын-кызның комплимент ишетәсе килми икән,—диде Нәфисә,—тик аксөякләр белән тиңләшә алмыйм, чөнки гап-гади керәстиән баласы мин.

—Мьсё, ошбу гамәлегез һәртөрле мактауга лаек,—диде Татли Марсель

ягына борылып,—рәхмәт, кыскасы, мин сезне гафу итәм.

—Марсельгә түгел, анын дусты, минем сабакташым Камил әфәндегә тиеш сезнең рәхмәтегез,—диде Нәфисә көлемсерәп,—шул үтенечне үтәп йөрүем. Күрәм, мьсё, нинди дер жүләрлекләр дә эшләп ташларга өлгергән ахры...

—О-о, анын жүләрлекләрен санап бетермәле генә түгел.

—Ул жүләрлекләр хәзер бермә-бер артачак инде,—диде Марсель,—икәү булдыгыз.

—Без әле тагын бер данәгә артачакбыз,—диде Нәфисә күз очлары белән генә көлемсерәп,—жыеныгыз, ул безне студиясендә көтеп тора инде.

—Кем дип белик әлеге мөхтәрәм затны?

—Жырчы, композитор, һәм дә клубыбызның иң мөхтәрәм әгъзасы. Исеме—Әлфия! Морзалар нәселеннән, княгиня. Ерак кардәше кенәз Мансуров Николай II патшалык иткән чорда меценат буларак танылa. Мәскәүдә Вахтангов театрына нигез салучыларның берсе.

Сылу сылу күренмәс, сөйгән сылу күренер. Бу әйтем Әлфия кебекләргә атап чыгарылгандыр, мөгаен. Чибәрлеге күзгә бәрелеп тормаса да, сөйкемлелеге белән теләсә-нинди чибәркәйгә дә конкурент була ала иде ул.

—Матурлык өләшкәндә йоклап калмагансыз, Әлфия ханым,—дип, Марсель анын да салпы ягына салам кыстырырга онытмады.

—Иләк авызның нәрсәсе матур булсын инде,—дип, Нәфисә ахирәтенә күз кысты.

—Мин үзем дә жырчының авызы зур булырга тиеш дип саныйм,—диде Әлфия канәгать елмаю белән.

—Әлфия ханым, сез жырлаячак жырларның аһәңе хәзер үк йөрәкләрне жилкетеп тора,—дип, Марсель очрашуны асыл юнәлешенә борып жибәрү чарасына керде.

—Безнекеләрне дә бер-ике көн француженкалар белән аралаштырып аласы иде, күрегез, Марсель әфәнденең теленнән бал гына тама бит,—диде Нәфисә,—жырламас жиреннән жырларсын.

Әлфиянең озынча нәзек бармаклары фортепиано телләре өстеннән йөгерешеп узды. Бүлмә эченә йөрәкләрне чеметтерә-чеметтерә ниндидер сагышлы моң таралды.

—Сөенбикә ханбикәнең ачы язмышы тәэсирендә язылды бу көй,—дип аңлатты Әлфия уен барышында,—артык сагышлы дип әйтүчеләр дә бар, ә үземә ошый. Инде сездән фикерләр көтәм.

Әлфиянең тавышы бизәкле иде. Ул көйнең иң тирәндә яткан аһәңнәренә кадәр үтеп керә, күңел төпкелендәге иң урын хисләрне кузгата иде.

Сөенбикә атым, нугай затым,
Күзем яшьле, юк рәхәтем.
Күрдем михнәт, чиктем газап,
Онытылмый һич хәсрәтем.

—Ханбикәнең фажигасенә тәңгәл жыр ижат иткәнсез,—диде Марсель,—котлыйм.

Шулай да күзләр Татлига төбәлгән. Пентатоникага нигезләнгән татар моңы күңелен кузгата алдымы? Ә ул сүзен уратыбрак башлады.

—Мин шәхсән классикага мөкиббән,—диде,—шулай да кечкенәдән көнчыгыш музыкасының кабатланмас мелизмы йөрәгемне ярсыта иде. Мәсәлән, Салих Сәйдәшевнын «Әдрән дингез» көен көнчыгыш композиторлык сәнгатенең эталоны дип саныйм...

Марсель кулындагы каләмен төшереп җибәрә язды. Бүген Татли аны икенче тапкыр гаҗәпләндерә иде инде. Каян белә ул Сәйдәшевнын «Әдрән дингез»ен?

—Княгиня, Әлфиянең «Сөембикә» җыры сездә нинди хисләр уятты, бу минутта барыннан да элек шушы мәсьәлә кызыксындыра безне?—дип Нәфисә сорауны тәгаенли төште.

Татли әүвәл кул көзгесенә карап, иреннәренең буявын тигезләгәндәй итенде, кашларын шомартты.

—Хәзерге заман җырларын йөз чытмый гына тынлап та булмый,—диде косметичкасын букчасына урнаштырган арада,—ә Әлфиянекен һич ялыкмыйча азагына кадәр тыңладым. Бу—яхшы фал. Мәгънәсен, төшенчәнамәсен менә кабул итеп бетермәдем. Бәлки, бу хакта сүз озынайтып торырга да кирәкмидер?

Татли бүленеп, бүлмәдәгеләргә күз төшереп алды.

—Нишләп кирәкмәсен, бик кирәк,—диде Әлфия күңелсезләнебрәк,—тыңлыйбыз...

—Ихтыярыгыз,—диде Татли,—мин, әйтик, Сөембикә ханбикәне һич тә мескен зат дип әйтмәс идем.—Җә, ничек инде бик күп әдәби әсәрләрнең, сынлы сәнгать әсәрләренең, опера-балетларның баш героинясы мескен булсын ди? Аны әле бүген дә олылап искә алалар, хәтерен мәңгеләштерү өчен житди чаралар күрәләр. Сөембикә—татар халкының дәүләтчелек символы. Ничек кенә сәер тоелмасын, ханбикәгә бәхетне аның шәхси фаҗигасе алып килә. Әгәр ул тәхеттә калган булса, әсир ителмәсә, килер идеме икән бу танылу? Шул чорның Нурсолтан, Үрбәт, Гәүһәршад кебек ханбикә-тәнәкәләре аннан күпкә өстен булганнар лабаса. Урысларда: «За все надо платить» дигән гайбарә бар. Сөембикәгә дә әлеге бәхетле язмышы өчен шәхси бәхетсезлек белән түләргә туры килә. Бу җәһәттән ул һич тә ялгыз түгел. Мисыр патшабикәсе Клеопатра, Һиндстанның намусы саналган Индира Ганди, Пакистанның азатлык җырчысы Беназир Бхутто, шул ук Жанна Д Арк һәм тагын бик күп мәшһүр шәхесләр тарихта калу өчен хакны гомер бәрабәренә түләгәннәр. Озын сүзнең кыскасы, Сөембикә турында оптимистик җырлар күбрәк тусын иде дигән теләктә калам.

—Афәрин! Чорларны берләштереп куйдыгыз... Княгиня, мин бу тостны сезнең хөрмәткә тәкъдим итәм,—дип урыныннан торып басты Марсель.

Ханымнар иреннәрен бокалга тигезеп алдылар. Әңгәмә исә яна әйләнешкә кучте.

—Шушы көннәрдә генә бер танылган актрисабыз белән корпоратив кичәдә катнашырга туры килгән иде,—дип соңгы яңалыкларын бүлеште Нәфисә,—ипи тотып ант итә алам, валлаһи танымадым. Бу инде без яраткан, без охшарга тырышкан артистка түгел. Тавышы гына үзенеке. Тарихи шәхеснең асылын үзгәртә торган мондый операцияләрнең, ачуым килмәгәе, ни пычагыма кирәге бар? Бу—вәхшилек. Мин, гомумән, пластик операцияләргә каршы.

—Кызма, подруга, тормозына бас,—дип, Әлфия дустының җиңеннән тартты.—Үзең чибәр булгач та теге... Безнең дә ир-егетләрнең күзләрен кыздырасы килә ич.

—Ир-ат табигыйлекне хуп күрә,—диде Марсель шаяртыбрак,—шуны колагыгызга киртләгез, кызлар. Хәер, княгиня нинди карашта торадыр бит әле?

—Княгиня мьсё белән дә, Әлфия белән дә, Нәфисә белән дә килешә,—диде Татли,—һәркемнең үз урыны, үз шәхси омтылышы... Шушы җәһәттән, үзем дә бер бик мөһим гамәлемне сезгә житкерәсем килә. Әлеге серне ахыргача саклармын дигән идем дә намусым баш күтәрде. Чөнки шушы

кыска гына очрашу вакытында да сез иң якын дусларыма әвereлдегез. Рәхмәт. Ә дуслардан яшерен сер була алмый.

—Браво, княгиня!

—Әйе, мин княгиня,—диде Татли,—монысы хак,—әмма Юсуповлар нәселенә бернинди катнашым да юк.

Марсельнең йөзе кыйшаеп чыкты.

—Ничек?—диде ул үзен-үзе белештермичә,—син... ягъни сез...ни... сез соң үзегезне княгиня Ксения Юсупова-Шереметьева-Сфириның кызы Татьяна дип тәкъдим иттегез лә...

—Минем сезгә житкерергә теләгән серем шушы инде, мьсё,—дип сүрән генә елмайды Татли.

Марсель шаркылдап көлеп жибәрде.

—Шушындый усал шаяру белән шаяртырга ярамый бит инде, княгиня,—диде,—йөрәк ярыла язды ич.

Татли башын чайкап куйды.

—Алайса сез кем соң?—дип ачынып сорады Марсель.

—Мин Тәфкил атлы Казан морзасы токымы вәкиле буламын,—диде Татли,—морза XVI гасыр башында Шәехгали хан белән хезмәттәшлек итә, соңыннан аны Иоанн патша үзенә кодалый. Тора-бара кавем христианлаша. Үктәбер инкыйлабы чорында бабам кенәз Евгений Александрович Тавкилев гаиләсе белән Франциягә күченеп килә. Мин Евгений Александровичның оныгы. Татьяна Дюпон.

—Ә-ә...

—Ашыккан ашка пешкән, диләрме әле татарлар, кабаланмагыз, мьсё, кызыксындырган барлык сорауларыгызга да җавап алырсыз,—диде Татли.

—Сөенбикә ханбикә эзләре буйлап сәяхәт итүегезнең максаты нинди соң?—дип үз соравын юллады Нәфисә,—хәзинә артыннан йөрмисездер, шәт?

—Әйе, әйе,—дип күтәреп алды аны дулкынлануыннан чөгендер кебек кызарып чыккан Марсель,—һәм под чужой фамилией...

—Максатым изгеләрдән изге,—диде Татли—мине монда бабамның васыяте йөртә. Ул гомеренең көзендә Сөенбикә ханбикәнең Казаннан куылганнан соңгы тормышы һәм аның шул чордагы якыннары Кәшһәк углан, Йосыф би, Үтәмешгәрәй хан турында «Әлвидаг» исемле мәҗмуга язарга тотынган булган. Ләкин төгәлләргә житешмәгән, яман чир бугазыннан алган. Ул чакта мин ими баласы гына. Шулай да васыятен яраткан оныгына—княгиня Татьянага багышлаган.

Ни өчен «Әлвидаг» дип сорарсыз, мөгаен. Җавабын алдан ук биреп куям. Бабам кенәз Тәфкилев мәҗмугасының исемен шәрехләп тормаган. Минем фаразлавымча, бу исем һич тә очраклы рәвештә бирелмәгән. Гарәпләр аерылышканда «Әлвидаг», ягъни «Хуш, сау бул!» дип сәламләшәләр. Гади генә сүз кебек, әмма төбендә тирән фәлсәфә ята. Бу җәһәттә, ул татар халкының олы фаҗигасенә ишарә.

Сәгате сугып, тотындым мин бу эшкә. Форсаты да килде. Чөнки нәкъ шушы көннәрдә княгиня Ксения Юсупованың Казанда булуы, аны олылап, зурлап кунак итүләре турында бик жентекләп язылган берничә мәкалә кулыма килеп керде. Тәвәккәлләдем. Һәм мин княгиня Юсупованың кызы Татьянага әвereлдем. Әлеге исем белән йөрү миңа бик күп ишекләрне ачарга булышты. Әйтергә кирәк, мин бу гамәлемне, мьсё ишарәләгәнчә, җинаятькә санамыйм. Бу фәкать иҗат алымы гына.

—Юсуповалар ни әйтер бит?

—Юсуповаларны көйләү авыр булмас, иманым камил, эмигрантлар жинел

татулаша,—диде Татли,—мин, барыннан да элек, Сөенбикә ханбикәнең нугай токымы вәкиле мадам Зөлхәбирә алдында үземне гаепле саныйм. Бу ялганны, ай-һай, ул күтәрә алыр микән? Андый самими, ышанучан, саф күңелле затлар артык хискә бирелүчән була бит. Әмма барыбер аңлашу юлын табарга кирәк.

—Белмим, белмим...

—Тәмам пыркырур булдыгыз,—дип, Әлфия утлы күз карашы белән Марсельне куырып алды.—Мәдхия җырларга тиешбез без бу чибәр, кыю, тәвәккәл, булдыклы ханымга. Княгиня, браво!

—Минем әле Касыймга барасым бар, ә маршрутым Санкт-Петербургта тәмамланачак. Мьсё Марсель ярдәменнән ташламастыр, дип өметләнәм,—диде Татли бокалын кулында әйләндергәләп.

Марсель өчен Нәфисә җавап бирде.

—Борчылма, Татли,—диде мут елмаю белән,—мьсё Марсельне хәзер синең яннан куып та җибәрә алмассың. Парижга ук ияреп китмәгәе әле.

***

Кызга күзе төште Александрның, күңелен нindидер ярсулы хис биләп алды, йөрәге сулкылдап куйды. Мондый ашкынулы аңлаешсыз тойгыны әле аның кичергәне юк иде, каушап төште, үзе дә сизмәстән кул-бармак бияләйләрен әрле-бирле китереп, әле учына йомарлады, әле бармакларына элде. Бу хәлдән аны патшабикә Анастасия коткарды.

—Хан, мин сине үземнең яңа туташым белән таныштырырга телим,—дип, Александрны култыклап алды.—Княгиня Наталья. Княгиняга карата яхшы мөнәсәбәттә булырсыз дип ышанам.

—Хәерле көн, княгиня, сезнең белән танышуыма бик шатмын,—диде Александр һәм кагыйдәсенә туры китереп, фрейлинны башын иеп сәламләде.

Наталья үз чиратында, кабарынкы күлмәк итәкләрен чеметеп кенә тоткан хәлдә, чүгеп куйды. Оялчан иде, күрәсең, керфекләрен дә күтәрми. Хәер, моңа гаҗәпләнәсе юк, чөнки яшь княгиняның җәмәгать алдына тәүге тапкыр гына чыгуы иде бу. Шулай да, гәүдә-сыны инде күрсәтерлек, буе буйга житеп килә.

Патшабикә үзенә охшаган туташны сайлаган икән дип уйлап куйды Александр. Ә бөек княгиня хур кызына тиң асыл җефет. Үзе чибәр, үзе булдыклы, үзе ярдәмчел. Сарай ханымнары аның кисеп ташлаган тырнагына да тормый. Иоанн белән алар шул кадәр пар килгәннәр иде ки, әйтерсең лә, бер анадан туганнар. Икесе дә күркәм, икесе дә зирәк акыллы, икесе дә ихтирам вә эчкерсез хөрмәт иясе, икесе дә Тәңрегә чын күңелдән бирелгән диндар зат. Иоанн патшаның: «Мин үземне дингә һәм Рәсәй дошманнарына каршы көрәшкә багышладым»,—дигән канатлы сүзләрен Александр һәр догасында олылап искә ала. Ул да православиегә, Рәсәйгә рухи атасы Иоанн шикелле намус белән хезмәт итәчәк.

Анастасия катында Александр әнә шулай гыйбадәтханәләрдә генә була торган илаһи хозурлык кичерә иде. Бүген исә ике арага княгиня Наталья килеп керде. Килеп керде дә, сораусыз-нисез бөтен күңелен биләп тә алды. Ни гаҗәп, моңа үзе дә риза-бәхил иде.

Шушы дулкынланган хәлендә ул Петр Серебряныйга килеп бәрелде.

—О-о, минем яшь дустым гашыйк булган, ахры,—диде кенәз һәрвакыттагыча уенын-чынын бергә укмаштырып,—мактыйм, мактыйм... Миңа рәхмәтле бул, теге вакытта вәхшиләрдән азат итмәгән булсам, бу бәхетле көннәр, ай-һай, тәтер иде микән?

Серебряный аны үз итә. Ул да аңа хөрмәт белән карый. Тик азат итү

турындагы төртмә сүзләре генә косасын китерә. Александр инде күптәннән башка тормышта яши, алда нәрсә булган, монысы ике ятып бер дә төшенә керми. Яратмый ул узганын. Азат итүгә килгәндә исә, кенәз Иоанн патша кушканны гына үтәгән. Шуңа күрә рәхмәтнең иң зурысы—Иоаннга.

—Саулыгыгыз ничек, кенәз, исән-имин генә йөрисезме?

—Рәхмәт, яшь дустым, саулыгыма зарланмыйм, калганын үзең күреп торасың,—диде Серебряный.

Александр шунда гына әңгәмәдәшенең жилкәсенә салынып төшкән ат койрыгыдай озын чәченә игътибар итте. Җәбердә икән ләбаса кенәз! Патша үз даирәсендәге бер-бер югары затка ачуланып: «Күземнән югал!»—дип әйтә икән, шул ук мизгелдә ул җәберле адәмгә әйләнә. Ә җәбер иясенең чәчен кырдырырга хакы юк. Аны бөтен кеше күреп-белеп торырга тиеш.

Серебряный күрекле түрә. Тик патша шундый абруйлы кенәзнең дә ниндидер гаебен тапкан. Нишләмәк кирәк, кем әйтмешли, кояшта да таплар бар.

—Патша гафу тамашасына чакыртты, тәхет залына барышым, Ходай кушып, кара тамгадан арыначакмын,—диде Серебряный. Алар яныннан җәт-җәт атлап, Михаил Воротынский узып китте, ханымасы чүт-чүт җитешеп бара. Нинди таныш буй-сын дип ныклабрак багып караса, күңеле янә сызылып китте. Наталья ич бу. Наталья!

Шунда гына патшабикәнең тәкъдим сүзләре аңына барып иреште: «Воевода Михаил Воротынскийның кызы...»

Александрның йөрәген гүя телгәләп ташладылар. Шулай булмыйча, княгиня белән дуслашуга бу гаилә, бигрәк тә агасы Алексей каршы булачак. Хәер, бу хакта баш ватырга әле иртәрәктер мөгаен.

Александрның бу нәзакәтле уйларын Серебряный өзде.

—Михаил, нинди дорфалык бу, сәлам дә бирми үтеп киттең?—дип кычкырды ул воеводага.

—Петр, ишетмәдеңмени әле, патшабыз сырхаулап егылган бит,—диде Воротынский башын гына борып,—шунда ашыгам...

Александрның күз алдыннан яшелле-зәңгәрле утлар чәчелеп китте, гүя башына чукмар белән тондырдылар. Бу дөрес хәбәр түгел, андыйларны чир ала димени, аюларны тәпәли торган әзмәвер ич ул Иоанн!

Патша катында кеше күп җыелган иде. Барысы да пошаманда. Төркем-төркем булып оешканнар да, авыздан-авызга гына сөйләшәләр.

—Гөнаһларыбыз күп, Тәңре шул бәрабәргә кайгы-сынауларын җибәрә, мондый олпат хөкемдар туса да йөз елга берәү генә туа,—диде Александрга якынрак төркемдәге кенәз Мстиславский тирән борчылу белән.

«Государьны күмәргә ашыкмагыз, ул әле Рәсәйне данга күмәчәк»,—дип кычкырасы килде Александрның. Кычкырмады, тыелып калды, чөнки әңгәмәдәшләр тагын ни-нәрсә сөйләр—моны белеп тору да зыянга булмас.

—Гөнаһ баштан ашкан анысы,—дип сүзгә кушылды кенәз Шереметьев,—мен дә биш йөз илле икенче елның үктәберендә Псковта булган үләтне генә исегезгә төшерегез. Кан косудан чирек миллион кеше вафат булды ич. Новгородта—ярты миллион. Чүп өстенә чүмәлә дигәндәй, Казан вәхшиләре котырына. Арча янә антын бозган...

Патшаның хәле турында тәүге мәгълүматны ирештерделәр. Бизгәк екты, диделәр. Хәле авыр икән. Шуңа күрә хәләл җефете, балалары, туганнарыннан кала берәүне дә янына кертмиләр, имеш.

Икенче көнне сарай даирәсе канәгатьсезлеген ачыктан-ачык белдерә башлады.

—Рәсәй үз патшасының хәл-халәтен белеп торырга тиеш,—дип сөрән

салды окольничий Федор Адашев,—урамга күз салыгыз әнә, карга чукыр жир дә калмаган бит. Һәммәсенең чын дәреслекне беләсе килә. Һәм алар хаклы!

—Делегация сайларга кирәк,—дип кычкырды кемдер.

Бу тәкъдим тулы яклау тапты. Делегация составына патшаның фавориты саналган Александрны да керттеләр.

Ул бүлмәгә керүгә, бернигә карамый туп-туры Иоаннның ятагы янына узды.

—Государь, үз гомеремне дә бирергә риза, син генә тизрәк аякка бас,—диде аның хәлсез кулларын үбә-үбә.—Рәсәйне ятим калдырма...

Патшаның кәгазьдәй ак бите буйлап күз яшьләре тәгәрәште. Ул шактый бетерешкән иде. Чуалышкан сакал-мыекларына кадәр керпе энәләредәй тырпаеп каткан. Шулай да күзләре якты, яшәү чаткылары сүнмәгән.

—Рәхмәт, туганым,—дип Иоанн,—сүзләрең алтын бәясе. Минем әле Көнбатышта кичектергесез бурычларым бихисап. Литваны, Польшаны, Ливонияне, Курляндияне тез чүктерәсем бар. Бурычлы кеше яши ул.

Александр күреп-тойганны башкалар сиземләмәде. Аларда бүтән кайгы иде. Әнә, юлпыч корсаклы баш дьяк Михайлов ниндидер кәгазьләр белән селтәнә.

—Государь, васыятьнамә язарга вакыт житте дип саныйбыз,—диде ул делегация исеменнән,—ни боерасыз?

—Языгыз,—диде Иоанн ачуы аша,—варисым итеп төпчек улым Дмитрийны билгелим.

Барысы да баскан урыннарында катып калды. Чөнки берәү дә патшаның шулай жиңел генә ризалашуына өмет тотмый иде. Димәк, хәле, чыннан да, мөшкел. Бу шомлы тынлыкта Михайловның кәгазьләрен кыштырдатуы баш чүмечен игәүләгәндәй тоела иде.

—Һәм язабыз!—дип тавышын күтәрде Адашев.

Шуннан соң шау-шу башланды. Патшаның сырхавын да онытгылар. Воевода Воротынский олуг кенәзнең васыятьнамәсен яклап кычкыра, Адашов аңа каршы килеп, төкрекләрен чәчә. Хәтта бөек кенәз Владимир Андреевич та патшаның васыятьнамә тәкъдимен хупларга ашыкмады.

—Кем хакына тәре үбеп ант эчәргә ният ит дисез соң алайса?—дип сорады Иоанн. Бу минутта ул Дмитрий Донскойны каһәрләде. Чөнки мәшһүр кенәз, элеккедән килгән гореф-гадәтләрне бозып, олуг кенәзнең канунилыгын хуплау-хупламауны югары катлам боярларга фарыз итеп калдырган, шуның белән башбаштаклыкка юл ачкан.

—Владимир Андреевич ясап куйган патша,—диде Адашев,—кануни тәхет иясе, аталарыгыз бертуган.

—Сез бит барыгыз да миңа, минем балаларыма турылыклы булырга ант иттегез,—диде Иоанн хәлсез тавышын күтәрә төшеп,—бу бит хыянәт!

Озын сакалын сыпыргалый-сыпыргалый күренекле бояр Иван Михайлович Шуйский сүзгә кушылды.

—Государь, без бит сиңа вә яхут улыңа буйсынудан баш тартмыйбыз,—диде бүлмәне гөрелдәтеп,—Дмитрий әле имчәк бала гына, ә бу Рәсәй белән бөек княгиняның туганнары Захаринь—Юрьевлар идарә итәчәк дигән сүз. Без моңа юл куя алмыйбыз...

Иоанн кулын селтәде. Бу аудиенциянең тәмамлануына ишарә иде. Ә низаг атна эчендә үзеннән-үзе сүнде. Чөнки патша тернәкләнде. Ходай минем догаларымны кабул итте, дип Александр аның аяк астына егылган хәлдә үкси-үкси елады.

—Тынычлан, туганым. Ходай барыбызга да мәрхәмәтен күрсәтте,—диде

Иоанн,—Тәңрене олылау җәһәтеннән мин хатыным, балаларым, иң якын туган-тумачам белән рәхмәтле гыйбадәт сәяхәтенә чыгарга булдым. Ул исемлектә син дә бар. Жыен, тиздән кузгалабыз.

***

Мен дә биш йөз алтмышынчы елның җәй уртасында Мәскәү әтәчләре кояш баегач та кычкырып йөдәттеләр. «Афәт чакыралар, үз башларына булгыры»,—дип сукранды поп Афанасий.

Афәт корылык киеме киеп килде. Кояшның рәхимсезлеге шул дәрәҗәгә житте ки, эсселектән миләр кайный, очар кошлар җиргә мәтәлә, елгада балык пешә... Александр да һәрдаим догада булды. Чөнки аңа патша гаиләсе белән Изге Кирилл монастырена гыйбадәт сәяхәте вакытында да шушындый ук көннәрне кичерергә туры килгән иде инде. Сәяхәт зур кайгы белән тәмамланды. Кояш сугудан Иоанн патшаның төпчек улы, тәхеткә тәгаенләнгән кануни варис вафат булды. Дмитрий Ивановичка ике яшь тә тулмаган иде әле.

Бу хәсрәтле хәлләрдән соң, ни гаҗәп, олуг кенәзнең сәламәтлеге дә, эшләре дә җайланды. Ливония, Литва тарафларында уңыш арты уңыш яуланды. 1554 елда Әстерхан тез чүкте. Анастасия янә малай алып кайтты. Кызлары Евдокия туды. Күрәсең, Ходай Иоаннга гомер сынавын сабый улы гомере исәбенә тәгаенләгән иде.

Каһәр суккан әтәчләр вакыт чамасын тәмам оныттылар. Патшаның да түземлеге бетте, акылдан язган мәхлукларны берсен калдырмый чалып ташларга, дигән фәрман чыгарырга мәҗбүр булды. Атчабар телмәр боерчылар әлеге фәрманны урамнан-урамга оранлап йөрделәр.

Файдасы гына тимәде. Бәла өстенә бәла: Арбатны ут ялмап алды. Башкалар белән беррәттән, патша үзе дә янгын эчендә кайнады. Тик аны йөгәнләү мөмкин түгел иде инде. Чөнки җил янгынның чикләрен кинәйткәннән-кинәйтә генә барды.

Һәм менә янә сынау. Чарасызлыктан нишләргә белмичә мазаланып йөргәндә Иоаннга хатыны Анастасиянең сырхавы турында хәбәр житкерделәр. Бернигә карамый, кырык эшен кырык якка калдырып, ул хәләл җефетен янгын котырынган каладан Коломенское авылына алып китте. Эчкерсез ярату белән ярата иде Иоанн хатынын. Бер-берсенә җан атып яшәлгән унөч ел гомернең һәр мизгеле кадерле иде аның өчен.

Иоанн бояр кызы Анастасияне Рәсәйнең иң дәрәҗәле, иң чибәр, иң акыллы мең биш йөз кәләше арасыннан үзе сайлап алды.

Анастасия кече күңеллеге, игелеклелеге белән аерылып тора иде. Япаялгыз урамга чыгып китә, базарларга йөри, кешеләр белән аралаша, аларның зарын тыңлый, шатлык-кайгыларын уртаклаша. Ә Александрны «Олы улым» дип йөртә иде. Соңгы вакытта өйләндерү, башлы-күзле итү турында да сүз кузгата башлады. Моннан берничә көн элек кенә:

—Патшаны күндерүне үз өстемә алам, яраткан кызыңа яучылар җибәрү хакында уйлый аласың,—дип шаярткан иде.

Александрның битенә кызыллык йөгерде.

—Оялма, хан,—диде Анастасия,—синең дә безнең шикелле бәхетле булуыңны гына телим мин.

Анастасия, берәүгә дә мәшәкать тудырмыйча, бөтен Рәсәйне кайгыга салып, үзенә генә хас инсафлылык белән августның җиденче көнендә төштән соң үлеп тә китте. Женазасына бөтен Мәскәү, бөтен тирә-як күтәрелде. Матәмгә көч-хәл белән генә юл ачтылар. Чөнки һәркемнең хак мәрхәмәт иясе дигән даны чыккан патшабикәгә хөрмәт күрсәтәсе, догасын юллап-багышлыйсы килә иде. Бу көнне хәтта хәерче-сөальчеләр

дә сәдакадан баш тартты. Ничек инде, Рәсәй халкы шушындый зур хәсрәт кичергән көндә шәхси мәнфәгатьләрне алга сөрәсен, ди.

Табутны Иоанн үзе, якын туганнары Юрий белән Владимир һәм дә Александр күтәреп барды. Шунда Александр княгиня Натальяны күреп алды. Дөрес, кыз күз ачып йомганчы күздән дә югалды, шаулы халык дулкыны аны каядыр башка ярга илтеп сылады булса кирәк. Сөяр кайда—күз анда, ди, егеткә гүзәлкәйнең буй-сынын, килеш-кыяфәтен күнелендә сендереп калуга шушы мизгел дә житте. Наталья жыйнак кына гади соргылт күлмәктән иде. Өстеннән халат киеп жибәргән. Башындагы бизәкле какошнигы да күлмәге белән бериш. Кайгы билгесе итеп, бүтән ханым вә туташлар кебек үк, кара төстәге жинел фата бөркәнгән. Чырае ап-ак иде, хәсрәте йөзенә бәреп чыккан. Шушы халәттә дә искиткеч матур иде Наталья.

Кенәз Владимир каты гына итеп аның кабыргасына төртеп куйды.

—Аяк жаена атла!

Ул сискәнеп китте. Догага инү урынына ни-нәрсә турында уйланам мин, дип эченнән генә үзен битәрләп алды.

Иоанн да еш-еш аяк жаен буташтыра, абынгалап та куя, ике адымның берсендә:

—Жә, әйтегез, нинди гөнаһларым өчен Ходай мина шундый жәза бирә,—дип уфылдап куя.

—Болай бетерешергә ярамый бит инде, тынычлан, падишаһым,—дип юатырга тырышты аны Александр,—Ходай сынауларны иң яраткан бәндәмә генә жибәрермен дигән ләбаса...

Александрның әлеге сүзләре чынлыкта үзенең шәйтани вәсвәсәсен куарга тырышуыннан иде. Чөнки Наталья әле һаман күз алдында тора: тулы сусыл иреннәре, кыйгач кашлары, ак нәфис куллары... Их, тотып карыйсы иде ул мамыктай йомшак кулларны!..

Тукта, житте, Ходайдан курык!

Коры куык, хыялый, бу бит аягүрә саташу гына. Бәлки, княгиня ярәшелгәндер дә инде...

Матәм Вознесение Кызлар монастырена килеп житте. Биниһая зур чуен капкалар киереп ачып куелган иде инде.

Хуш, патшабикәм!

Александр төне буе саташып чыкты. Башта нindидер иләмсез куркыныч ерткыч жанварлар куып йөдәтте. Ырылдый-ырылдый артыннан тотам да калмый чабалар, кайнар сулышларыннан тын кысыла, бер ерткычы куып та житте бугай инде, жилкәсенә тырнаклары кадалды.

—Аh-h!

Калтыранып уянып китте, жилкәсе сызлапмы-сызлый, караса, мендәр йоны кадалган икән.

Наталья исенә төшеп, егет елмаеп куйды. Күзләре дә үзеннән-үзе йомылды. Ә бераздан үзенә төбәлгән сынаулы карашны тоеп алды. Ялт итеп шул якка борылды. Ә анда ак биләүгә уралган Анастасия басып тора иде.

—Патшабикәм, ничек болай...

Александр сүз таба алмыйча төртелеп калды.

—Әйе, бу мин, хан, яраткан патшабикән,—диде Анастасия уйчан гына,—сине алырга кайттым...

—Мине алырга?

—Син, Сашуля, фани дөнья кешесе түгел. Үзәге суырылган агач син, яфракларың буш, тиздән алар саргаеп коелачак. Сине бу хәлгә патша төшерде. Нәсел-нәсәбенне кырды, ыруг тамырларыңны кубарып ыргытты, газиз ананнан ваз кичерде. Көчләп диненнән яздырды. Патшага адым саен бил бөгеп торган ялагай хан ул син түгел, шәүләң генә. Горурлык дигән

хисен дә күеп көлгә әйләнде. Кызганам мин сине, Сашуля... Урының бакыйда синең, Сашуля...

—Ялган, барысы да ялган!—дип кычкырды Александр.

Ул үз тавышыннан үзе куркып уянып китте. Иблис котырта, кыйбламнан яздырырга маташа, мәлгунь, дип ачынып куйды.

Йокысы качкан иде инде, торып жилкәсенә халатын элде дә, тәрәзә каршына килеп басты.

Кала артыннан таң сызылып килә иде. Тирә-юнь ничектер киңәеп, матураеп киткәндәй булган. Арбатның ут ялаган хәрабәләре дә таң кочагында эреп югалган. Табигать барыбер үзенекен ала ул, спас житте ләбаса, челлә чигенә булыр.

Гөнаһлы төш тә онытылды, аны күнелённән бу юлы да Натальяның күркәм образы кысрыклап чыгарды. Тукта, тукта, ул соң княгиняга хат яза ала бит. Алар бер-берсенә тәкъдим ителгән затлар. Шуңа күрә хат княгиняның исем-дәрәҗәсенә тап төшерү булып кабул ителәячәк. Дуслык урнаштыруның бу зыялы алымы сарай даирәсендә бик киң таралган.

Александр үз зирәклегенә үзе сокланып, буш бүлмәне инләп бөтерелеп алды.

Шул ук көнне өйләдән соң Натальяга аның хатын тапшырдылар. Хат рәсми һәм кыска иде. Менә ул:

«Хөрмәтле княгиня Наталья Михайловна!

Безне бер-беребезгә галиҗәнап Анастасия патшабикәбез тәкъдим иткән иде. Шуның өчен мин чиксез рәхмәтлемен, Ходай үзенә җәннәт рәхәтлекләре багышласын. Әгәр каршы килмәсәгез, минем сезгә сүзем бар иде. Очрашу вакытын билгеләсәгез, бик шат булыр идем.

Ихтирам белән Казан

ханы кенәз Александр.

1560 санә, августның

8нче көне, сишәмбе.»

Җавап озак көттермәде, киләсе шимбәдә мин Вяземскийларга яшьләр кичәсенә чакырулы, шунда күрә алырсыз, дигән.

Александр княгиняның кош теле кадәрле генә бу язуын гыйшык хаты кебек кабул итте. Дулкынланудан көне буе үзенә урын таба алмыйча йөрде. Ә кичкә таба чиркәүгә барып, гыйбадәткә оеды, соңыннан учлап-учлап сәдакә өләште.

Александрны төрле кичәләргә, уеннарга еш чакыралар. Әлегәчә рәсми булмаган андый шау-шулы күңел ачулардан мөмкин кадәр читтәрәк булырга тырышты. Ялгызлык ошыйрак төшә аңа. Тик үсмер чактагы тормыш рәвеше егетлекнең асылына туры килми икән шул. Дөрес, егетлек әле ишек кенә шакый, тик ул язгы ташкындай ярсулы булмакчы. Хәер, остазы кем соң? Иоанн 16 яшьтә инде гаилә башлыгы була.

Александр княгиняны агасы озатып йөрер дип шикләнгән иде. Рәхмәт яугыры, кызның акылы хәзинә икән, очрашуны бакчаның иң түрендә, иң аулак җирендә тәгаенләгән. Ул килгәндә чәчәкләргә хозурланып йөри иде.

—Мин чәчәкләргә мөкиббән,—диде ул сәламләшүгә,—шулай да миңа болын-кыр чәчәкләре охшыерак төшә.

Кызның күптәнге танышларча үзен дустанә тотуы егетне үсендереп җибәрде.

—Патшаның Александр бистәсендәге чәчәклегенә карап күзләр камаша,—дип, ул әңгәмә темасының очын эләктереп алырга ашыкты.

—Минем ул бакчаны бик тә күрәсем килә,—диде кыз,—әлегә тәкъдим генә алганым юк.

—Рөхсәт итсәгез, үзем алып барырмын, мин анда еш булам,—диде Александр.

—Чынлапмы?

Натальяның зәңгәрсу күзләрендә нур балкып китте.

—Миңа ышана аласыз, княгиня.

Наталья иелә төшеп, чәчәкләргә чиядәй алсу иреннәрен тигезеп-тигезеп алды, кулларын җәеп, күкрәгенә кыскандай итенде. Бу минутта Александрның чәчәккә әвереләсе килә иде.

Кыз шул ымсындыргыч халәтендә егеткә каш астыннан гына карап куйды да:

—Җә, кенәз, нинди сүзегез бар иде, игътибар белән тынлыйм,—диде.

Александр ирексездән княгиняның хадимәсенә күз төшереп алды. Үзенең сак-каравылын хезмәтчеләр катында калдырган иде.

—Һич икеләнмичә сөйли аласыз, Ефросинья сер саклый белә,—диде чибәркәй.

Александр отыры коелып төште. Чөнки кызга ни әйтергә икәнен үзе дә тәгаен генә белми иде. Очрашуны ул гадәттәгечә яшьләргә хас уен-көлке, сүз уйнату кебегрәк итеп күз алдына китергән иде. Ә княгиня туры җавап көтә. Сынап карап торуларын гына күр. Ык-мык килеп торсаң, ташлап кына китәчәк. Ялганны да шул ук язмыш көтә булыр.

—Минем сезне һаман күрәсем килеп тора,—диде Александр бөтен батырлыгын җыеп.

Наталья челтер-челтер көлеп җибәрде.

—Шул гынамы?

—Төшкә керүегезне дә телим...

—Кирәмме соң?

—Әлегә юк, тырышуын бик тырышам...

Княгиня күзләрен түгәрәкләндереп, үз-үзен чәбәкләгәндәй итенде, янәсе, аһ син, киребеткән нәмәстәкәй, нишләп егетнең төшенә кермисең.

—Менә мине күрдегез инде, кенәз, ә хәзер миңа китәргә кирәк, югалтканнардыр,—диде Наталья,—әле тагын күрерсез, алда төрле уеннар көтә.

—Мин ул уеннарга калмыйм,—диде Александр,—кичектергесез шөгыльләрем бар.

—Ихтыярыгыз...

Наталья егеткә кулын сузды.

—Сезнең кулыгыз шундый йомшак,—диде Александр һәм кыюлыгы килеп озак кына җибәрми торды. Кыз да алырга ашыкмады. Бер-берсенә карашып тордылар.

—Хушыгыз...

—Бер генә минут, княгиня...

—Сүз бирәм, очрашуларга чакыруыгызны кабул итәрмен,—дип вәгъдәләште Наталья,—инде, чыннан да, кузгалырга вакыт, кояш та баеп килә, вакытыннан элек гайбәтләргә дә юл куярга ярамый.

Александр әсәрләнгән хәлдә шактый вакыт куаклар, чәчәкләр арасында адашып йөрде. Үзе тиле кешедәй гел бер сүзне кабатлый: вәгъдә, вәгъдә, вәгъдә...

Һөҗүмчеләрне дә үзен эләктереп алгач кына абайлады. Ләкин соң иде инде. Чалкан яткырып, иң элек авызын чүпрәк белән томаладылар. Тыпырчынып карады каравын, нәтиҗәсе генә булмады. Көчләр тигез түгел иде. Ә дигәнче кул-аякларын да богаулап ташладылар, башына капчык элеп куйдылар. Ләм-мим сүзләре чыкмый.

Аны тиз генә күтәреп атка атландырдылар. Җайдак көчле куллары белән

биленнән кысып алды. Кузгалдылар. Тып-тын, бары тояк тавышлары гына ишетелә.

Нәрсә бу: шаяртумы, үчлекме? Шаяртудыр, мөгаен, усал ният күздә тотылса, башта тукмап хәлен алган булырлар иде. Тимәделәр ич. Димәк, шаярту. Яшьләр арасында дуамаллар бар инде ул.

Озак та үтми, атлар акрынайды, аннан бөтенләй туктап калдылар. Менә хәзер барысы да ачыкланыр. Бар соң бабасырлы егет кәмәшләре. Үзе дә буш калдырмас, Аллаһы боерса.

—Жә, ничек?—дип белеште кемдер. Ул төркемгә әле генә килеп кушылган иде ахры.

—Тәртип,—дигән кыска гына жавап ишетелде.

—Капчык авызын кысыбрак бәйләгез, ташның авыррагын тагыгыз,—диде тавыш иясе. Ул һич курыкмыйча акыл сата иде.—Корытырга кирәк ул татарваның тамырын. Мәскәүне бастылар бит. Патшаны сихерләп, аның ышанычына керәләр. Хакимият акрынлап алар кулына күчә бара. Кызларның да иң затлыларын гына, иң чибәрләрен генә сайлыйлар.

Суга батырырга телиләр түгелме соң болар? Нишләргә? Күрәләтә балыкларга азык булыргамы? Александр кычкырмак итте—авызы томалаулы, тибенеп карады—кул-аяклары тышаулы... Жайдак аның кыбырсынуын сизеп алды, күрәсең, кылыч сабы белән башына тондырды, чак аңын югалтмады.

—С богом!—диде башлык.

Александр сискәнеп китте. Кенәз Алексей тавышы лабаса бу!

Наталья жим, алдавыч кына булган икән. Ул очрашуның ни белән тәмамланасын белеп торган. Иуда! Елан... Хыянәтче...

Александрның гәүдәсе нәрсәгәдер гөрселдәп бәрелде. Шунда ук ул үзенең чуп-чуп итеп елга төбенә төшүен тойды. Капчыкка әлегә су саркымый. Сулыш алуы гына авырлашты. Кычкыра да алмый, селкенә дә алмый, төп кебек ята: үләм бит, үлә-ә-ә-м! Ходаем, гөнаһларымны ярлыка...

Шуннан соң барысы да сүнде...

***

Александр күзләрен ачты. Нинди куркыныч төш! Башына беренче шушы уй килде. Бу арада ни сәбәпледер аңа шундый бәла-казалы төшләр еш керә башлады. Митрополит белән кинәшергә кирәк, бозым була күрмәсен.

—Аллага шөкер, уянды,—дип пышылдады кемнәрдер.

Карап бакса—баш очында сакчылары, гасәбәләр...

—Нәрсә булды, ник өерегез белән жыелдыгыз?—дип канәгатьсезлеген белдерде ул,—хәзер үк аңлатып бирегез!

—Моннан ары, хан, рөхсәт итәсенме, итмисенме, артыңнан тотам да калмаска ант итәм,—диде баш сакчы,—менә, күрегез, тәремне үбәм. Әгәр безне калдырмаган булсаң, мондый фажига килеп чыкмый иде.

—Нәрсә булды соң?

Баш сакчы кыска гына хәлне шәрехләп бирде. Алар сәер атчабарларны абайлап алып, артларыннан ияреп барганнар. Һөжүмчеләр капчыкны елгага ыргытканнар да качканнар. Аннан соң сакчылар суга ташланган...

Төш кенә булмаган икән.

Александр кичәге хәлләрне хәтерендә яңартып, озак кына уйланып ятты. Тотылмаган бур—бур түгел. Гөман белән генә берәүгә дә гаеп ташлый алмыйсың. Тавыш куптару шулай ук берни дә бирмәячәк, үзе генә көлкегә калачак. Киләчәктә алны-артны карабрак йөрергә әйбәт булыр—сабак шул.

—Менә нәрсә,—дип мөрәжәгать итте Александр даирәсенә,—бу

вакыйганы берәү дә белергә тиеш түгел. Күзләрегез сукыр, авызыгыз йомык. Аңлашылдымы?

—Борчылма, хан, барысы да син әйткәнчә булыр,—диде баш сакчы,—безгә ташка ышангандай ышан.

—Бүләкләрем мул булыр,—диде Александр,—ә хәзер гыйбадәтханәгә китәм, атларны җигегез!

Ләкин нияте барып чыкмады. Йомышчы сарайның баш түрәсе кенәз Порфирий Ивановның килүен хәбәр итте.

—Дәшегез,—диде Александр,—көтәм.

—Хан, киен, яңа торагыңны карарга барабыз,—диде кенәз керәкерешкә.

—Минем торагым бар ич инде,—диде Александр аптыраулы кыяфәттә.

—Мин олуг патшабызның олуг ихтыярын гамәлгә ашырам,—диде Порфирий эре генә,—вакытым тар, ашык.

—Мин галиҗәнапның үзе белән киңәшмичә беркая да бармыйм,—диде Александр.

—Галиҗәнап кенәз Малюта Скуратов белән бистәгә китте,—диде дьяк,—язма фәрман белән үзем таныштыра алам.

Ул аңа фәрман кәгазен сузды.

Барысы да дөрес иде. Патша, дәүләти мәнфәгатьләрдән чыгып, Казан ханы Александрны Кремльдәге торагыннан мәхрүм иткән.

Яңа торак дигәне кала үзәгендәге аерым утар иде. Йорты ике катлы. Зур, киң, якты. Үзенә дә, даирәсенә дә урын җитәрлек. Моңа кадәр аның шәхси кәнүшние юк иде. Хәзер—бар! Күпкә иркенрәк, күпкә уңайлырак. Шуның белән бергә, бәгъзеләр патшаның бу адымын Александр Сафакиреевичны Кремльдән читләштерү дип карады.

Соңгы атнада башланган үзгәрешләр чылбырының бер буыны гына иде бу, әлбәттә. Иоанның кан туганы кенәз Юрий да шушы ук язмышка дучар ителде. Әлеге үзгәртеп корулар шул кадәр ашыгычлык белән башкарылды ки, атна-ун көн эчендә патша үзенең иң якын дусларыннан, фикердәшләреннән арынып беткән иде инде. Кремльгә Малюта Скуратовлар төркеме кереп тулды. Кремль йөзен алыштырды. Кремль шымчылар оясына әверелде.

Карагруһлар күптәннән патшаның ышанычын яуларга, дәүләтнең сәясәтен үтә шовинистик юнәлешкә борып җибәрергә җыеналар иде. Ниһаять, андый җай чыкты. Иоанның яраткан хатыны патшабикә Анастасиянең кинәттән вафат булуын алар бик оста файдаланды. Һөҗүм угы беренче чиратта күренекле дәүләт эшлеклеләренә юнәлдерелде. Скуратов патшага махсус хат белән мөрәҗәгать итте.

«Государь, син авыр хәлдә, шулай ук Рәсәй дә,—дип язды ул,—ә ике явыз зат тантана итә: саф күңелле патшабикәне Сильвестр һәм Адашев чыгырдан чыгарды, аның яшерен дошманнары һәм сихерчеләр, дәхи дә алар сихер кулланмыйча синең акылыңны алып, шулай озак вакытлар үзләренә каратып тота алмаслар иде. Патшабикәбезнең вакытсыз үлемендә фәкать алар гына гаепле, аны сихер көче белән боздылар, чирләшкә ясадылар.»

Иоанның яралы күңеленә агу шул рәвешчә тамып кына торды. Нәтиҗәдә ул араларына кыл да сыймастай тоелган данлыклы кенәз-воеводаларны җәзага тартты. Сильвестр Ак дингездәге кыргый Соловки утравына сөрелде, Адашев әле генә Литвадан үзе яулап алган Феллина каласына тоткын итеп җибәрелде. Ә туган-тумачаларының милекләрен тартып алдылар.

Дошманнар исә табыла гына торды. Дәрәҗәле олпат кенәзләрдән саналган Федоровны хәнҗәр астыннан үткәргәндә Александр үзе дә бар иде.

Бөтен сарай даирәсе жыелган бер мәжлес вакытында Иоанн Федоровны бастырды да, һич уйламаганда-көтмәгәндә: «Кенәзгә патша киемнәрен кидерегез, башына таж элегез!»—дип әмер бирде. Барысын да ул кушканча эшләделәр. Шуннан соң: «Хәерле көн, Рәсәйнең бөек патшасы! Мин сине тәхеттән бәреп төшерәм!»—дип кычкырды Иоанн һәм өлкән яшьтәге кенәзнең йөрәгенә хәнҗәрен батырды.

—Кем дә кем минем тәхетемә кул сузу уена керә, аны шушы язмыш көтә,—дип төкрекләрен чәчте Иоанн.

Шул ук көнне Федоровның хәләл җефете башына да йоклаган вакытында мендәр капладылар. Кешелеклелек хисе Иоаннга кире әйләнеп кайтмады. Анастасия аның бәхетен, тынычлыгын үзе белән салкын кабергә алып китте. Патша чарасызлыктан яралы ерткыч сыман ил өстенә ташланды. Рәсәй кансызлык, азгынлык, орыш-талаш баткагына кереп чумды.

***

Рәсәй күгендә котырынган бу зилзиләләргә бер Александр гына битараф иде. Дөресрәге, аның күнелен бөтенләй башка хис томалап алган иде. Мәхәббәт акылны кисә бит ул, күзне сукырайта, чукракландыра. Егетебез дә шул хәлдә иде. Беркөнне йомышчысы Афанасийны чакырды да әйтте:

—Княгиняның Ефросинья исемле хадимәсе бар, сиңа шуның белән ышанычлы мөнәсәбәт урнаштырырга кирәк,—диде.

Афанасий сүзсез калды.

—Ишеттеңме әйткәнне?—диде Александр күзләрен чекрәйтеп.

—Ишетүен ишеттем, шөкер, чукрак түгел әле, ләкин дә...

—Бернинди «ләкин» дә юк,—диде Александр,—Тәңре ярлыкауны хуп күрә, сабыр сонында носрат[12] бар, михнәт соңында рәхәт бар, кайгы сонында шатлык бар.

—Ул вәхшиләрнең туң йөрәкләрен эретергә, ай-һай, ялкының житәр микән, хан?

—Наталья мыскалга салынган ак ефәк бит ул,—диде Александр,—уйладым-уйладым да әлеге вакыйгага аның мөнәсәбәте юктыр дигән нәтиҗәгә килдем. Чөнки күзләре пакъ княгиняның...

—Бу гашыйклар тәкъбире, хан,—диде Афанасий,—сак бул, мәхәббәт кешедән көл ясый.

—Күп сөйләшмә, тартар теленнән табар, ди.

Александр алдан әзерләп куйган төргәген йомышчысына сузды.

—Хадимәне үз ягына аударырга шушы акча җитәр дип уйлыйм.

Афанасийның күзләре шар булды.

—Бу сон... еллык эш хакы лабаса... хан...

—Княгиня аңа гына торырлык.

—Ә вазифам?

—Якын көннәрдә мин княгиняның үз катында аның белән очрашырга ниятлим,—диде Александр сүзләрен чалгыдай кистереп,—Ефросинья белән сез шул очрашуны оештырырга тиешсез. Вазифаң шул.

Афанасий бер атнадан янә ханның бусагасыннан атлап керде. Авызы ерык, күзләрендә очкын, әйтерсең лә кош тоткан.

—Ефросинья—во!—диде ул баш бармагын тырпайтып,—үзе чибәр, үзе...

—Туктале, тукта, мин сине Ефросиньяның чибәрлеген күрергә җибәрмәдем ләбаса,—дип бүлдерде Александр егетнең ялкынлы нотыгын,—очрашу кайчан була, ничек килештегез?

—Их, хан, Ефросинья кебек тәвәккәл, кыю кызлар булган җирдә эш

[12] Носрат—ярдәм.

пешмиме соң? Барысы да яхшы, берне сугып икегә тигездек. Синең рөхсәт белән бер касә сыра эчәм дә бәеннән-бәенә сөйләп бирәм. Ефросиньямы, Ефросинья...

Афанасий бер омтылышта касәне бушатып куйды да өстәл янына килеп утырды.

—Инде тыңла, хан...

***

Воротынскийлар утарына алар эңгер-меңгер сүнеп, җиргә төн томаны тарала башлагач килеп җиттеләр. Куаклар арасында бераз тирә-якны күзәтеп тордылар. Шик уятыр нәрсә сизелмәде. Шуннан соң тиз генә атларның башына солы капчыгы астылар, пешкән эшне бозып куюлары ихтимал.

—Хәзер безгә этләрне алдалап, ялгыш юлга кертеп җибәрү зарур,—диде Афанасий,—этләре кәттә, умырып алырга гына торалар. Үзләре иләмсез зур, бозау кадәрле, усал булсынга ачлы-туклы тоталар икән.

—Афанасий, телеңә салынма, вакыт уза,—диде Александр. Аның йөрәге урыныннан чыгып китәрдәй булып тибенә иде.

—Без этләрне котырта башлауга, асыл кош катына элдерт,—дип күрсәтмәләрен бирде йомышчы,—Иван барысын да белә, тышкы якта ул булышачак. Онытa күрмә, икенче кат, икенче почмак тәрәзә.

Афанасий төркеме караңгылык эченә кереп югалды. Күп тә үтми, буыла-буыла этләр өргән тавыш ишетелде.

—Тәвәккәлләдек!

Иван яшерелгән урыннан баскычны алып, стенага сөяп куйды да, тәрәзәгә кечкенә генә таш кисәге бәрде. Тәрәзә шундук ачылды.

—Кенәз, анда көтәләр!

Александр мәче житезлеге белән өскә үрмәләде.

—Хуш киләсез, кенәз,—дип каршы алды аны Ефросинья,—аз гына көтеп торыгыз, хәзер княгиняны алып керәм.

Александр өстәлдәге кувшиннан су алып эчте дә тирә-ягына күз төшереп алды. Бүлмә зур иде. Ярымкараңгы. Аны ерак почмактагы тычкан күзедәй кечкенә генә бер шәм яктыртып тора иде. Ул тарафта янә дә тәбәнәк өстәл, ике кәнәфи шәйләнә. Тагын нәрсәләрдер бар...

—Исәнмесез, кенәз, менә сүземдә тордым, мин каршыгызда басып торам!

Александр дерт итеп китте.

—Наталья... Мих... ай... княгиня... гафу, күрмәдем...

—Безнең ишекләр күп,—диде кыз,—күзәтеп кенә бетерерлек түгел.

Александр аның мут елмаюлы йөзен караңгыда да шәйләп алды. Шуңа күрәме, каушавы басыла төште.

—Мин бик рәхмәтле сезгә,—дип, туташ алдында тезенә чүкте.

—Мин күрше бүлмәдә булырмын, рәхәтләнеп гөрләшегез,—диде Ефросинья, шәмне сүндерәм, утка килеп керүләре бар, югалтышмассыз, шәт.

—Ефросинья...

—Мин княгиняны бервакытта да югалтмаячакмын,—диде Александр.

—Менә бу егет сүзе, кенәз.

—Афанасийны сихерләгәнсең, ахры, Ефросинья, сине теленнән дә төшерми,—дип хадимә кызны да мактыйсы итте Александр.

Ишек катында кызның кеткелдәп көлгән тавышы ишетелде.

—Аһ, шалун ул сезнең егетегез, кенәз, впрямь шалунишка...

Гашыйклар караңгы бүлмәдә япа-ялгыз калдылар. Тәрәзәдән саркып кергән тонык яктылык та бу караңгылыкка нинлидер шом гына өсти иде.

—Кенәз, мин куркам...

Александр кызның кулларын эзләп тапты. Алар дөрестән дә дер-дер калтырана иде.

—Княгиня, сез матурлык алласы Афродитадан күпкә чибәррәк,—дип пышылдады Александр.

—Әллә сез караңгыда да күрәсезме?

—Минем күңел күзем бик очлы, Наталья...

—Без исемгә күчтекмени инде,—дип, княгиня бармак янады.

Алар шундый якын утыралар иде ки, бер-берсенең сулыш алуын, йөрәк тибешен тоеп та, ишетеп тә тордылар.

Александрның куллары мәгъшукасының биленә ятты. Ул моны үзе дә сизмәде, кыз да нишләптер карышмады.

—Наталья, минем сезне үбәсем килә,—дип пышылдады егет.

—Ә сез үбешә беләсезме соң?—дип сорады кыз.

—Юк...

—И, җүләр, үбегез соң...

Александр кызны үзенә таба тартып китерде дә, иреннәрен аның бит очына тигезде, әле берсенә, әле икенчесенә...

—Бу үбү ихтирам билгесе генә,—диде туташ,—яратышып үбешү ул башка, менә болай...

Наталья егетнең муеныннан кочаклап, иреннәренә беректе. Тыннары кысылганчы үбештеләр. Иң әүвәл кыз аңына килде.

—Җитеп торыр, кенәз,—диде Александрны читкә этәреп,—мин фәкать күрсәттем генә...

—Сез күпне беләсез,—дип сокланды Александр.

—Мине Ефросинья өйрәтә,—диде Наталья,—ул һәр нәрсәдән хәбәрдар.

Наталья кәнәфиенә чумыбрак утырды. Александр чүгәләп, башын аның тезләренә салды.

—Сез мине яратасызмы?—дип сорады кыз.

—Мин яратуның нәрсә икәнен белмим, княгиня, әмма сезсез яши алмыйм.

—Алайса нигә шулай көттереп кенә килдегез соң? Мин әллә нәрсәләр уйлап бетердем.

Александр янә каушап төште. Әле ярый караңгыда кыз аның халәтен абайламады. Нишләргә? Әйтергәме-әйтмәскәме? Хәлбуки, ул үз-үзенә сүз биргән иде ич инде. Чынында исә фаҗига фаҗига булудан туктап, гади бер кысыр хәсрәткә генә әйләнеп калган иде. Булган—беткән, төсе уңган. Икенче яктан, алар арасында бернинди икеләнү дә ятарга тиеш түгел, саф мөнәсәбәт—пакь мөнәсәбәт.

—Мине патша яңа йортка күчерде, мәшәкатьләр күп булды,—диде Александр туры җаваптан чигенеп,—гафу үтенәм. Кичерерсез бит?

—Алга таба тәртибегез ничек булыр әле,—дип, янә бармак янады княгиня,—язмышларыгызны шул хәл итәр.

—Сезсез тормыш—тормыш түгел инде, Наталья...

—Михайловна,—дип ялгады кыз.

***

Очрашу Александрга канат куйды. Дөрестән дә Наталья аның язмышы. Ходай шулай тәгаенләгән. Әүвәл изге зат—патшабикә Анастасия аша очраштырып, хисләргә ут кабызды. Аннан сынау артыннан сынау. Суга индерү дә шул чылбырның бер буыны. Ә ул, җүләр баш, иртәнге чыктай саф күңелле Натальяга нахак бәла якты, имеш, һөҗүм оештыручылар белән

бер яман төркемдә булган. Әле, ярый, аңы ачылды.

Алар Наталья белән бер-берсе өчен яратылган. Бу илаһи хакыйкать.

Чираттагы очрашуга Александр инде ныклы фикер белән килде. Нотыгын исә уратыбрак башлады.

—Наталья, сезнең абыегыз кенәз Алексей мине ыруыма мөнәсәбәтле рәвештә балачактан ук күрә алмый, ахрысы, ата-анагыз да шул караштa торадыр...

—Саша, бу миңа кагылмый,—дип, кыз хуш исле учлары белән аның авызын каплады.

—Миңа әйтеп бетерергә рөхсәт итегез, зинһар,—диде Александр,—белүемчә, воевода Михаил Воротынский Казанны буйсындыруда катнашкан, яраланган да...

—Саша, үтенеп сорыйм...

—Озын сүзнең кыскасы,—дип үзенекен тукыды Александр,—алар риза булырмы-юкмы, әйтә алмыйм, ә менә сезнең кулыгызны сорап, патшабыз Иоанн Васильевичка мөрәҗәгать итәргә карар кылдым. Шуңа күрә...

—Минем ризалык кирәкмиме?

Александр кызның каршына килеп тезләнде.

—Сез бит миңа сүз әйтергә ирек бирмисез, княгиня, һаман бүлдерәсез.

—Авызыма су каптым.

Александр урыныннан торып басты да шырпыдай төзгә каткан хәлдә җөмләләрен тезде.

—Мөхтәрәм княгиня Наталья Михайловна,—диде житди төс белән,—мин патшабыздан никахлашуыбызга фатиха бирүен үтенеп, рәсми мөрәҗәгать хәзерләдем. Шуңа сездән рөхсәт сорыйм. Җавабын кайчанрак көтәргә мөмкин?

Кычыткан чыпчыгыдай тиктормас Наталья тынып калды, йөзе буйлап ниндидер кырыслык чаткылары чайпалышып узды, иреннәре мелт-мелт итеп куйды.

—Җавапны тугыз айдан соң гына бирә алам, кенәз,—диде көрсенеп,—чөнки яшем җитеп бетми.

—Ярәшү яшькә карамый, княгиня, никахны мин күпме кирәк, шул кадәр көтә алам.

—Яратуыгыз чынмы соң?

—Наталья!

—Риза,—диде кыз,—мин дә сезсез яши алмыйм.

Александр идәнгә чүгеп, кәләшенең күлмәк итәкләрен үпте.

***

Бүген ниндидер могҗиза белән Татли кичтән тәгаенләгәнчә вакытында җыенып өлгерде. Марсель исә аның сәгатьне санга сукмавын истә тотып, очрашуны алданрак та билгеләгән иде. Шуңа күрә вокзалга егерме минутка иртәрәк килеп җиттеләр. Ә вокзал, гадәттәгечә, тузынган умарта күчедәй гөж килеп тора. Кеше дулкыны тоташ ташкын булып, әле бер, әле икенче тарафка агыла.

Марсель каш астыннан гына Татлига күз төшереп алгалый. Урынын ут алган кешедәй тынгысыз бу чәүчәләк ханымның шулай тыныч кына тамаша кылып утыруы гайре табигый хәл иде. Күр, мадам басынкы да була белә ич. Сәер. Аңа шәхсән минутына кырык рәвешкә керүче Татли ошыйрак төшә. Житдилек чибәркәйне олыгайта иде. Ә ул Напалеон планнары корып утырган икән.

—Мьсё, әйтегез әле, чын ир-ат беренче чиратта ни-нәрсә эшләмәскә

тиеш?—дип, карашы белән көйдереп алды.

Ошбу сорауның төбендә ниндидер хәйлә, уен, шуклык ята. Бу көн кебек ачык. Җавапны да шул рухта бирү зарур. Әйдә, куансын.

—Ир-егет, иң беренче чиратта, хатын-кызның теләгенә каршы килмәскә тиеш, аннан соң...

—Житте, мсьё, рәхмәт, мин моннан алдагы барча гаепләрегезне дә гафу итәм.

—Мадам, көлдермәгез, зинһар, сез әлеге җөмләне көненә биш-алты тапкыр кабатлыйсыз,—дип, кулын селтәде Марсель.

—Ышанмыйсызмы?

—Юк!

—Менә күрегез...

Татли кыенсынмыйча-нитмичә Марсельнең иреннәреннән суырып үпте.

—Инде бер үтенечемне тыңла, мсьё.

—Татли, сабыр, әнә, безнең поездга утырту башланды...

—Касыйм качмас, әле Мәскәүдә дә эшебез бетмәгән икән ич.

Марсельнең колаклары шәмдәй турайды.

—Әйе-әйе,—диде княгиня,—Мәскәүдә булып та данлыклы Тарих музеен карамасак, безне кешелек гафу итмәячәк.

—Бу намуссызлык, Татли, үбешү коммерция гамәле түгел...

—Мин Иоанн патшаның Казанны буйсындыру хөрмәтенә эшләткән таҗын күрмичә китә алмыйм ич инде,—диде Татли берни булмагандай.

—Иоаннның коронасы Тарих музеенда түгел, Корал палатасында саклана...

Марсель үкчәсен-үкчәсенә бәргәли-бәргәли княгиня артыннан теркелдәде.

Палатаның экскурсантлар кабул итми торган көне икән. Ә Татли өчен «юк» дигән сүз гомумән юк. Директорга кереп, мәсьәләне бик тиз җайлап чыкты. Аларны яшь кенә бер сакау ханым озатып йөрде. Сөйләме күнелгә ифрат та ятышлы иде. Марсель эреп китте. Бу княгиняга ошап житмәде булса кирәк.

—Мсьё, без монда кызлар күзләргә килмәдек, вазифагыздан читләшмәгез,—дип ачыктан-ачык кисәтте.

Экскурсия Монамах бүреге янында башланды.

Бүреккә вакыт галиҗәнаплары әллә ни зыян салмаган. Дөрес, мехлары шактый уңган, үзе чүгелгән чүмәлә рәвешенәрәк кергән. Әмма алтын-көмештән үреп ясалган филигран бизәкләре, асыл ташлардан уелган кашлар ут яктысында күктәге йолдызлардай ялык-йолык килеп җемелдәшә.

—Ошбу бүек Мәскәү кенәзлегенең, гомумән угыс патшалыгының иегалиясе, дәүләт хакимиятенең иң дәгәҗәле символы саналган,—дип аңлатма бирде галимә.

—Урыс осталары кулы белән ясалганмы?—дип сорады Татли.

—Юк, аны XIV гасырда Угта Азия сәнгаткәгләге иҗат иткән.

—Ә ничек Рәсәйгә килеп эләккән?

—Ыгиваять буенча, XV гасыг азагында, XVI йөз башында, угыс пыавославиесенең бишеге булган Византиядән импегатог Константин Монамах оныгы Киевнең олуг кенәзе Владимиг Мономахка бүләк итеп җибәргән.

Татлиның күзе кечерәк кенә бер портретка төште.

—Бу нинди ваемсыз гафил бәндә?

—Ваемсыз бәндә дигәнегез Иван Ггозныйның атасы Василий III. Погтегетны хәтеге буенча Мәскәүгә килгән алман дипломаты сәясәтче

Сигизмунд Гегбегштейн ясаган. Шуның белән ул бик тә бәһале.

—Мине хәзерендә Иоанн патша күбрәк кызыксындыра, бигрәк тә бүреге,—дип көлде Татли.

—Коронасы,—дип төзәтте Марсель.

—Корона, белүемчә, королеваларга хас бизәк.

—Бүек егәвешендәге коона,—дип бәхәскә нокта куйды экскурсовод.

Иоанн патшаның бүрек-коронасы Мономах бүрегенең төгәлише иде. Шундый ук филигран ысулы белән алтын чыбыктан үрелгән өлгеләрдән гыйбарәт. Ул өлгеләргә энже, кызыл якут, фирәүзә кебек кыйммәтле асылташлардан күзләр уелган. Кырпуын затлы кеш мехыннан теккәннәр. Очлы бүрекнең түбәсенә тавык йомыркасыннан аз гына калыш зур топаз ташы беркетелгән. Шул рәвешле архитектурасы бербөтен төс ала.

Бүрекләрнең яшь аермасы—чама белән ике гасыр. Шуңа күрә Иоанныкы әйбәтрәк сакланган. Аермалары да бар, әлбәттә. Шуларның иң бәрелеп торганы—бүрек очына беркетелгән дәрәҗә билгесе. Мономах бүрегендә—тәре, Иоанныкында—түгәрәк асыл таш.

—Иоанн патшаны бик тәкъва кеше булган дип язалар, ә коронасында бу бөтенләй чагылмый,—диде Татли,—моны ничек аңларга?

Галимә туташ княгиняга сөзеп карап алды. Ул аны үзенең һәр капризын канәгатьләндерергә күнеккән калын кесәле җилбәзәк зат дип кабул иткән иде. Чөнки ял көнендә музейга үтеп керү, шәхси экскурсия оештыру гадәттән тыш сирәк күренеш. Әлеге сорау анын фикерен үзгәртте, юк, савыты буш түгел икән бу мадамның дип уйлап куйды.

—Иван патша динле кеше булган, анысы хак,—дип башлады ул аңлатмасын,—сугыш-огышлагын да дин байгагы астында, пыавославие мәнфәгатләген күздә тотып башкаган. Шуның белән беггә, Оассияне дәүләт булаак ныгыту, чикләген киңәйтү анын хакимлегендә үзәк уынга күтәгелгән. Ул инде ата-бабалагы кебек Мәскәү кенәзлегенең олуг кенәзе генә түгел. Ә багча угыс җигенең патшасы. Уналты яшьлек хаким ыгәсми эгәвештә үзен шулай игълан итә. Коронасында да нәкъ менә шул бөек дегжавачылык чагылыш тапкан.

—Бу бүрекне Казан бүреге дип тә йөртәләр,—дип, Марсель дә үз мәгълүматын кыстырып куюны кирәк тапты.

—Моңа һич тә гаҗәпләнәсе юк,—диде экскурсовод,—ник дисәң, ул Казан ханлыгын яулап алу хөгмәтенә эшләтелә, җиңү символы булып тора.

—Бәлки, Казан осталары кулы белән эшләнгәнгәдер?—диде Татли.

—Андый вегсия дә баг, әмма фәнни яктан нигезләнмәгән.

Вакыт тар булу сәбәпле, Марсель бәхәскә кереп тормады. Чөнки кичке поездга да соңга калу ихтималы бар иде.

***

Александр кафтанының кайтарма якасы өстеннән салынган җылы муенсасын кысыбрак бәйләп, башлыгын батырыбрак киеп куйды. Аллам сакласын, томау төшеп интегүең дә бар. Болай да тернәкләнеп кенә килүе. Диңгез хастасы турында ишеткәне бар иде барын, әмма анын шушы дәрәҗәдә үк хафалы икәнен күз алдына да китергәне булмады. Ис китмәле, атна буе шешә бөкесе кебек караб идәнендә ауна әле. Коса-коса эчәгеләре авызына килде. Башы әйләнә, баш белән бергә бөтен дөнья әйләнә.

Караб үзе дә гөрләвектәге йомычка урынына бөтерелә, асты өскә әйләнер кебек. Әйләнми үзе, ерыпмы-ера дулкыннарны.

Сигезенче көнне аз гына җибәргәндәй булды, хәтта хәтәр-хәвефсез генә бер-ике йотым шәраб та эчеп куйды. Шәрабны диңгез хастасыннан иң

әйбәт дару диләр. Ә бүген, әнә, палубага ук алып чыктылар.

Бу кадәр ишле суны күргәне юк иде әле анын, куркып калды, әйтерсең лә упкынга тәгәри, ә тотыныр нәрсә юк...

—Искиткеч матур манзара,—диде баш илче Непея.

Александр муенын бормый гына тирә-якка күз ташлады. Матур дигәне дәрья да күк, күк тә дәрья. Әле ярый, күнелгә өмет хисе өстәп, кояш нур сибә.

—Мин җирдә әүмәкләнеп үскән кеше бит, кенәз, вологжанин,—диде баш илче,—сине бик яхшы аңлыйм, чөнки үземнең дә баштан үткән хәл. Англияга беренче тапкыр корольнең ышанычлысы граф Ченселер корабында чыгып киткән идем бит мин. И, андагы күргәннәр, искә килеп, әле дә сискәнеп китәм. Шотландия ярларына якынлашканда безне искиткеч которынкы давыл-өермә куып житте дә, дүрт корабны дүрт якка чәчеп тә ташлады. Шуларның берәве генә Лондон портына кайта алды. Бәхетемә, мин шул карабта идем. Графка исә ул бәхет тәтемәде.

Непея Александрның агарынган йөзен күреп, тынычландырырга ашыкты.

—Борчылма, кенәз, бу караб зур, аңа куркыныч янамый,—диде,—күр, җилкәннәрен ничек киергән.

Моннан берничә ел элек дипломат һәм диңгезче граф Ченселер Ак диңгез ярындагы изге Николай монастыре причалына якорь салды. Кулында король Эдуард VIнын Рәсәй патшасы Иоанн Васильевичка атап язган хаты иде. Король патшаны сәүдә мөнәсәбәтләре урнаштырырга өндәгән иде.

Иоанн бу адымнын киләчәге зур икәнен шундук аңлап алды, мәсьәләне сузмыйча бик тиз хәл итте. Сәүдә илчесе Непеяны инглизләр карабына утыртып, Лондонга озатты. Тиздән изге Николай монастыре биләмәсендә Архангел каласына нигез салынды, Колмогор шәһәрендә сәүдә үзәге төзелде. Инглиз купецлары Рәсәйдә чикләнмәгән күләмдә сукно һәм шикәр белән сату итә башлады. Урыс мехлары исә инглиз аксөякләре күңеленә бик хуш килде.

Патша чит ил сәүдәсен үз карамагына алды. Рәсәй өчен тышкы сәүдәне үстерү дәүләтнең чикләрен киңәйтү кебек үк бик мөһим иде. Шул унайдан белгечләр булдыру мәсьәләсе көн тәртибенә басты. Александрны да шушы максат белән үзенә дәштерде.

Алар хәзер сирәгрәк очрашалар. Патшаның фаворитлары күпкә яңарды. Шулай да Иоаннның Александрга мөнәсәбәте элеккечә калды, үзгәрмәде. Әлеге аудиенция шунын бер дәлиле иде. Дөрес, Иоаннның кәефсезрәк чагы. Польша короленең сеңлесен сорарга җибәргән яучылар буш кул белән кайтты. Санлашмадылар.

—Туганым, син чын азамат егеткә әверелгәнсең икән ич,—дип, Иоанн кулын аның киң җилкәсенә салды,—башлы-күзле итәргә вакыт җиткән лабаса, буйдаклык сиңа килешми.

Залдагылар патшаны хуплап шаулашып алдылар.

—Рәхмәт, падишаһым, фатихаң бик вакытлы,—диде Александр сөенеченнән күккә сикерергә житешеп,—рәхмәт!

—Кәләшеңне әллә сайладыңдамы?—дип белеште Иоанн мут елмаю белән,—миңа эш калдырмагансың димәк ки?

—Синең мөһимрәк шөгыльләрең дә җитәрлек, галиҗәнап!

Патша җавапны ошатты.

—Мактыйм, хан,—диде,—бездә патша эше баш өстендә, үземнекe куенымда кыйбласы белән көн күрүче түрәләр дә хәттин ашкан.

—Падишаһым, җаным—алланыкы булса, тәнем синеке, мин тулысынча синең карамакта.

—Бик хуш, туганым,—диде Иоанн,—илнең эше ир муенында, ирнең эше ил муенында, ди, сиңа да Англиягә барып, сәүдә мәсьәләләре белән шөгыльләнергә туры киләчәк, мин сине илче итеп билгелим. Бик дәрәҗәле вазифа. Тора-бара баш илче Непеяне алыштырырсың. Кенәз өлкәнәеп килә, сәфәргә йөрүләре авырлаша бара. Телне өйрәнү дә яшь кешегә җиңелрәк булыр. Өйләнү хәстәрен Англиядән кайткач тәгаенләрбез.

Александр китәр алдыннан Воротынскийларга рәсми визит белән барып, үзенең ниятен җиткерде.

Бу хәбәр воеводаның йөрәгенә тигәнәк булып кадалды, истән таеп торды, хәтта кулындагы бокалы төшеп ватылганны да сизмәде. Аны күрше бүлмәгә алып чыгып киттеләр. Ул тиз генә улы Алексейны дәштереп китерде.

—Без басурманнар белән туганлаша алмыйбыз,—диде яшь кенәз,—табанын ялтыратсын.

—Александр Сафакиреевич безнең кебек үк христиан динен тота, православие чиркәвенә йөри,—дип төзәтте улын воевода.

—Сафакиреевич, Сафакиреевич...

Алексей бер-бер артлы чәркә бушаткан арада өлкән Воротынский башын кырын салып, уйга чумды. Бу шактый озак дәвам итте. Шуннан соң гына уйларын сүз тезмәсенә тезеп, әңгәмәдәшенә җиткерде.

—Падишаһыбыз Александр Сафакиреевичка олы дәүләти вазифа йөкләгәндә мин дә катнаштым, тәхет залына чакырулы идем. Алар бер агачтагы алмалар кебек. Һәм Иоанн Васильевичның яшь илче ниятләгән никахка шәрәфле фатихасын юллаячагы берәүдә дә шик тудырмый. Безнең тәкәбберлек исә баш бәрәбәре торачак.

—Атакай, Кремль синең әшнәләрең белән тулы лабаса, шулар аша патшага йогынты ясарга кирәк, шәт, ялгышын төшенер.

—Иоанн Васильевич өр-яңа даирә туплады, иске даирәне турыдан-туры кысрыклыйлар. Сарайда хәзер безнең сүз үтми. Озын сүзнең кыскасы, ризалыгыбызны бирмичә булмас. Белүемчә, Наталья белән алар инде аралашалар да .

—Ул бәбәлән иркәсе нәрсә белә соң, чибәрлегенә кызыга булыр.

Шатлык эчендә кайгы бар, кайгы эчендә шатлык бар. Наталья да шул хәлдә иде. Көлде дә елады да. Билгеле, ул яшерен никахка да ризалыгын биргән иде. Әмма гаилә тормышын ата-ана фатихасыннан тыш башлап җибәрүне барыбер җаны өнәп бетерми иде. Күк капусы көтмәгәндә ачылды. Һәм күктән ишелеп бәхет төште. Әлеге бәхет хакына ул сөйгәне белән вакытлыча аерылышып тору кайгысын да сабырлык белән үткәрәчәк.

Воевода яшьләргә күрешеп сөйләшергә дә ирек куйды.

Ефросинья гадәттәгечә постка басты. Урыны да уңайлы, ул барысын да уч төбендәгедәй күреп тора, ә үзен абайламыйлар.

Уяулык зыян итмәс, чөнки Воротынский сөешергә түгел, кара-каршы утырып сөйләшүне генә фаразлады. Шуңа күрә очрашу княгиняның хадимәсе, ягъни Ефросиньяның күз алдында үтәргә тиеш иде.

Гыйшкый нәфесне тышаулап буламы соң? Үбеш-кочыш мәгъшукларның йөрәкләренә төште.

—Мин бер теләгенә дә каршы килмим,—дип пышылдады кыз егетенә уралган хәлдә.

—Күңелемә коткы салма, әүвәл никах,—дип кайнар тынын өрде Александр.

—Сынау өчен генә әйткән идем,—диде Наталья,—шатландырдың, чын хан икәнсең.

Александр «хан» сүзенә суга батканда саламга ябышкан кешедәй ябышты. Йөгәнсез хисләр өермәсен басу өчен бу бик уңайлы форсат иде.

—Беләсеңме, Кремльдә без өчәү бит, өч Казан ханы,—дип, гүзәлкәйнең кочагыннан арынды.—мин: Александр—Үтәмешгәрәй, Ядкәр—Симеон һәм дә Шәехгали...

—Миңа бер хан да житә,—диде кыз иреннәрен бүлтәйтеп.

—Бу житди мәсьәлә,—диде Александр янә дә читкәрәк елышып,—син бу нечкәлекләрне белеп торырга тиеш, Наталья, без бит бер жан—бер тән буласы затлар.

—Әйт соң, мин нәрсәне белеп торырга тиеш.

Александр сөзелеп кәләшенә бакты. Ул монарчы Натальяга туры карарга кыймыйча күз генә аткалап ала иде. Һәм кыз ничектер күнелендә ап-ак йөзле булып уелып калган. Озынчарак ак йөз! Ә аның йөзе түгәрәгрәк икән ич. Ак та түгел, шикәрдәй ягымлы тоныкк төс. Күзләре зур, зәңгәр. Алары туры килә. Борыны да—очы аз гына өскә таба тырпаебрак торган почык борын. Ә килешле. Ихтимал, кемгәдер Наталья егылып китәрлек чибәр дә күренмәс, әмма Александр өчен суырып йотардай матур иде Наталья, матурлык алиһәсе.

—Кәләшең чибәрме?—дип елмайды Наталья аның йотылып карап торуыннан кәефе килеп,—иркәләр—назлар иден...

Александр вәсвәсәгә бирелмәде, кызның кулыннан үбеп алды да, өзелгән сүзен ялгап жибәрде.

—Бер казанга ике тәкә башы сыймый диләрме әле? Без менә шул хәлдә. Дөрес, Шәехгали хан Касыймыннан читкә чыгып йөрми хәзер. Ә менә Симеон чамадан тыш көнчел, хөсетле вә һавалы бәндә. Пычрак ягарга гына тора, патшага төрле гайбәт сүзләр житкерә. Имеш, Анастасияне сихерләүдә мин дә катнашканмын. Казанда үз башы гына булсынга жан-фәрман тартыша. Ходай каршында да, патшабыз алдында да минем намусым пакь-чиста. Иоанн Васильевич моны үзе дә яхшы белә. Шул ук вакытта, Симеонны да үз янында тота, аңа Руза каласын багышлады. Дөресен әйтергә кирәк, Симеон яхшы воевода, орыш остасы.

Бу хакта сүз кузгатуымның сәбәбе шул, әлеге гайбәтләрнең атаң—мөхтәрәм воевода кенәз Воротынскийга да, сиңа да килеп ирешүе бар. Минем һич тә нахак бәла иясе булып, сезгә күләгә төшерәсем килми.

—Кайгырма, хан,—диде Наталья,—синең кебек үк мин дә сүз кешесе. Онытма, без бер-беребезнең каны белән ант эчтек.

***

Караб жинелчә генә чайпала-чайпала дулкыннарны ерып, алга омтыла. Ә жилкәннәр киерелгән. Дөрес юнәлеш биргәндә жилне таба беләләр икән.

—Дингезнең тоз сеңгән шифалы һавасы сулыш өчен ифрат та файдалы,—диде Непея,—күкрәкләр киңәеп китә.

—Бер жан иясе дә күренми, су өстендә акчарлаклар була торган иде, алар кая соң?—дип шөбһәләнүен белде Александр. Очсыз-кырыйсыз дәрья эчендә ул үзен тузан бөртеге шикелле генә хис итә иде.

—Акчарлаклар ярдан ерак китми бит,—диде Непея,—жан иясе мәнфәгатендә исә ялгышасыз, яшь дустым, әнә, сул якка күз төшер әле.

Александр офык читендәге жилкәнсез ике кара көймәне шәйләп алды. Офык йоткысында югалышып-югалышып та торалар, янә калкып чыгалар.

—Дөньядагы иң зур балык,—дип аңлатма бирде илче.

—Балык?!

—Әйе, балык, кит балыгы.

—Алар карабка һөжүм итмиләрме соң?

—Юк, юашның юашы ул мәхлуклар. Ә үзләрен аулыйлар, мае-сөяге өчен.

Көн арты көн үтте. Тора-бара Александр да диңгезгә ияләшә башлады. Шуңа тәңгәл рәвештә әңгәмәләрнең дә асылы үзгәреш кичерде. Хәзер инде сүз башлыча Англия, инглизләр турында иде. Непея аңа бик күп файдалы мәгълүмат бирде.

Инглизләр женаза мулласыдай бик төгәл халык икән, һәр минутлары исәптә, ди. Чакырылган җиргә нәкъ әйтелгән вакытта барып, билгеләнгән арада китеп тә баралар, имеш, кеше өстендә тормыйлар. Өстәлләреннән шәраб өзелмәсә дә, исергәнче эчү гадәте юк икән. Шунын белән бергә, сыйлаганны яраталар ди, үз кесәләреннән чыкмаса, хәтта бокалларны да санап тормыйлар икән. Билгеле инде, инглизләр дөньяның иң зыялы кавеме!

Александрны инглизләрнең кунактан хуҗалар белән саубуллашмыйча да, сый-хөрмәт өчен рәхмәт тә әйтмичә качып китү гадәтләре гаҗәпләндерде. Бу соң гап-гади оятсызлык лабаса.

Александр Англиядә үткәргән бер ел эчендә боларның барысын да үз җилкәсендә татыды. Инглизләрнең кабарынган ата күркәдәй кукраерга маһир икәнен дә, раштуада бер көрәк кар бирмәс саранлыкларын да өстәр иде әле ул әлеге сыйфатларга. Театр дигән сәхнәгә мөкиббән булып утырулары үзе бер сәер тамаша. Ул туп тибү тагын. Башка сыймастай хәлләр. Шулай да аның йөрәгенә үткәне инглиз язуы булды. Урыста бер хәреф бер аваз белдерә. Аларныкында исә боткадагы ярмадай буталып беткән. Аваз хәрефкә бөтенләй туры килми. Аваз башка, хәреф башка. Берничә хәреф укмашып, бер аваз да тәгаенләргә мөмкин. Дөрес, ул язу өлкәсенә тирәннән кермәде, башлыча сәүдә мөнәсәбәтләрендә кулланыла торган сөйләм үзенчәлекләрен генә өйрәнде. Әйтергә кирәк, ул рәсми булмаган вәзгыятьтә инглиз сәүдәгәрләре белән тылмачсыз да аралаша ала. Мәскәүгә кайткач та тел өйрәнүне дәвам итәчәк. Башкалар өчен дә мөмкинлекләр тудырылачак. Аерым алганда, Мәскәүдә Инглиз үзәге ачу турында килешенде. Лондоннан бер төркем белгеч Рәсәйгә чыгып та китте инде.

Шөкер, ел заяга үтмәде. Ә җаны барыбер Мәскәүгә тартылды. Белеп әйткәннәр шул: үз илең—Гөлстан, кеше иле—чүрстан. Англиянең томанлы җепшек кышыннан соң Архангелнын салкынча җәе дә Александрга оҗмах сыман тоелды. Яр буендагы әрсез акчарлакларның чәрелдек тавышы гүя ләззәтле моң. Беренче тапкыр гына күргәндәй һәр нәрсәгә шаккатып, исе китеп барды:

—Кара әле, кара, нинди матур чыршы!

—Тапкансың матур нәрсә,—диде сак башлыгы сәерсенебрәк,—чатлы-ботлы кәрлә. Җәй кыска, шуңа күрә үсә алмый, туфрагы да туфрак түгел.

Александр бу сүзләргә колак та салмады, чөнки күңеле ләззәтле уйлар дәрьясында чайпала иде. Шулай булмыйча, тиздән кәләше белән очрашачак ич!

Сагынды, бик сагынды ул аны. Күрешү вакыты якынайган саен, сагыну хисе дә көчәя генә барды. Их, әкияттәге кебек тылсым иясенә әверелсәң иде дә, керфек кагып, күз ачып йомганчы сөйгәненнең кочагына керсәң иде! Шуңа күрә атларын чаптырды да чаптырды. Ә ике-өч көннән бу тизлеккә чыдый алмыйча алар бер-бер артлы сафтан да чыга башлады.

—Кенәз, ашыгу борча тотканда гына ярый,—дип, ризасызлыгын белдерергә мәҗбүр булды җайдакбаш,—якын ара түгел бит.

Никадәр генә ашкынып кайтса да, Мәскәү Александрны кочак җәеп каршы алмады. Шәһәр капкасы янында эскортны тупас рәвештә туктатып тентеделәр.

—Барыгыз да ат өстеннән төшегез, тикшерү үткәрәбез,—дип акырды капка башлыгы. Нindидер сәер каравыл иде бу. Иярләренең бер ягында эт

башы эленгән, икенче ягында—саберке. Бер-бер юлбасар өере булмагае.

—Мин патшаның вәкаләтле илчесе,—диде Александр,—тоткарларга хакыгыз юк.

—Ха-ха,—дип йөгәнсезләнеп шаркылдады тегесе,—безгә патшадан кала барча юлчыларны да тикшерү хокукы бирелгән, беләсездер, шәт, күктән төшмәгәнсездер.

Буйсынырга туры килде, чөнки камалуда калдылар.

Александр әлеге хәлләрдән хәбәрдар түгел иде. Ул Мәскәүдән киткәч, ягъни 1564 елның кышында Иоанн бөтен казнасы, изге иконаларны һәм дә башка байлыкларны чаналарга төяп, гаиләсе, яңа даирәсе белән Александр бистәсенә күченеп китте. Имеш, боярлар аңа каршы фетнә әзерли, тәхетенә кул салырга чамалыйлар.

Башкала ятим калды. Халык өстенә кайгы болыты төште. Елаш-кычкырыш, кая барып бәрелергә белмиләр. Патшасыз ничек яшәмәк кирәк. Илне чит баскыннардан кем саклар? Көтүчесез көтү үлемгә дучар. «Ым гына каксын, хыянәтчеләрне үзебез казыкка утыртырбыз»,—дип шаулашты халык.

Руханилар, боярлар, югары түрәләрдән махсус депутация оештырылды. Депутация әгъзалары, ниятләре изге икәненә ишарә йөзеннән, патша тарафына яланаяктан җәяүләп чыгып киттеләр. Максат бер генә—патшаны тәхетенә кайтару.

Ике айдан артык ялындырганнан соң Иоанн, ниһаять, ризалыгын бирде, февральнең икенче көнендә Кремльгә аяк басты. Аны танырлык түгел иде. Эченнән энә үтәрлек, йөзендә борыны гына утырып калган. Элекке типсә тимер өзәрдәй утыз дүрт яшьлек азамат ир-егетнең шәүләсе генә иде бу. Аның урынына, күзләре усал, карашы мәрхәмәтсез, сүзләре үтергеч.

—Үз дәүләтемдә чын тәртип урнаштырачакмын,—дип башлады ул тәхет нотыгын,—кем дә кем каршылык күрсәтә, белегез, аны үлем көтә. Җәзалы үлем. Кырын уйларыгыз өчен дә җавапка тартачакмын. Чөнки бу мәсләккә үзегез вәкаләт бирдегез. Ул вәкаләтнең чикләре юк.

Күп тә үтми, опричнина дип аталган алты меңле шәхси гвардия кылыч астына басты. Алар аяусыз ау кампаниясен башлап җибәрделәр. Рәсәй канга батты. Шик астына эләктеңме—бетте, сине байлыгың да, дәрәҗәң дә, ыру-нәселең дә коткара алмый.

Каравыл аларны бик җентекләп тентеде, һәр нәрсәне энә күзеннән диярдәй үткәрделәр. Бигрәк тә затлы бүләкләргә күзләре кызды.

—Нәфсегезне уйнатмагыз,—диде Александр,—алар патшага аталган бүләкләр.

Патша сүзе бу юлы нәкъ урынына сенеп утырды.

Икенче көнне иртән иртүк Александр патша катына юнәлде.

Таныш диварлар, Кремльнең үзенә генә хас һавасы! Алар аңа бик якын иде.

—Һо, берәү диңгез артыннан кайткан, күрегез әле, танырлык та түгел.—дип, патша кочаклап ук алды. Хисап нотыгын да ошатты. Тәүге тост та аңа багышланды.

—Туганым, өметле яшь илчебез Александр Сафакиреевич хөрмәтенә!

Иоанн бушаган бокалын идәнгә бәрде.

Александрга гүя канат үсеп чыкты, шик-шөбһәләре онытылды, барысы да элеккечә, һични үзгәрмәгән! Ул шул кадәр бәхетле иде ки, Иоанның көмеш төсе куна башлаган сакал-мыегын да, чырага калган йөз-битен дә абайламады. Бәхет алдында сайрап кунганда күзләр томалана икән. Хәзер шул бәхет кошын кулга ияләштерү вакыты житте.

—Барча урыс жиренең бөек падишаһы Иоанн Васильевич галижәнаплары,

син мине Англиядән кайткач, башлы-күзле итәрмен дип шатландырган идең. Вакыты җитте, хәер-фатиханны бирсәң иде.

Иоанн урыныннан торып, уңлы-суллы йөрештереп алды. Аннан соң бармагын янап әйтте:

—Син тиздән Англиягә тагын китәчәксең,—диде,—бу юлы яучы илче сыйфатында. Мөхтәрәм королева Елизаветага минем шәхси ярлыгымны тапшырырсың. Королеваның Мария атлы тудыкасы[13] бар, шул чибәркәйгә җәтмә салу эшен башлау мәслихәт булыр дип саныйм. Дөрес, әле өйләндем генә, ләкин бу киртә булмаячак. Бабам Иван III тә Византия императорының сеңлесе Софья Палеологны яраткан. Бу никах Мәскәүгә зур файда китергән. Англия белән туганлашсак, бөтен дөньяны кулыбызда тотачакбыз.

—Бирсен Ходай,—диеште даирә.

—И, бөек падишаһым, мин синең теләсә-нинди биремеңне үтәргә әзермен,—дип башын күкрәгенә салды Александр,—тик шунысын да белеп тор, Англиядә дәрәҗәле, житди, ышанычлы кешеләрне генә үз итәләр, сүзләренә колак салалар.

—Синдә боларның барысы да бар,—диде Иоанн.

—Инглизләр өчен абруйлы кеше—гаиләле кеше.

Иоанның йөзе җитдиләнде.

—Теге вакытта кәләшем бар дигән идең, кем инде ул бәхетле чибәркәй?

—Синең иң булдыклы воеводаң Воротынскийның кызы княгиня Наталья Михайловна!

Дивар буйлап шом дулкыны йөгереп узды. Кешеләр сулышларын кысып, таштай хәрәкәтсез калдылар. Александр гөнаһсыз күзләре белән әле патшага, әле аның яраннарына күз төшереп ала: ни-нәрсә булды соң—һич аңлашылмый.

—Хыянәтче ул синең воеводаң!—дип, Иоанн тын һаваны ярды,—ошбу исемне минем алда башка кабатлыйсы булма!

—Галиҗәнап, кенәз Воротынский синең өчен утка-суга кергән хәрби җиһангир...

—Акыл сатма!

—Мин княгиня Наталья Михайловнага вәгъдә бирдем, падишаһым,—диде Александр,—мин кан антымны боза алмыйм...

Иоанн кулындагы хәнҗәрен болгый-болгый йөгереп килде дә, Александрны изүеннән эләктереп алды.

—Әй, син, үләт, эчеңне айкыйм бит.

Александр куркырга өлгергәнче үзе шаһит булган канлы фаҗигане исеннән үткәрде. Ул вакытта патша фетнәче дип, кайчандыр бер табактан ашаган яшьлек дусты (якын дусты) күренекле сәясәтче кенәз Федорга пычак аткан иде. Инде, әнә, үзенә дә чират җитте.

—Вон, күземә күренмә, үләт!—дип акырды күзләрен кан баскан Иоанн.

Александр күкрәгенә хәнҗәр керүен көтә иде. Шуңа күрә аңышмыйчарак торды.

—Вон!

Аны бүлмәдән эткәләп чыгардылар.

—Бәхетең бар икән, кенәз,—дип пышылдады колагына сакбаш.

Дөрестән дә, Александр Рәсәйгә опричнина афәте төшкәннән соң патша белән сүз көрәштерергә батырчылык иткән куш йөрәкләр арасында экзекуциягә дучар ителмәгән беренче кеше иде. Ул исенә килүгә, Воротынскийлар утарына ашыкты. Ә анда каравылчы һәм аның этеннән

[13] Тудыка—кузина.

башка бер җан иясе дә юк иде. Йортның тәрәзәләренә, ишекләренә такта кагылган, кайчандыр чәчәкләр хозурлыгындагы ишек алдында кеше буе булып алабута үләне үскән, утар ташландык хәлдә иде.

Воеводаның язмышы турында азмы-күпме хәбәрдар иде инде ул. Патша, шул әлеге дә баягы, фетнә хәзерләүдә гаепләп, аны гаиләсе белән Ак күл сөргененә сөргән икән. Биләмәләренә, утарына, барча мал-мөлкәтенә табу салган.

Александрның күңеле катты. Һәм беренче мәртәбә Иоанн кылган гамәлләрнең хаклыгын шик астына алырга җөрьят итте. Алла урынына күрә иде бит ул аны. Их, Иоанн Васильевич, Иоанн Васильевич...

Йокысыз төннән соң, әзергә бәзер булып, артыңны кысып утырыр чак түгел икән, дигән фикергә килде Александр. Үз бәхетең өчен иң элек үзеңә көрәшергә кирәк. Натальяга биргән вәгъдәсен ул үтәргә бурычлы!

Беренче булып, Александр кенәз Василий Грязнойның ишеген какты. Ул аны ярдәмчел, ихтирамлы сәясәтче дип белә иде. Нотык мәҗлесендә ул аны тәүгеләр рәтендә ихластан котлаган иде, «Кенәз синең өчен минем ишекләр һәрвакыт ачык»,—дип дустанә мөнәсәбәтен күрсәткән иде.

Грязной аны көзге каршында ясанган хәлдә кабул итте. Кыска юан бармаклары белән ике катлы иягенә суккалап алды да, урынына килеп утырды.

—Кенәз, мине бүлдермичә генә тыңла әле, зинһар,—диде Александр хәл-әхвәл белешкәннән соң,—каядыр җыенасың ахры, кыска тотарга тырышырмын.

—Рәхим ит.

—Мин воевода Воротынский мәсьәләсе белән йөрим,—диде Александр,—көнчеләре аңа нахак бәла яккан булырга тиеш...

—Патшабыз Иоанн Васильевич кабул иткән карар шәрехләүгә мохтаҗ түгел!

—Зинһар, тыңлап бетерсәң икән.

—Дәвам ит.

—Үзеңә дә мәгълүм, воевода Воротынский Рәсәйнең танылган җиһангиры. Казанны патшабызның аяк астына салучы да нәкъ менә Воротынский. Хаҗитархан да аның катнашында яуланды. Көнбатыш юнәлешендә исә әлегә максатыбызга ирешә алганыбыз юк. Ливония белән Польша Балтыйк диңгезенә чыгарга һич ирек бирмиләр. Югыйсә Иоанн Васильевич Аурупага тәрәзә ачуны кичектергесез бурыч дип бәяли. Мин воевода Воротынскийның тәҗрибәсе, таланты анда да уңыш китерер иде дип саныйм. Андый хәрби башлыклар патшабызга бик кирәк. Аның урыны сөргендә түгел, орыш кырында.

Александр төкереген йотып куйды да, үтенечен җиткерде.

—Кенәз, бер җаен табып, ошбу фикерләрне Иоанн Васильевичка җиткерсәң, бөтен Рәсәй сиңа рәхмәтле булыр иде.

Грязной такыр башын учларына салды. Александр хушлашып чыгып киткәндә дә рәвешен үзгәртмәде.

Төштән соң бар булган үпкә-рәнҗүләрен читкә тибеп, Александр кендәше Симеон янына китте.

Ни гаҗәп, Симеон аны кочак җәеп каршы алды.

—Әйдүк, әйдүк, хан, аралашып яшәүне китап та мактый,—дип, бер алдына, бер артына төште.—Без бит якташлар, тамырларыбыз Нугайда, җаныбыз Казанда. Язмыш барысын да пыран-заран китереп ташлады. Их...

—Хан, син патшабызның данлыклы воеводасы,—дип, ватандашының салпы ягына салам кыстырырга ашыкты Александр—1555 елда Кырым ханы Дәүләтгәрәйне бәрелеш башланганчы ук качарга мәҗбүр итүеңне әле

дә булса горурланып искә төшерәбез. Бу кансыз орышны хәрбиләр урыс коралының зур дәрәҗәсе дип бәһали.

Симеонның авызы кинәйгәннән-кинәя барды. Чөнки яшь әңгәмәдәше йөрәгенә ятышлы сүзләр сөйли иде. Әйе, Иоаннның ышанычын урыс җиреннән Дәүләтгәрәй ханны куып җибәрү бәрабәренә яулады ул. Көчле иде Дәүләтгәрәй, алтмыш мең җайдак кына санала иде гаскәрендә.

Әңгәмә чәй табынына күчте.

—Булды андый хәлләр,—диде Симеон буы чыгып торган чәенә өрә-өрә,—патша үзе күреп торды безнең каһарманлыкны.

—Белүемчә, воевода Воротынский гына синең белән тинләшә аладыр,—дип, Александр янә мактау учагына ялкын өстәде.

—Дау бидад[14], Казанда шул дуңгыз әсир итте ич инде мине,—диде Симеон кеткелдәп көлә-көлә.

—Олуг воевода сөргендә җәфа чигә икән, кемдер өстеннән торган.

Александрның соңгы җөмләсе ханны сискәндереп җибәрде. Миңа сылтамакчы итенмиләрме болар, дип шөбһәгә төште, ахры. Шымчы өстеннән шымчы, берәүгә дә ышаныч юк.

—Житешеп кенә утыр әле, безнекеләр аш-суга бик оста,—дип, Александрны кыстый башлады.

—Ризыкларыгыз бик тәмле, рәхмәт,—диде Александр,—Англия аш-суына һич күнегә алмадым.

Ул ханның шиген басар өчен Англиягә сәфәре турында сөйләп алды. Ә килүенең максатын саубуллашканда гына әйтте.

—Хан, воевода Воротынский хакында патшабызга гадел фикерләребезне житкерәсе иде бит, кайгы агач башыннан түгел, адәм башыннан йөри, ул яхшылыкка яхшылык белән җавап бирәчәк.

Симеон аның үтенечен ишетмәмешкә сабышты.

—Син анаеңа ошагансың, хан, ул дөньяда бер чибәр иде,—дип, Александрны көйләп-чөйләп озатып җибәрде.

***

Александрның өмете тәмам киселгән иде инде. Теге вакытта капчыкка томалап, елгага ташланган халәттә иде ул. Кул-аягың таза, башың эшли, әмма үз-үзеңә ярдәм итә алмыйсың. Ә хәзерендә бердәнбер чара—монастырь. Ул шулай хәл итте: мал-мөлкәтен чиркәүгә яздырачак! Әлеге зур кайгыдан фәкать үзенне тулысынча Тәңрегә багышлау, аңа табыну, эчкерсез гыйбадәтләр белән генә арынып буладыр, мөгаен.

Һәм кукне ярып, аяз көнне яшьнәгән яшендәй көтмәгәндә адәм ышанмастай хәбәр килде: воевода Воротынский Ливония чигендәге зур хәрби төмәннең башлыгы итеп билгеләнгән. Димәк тырышлыгы бушка китмәгән. Бу исә воеводаны ярлыкау, утарын, биләмәләрен, мал-мөлкәтен кире кайтару дигән сүз! Бу—кенәз, Казан ханы Александр Сафакиреевичның княгиня Наталья Михайловна белән никахына рәсми фатиха дигән сүз!

Александр хәлсезләнеп кәнәфиенә ауды, бик озак үксеп-үксеп елады. Фикерләү куәте кайтып, башына килгән беренче аек уе Иоанн патша турында иде: «Ходаем, уйларым белән шул изге затның абруена күләгә төшерергә вазганым өчен нинди генә катгый сынаулар бирсәң дә ризамын, гомерем буе аның исәнлеген, дәүләти хозурлыгын теләп дога кылачакмын... Кичер, туганым Иоанн Васильевич...»

Кичке якта, бераз тынычлана төшкәч, йомышчысы Афанасийны чакыртты.

[14] Дау бидад—ни кызганыч.

—Минем ышанычлы сак атчабарларымны ал да, Ак күлгә чыгып кит, дип күрсәтмәсен ирештерде,—княгиня Наталья Михайловна Воротынскаяга юллама язуымны тапшыр. Ефросинья белән никахың турында да сүз кузгат. Мин хуплыйм.

—Җәнабе гали, мин синең гомерлек колың...

—Юл озын, катлаулы, сак булыгыз,—диде Александр егеткә шатлыгы эчендә эреп китәргә ирек бирмичә.

Юллама язуы берничә генә җөмләдән гыйбарәт иде: «Хөрмәтлем княгиня Наталья Михайловна! Патшабыз сезне рәсми рәвештә минем кәләшем дип игълан итте. Котлыйм. Яратам. Түземсезлек белән күрешүебезне көтәм. Ихтирам белән Казан ханы, Иоанн патшаның махсус илчесе, кенәз Александр Сафагәрәй. 1566 сәнә, август аеның утызынчы көне.»

Дөнья түгәрәк, тормыш бөтен. Кешеләрнең йөзе якты, нурлы. Үзләре шундый мәрхәмәтле, шундый рәхимле, алларына барып тезләнәсе, кочасыүбәсе генә килеп тора. Һәммә нәрсә матур: көн матур, кояш матур, кала матур, агач-куаклар матур. Матур дөнья, матур гамәлләр...

Шушы матур дулкында матур төштәй анасы хәтеренә килде, колагында Симеонның сүзләре яңгырады: «Син анаеңа охшагансың, хан, ул дөньяда бер чибәр иде»,—дигән иде ул.

Александр көзгедәге сурәтенә карап бакты. Көзгедән озынчарак коңгырт йөзле, зур зәңгәр күзле, кош каурыйларыдай тезелешеп киткән тигез ак тешле, килешле сакал-мыеклы, киң җилкәле олпат егет карап тора иде.

Димәк, анасының да күзләре зәңгәр булган. Кызык, нишләп атасына охшамады икән?

Хәтереннән җуелган дисә дә, күңелендә анае белән соңгы очрашуының аерым мизгелләре барыбер саклана икән әле.

... Анаен өзгәләнеп, сабырсызланып, түземсезләнеп көткән мәле иде. Чит-ят кавем арасында ул үзен бик бәхетсез хис итә иде. Бу тәмугтан аны яраткан анасы йолып алачак. Алар элеккечә сөенеп-ератышып яши башлаячак.

—Улым, сау бул, мин тагын килермен...

Коткару урынына яңгыраган шушы бер җөмлә аның ератуын нәфрәткә әйләндерде дә куйды. Ниндидер тупас сүз дә әйтте бугай әле. Сүзе исендә калмаган, ә ханбикәнең нәүмиз карашы бүгенгедәй күз алдында. Сагыш, чарасызлык, өметсезлек, билгеләмәләре уйлап табылмаган тагын әллә нинди хәсрәтле хисләр белән тулы караш иде бу. Хәзер белә, ханбикәне Шәехгалигә үз ирегеннән тыш биргәннәр. Күрәсең, хан аны үз янына сыйдырырга теләмәгән.

Ана белән бала икесе ике ярда торып калды. Сөенбикә мөселман өммәтендә, Александр—христианлы. Беләсе иде, ул анасы рухына чиркәүдә шәм куя аламы икән? Моңа кадәр бу хакта уйланганы булмады. Шунысы тәгаен ачык: теләсә-нинди шартларда да Сөенбикә ханбикә Александрның анасы булып кала.

—Анаем, мин сиңа риза-бәхил, соң булса да догаларымны кабул ит,—диде әнкәсенең күңелендәге сурәтенә мөрәҗәгать итеп,—рухың тынычлансын. Улың бик бәхетле!

Александр тәрәзә янына басты. Көн төгәлләнеп килә иде инде. Кояш, нурларына төренеп, бишегенә төшеп бара. Тын. Ара-тирә яфракларны иркәли-иркәли салмак җил генә дулкынланып куя.

Гомере барның күреге бар, нинди күркәм бу тормыш!

—Мөхтәрәм кенәз, кичке ширбәтегездән рәхим итегез, тыныч йокы, Ходай тәмле төшләр насыйп итсен!

—Рәхмәт, Аграфинья,—диде Александр табынчы туташка тәрәзәдән

күзләрен алмыйча гына,—башка бернәрсә дә кирәкми, китәргә мөмкин.

Ул баеп баручы кояшка, кала өстенә инеп килүче энгер-менгер манзарасына байтак вакыт хозурланып карап торды. Аннан соң ширбәтен эчеп, ятагына ауды. Озакламый күзләре йомылды. Ә иреннәрендә—елмаю.

Агулы ширбәт җанын өзгәндә дә бәхетле иде әле ул.

Рәсәйдә бер мәчегә ике эт ябышкан дәвер иде, афәтле дәвер.

## ДҮРТЕНЧЕ КЫЙССА

### Сөенбикә атым...

Татли фатирга урнашу өчен хосусый гаиләгә тукталуны мәгъкуль күрде. Бу бернинди кыенлык та тудырырга тиеш түгел иде, чөнки шәһәрнең Иске татар бистәсе тулаем шәхси йортлардан гына гыйбарәт. Шулай да әбилебабайлы татар гаиләсенә юлыкканчы шактый таптанырга туры килде.

Бистәнең читенә җитеп киләләр, тик әлегә корыны бушка әйләндерү генә. Татли да арыды. Әүвәлге таләбеннән баш тартмакчы, кунакханәгә урнашырга да риза, ди.

—Эзләгән—бал агачы тапкан, дигән мәкаль бар мишәрләрдә, княгиня,—диде Марсель каршыдагы өйгә күрсәтеп,—без эзләгән мишәр бабасы менә шушы сарайда яши дә инде, әйдәгез, рәхим итегез.

Чыннан да, капканы кырпы сакал-мыеклы, киң вә озын ак күлмәге өстеннән кара камзул киеп җибәргән фырт бабай ачты. Әйтерсең лә Хәлил Әбҗәлиловның Хуҗа Насретдины.

—Әссәламегаләйкем, дин кардәшем,—дип сәлам бирде Марсель.

—Вә-ә-галәйкем-әссәлам,—диде карт сузып кына,—сорашкан Сорилегә житкән, ди, кем дип белик үзегезне?

Марсель гозерен житкерде.

—Алай, бер фаразан,—дип, карт баш чүмеген кашып алды,—жәл, атыгыз юк, миндә кунак булып китәрсез дип тәкъдим иткән булыр идем. Ә халь болай. Мәнди атлы бер адәм зимерек кабак төбенә цыгып, урамнан үткән атлы кешеләрнең үзенә төшмәсен белеп: «Адә төш, миндә кунак булып китәрсез,—дип атеп калудан тәм таба, имеш.

Шулай бервакыт ат менгән бер адәм киц-кырын авылга килеп кергән. Кайда урнашырмын икән дип уйланып килсә, кабак төбендә басып торган әлеге Мәнди аңа:

—Адә, төш, миндә кунак булып китәрсез,—дип кычкырган. Юлчы бик сүенеп, рәхмәтләр атеп атыннын төшкән дә:

—Атымны кайда бәйлим?—дип сораган.

Мәнди аптырап калмаган, телен цыгарып күрсәткән дә:

—Минем кыбырцык телемә бәйлә,—дип әйткән, фаразан.

Бабай тел чарлаган арада болдырда кәшимир яулыгын иңенә жәеп салган юмарт йөзле ак әби пәйда булды.

—Их, шул цурсыз телкәйләренне, бәндә күрсә цат ябыша,—дип сукранасукрана баскычтан төште.—Мосафирларны үгә цакыр, кесе заптрыкым да гатувай.

—Рәхмәт әйтегез, княгиня, нәкъ кирәкле кешеләргә эләктек, мондыйлар хәзер музейларда да юк,—дип пышылдады Марсель.

—Рәхмәт, мьсё, үзем дә күреп торам.

—Тел дигән дәрья бар, төбендә энзе-мәрзән бар, белгәннәр цумып алыр, белмәгән коры калыр, ди, кортка, алай бик пыргыма[15] әле,—диде карт,—күр, ниндәй күәз кунаклар тотып алдым. Мәндиең бер якта торсын. Зерә дә

[15] Пыргыма – ачуланма.

изге гамәл артыннан йөрүләре, рәхмәт яугыры.

—Без кунакларга бик рад,—диде карчык,—үзебезнең дә оланнарыбыз бар, Москвада яшәйләр.

Әмиржан бабай белән Мәрьям әбинең өйләре үзләре кебек үк пөхтә, чиста иде. Бар нәрсә урынында, бар нәрсә тәртиптә. Татлиның урын-жир өстенә чүмәләдәй өелгән купшы мендәрләрне беренче күрүе иде. Алар чәчәкле-чуклы челтәр белән ябылган. Тәрәзә кашагаларына киҗе-мамык сөлгеләр эленгән. Һәр җиһаздан борынгылык, миллилек бөркелә. Өйнең һавасына кадәр үзгә иде, ниндидер йомшак, шифалы һава.

—Кул-битләрегезне югалаганцы сымараум кайнап цыгар, салма вакытына[16] кадәр авыз цылатып алырсыз,—дип, карчык табын хәстәрли башлады.

Әмиржан бабайның һәр гамәлгә карата мәзәге дә әзер. Тыңлаучылар булганда ник сөйләмәскә?

—Килен булып төшкәндә Мәрьям әбиегез ифрат та оялцан зат иде, хәзерендә генә цәц еланына[17] әверелде, фаразан,—диде карт сакалын сыпыргалап,—шулай...

—Сиңа атәм, берсәк авызыңны ябып тор пыжалста, кунакларның гайрәтен кайтарма,—дип, бабайны бүлдерергә омтылыш ясап карады карчык.

—Бәбәгенне ничу терәргә, кортка, анә гальнигың[18] ташый,—диде карт хикәятен дәвам иткән арада.—Але дә хәтердә, төшкән көнне үк Мәрьямнән белен пешерттеләр. Атерең бармы, килен хватлы[19].

—Үзең дә аша,—диде атаем.

Мәрьям оялып кына беленне үрелеп алды.

—Аша,—диде анаем да, атаемнан калышырга теләмәде.

—Юк, ашамаем,—дип, килен кәҗәләнә башламасынмы.

—Аша!

Каенатай белән каенанайның сүзен аяк астына салып ташлап булмай бит инде.

Кыстай торалар, Мәрьям цыптыра тора. Шылай итеп, ашамай торган мактаулы килен алтмыш беленне бөгеп цалды.

—Ыцана күрмәң шул уротның[20] ялганына,—дип, карчык бабайга багып алды. Бу багуда яратудан гайре бер тойгы да юк иде.

Чәйдән соң Марсель Татли белән Хан манарасын карарга киттеләр.

—Искене тикшерсәң, яңаны белерсең, үткәнне тикшерсәң, хәзергене белерсең,—дип озатып калды Әмиржан бабай.

Касыймдагы архитектура истәлекләре Шаехгали төрбәсе, Авган бәк төрбәсе, хан мәчете, татар зиратыннан гыйбарәт иде. Ачык һавадагы бу музейга игътибар җитмәве күзгә бәрелеп тора, ул ярым ташландык хәлдә иде.

—Еллар үтә, гомер сүтә, ертык киңәя,—диде Марсель Әмиржан бабай рухында.

Татли аның шаяртуына битараф калды. Житдинен-житдие. Ияге очлаеп чыккан, иреннәре җеп шикелле кысылган, кашлары сынган... Атлауларына кадәр үзгә. Дәшми-тынмый гына әле башын артка чөеп манарага мөкиббән булып карап тора, әле учына алып, кирпеч балчыкларын уалый.

—Манараның һәр тузан бөртегеннән борынгылык бөрки,—дип телгә килде, ниһаять,—мондый табигый борынгылык белән тәүге тапкыр

[16] Салма вакыты—төш вакыты.
[17] Цәц еланы—үткен.
[18] Гальник—чәйнек.
[19] Хватлы—уңган.
[20] Урот—юләр.

очрашуым. Бу бит минем ата-бабаларымның да күз суы түгелгән җир!

—Борынгы һәйкәлләр күп,—дип, Марсель әңгәмәнең колачын киңәйтебрәк җибәрәсе итте,—әйтик, Таҗ-махал, Акрополь...

Татли башын чайкады.

—Сез әйткән ул һәйкәлләргә инде цивилизация микробы кергән, мсьё. Алардан борынгылык исе түгел, коммерция исе аңкый.

—Княгиня, матур хатын-кызларга акыл кирәкми диләр, адым саен сез аның киресен дәлиллисез,—диде Марсель соклануын яшермичә,—чынлап әйтәм.

—Рәхмәт, мсьё,—диде Татли шул ук җитдилек белән,—мине менә тагын нәрсә кызыксындыра: әйтегез әле, Бүләкшадбикә кабер ташы кисәкләренең Сөенбикә ханбикәгә мөнәсәбәте бармы?

—Тел төбегезне аңладым,—диде Марсель,—Бүләкшадбикәне Сөенбикә белән тиңләштерү тамырыннан дөрес түгел. Сөенбикә 1554 елда вафат була. Әлеге таш кисәкләре исә 1557 елга карый. Сөенбикә алтмышынчы елларга кадәр яшәгән суратта дә, Шәехгали хан аңа мондый дәрәҗәне күрсәтмәс иде. Чөнки аралары киеренке булган. Бу—бер. Икенчедән, Шәехгали Ак күл сөргеннәрен бергә кулга-кул тотышып үткәргән хатыны Фатыйма-Солтанны яраткан, бик хөрмәт иткән. Кабернең аныкы булуы ышандырарак төшә. Гомумән, Шәехгали даирәсендә кыз-хатыннар күп булган һәм алар ихтирамлы урын биләп торган. Ул Сөенбикәнең беренче ире, бертуганы Җангали ханның кызын тәрбияләп үстерә, зурлап кияүгә бирә. Бу яктан Шәехгалигә тел-теш тигезә алмыйсың.

—Мсьё, сезнең Сөенбикә манарасы тарихына карата булган мөнәсәбәтегезне дә беләсем килә иде минем,—диде Татли ханбикә турында сүз чыгуга.

—Бәхәсле мәсьәлә,—диде Марсель ,—кем сөйләсә, шуныкы дөрес, чөнки төгәл чыганаклар юк.

Татли аның белән килешмәде.

—Ялгышасыз, галим әфәнде, андый чыганак бар,—диде.

—Дәлилегез?

—Рәхим итегез, мсьё: Казанны буйсындыруда катнашкан кенәз Андрей Курбскийның истәлекләре. Ә ул Хан йорты янында биек манара булуы турында яза. Сөенбикә ире Сафагәрәй ханның җәсәде белән нәкъ менә шул манара янында хушлаша да. Тора-бара казанлылар аны Сөенбикә манарасы дип йөртә башлыйлар.

—Дөрескә охшаш версия,—диде Марсель.

Көн уңышлы узды, эзтабарлар бик канәгать калды. Күп бүләкләр төяп, кич-кырын гына фатирга кайттылар.

—Мона, самый рас,—дип каршы алды Мәрьям әби,—ләкшәмне[21] кабартып алам да, рәхәтләнеп шурба ашарбыз, бәлешем дә өлгерде.

—Әмиржан бабай кая соң?—дип белеште Марсель.

—Черкуш[22] кына шөгале бар ие, ул да керер, кәтә-кәтә кәтек булып бетте инде.

Бабай аш өстендә үзен муллаларча тотты. Әби әйбәтләп кенә боргычлаган иде, күрәсең.

Урысчаны да су кебек эчәләр икән, бернинди акцентсыз сөйләшәләр.

—Улларыгыз татарча беләме соң?—дип сорады Марсель.

—Белмәенчә сун,—диде әби,—атай-анай телен белмәскә теге, беләләр, җомга намазына мәчеткә йөриләр, зерә дә җәятле[23] улларыбыз.

[21] Ләкшә—токмач.
[22] Черкуш—кечкенә.
[23] Җәятле—зиһенле.

—Инженерлар,—дип ярдәмгә килде бабай,—үдә аман үзебезцә генә сүләшәбез без.

Татлиның үз туксаны туксан.

—Шәехгали ханга ихтирамыгыз бармы Әмиржан Әкътәсович?—дип белеште.

—Атай-анайны ницек итеп ихтирам итмәскә мөмкин?—дип җавабын сорау җөмләдән башлады карт,—безнең, канәтем, җиде буын бабаларыбыз шушы игелекле җирдә гумер сөргән. Ханнарыбыз халыкны кысмаган, үкмәктән өзмәгәннәр, кәпечник[24] булмаганнар. Шәехгали хан арада иң дәрәҗәлесе. Москва да аның сүзеннән цыкмаган. Без аны догабыздан калдырмайбыз.

—Казанда Шәехгали ханны татар халкына хыянәт итүчеләр рәтендә саныйлар.

Әмиржан картның мона һич тә исе китмәде. Түбәтәен бармак очы белән генә калкытыбрак куйды да:

«Чья-бы корова мычала, твоя молчала»,—диде,—цырайларын умырмасыннар, кабәм, үз куллары белән патшабикәләрен Иванга тотып биргән умырткасыз адәмнәр алар, фаразан. Пәри башка, җен башка, ди. Казан үзенә, Ханкирмән үзенә. Ничу докымсызланырга[25]?

—Ә Сөенбикә ханбикә?

—Ул мөхтәрәм ханыбызның катыны, ханбикә. Затлы ханбикә. Тормышында зерә дә авырлыклар күргән бицара. Ханбикә дә безнең догабызда. Сүембикә ханбикәнең Ханкирмәнгә килен булып төшүенең Аллаһы Тәгалә хак кылган тирән мәгънәсе борын да атеп китим әле. Сүембикә цынында Казанның соңгы патшабикәсе. Ханкирмәннең ахыргы ханаме шулай ук катын кеше. Акмөхәммәдсәет бине Буләксәед Шаһколның кызы, Арыслангали ханның бицәсе Фатыйма-Солтан. Углы Сәедборһан ханның урыс патшасы кызы белән никахлашуына каршы төшә, аны тәхеттән ваз кицтерә, хукуматны үз кулына ала. Ифрат та тәкъва зат була. Аның вафатыннан суң Ханкирмән дә җан тәслим кыла. Мона шындый асыл ханбикәләр алар Сүембикә дә, Фатыйма-Солтан да.

Канәгатьме җавабымнан дигәндәй, карт Татлига күз сирпеп карап алды да, карчыгына ишарә ясады.

—Суңыннан,—диде Мәрьям әби,—кунакларны сүз белән сыйламайлар, кыстар иең...

—Цак вакыты, кортка, ашау кацмай ул.

Мәрьям әби ашъяулык астыннан юка гына бер китапчык тартып чыгарды. Ул гарәпчә басмада иде.

—Сүембикә бәете,—дип шәрехләде,—Рәшиди атлы цицән цыгарган. 1912 елда Казанда нәшер ителгән. Анаем бәгырем мирасы.

Мәрьям әби үтә бер саклык белән китапчык өстенә сыр баскан кулларын куйды да, җинел генә тамагын кырып алды. Шуннан соң ук бүлмәгә калтыравыклы моңлы көй таралды.

Тәкъдирләрдән бәндә узмай. Бер хода түзгәнгә
Әҗерен хода бирүче. Казага түзгәнгә.
Сүембикә атым, нугай затым, кайда минем яшь дәүләтем.
Сабый цагым, нурлы йөзем, морза кызы булган вактым.

Ут алыр чак җиткән иде инде. Ярымкараңгы мөхиттә бәет көйләүченең сагыш төренгән тавышы ханбикәнең үз сыктавы кебек янгырый иде. Күңелнең иң яшерен төпкеленә үтеп керә, йөрәкне сулкылдата. Сөенбикә

---

[24] Кәпечник – саран.
[25] Докымсызлану – ямьсезләнү.

үзе дә пәйда булыр да: «Минем хәлгә калмагыз, бар көчегезне гаделлек хакына сарыф итегез»,—дип әйтер төсле.

Моң дәрья булып агыла, гүя дөнья тоташ шушы моңнан яралган.

Дөньяга килгән адәм, кайгу күрмичә тормай,
Дөньяда шат йөргәннең дә тупрактыр урыны...

Бәет тәмам. Ә бүлмәдә чәч селкенгән тавыш та ишетелерлек тынлык. Һәрберсе уйда. Әйе, кеше гомере су өстендәге ак күбек кенә ул—өрүгә очып юкка чыга. Гомерне ничек кичерсәң, шулай кичәр, яхшы да үтәр, яман да үтәр, хак яшәүгә ни җитәр, ди халык. Ходай замананың сәкесен әнә шулай бик киң итеп корган, анда һәр нәрсәгә урын бар.

Татли урыныннан кубып, карчык алдына килеп тезләнде.

—Бу бәя биреп бетергесез мәгънәле кичә өчен мең-мең рәхмәт, Мәрьям Минһаҗевна,—диде яшь аралаш,—мин шуны аңладым, татар дигән асыл милләткә бернинди инкыйраз да янамый.

—Үгез муены өзелде, Бирдебәк тә киселде дигән мәкаль атеп калдырган бабаларыбыз,—дип, Әмирҗан карт Татлиның сүзләренә куәт өстәде,—туган-тумачасын кырып бетереп, ыруын кискән шушы тәхет колы халенә генә калмаек, фаразан. Мона нәрсә куркыныч.

—Сымараумны яңартып зибәрәем әле, оланнар, илла да хаксыз[26] бәндәләр икәнсез, Аллаһының рәхмәте төшсен,—дип сөйләнә-сөйләнә Мәрьям әби янә табын хәстәренә кереште.

***

Сөенбикә Шәехгалине кан калтырап көтте. Кулларының хәле китте, һич нәрсә тормый, ике-өч затлы чынаякны да идәнгә төшереп ватты.

—Ханбикә, табынны үзебез җыярбыз, утырып кына тор,—дип, хуҗабикәсенең хәленә керергә тырышты гасәбә туташ, хәлбуки үзенең дә тәне дер-дер калтырана иде.

—Зөфаф кичәсе бит, Хәдичә, һәр тәгам үзем аша үтәргә тиешле, йоласы шундый.

—Урын-җирегез бик йомшак, ханбикәм, чумып кына йокларсыз,—дип, түшәкче туташ та сүзгә кушылды.

—И, Сафагәрәй сөеклем, мин дә синең яныңа барыймчы, икәүләп бергә торыйкчы,—дип шыңшыды Сөенбикә,—белсәң иде тәннәрем тартмаганны...

—Чү, ханбикәм, акрын, монда стеналарның да колагы бар, сарай тулы шымчы,—дип кисәтте Хәдичә.

Ишек ачылып, анда өлкән ханбикә Фатыйма-Солтанның йорт үрдәгедәй мыймылтык гәүдәсе күренде. Бер хадимәсенең кулында су ләгәне, икенчесендә үлән төнәтмәсе иде.

—Ханның аякларын шушы төнәтмә белән юарсың,—диде ул төксе генә. Күренеп тора, ханбикәнең күңелен дә корт кимерә иде. Шулай булмыйча, арага көндәш керүне нинди катын-кыз тыныч кына кабул итсен соң?

—Суың кайнар булсын, хан кайнар суны хуп күрә,—дип тә өстәде Фатыйма-Солтан,—төнәтмә тәненә сеңсен, корытма. Үзеңне караштыр, төзән дип шырпы кадамакчы итенсә дә, Сөенбикәнең яшь туташларга биргесез сылу йөзен, зифа камыштай күркәм буй-сынын күзеннән үткәргәннән соң, теле әйләнмәде.

—Борчылма, мөхтәрәм ханбикә, синең сүзеңнән чыкмам,—диде Сөенбикә тыныч кына. Ә үзенең эчендә тәмуг утлары кайный иде, ничекләр

[26] Хаксыз—күндәм.

үткәрермен бу зөфаф кичен дип өзгәләнә иде күнеле.

Шаехгали аны күргәч үзе дә каушабрак китте кебек, һәрхәлдә, ишек катындагы чөйгә камчысын элә алмыйчарак торды.

—Исән-сау гынамы, Шаехгали, кулыңны юып ал да, табынга рәхим ит,—диде Сөенбикә йоласына туры китереп. «Ханны көттермәгез, җәтрәк кыланыгыз»,—дип хадимә туташларны да ашыктырды.

Сөлгене киявенә үзе тоттырды. Шаехгали ләм-мим, бары җыерылып төшкән йөнтәс калын кашлары астындагы чепи күзләре генә күчәргә асылган шар кебек әле бер, әле икенче тарафка суккалана иде.

—Сезгә китәргә мөмкин,—диде Сөенбикә хадимәләренә.

—Калсыннар!—дип өзде Шаехгали таушалган кырыс тавыш белән.—Ә син бер касә шәраб агыз. Мөлдерәмә булсын!

Шаехгали чалыш аякларын тәпелдәтеп өстәл янына килде дә баскан килеш кенә касәне авызына агызды. Шәраб урынына ятты, ахры, ләззәтле бер канәгатьлек белән кикереп җибәрде. Үзе үк «Әлхәмделиллаһ» дип, гамәлен хуплап та куйды.

—Инде, тәти кәләш, камчымны китер!

Ханның йоклаганда да камчысын кулыннан төшермәве күпләргә мәгълүм, ул аны дисбе урынына йөртә. Шуңа күрә Сөенбикә әлеге җәһәттән тәшвишләнмәде.

Шаехгали исә камчысын берничә мәртәбә шартлатып алды да, һич көтмәгәндә Сөенбикәнең аркасын сызып узды.

—Аһ!..

—Шыңшыма,—диде Шаехгали селтәнүеннән туктамыйча,—минем хозурымда Кырым көчеге Сафагәрәйнең исем-атын авызыңнан чыгарасы булма. Янә шундый хәбәр алам икән, гомереңбазда үтәр, аңладыңмы, Кырым сөйрәлчеге?

—Мин сөйрәлчек түгел...

—Аңладыңмы?—дип сорыйм мин синнән.—Җә!

Шаехгали янә кизәнде.

—Сукма, аңладым,—диде Сөенбикә.

Ул керфек астыннан гына яна табынчы хадимәсенә күз сирпеп алды. Тегесе аның карашын сизде, әмма йөзен үзгәртмәде.

Үзе корган тамашадан соң Шаехгали туташларны үзе чыгарып җибәрде. Бүлмәдә икәве генә калды. Кәләш киявен аягүрә сыйлады, чөнки тегесе «утыр» димәде. Ул инде еш-еш ятак ягына карангалап ала башлады. Бераздан урыныннан ук купты.

—Чишендер, аякларымны юу!

Исермәде дә ичмасам, дип уйлап куйды Сөенбикә. Чыннан да, Шаехгали беренче касәдән соң шәраб ягына борылып та карамады. Ашавы да чамалы икән. Сафагәрәй бер утыруда бер сарык бәрәнен әйләндереп куя иде. Тегермән көче су белән, адәм көче ашау белән, ди. Ашаганның гына биле нык...

—Суыңны кайнарла,—дип чекрәйде Шаехгали,—үзең монда, уйларың әллә кайда. Мине гел камчыга тотынырга мәҗбүр итмә.

Җә, Ходаем, әллә күрәзәлек тә итә инде дип ачынды Сөенбикә.

Кияү егетенең калын төкле аякларын юган арада аның күзләре тезләренә кадәр асылынып төшкән җыерчыклы корсагына төште. Шушындый да иләмсез булыр икән, җә, Ходай!

Түз, ханбикә, ир хакы—Алла хакы, дип үз-үзенә күрсәтмә бирде Сөенбикә, ир—аяк, хатын—олтырак.

Шулаен ул шулай, тик йомшак агачны корт баса, дигән әйтем дә бар ич әле. Җебеп тә төшәргә ярамый.

—Шәехгали, минем сиңа әйтер сүзем бар, игътибар белән генә тыңласаң иде,—диде ул хадимә кыз ләгәнне алып чыгып киткәннән соң.

—Җә!

—Камчы белән буйсындырырга мөмкин, әмма дә яраттырып булмый,—диде Сөенбикә,—матур гаиләнең нигезендә мәхәббәт ята дип беләм мин.

Шәехгали кәләшенә тутырып карап алды да иреннәрен кыйшайтты. Ул бит Сөенбикәне хадимәләр алдында кимсетү өчен камчылады. Ә ханбикә матур гаилә турында сафсата сата. Мәхәббәт, имеш.

—Шуны бел, ханбикә,—диде Шәехгали,—дөньяны көч тота. Камчы—көч ул!

Димәк, мәхәббәтне татып карамагансың, дип уйлап куйды Сөенбикә. Мәхәббәт—ул сулаган һаваң, уйлаган уең, җан авазың, күз суың, тойгыларың бизгәге, акылыңның томалануы, бетмәс-төкәнмәс ләззәт вә аерылышу ачысы. Аны күтәрү ай-һай авыр. Авыр, шуның белән бергә, зур бәхет тә. Ходай Сөенбикәгә дә әлеге бәхетне насыйп итте...

Шәехгали көчле куллары белән Сөенбикәне ятакка суырып алды. Бер утыруда бер сарык ашамаса да, гайрәте чамасыз иде. Сөенбикәнең якынлыктан болай җәфа чиккәне юк иде әле. Тыныч чагын, дәртсез көннәрен, бер кайгысыз гомер иткән вакытларын сагынып искә төшерергә генә калды.

Шәехгали шактый вакыт югалып торды. Патша фәрманы нигезендә Ливония чигендә булып, гаскәрләрнең хәрби әзерлеген тикшереп йөргән, имеш.

Сөенбикә дә элеккеге гадәте буенча үзенә шөгыль тапты. Казанда ул бик күп файдалы гамәлләр кылган иде. Мәгариф, кул сәнәгатен үстерү белән кызыксынды. Бигрәк тә көтепханә эшен җайга салу, китаплар җыюны бөтен күңелен биреп башкарды. Касыймда исә китаплар нигездә мәдрәсәләрдә саклана икән, алары да бик аз. Дөньяви китаплар гомумән бармак белән генә санарлык.

Ханбикә бу хәлне төзәтергә карар итте. Иң әүвәл булган китапларны барларга, бер урында тупларга кирәк иде. Аерым бина тапкалаганчы, Хан мәчетендә берәр бүлмәне вакытлыча файдаланып торырга мөмкин. Имам-хатыйб бик шатланып ризалыгын бирде.

Көнчелек, шымчылык хөкем сөргән җирдә сүз-гайбәт һәрвакыт алдан йөри. Гадәттә, ул кара буяуларга манылган була. Яшь ханбикәнең игелекле шөгыле дә ханга бозык кимәлдә килеп иреште. Әле юлда иде. Кайтуга хатынын тәхет бүлмәсенә чакыртты.

Сөенбикә бүлмәгә кергәндә Шәехгали камчысын бөгәрләп тоткан хәлдә ишекле-түрле йөренә иде. Ярдәмчеләре үрә каткан. Күренеп тора, аларның да тузанын кагып алган.

—Исән-сау гына йөреп кайттыңмы, Шәехгали, сәфәрең уңдымы?—дип хәл белеште Сөенбикә,—минем догаларымның да файдасы тигәндер, шәт.

Шәехгали сәлам алу урынына ачулы укларын очырды.

—Әй, син, Кырым сөйрәлчеге, ни җаның белән минем эшкә тыгылырга җөрьәт итәсең?

Сөенбикәнең йөрәге өзелеп төшәрдәй булып кысылды. Шулай да түзде, берни булмагандай сорап куйды:

—Нинди эш турында сүз бара, Шәехгали, һич нәрсә аңламыйм.

Хатынының горур тынычлыгы ханга дә тәэсир итте булса кирәк, камчы сабын сузып, урын күрсәтте. Утырырга ярый, димәк.

—Туганым Җангалинең тол хатыны булган өчен генә мин сине үземнеке иттем, шуның белән Ходай алдындагы бурычымны үтәдем,—диде Шәехгали

иреннәрен ялмый-ялмый,—югыйсә, Иоанн чукындыра иде сине. Мин алмаган булсам, хәзерендә берәр карт бояр астында яткан булыр идең. Аңлашылдымы? Рәхмәтең кая?

—Аңладым,—диде Сөенбикә, шулай да рәхмәт әйтергә теле әйләнмәде. Чөнки ул белә, Шаһгали барыннан да элек дошманы Сафагәрәйгә, аның рухына үч итү максатыннан никахлашты.

—Аңласаң шул, Казан гадәтләрен оныт, син монда ир хатыны гына, дәүләт эшләре хан җилкәсендә. Китап белән дөнья көтеп булмый. Беренче чиратта—гаскәр, корал!

Сөенбикә ишек катына юнәлде.

—Сабыр,—дип туктатты аны Шаһгали,—сүземне әйтеп бетергәнне көт: Казан дип бик авыз суыңны корытма, алар сине саттылар, ә мине куып җибәрделәр. Бу яктан без охшаш, икебез дә уеныбызны оттырдык.

Шаһгалинең сүзләре хак иде. Сөенбикә үзен-үзе белгәннән бирле уен эчендә кайнады. Башта Казан-Нугай-Мәскәү мөнәсәбәтләрен җайлау максатында аны Җангалигә кияүгә бирделәр. Аның вафатыннан соң, Кырым белән бозылган араны көйләү көн тәртибенә килеп басты. Монысында кыек атып, туры тигезделәр. Сафагәрәй хан аңа чын бәхет бүләк итте. Ләкин тиздән бу оҗмахның да капкалары ябылды. Уен гына дәвам итте. Шаһгали әйткәнчә, бу юлы аны сатып ук җибәрделәр. Янәсе, Казан ханлыгын саклап калалар. Иоанн төп башына утыртты үзләрен, алданганнарын сизми дә калдылар.

Сөенбикәне Казаннан кенәз Петр Серебряный алып китте. Төз гәүдәле, матур кыяфәтле, тәмле телле кеше. Йомшак мөгамәләсе белән теләсә-кемне үзенә җәлеп итә белә иде ул. Әсир ханбикәгә карата да искиткеч ихтирамлылык күрсәтте, теләгән һәммә гамәленә ирек куйды. Сафагәрәйнең каберенә барып хушлашу сыктавына да каршы төшмәде.

Ул чакта Сөенбикә бар дөньясына ачулы иде. Йөрәге сүрелмәс үч белән ярсый, өзгәләнә. Авызында бары каһәрле сүзләр генә. Хәтта үзен озатырга килгән кешеләргә дә каргышын сипте: «Әй Алла! Безнең көнчебез һәм азгын дошманыбыз булган Шаһгалине үзең хөкем ит, үзең җәзасын бир! Мине дошманым кулларына биргәнлекләре өчен, миңа килгән кайгылар Шаһгали илә казанлылар башына да килсен... Мин тоткынны Шаһгали үзенә алырга теләмәде. Мине зур хатын итәсе килмәде. Муены астына килсен нәләт төшкеренең. Мин аның тарафына хәзер чәче белән җир себерсә дә борылып карамаячакмын. Күземнән югалыгыз, барыгызга да Алланың каһәре төшсен...»

—Алай бик өзгәләнмә әле, ханбикә, сине Мәскәүгә олы сый өчен алып барабыз ич без,—дип юатты аны Серебряный,—үзең дә беләсең ләбаса, Казанның идарәче даирәсе хаким булуыңны теләми. Дәргаһтан[27] сөрелүеңнең сәбәбе дә шунда. Сиңа монда урын юк. Падишабыз Иоанн Васильевичка рәхмәт, ул сине кайгы вә сагышта калдырмас, киресенчә, аларны шатлыкка алыштырыр.

Кенәз, аңлыйсыңмы мине дигәндәй, берара сынап карап торды да фикерен йомгаклады.

—Шаһгалигә мөнәсәбәттә мин синең белән тулысынча килешәм,—диде.—Адәм актыгы. Аннан китереп, ул синең атаң вә яһүд бабай шикелле үк карт. Син матур чәчкә, пешкән җиләк кебек яшь. Шуның өчен, кая ул никах, Шаһгали сиңа сүз кушарга җөрьәт итмәс.

Серебряныйның җаен табып кына үтә бер иплелек белән әңгәмә кора белүе Сөенбикәгә тәэсир итмичә калмады.

—Рәхмәт, кенәз, хәлемә керүеңә,—диде,—Тәңренең язмышы, Мәскәү

[27] Дәргаһ – югары даирә.

патшасының теләгәне булсын инде. Алла кушмаган эш булмас.

—Мөселманнарда гаилә мәсьәләсендә яшьлек-картлык роль уйнамый, кенәз,—диде ханбикәне озата килгән Мурали бәк,—яшь аермасы никахка киртә була алмый. Бу нисбәттән кырык җиде яшьлек Шәехгали утыз алты яшьлек ханбикәгә мач кына килеп тора.

—Беләм,—дип пышылдады Серебряный,—болай гына әйтүем, кызганыч бит...

Билгеле, Шәехгалигә ханбикәнең сүзләрен көне-сәгате белән җиткереп кенә тордылар. Мондый дошманлык шартларында кул сорау, өйләнешү гайре табигый хәл иде. Әмма уенны Иоанн үзенчә корды, мәңге кушылмастай тоелган Ут белән Суны берләштерде: Сөенбикә белән Шәехгалине бер ятакка яткырды. Әйтергә кирәк, әлеге уен Шәехгалинең мин-минлегенә бик тә туры килә иде.

—Син күренекле җайдак лабаса, кыргый атларны ничек өйрәтергә кирәк икәнен бик яхшы беләсең,—дип фатихасын бирде Иоанн.

***

Сөенбикә ирен көтми иде.

—Чиратынны буташтыргансың, Шәехгали,—дип аптырабрак калды.

Шәехгали кочмак булып үрелгәч тә куркак бәрәндәй читкә тайпылды.

—Мин әзерлексез бүген, зинһар өчен кагылма,—диде.

—Син минем яшь хатыным, кайчан телим, шунда кагылам.

Бүген ул карап торуга ничектер итәгатьлерәк булып күренә иде. Тик аның акылы үзе белән, керәле дә чыгалы.

—Хатын-кызга җен ояланучан, аларны вакыт-вакыт туздырып алу фарыз,—диде Шәехгали ачусыз гына,—ә син күркәм күренәсең, җеннәрең юктыр, шәт. Мә, камчыны үзең элеп куй.

Хадимәләр табын хәстәренә кереште.

—Миңа ит белән кымыз куегыз, ханбикәгә ширбәт тә җитеп торыр, тулы корсак комачау гына итәр,—дип, Шәехгали җорланып алды.

—Син ашаган арада мин урын җәеп куйыйм алайса,—диде Сөенбикә.

—Сабыр,—диде Шәехгали кымыз чәркәсен кулында бөтергәли-бөтергәли,—әйтәсе сүзем бар.

Тагын ни уйлап чыгарды икән инде, Ходаем, дип эчтән генә сызланып куйды Сөенбикә.

—Тынлыйм, Шәехгали...

Тегесе сүзен әйтергә ашыкмады, чәркәсен өстәлгә куеп, ит ашарга кереште. Озаклап, чемченеп. Кымызын да эчкәләп куя. Аннан соң, гадәттәгечә, ләззәтле төчкерү белән төчкереп җибәрде.

—Әптечи... әптечи... әптечи... әл-мукаддим, сүбханә раббикә раббил гыйззәти...

—Син улыңны күрергә теләвең турында әйткән иең, фикерең үзгәрмәдеме әле?—дип сорады хатынын баштан-аяк күзәтеп чыккач.

Сөенбикәнең гәүдәсе тураеп китте, күзләрендә очкын кабынды, йөзе нурга күмелде.

—Үтәмешем бер генә дә исемнән чыгып тормый, көндез—уемда, төнлә—төшемдә...

—Мәскәүгә барып күреп кайт соң алайса,—диде Шәехгали тәгаменнән аерылмыйча гына.

Сөенбикә дөрес ишетәмме дигәндәй, иренә ышанмыйчарак карап торды.

—Зинһар, хафага салма мине...

—Ихтыярың,—диде Шәехгали,—көчләмим.

Сөенбикә йөгереп килеп, башын иренең җилкәсенә салды да, үксеп

елап җибәрде.

—Рәхмәтләр яусын, Шәехгали... и, Шәехгали, көннәрең якты, эшләрең уң булсын. Миһербанлыгың үзенә мине белән кайтып, Ходай бәхетле озын гомер насыйп итсен... Шатлыгым эчемә сыймый, Шәехгали... и, Шәехгали...

—Янә дә бер күркәм хәбәр: бүген-иртәгә атаең Йосыф бинең илчеләре киләчәк,—диде Шәехгали татлы төн ахырында,—каршы алырга хәзерлән.

Алдагы көндә генә аңа Иоанн патшаның ярлыгын тапшырганнар иде. Анда түбәндәгеләр теркәлгән иде: «Барча Рәсәйнең падишаһы һәм олуг кенәзе булган Иоанн Васильевичтан туганыбыз Шәехгали ханга: Исмәгыйл, Касай, Юныс мирзалар безгә язу язганнар. Сез, туганыбыз, безнең кушуыбыз буенча, Сөенбикәнең борынын кискән, аңа төрлечә зур сыйсызлыклар кылып, аны үтергәнчегә чаклы кыйнаган, дип Йосыф бәккә сүз булды дигәннәр... Юныс мирзаның Зын-Гали исемле кешесе илә Гали мирзаның Бәхет-Килде исемле кешесен синең яныңа барырга боердык. Зын-Гали илә Бәхет-Килде синең яныңа баргач та, син аларга үзеңнең яныңда, шулай ук хатының Сөенбикә янында булырга боерсаң иде. Алар аны күрсеннәр иде. Сөенбикә үзе дә атасы илә анасына язу язып, үзенең саулыгын белдерсә, үзләренең дә саулыкларын сорашса, яхшы булыр иде.

Синең үзенә дә дуслык турында Йосыф бәккә бер ярлык җибәрү яхшы булыр иде. Син аңа ярлык җибәр әле. Без Йосыф бәккә үзебездән ярлык җибәрдек. Кызын ничек багышлап, ничек саклаганыбызны, нинди зур сыйлар илә сыйлап сиңа биргәнлегебезне, шулай ук торынын үзебезнең углыбыз урынында тотуыбызны мин аңа яздым. Менә шуларның барысы хакында мин аңа язып, ул эшләрне эшләвем аның өчен булды, дидем. Киләчәктә Йосыф турында син туганымның уе ничек? Син шушы ярлыкны сиңа илтүче чапкын илә ул хакта миңа язсаң иде.»

Шәехгалинең яшь хатыны катына чиратсыз керүенең сәбәбе шушы ярлык иде.

Сөенбикә ватандашларын тыны белән суырып алырга житеп көтте. Тик күрешү шактый мазалы булды. Шәехгали ике-өч көн аларны үзе янында тотты, зурлап кунак итте. Биючеләр, җыручылар, телмәрләр чакыртып, кәеф-сафа корып утырдылар. Нугайларның түбәсе күккә тиде. Чөнки Рәсәйдә мондый мул, мондый ихтирамлы табынга беренче тапкыр юлыгулары иде. Шәехгалине бик ошаттылар. Ханбикә катына да шаулашып-гөрләшеп, күркәм кәеф, канатлы күңел хозурында килеп керделәр.

—Менә күрегез ханбикәне, исән-сау, тулган ай кебек балкып, нур чәчеп тора,—дип, Шәехгали хатынын кочагына кертте,—җәмәгатем илдә бер.

—Сөбханалла, сөбханалла, күз тимәсен...

Бәхет-Килде мирза кулларын җилкәндәй җәеп, түргә атлады,—мөхтәрәм киявебез Шәехгали хан гаеп итмәстер, шәт, сеңел белән мөселманнарча ике куллап күрешик әле,—диде,—туганнар бит без.

Ул Сөенбикәнең нәзек кулларын юлпычтай киң учына йомды.

—Ходаем, адәм итен чәйнәүче ул бәгъзе гайбәтче адәмнәргә үз язанны бирсәнә,—дип, Зын-Гали мирза да сүзгә кушылды,—сасыклары белән дөньяны былчыраттылар бит.

—Сүзләрең хак, мирза,—дип хуплады Бәхет-Килде юлдашларын,—бу күренештән шатлык-куанычларыбыз эчебезгә сыймый.

—Нинди гайбәт турында гәп корасыз?—дип сорады Сөенбикә.

—Имеш, Шәехгали хан сине типкедә йөртә, башыңны җәзадан чыгармый...

—Имеш, мин синең борыныңны, колакларыңны кискәнмен,—дип ялгап китте Шәехгали.

—Әстәгъфирулла!

Сөенбикә калтыранып куйды.

—Гафу үтенеп, миңа китәргә рөхсәт итегез,—диде Шәехгали камчылы кулын күкрәгенә терәп,—бик мөһим эшләрем бар. Ә сез табынга утырышыгыз, рәхәтләнеп сайрашыгыз.

Ул дөп-дөп басып, бүлмәдән чыгып китте.

—Илдә ниләр бар, атаем-анаем ни хәлдә, туганнарым исән-саумы?—дип, Сөенбикә сорауларын яудырырга тотынды.

—Аллага шөкер, сенлем, бездә барысы да ал да гөл,—диде Бәхет-Килде,—дала синең хакында борчыла, Мәскәүгә дә эзне суытмыйбыз, илче арты илче килә, ярлык арты ярлык. Иоанн патшага тынгы бирмибез. Сине улың Үтәмешгәрәй белән Нугайга җибәрүен таләп иттек, хәтта яу да чабып карадык...

Сөембикә тамагына тыгылган кайнар төерне әңгәмәдәшләренә сиздерми генә йотып җибәрде.

—Туган җирдәй җир булмас, туган илдәй ил булмас,—диде хисләнеп,—мин бу хакыйкатьне әле генә аңладым. Кайвакыт таң алдыннан өзелеп уянып китәм дә бала чакларымны искә төшереп ятам. Колак төбендә кабал сугулар, ат кешнәүләре яңгырый, атаемның җылы карашын, анаемның йомшак кулларын тойгандай булам. Сагындыра, юксындыра туган ил.

—Дини йолаларга патша да каршы бара алмый шул,—диде Зын-Гали,—тол хатын җәмәгатенең ир туганына кануни мирас бит инде ул. Аллага шөкер, Шәехгали хан бик дәрәҗәле, бик күркәм зат...

Бәхет-Килде чынаягын читкәрәк шудырып куйды.

—Үзебез генә калдык, инде турысын әйтеп аңлашырга да була,—диде ул Сөенбикәгә таба борылып,—әйт әле, сеңел, Шәехгали күзгә төтен генә җибәрмиме, дөрестән дә ул гайбәтләр, көнчелек, ялган касәфәте генәме? Би сүләсә—бинеке, кол сүләгә—колны, дигән бабаларыбыз. Шулай гына түгелме?

Сөенбикәнең шома ак маңгаена вак сырлар ятты, күзләренә, йөзенә, хәтта йомры иягенә кадәр уй дулкыны йөгерде.

—Минем сүземне дөнья яралу вакытында булган бер гыйбрәтле вакыйгадан башлыйсым килә,—дип, уй агышларына юл бирде.—Барыбызга да мәгълүм, Тәңребез Адәм галәйһиссәламне туфрактан яратты. Аңа кадәр Тау белән Диңгез үзләрен тәкъдим итеп караганнар иде. Аллаһыбыз Җәбраил фәрештәне Җиргә төшереп җибәрде. Җир исә кагылмауларын үтенде. Шуннан соң Газраил фәрештә инде. Җир янә шул ук үтенечен кабатлады. Газраил аны тыңламады, умырып бер уч туфрак алды. Җир әйтте:

—И, Газраил, каты җанлы икәнсең,—диде,—моннан соң минем туфрактан ясалган бәндәләрнең җаннарын үзең алып китә торган булырсың.

Газраил фәрештә умырып алган теге бер уч туфракны Аллаһы Тәгалә әмере буенча аерым урынга куйдылар. Кырык ел буе бу туфракка яңгыр койды: утыз тугыз ел буена михнәт яңгыры һәм бары бер ел гына рәхмәт яңгыры яуды. Шул сәбәпле, адәм балалары михнәттән—рәхәткә, рәхәттән михнәткә төшеп яшиләрдер.

Менә шулай, агаларым, язмыштан узмыш юк. Бәхет мизгелләрдән генә тора ул. Өскә күбрәк михнәт яңгыры коя.

—Хак, авызыңда кан булса да төкерергә ярамый,—диде Бәхет-Килде.

—Мирза, алай дигән белән дә,—дип, сүзенә Зын-Гали кушылмак итсә дә, Сөенбикә фикерен шәрехләүне кирәк тапты, күрәсең.

—Агаларым, сезне баккач, туган-үскән илемне күргәндәй, атаем-анаем, туганнарым белән күрешеп сөйләшкәндәй булдым. Кайгыртуыгызга, хәлемне

белүегезгә бик зур рәхмәт, барысына да ихлас сәламемне җиткерегез, ә атаема хатымны тапшырыгыз,—диде ул,—хәзергесе тормышыма кагылганнары исә шушында, шушы хан сараенда калсын, бу минем өлешемә тигән көмешем. Әүвәл әйтелгәннәрнең, элек сөйләнгәннәрнең көче дә, мәгънәсе дә калмады.

—Әлгаязе билла, Ходай иминлек бирсен,—диде Бәхет-Килде.

—Амин!

Сөенбикә өстенә келәм ябылган зур сандыктан бер төргәк алып килде. Аны саклык белән чиште дә, җәеп җибәрде.

—Сөбханалла!—дип бертавыштан соклануларын белдерде кунаклар.

Өстәл өсте салават күпередәй бизәкле нур белән тулды: асыл ташларның ниндиләре генә юк! Алмаз, кызыл якут, зөбәрҗәт, энҗе, ахак, фирәзә... Алар оста зәркәнче кулы белән алка, айчык, каптырма, яка чылбыры, беләзек, йөзек, асылма, чулпы ише бизәнү әйберләре рәвешендә алтын-көмешкә төренгән. Араларында тоташ асылташлардан гына торган асылма, муенса, тезмә, үрмә, беләзек кебек аерата затлы вә бәһасез дәрәҗәдә кыйммәтлеләре дә шактый. Җем-җемелдәгән калфаклар үзләре генә дә ис-акылың китәрлек.

—Бу минем шәхси мирасым,—диде Сөенбикә,—шул җөмләдән әманәтем дә бар иде, агайларым.

—Без әманәтенне үтәргә әзер,—диде Бәхет-Килде,—шулай бит, мирза кем Зын-Гали?

—Ышанычлы вафаларың[28] булырбыз, ханбикә!

—Ошбу хәзинәнең иң затлыларын рәсми бүләкнамә кәгазе белән атаем Йосыф бигә алып кайтып тапшырсагыз иде,—диде Сөенбикә,—язуымда, бу сер түгел: «Нугай иле хакына үзең теләгән мәнфәгатьләрдә файдалана аласың, миннән хәер-фатиха»,—дип теркәдем.

—Бик күркәм, Ходай исәнлегенне бирсен, хәйриялелек пәйгамбәребездән килә,—дип хуплады Бәхет-Килде ханбикәнең гамәлен.

Ә Зын-Гали мирзаның бу өлкәдә тәҗрибәсе зуррак иде, ахры.

—Җәмәгатең Шаехгали ханның ризалыгы бармы соң?—дип сорады.

Сөенбикә әлеге сорауны көткән иде, җавабын да ирештерде.

—Ошбу мөнәсәбәттә тәшвишләнмәгез,—диде ышанычлы рәвештә,—хәзинәм Казаннан алып килгән мөлкәтем. Ул мөлкәтне, миңа хезмәт күрсәтергә билгеләнгән йөз Казан туташын һәм дә башка мөлкәтемне дә кертеп, Иоанн патша, бүленмәс милек сыйфатында, үземә багышлады. Имзасы куелган, мөһере сугылган. Шаехгали дә бу хакта хәбәрдар. Менә, патшаның ярлыгына да күз төшерә аласыз.

Ул төргәк итеп йомарланган ярлыкны Бәхет-Килдегә сузды.

—Бик хуш, ханбикә,—диде мирза канәгать кыяфәттә,—борчылма, әманәтең үтәлер.

—Рәхмәт агайларым, юлыгызга ак җаймә, исән-сау йөрегез.

***

Мең биш йөз дә илле өченче елның язы кышны хәтерләтә иде. Апрель, һич булмаганча, салкын килде. Кешеләрнең өстеннән тун-толып, кулларыннан тире бияләй төшмәде. Май исә мәңге бетмәстәй тоелган әлеге тымызык салкынны бер төн эчендә җебетеп ташлады. Иртән торганда суларын тамыза-тамыза җепшек кар ява иде инде. Төш вакытында ул тоташ яңгырга әверелде. Яңгыр суы кая керергә тишек тапмыйча туң җир өстеннән урамнарга, ихаталарга таралды. Тора-бара аңа кар сулары кушылып, бер-ике көндә кала дәрья эчендә калды.

[28] Вафа – сүздә торучы.

Кышкы йокыдан айный алмыйча инке-минке килеп йөргән үшән кала халкын капылт яз бик тиз аякка бастырды. Чөнки терлек-туарны, мал-мөлкәтне саклап калырга кирәк иде. Су котырынса—яман котыра, өлгерсәң өлгереп каласың, өлгермәсәң коры каласың.

Сөенбикәнең мондый йөгәнсез мул суны күргәне юк иде әле. Казанда вакытта язгы ташу чорында боз китү манзарасын күзәтергә ярата иде. Актарына-актарына боз ага, ә күңел ниндидер ашкынулы, дәртле хисләр белән тулыша, каядыр китәсе, дәрья-диңгезләр кичәсе килә башлый...

—Әссәламегаләйкем, ханбикә, хәерле көн!

Сөенбикә уйларыннан арынып, сәлам бирүче тарафына борылды.

—Быел Касыймга әллә нинди котсыз яз килде,—диде аның янына килеп баскан яшь туташ. Ул көрпә йөзле, чын ясау чибәр иде, алма битле каракаш.

—Вәгаләйкемәссәлам, гүзәл туташ, гафу итәсең, кем дип мөрәҗәгать итәргә белмим, кунак булсаң кирәк,—дип, Сөенбикә дә үз чиратында сәлам юллады.

—Ә мин сине бик яхшы беләм, ханбикә,—дип елмайды туташ,—күбесенчә Мәскәүдә яшим мин, шуңа очрашканыбыз юк.

—Шулайдыр, гүзәл туташ, барыбер танымыйм...

—Исемем Пакизә-Солтан, атаем Җангали хан, синең беренче җәмәгатең.

Сөенбикә өнсез калды. Шушы инде алайса уйнаштан туган теге хәсрәт күбәләге. Анасына бәйле мөнәсәбәттә күпме йокысыз төннәр үткәрде ул. Бу кимсетелүне сүз белән генә аңлатырмын димә. Чәчәк кебек вакыты иде ич, сөю-сөелү уты эчендә янган чагы. Кияве Җангали хан исә Пакизә атлы сөйрәлчеге—сарай хадимәсе хакына кавышмас борын аны читкә типте. Тулгактан дөнья куйган сөяркәсенең үксез кызын үз исеменә яздырды. Җә, дәрәҗәле нәсел-ыру вәкиле шул юлга баса димени?

Белми иде, димәк, Җангали бу пәри валчыгына анасының исемен куштырган. Пакизә ди бит.

Шушы канатсыз чебеш инде буй җиткергән, үзенә бер көязлек вә тәкәбберлек белән өстән генә торып аңа сүз куша.

—Мин томана ятим сабыйны агаем Шәехгали хан үстерде, ул минем иң якын кешем, шуңа күрә мин аны атаем дип йөртәм,—дип яңа мәгълүмат өстәде кыз.

Сөенбикә кара коелып басып тора. Пакизә сайравын белә.

—Никахны Касыймда укытырга хәл иттек,—дип тезеп китте һәм шундук челтерәтеп, көлеп тә җибәрде.—Уф, кызлар күңеле—кызган казан, ди, исәр дә инде мин, әйеме, кияүгә чыгасымны әйтми дә торам икән ич. Ничек диләр әле: уналтыда—кыз солтан, унҗидедә—чулпан, егермедә—гөлбостан, егерме бердә—чуртан, диләрме, шуның кебек чуртанга әйләнгәнче чыгып калу хәерле. Сорарга килгәч, башта куркып та калган идем. Олаккан җир диләр ич Әстерханны. Киявемнең Мәскәүдә төпләнеп каласын әйткәч кенә борчуларым таралды. Уф, тагын чалулап киттем, җүләр дә инде мин, әйеме? Кияү егете кем соң дип сораячаксың бит инде. Әйтәм: Хә-би-бул-ла! Аккүбәк ханның улы, шаһзадә.

Куакларны шаулатып, кисәк кенә җил исеп куйды. Шул ук мизгелдә күкне каплап алган тоташ болыт нәкъ Хан мәчете өстендә икегә ярылды. Әүвәл яктысы сибелде, аннан соң кояш үзе дә йөзен күрсәтте. Кала ялтырап китте.

—Минем бәхеткә бу,—диде кыз куануыннан кулларын чәбәкли-чәбәкли,—язган булыр ди яз башында. Ходаем, Иоанн патшабызга озын

гомер, эш-гамәлләрендә уңышлар насыйп ит. Никахыбызга биргән фатихасына өстәп, ясак җыю хокукы белән Хәбибуллага Юрьев шәһәрен багышлады.

Шунда яшәячәкбез, Мәскәүдә дә йортыбыз булачак...

Ул Сөенбикәнең төксе чыраен күреп, бүленеп калды.

—Ханбикә, әллә минем шатлыкларым сине сөендермиме?—дип күзләрен түгәрәкләндерде,—гаҗәп, без бер гаилә ләбаса!

—Мин үземне начар хис итәм, баш өянәгем кузгалды,—дип алдады Сөенбикә,—тотрыксыз яз галәмәте булса кирәк.

—Әйдә, сарайга керик, табибка күреник,—дип, Пакизә ханбикәне җитәкләп алмакчы итте.

—Юк, юк,—дип читкә тайпылды Сөенбикә,—минем үз ярдәмчеләрем бар...

—Җимешләрем, ханбикәгә булышыгыз, җәтрәк кыймылдагыз—дип, туташ хадимәләрне дә җилтерәтеп алды.—Менә шулай, ипләп кенә, ипләп кенә...

Сөенбикә гарьлегеп йотып, сарай тарафына атлады. Ана Пакизә-Солтанның үзе дә, сүзе дә, үз-үзен тотышы да—бернәрсәсе дә ошамый, фәкать ярсулы хисләр генә уята иде. И, Ходаем, ниләргә чыктым бу бакчага, ниләргә күрдем бу корчаңгы бәрәнне.

Икенче көнне кыз озату мәҗлесе булды. Алар шунда янә очраштылар. Мәҗлес хуҗасы өлкән ханбикә Фатыйма-Солтан булып, Сөенбикәгә бернинди вазифа да йөкләнмәгән иде. Шуңа бер яктан сөенеп, икенче яктан, Пакизәнең кыланышына үртәлеп утырды.

—Яшьлеге, чибәрлеге белән кирәгеннән артык масая бу кәләш, косасыны китерә,—дип пышылдады хадимәсе Хәдичәнең колагына.

—Тсс, ханбикә, тишек колаклар ишетер,—дип кисәтте тегесе.

Сөенбикәнең кара янып утыруына да карамастан, мәҗлес бик күркәм оештырылган иде. Табын искиткеч мул. Җыр, уен-көлке дә тынып тормый. Озату кичәсендә, югыйсә, моңсу төсләр өстенлек итәргә тиеш кебек үзе. Пакизә исә бәхетенә туенуын һич яшерми: теле телгә йокмый, уйный, шаяра, көлә, тач күнә суы[29]*. Ап-ак киемнән, аккош шикелле очып кына йөри.

Кигән күлмәк киң кирәк,
Сөйгән ярың тиң кирәк,
Сөйгән ярың тиң дә булса,
Бу дөньяда ни кирәк?

Аның бу такмагыннан мәҗлес гөр килеп алды. Яшь кәләш тапкыр сүзле икән: «Гыйшык—төтенсез ут, ачкычсыз йозак, дәвасыз сырхау, тәмле ширбәт, йөксез авырлык, йокысыз сәфәрдер»...

Сарай чичәннәре «Бүз егет» тарихын уен-тамаша итеп күрсәттеләр: бер шаһзадәнең кызы Карачәчсылу бүз егетне төшендә күрә дә гашыйк була. Ике ел буе йөзе сулып, кайгылы йөргәннән соң, янә төшендә күреп, җавап сорый.

Кыз:

Төнлә елап, көндез—зар,
Мин йөзенә интизар.
Ни сәбәптән булдың яр,
Мине мондай кылып зар?

[29] Күнә суы—терекөмеш.

Егет:

Бән сәненмен, сән—бәнем,
Жаныма төште жаның...
Морадка бер көн йитәр,
Сабыр кылсаң кирәкте...

Тамашаның нәкъ кызган мәлендә бүлмәгә мыштым гына бер ир-ат заты борын төртте. Сакал-мыеклары бик килешле итеп кырылган. Үзе энәдән-җептән киенгән. Яшел төстәге укалы озын җиләне, бизәкле сахиян читеге, мехка төренгән кырма бүреге аны үзенә бер мәһабәт иясе итеп күрсәтә иде. Әйтерсең лә, коеп куйган кургашын.

Адашкан ахры бу көяз агай, кыз-хатын мәҗлесенә килеп кермәс иде, дип уйлап куйды Сөенбикә. Хәер, үз-үзен тотышына караганда, ул монда очраклы рәвештә генә кермәгән иде. Күр, йөзе ничек балкый, эченнән дә, тышыннан да якты нур бөркелә, шатлыгы эченә сыймый, күрәсең. Бар соң бәхетле бәндәләр!

Кунакны Пакизә дә күреп алды. Аның да йөзенә кояш тургае кунды.

—Атаем, атаем!

Ул йөгереп барып, ыспай кунакның алдына тезләнде. Тегесе кәләшне күтәреп торгызды да күкрәгенә кысты.

Шәехгали түгелме соң бу? Дөрес күрәмме дигәндәй, Сөенбикә кулъяулыгын күзләренә тигезеп алды. Юк, ялгышмый, чыннан да, Шәехгали!

Матурлыкны мөкаммәл кыяфәткә тиңләүчеләр бик нык хаталана. Матурлык кешенең шул мизгелдәге халәте ул. Бүген Шәехгали нәкъ менә шул илаһи да, серле дә, куанычлы да халәттә иде.

—Мин монда хан сыйфатында түгел, кызым Пакизә-Солтанның тәрбиячесе, атасы сыйфатында кердем,—диде Шәехгали,—мин аны өстеннән кош та очыртмый үстердем. Куанып һәм сөенеп үзе сайлаган егет солтанына кияүгә бирәм...

Сөенбикә дерт итеп китте, әйтерсең лә, тәненә энә белән кадап алдылар. Ул күз карашы белән генә хадимәсен чакыртып алды.

—Хәдичә, кәләшнең муенсасына күз төшер әле, минеке ләбаса ул! Минеке!

—Ошагангынадыр, ханбикә...

—Ныклабрак кара, ныклабрак!

—Ничек инде... син аны Нугайга озаткан идең ич...

Хәдичә төртелеп калды. Чыннан да, кәләшкә эленгән муенса ханбикәнеке иде, аны буташтыра алмыйсың, ул бер нөсхәдә генә.

—Барып муеныннан умырып алам!

—Җәнҗал куптара күрмә, ханбикә, хурга гына калырсың,—дип хадимә хуҗабикәсен тыеп калды,—баштa ханның үзе белән сөйләшеп аңлашу хәерлерәк булыр. Аннан узу яхшыга китермәс.

—Минем бу пәри оясында азга гына да каласым килми,—дип, Сөенбикә урыныннан сикереп торды,—бар, әйт, ханбикәнең баш өянәге кузгалды диген.

Сөенбикә никах, туй мәҗлесләре үткәләгәнче сырхауга сабышып, үз бүлмәсеннән чыкмады. Шау-шу тыну, кунаклар таралу белән Шәехгалигә кеше җибәрде. Тегесе бик егылып төшмәде, ике-өч көннән соң гына әбәт арасында үзенә чакыртты. Очрашу аш-су бүлмәсендә үтте.

—Күптән интегәсеңме баш өянәге белән?—дип белеште Шәехгали.

Көтелмәгән сораудан Сөенбикә төртелеп калды.

—Әллә тагын...

—Димәк, хәйлә,—дип нәтиҗә ясады Шәехгали ачусыз гына,—күзгә төтен җибәрү.

Ул хатынына текәлгән халәттә чынаягын иреннәренә тигезеп алды, әмма эчмәде, кире урынына куйды да әйтте:

—Мин синең ни-нәрсә өчен койрыгына ут капкан мәчедәй үрсәләнеп йөрүеннең сәбәбен бик яхшы беләм,—диде.

—Алайса аңлат инде, ни рәвешле минем алмаз муенсам Пакизә-Солтан муенына эленде?

—Мин аны, башка бизәнү әйберләре белән бергә, Нугайга җибәргән идем дип тә өстә,—диде Шәехгали.

—Шәхси милкемә мин үзем хуҗа, ничек телим, шулай...

—Юк!—дип өстәлгә китереп сукты Шәехгали,—сарай эчендә генә алар синеке, дәүләт чигеннән чыгарылганда ханлык милкенә әйләнә. Ханнан сорамый, ханга белдертмичә, аның артында җинаять кылган өчен син еланга иң каты җәза тиеш.

—Нугай илчеләренә тимәгәнсездер, шәт?

—Чит мәмләкәт байлыгына кул сузган бур кешегә нинди җәза тиеш булса, алар шуны алды.

—Аһ!

Сөенбикә учлары белән йөзен каплады.

—Пакизә-Солтан синең үги кызың икәнен дә онытма,—диде Шәехгали.

Сөенбикә атылган таштай урыныннан купты. Аны танырлык түгел иде: иреннәре дер-дер калтырана, йөзе чалшайган, бәбәкләре киерелгән.

—Мыскыл итмә мине, дәҗҗал,—дип ут чәчте,—мин... мин дәрәҗәле ханбикә, уйнаштан туган ул мәкерле кара затка бернинди мөнәсәбәтем дә юк. Юк! Юк!! Юк!!!

Шәехгали Сөенбикәнең иягеннән эләктереп үзенә суырып китерде дә:

—Бәхетең, шатлыклы көннәремдә кулымны былчыратасым килми,—диде. Аннан соң ачу белән этеп җибәрде. Сөенбикә идәнгә мәтәлеп төште.

—Бар, күземнән югал, Кырым сөйрәлчеге!

***

—Княгиня, көнләшәм мин сездән, гыйлем эстәүдә мәшһүр Әбүгалисинә белән яраша алар идегез,—диде Марсель китапханәдән чыкканда,—ябылмаса, һаман утыра идегез әле.

Татли озын керфекләрен чәнчеп кенә аңа күз ташлап алды.

—Хәзер иң яхшысы, берәр аулак кафеда тамак ялгап алу,—диде,—шәт, андый урыныгыз бардыр, мсьё?

Марсель җилкәләрен сикертеп куйды.

—Княгиня, төнге Мәскәү көндездән дә шау-шулырак ул.

—Ә нәрсә тәкъдим итәсез?

—Торагыбызга кайтыйк, ашау-эчүне анда да көйләп була ич, минем әле сезгә бүләгем дә бар.

Татлиның йончыган йөзе яктырып китте.

—Нәрсә көтәсез соң, тизрәк такси тотыгыз!

Марсельнең шушындый гадәттән тыш хәлләр өчен алдан хәзерләп куйган затлы француз шәрабе бар иде, өстәлгә беренче булып шул кунаклады.

—О-о, мсьё, нинди игътибарлы сез, татар егетләре,—диде Татли сөенүен яшермичә,—бүген чыннан да истәлекле көн, уртак проектыбызның тикшерену өлешен, ниһаять, тәмамладык, китапханә бик күпкә баетты, мин риза-бәхилмен. Бу минем тостым, мсьё.

Һич булмаганча, Татли ялындырмыйча гына бокалын бушатып та куйды.

—Парижда да китапханә юлына тузан кундырмыйсыз булса кирәк,—дип, Марсель өзелгән әңгәмәне ялгап җибәрде,—китап, чыганаклар белән һөнәри дәрәҗәдә эшли беләсез.

—Их, мсьё, Сөембикә ханбикә көтепханәсендә дә айлар-еллар буе казынып утырган булыр идем, кызганыч, тар-мар ителгән.

—Мин Искәндәр җиһангир көтепханәсе турында хыялланам,—диде Марсель,—тиңе юк мирас булган булыр иде.

—Мисырдагы Александрия шәһәрендәгесеме?—дип белеште Татли.

—Тарихчылар папирус төргәкләренә уелып язылган меңләгән китап хакында сүз йөртәләр бит. Чын мәгънәсендә мәдәни үзәк. Галимнәр, шагыйрьләр, рәссамнәр каласы. Математик Евклид шунда үз теориясенә нигез сала. Астроном Аристарх Коперникка кадәр үк галәмнең үзәге Кояш икәнен дәлилли.

—Сугыш-орыш—вәхшилек юлдашы, мсьё,—диде Татли,—вәхшиләр, ни гаҗәп, сыңгар гамәлләрен китап яндырудан башлыйлар.

—Китапның көле безнең заманда да мактанырлык түгел анысы, княгиня, татар китабы бигрәк тә авыр дәвер кичерә,—диде Марсель,—тик бу күңелле кичтә гел яхшылык турында гына сөйлисе, матур гамәлләр генә кыласы килә. Бүләгем моңа дәлил.

Татли күзләрен төймәләндереп, Марсельгә текәлеп бакты.

—Рәхмәт, мсьё, шәрабыгыз искиткеч.

Марсель чәчләрен сыпыргалап алды. Татлидан рәхмәт ишетү бер алгысыту булса, бүләгенең әле һаман сюрприз булып калуы икеләтә канәгатьләнү китерә иде. Шул ук вакытта, артык сузу да ярамый. Һәм ул идән уртасына басып, шигырь укый башлады.

Зөләйхә бер куни йотыб уйур иди,
Йусефен суратен дүшдә күрди,
күрүбән һәман сафәт ғашик улди,—
ағлайуб уйанубән кәлүр имди...

—Кече Азия шагыйре Шәйяд Хәмзәнең «Йосыф вә Зөләйха»сы,—диде Татли,—искиткеч камил шигърият!

—Ялгышасыз, княгиня!

—Ә-ә, төшендем, Сарай шагыйре Котбидан ич. «Хөсрәү вә Ширин»! Мәхәббәткә мәдхия.

Зөләйха—тик мине мәшһүр кыйлды,
дәва тапмаз, мине уш рәнҗүр кыйлды...

—Хак, княгиня, мәхәббәт дигән илаһи хис-тойгыны борынгы көнчыгыш поэзиясе генә менә шулай тәэссоратлы, барча нечкәлекләре белән тасвир итә алган. Бу—эталон!

Марсель үзе дә сизмәстән, Татлиның кулларыннан алды, һәм нотыгын икенче юнәлешкәрәк борып дәвам итте.

—Дөресен генә әйткәндә, мәхәббәт хисе үзе дә тоныклана бара кебек. Менә әйтегез әле, французларда мәхәббәт бармы?

—Бар, нишләп булмасын, тик...

—Менә-менә,—дип элеп алды Марсель,—тик дигән искәрмә барысын да боза да куя. Ресторанда кичке ашны ашаган өчен аерым-аерым түләгән ир белән хатын арасында нинди мәхәббәт булсын ди? Гыйшык бар, мавыгу бар. Ә мәхәббәт, пардон, юк!

—Төрттерүегез инде бу,—диде Татли көлемсерәп,—французлар әйткәнчә:

«Си ля ви», тормыш шундый ягъни-мәсәлән.

—Салулап китүем өчен кичерегез зинһар, княгиня,—дип, Марсель башын күкрәгенә салып алды,—шуны да әйтергә бурычлымын, икенче мисалыгыз да дөреслеккә туры килми. Мин укыган өзекләр борынгы татар шагыйре Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасына мөнәсәбәтле. Халык арасында аны «Йосыф китабы» дип йөрткәннәр, фәнни әдәбиятта «Йосыф-Зөләйха», «Йосыф вә Зөләйха» дигән исемнәре дә теркәлгән. Әсәрнең сюжеты башка шагыйрьләрне дә иҗатка илһамландырган. Хәмзә дә, Котби дә шундыйлардан. Алар күп. Татар әдәбияты шул традицияләр рухында тәгаенләнгән, үскән дә инде. Шик юк, поэма Сөембикә ханбикә көтепханәсендә урын алган булырга тиеш.

Сезгә, Княгиня, «Кыйссаи Йосыф» поэмасының 1983 елда Казанда басылып чыккан академик басмасын бүләк итәсем килә. Кабул итеп алыгыз.

Татли китапны күкрәгенә кысты. Марсель янә шигъри телгә күчте.

> Зөләйха әйдүр: «Җәмалүм, малум вирдүм,
> сәнең үчүн җөмлә—син фида кылдым,
> бәхетемдән, тәхетемдән кирү дүндүм,—
> сәнең ғишкың бәңа әсәр калди имди!»

—Мьсё, сез мине мәхәббәт корбаны итмәкчесез ахры,—диде Татли яшь аралаш.

—Княгиня, каләм бар—очыннан алтын тамар, каләм бар—очыннан дөнья янар, ди. Сезгә хәзерендә Мәхәббәттән битәр, Илһам зарур. Бүләгем шуңа юл ачарга булышса, үземне бик бәхетле санар идем.

***

Шәехгали хатынына Йосыф бинең фаҗигале үлеме турындагы хәбәрне канәгатьлек кичерүен яшермичә, үзенә бер гафиллек белән житкерде.

—Кем дә кем олуг падишаһыбызга кылыч күтәрә, үз кылычы ук аның башын кыя,—диде сүзләренә тирән мәгънә салырга тырышып.—Хәер, син үзең дә акылсызлык корбаны. Сезнең барыгызның да борыныгыз югары, акылыгыз гына сай.

Имеш, бине Исмәгыйл бәк чәнчеп үтергән. Бу Сөенбикәнең хәсрәтен тагын да тирәнәйтте. Ничек инде, алар бер ана, бер ата балалары лабаса! Ашаудан калды, ябыкты, каш арасында тирән бураэна хасил булды, күз төпләрен җыерчыклар каплады. Йөзендә кылыч борыны вә очлы ияге генә утырып калды. Тыгыз матур гәүдәсе дә зифалыгын җуеп, шәлперәеп төште.

—Кайгымны уртаклашыр якын кешем дә юк бит минем,—дип бүген иртән дә хадимәсен кочаклап елады,—нишлим, кемнең җилкәсенә башымны салыйм?

—Үзенә гөнаһ алма, ханбикә, синең никахлы ирең бар,—диде хадимә ишек ягына ишарәли-ишарәли.

Сөенбикә чыраен гына җыерды.

Шул ук көнне, уйламаганда-көтмәгәндә, көндәше Фатыйма-Солтан ишек шакыды. Алар бер-берсе белән ачыктан-ачык дошманлашмыйлар, шул ук вакытта, якынлашканнары да юк. Мөнәсәбәтләре үзара сәламләшүдән үтми иде, хәлбуки, өлкән ханбикәнең хокуклары күпкә киңрәк.

Фатыйма-Солтан гәүдәгә шактый мул булып, ул аны үзенең өстенлеге дип саный иде, шуңа күрә көндәшен кипкән балык дип йөртә иде. Сөенбикә дә аннан калышмады, гөберле бака кушаматы такты.

—Алдан хәбәр салмавым өчен гафу ит, гөлкәем,—диде Фатыйма-Солтан ихтирамлы елмаю белән,—табын корып тормыйбыз, хәленне белергә генә кердем. Бик борчыла дигәннәр иде, хак икән, коры сөяккә калгансың бит.

—Юкка бимазалангансың, ханбикә, хәлем әйбәт минем,—диде Сөенбикә.

—Ул әйбәт хәлләр үземнең баштан да үтте,—диде Фатыйма-Солтан уфтанып,—олуг кенәз Василий атакай Шәехгали ханны кечкенә генә ялгышы өчен дә Ак күлгә сөргән иде бит, якын кешеләребезне кырып бетерде. Өч елга якын җәфа чиктек. Рәхмәт, Иоанн патша тәхеткә утыргач, безне дә коткарды. Ходайдан үзенә гел яхшылыклар гына телим.

Фатыйма-Солтанның самими ачык йөзе, күкрәк төбеннән чыккан тәэсирле йомшак тавышы, тәмле теле Сөенбикәне дә битарафлык төбеннән тартып чыгарды, ачылып китте.

Өстәл өстенә чәй тәм-томнары да куелгач, әңгәмә тагын да дустанә төс алды.

—Атаем бик дәрәҗәле ил агасы иде, ничәмә-ничә углы гына бар, анламаем, алар ничек бу фаҗигага юл куйгандыр?—дип зарланып алды Сөенбикә.

—И-и, гөлкәем, син үзең дә шул казанда кайнаган кеше ләбаса, беләсең, тәхет ата-анадан өстен йөри ул.

Фатыйма-Солтан чәйне бөтен кагыйдәсенә туры китереп, ләззәт вә канәгатьлек белән эчәргә күнеккән иде. Әле дә биш бармагының очына гына эленгән тәлинкәсендәге кайнар чәйнең буларын өрә-өрә вак-вак йотым белән иреннәренә тигезеп-тигезеп ала. Сөенбикә аңа кызыгып та, көнләшебрәк тә карап торды. Ул үзе дә тормышның һәр мизгеленнән ямь таба белә иде ич. Ә хәзер бөтенләй сүтелде.

—Хак, мөхтәрәм ханбикә,—диде ул әңгәмәдәше белән килешеп,—хакимияттә гаделлек була алмый.

—Һәм дә, гөлкәем, тормышны ничек бар, шулай кабул итәргә кирәк,—дип күтәреп алды Фатыйма-Солтан,—Ходай язганны үзгәртә алмыйсың. Соңыннан җае чыга аның, болыт ничек кенә калын булмасын, кояш аны барыбер эретә.

Кунак, ниһаять, китәргә җыенды.

—Мөхтәрәм ханбикә, мине чәй тамашаң белән таң калдырдың,—диде Сөенбикә,—Кытайга барып кайткандай булдым.

Фатыйма-Солтан көндәшенең аркасыннан сыйпап куйды.

—Тагын бер киңәшем, гөлкәем, дөньяга үч тотып яшәвеңне ташла,—диде,—үзеңә шөгыль тап, йомылып утырма, ялгызлык чирдән яман.

И, «Зирәкбикә» дигән даның чыккан мактаулы вә дәрәҗәле Казан ханбикәсе, кем уйлаган шушы көннәргә калырыңны. Элек син сабак бирә идең, хәзер үзеңне ничек яшәргә өйрәтәләр. Әмма дөрес сүзгә җавап юк.

Сөенбикә янә китап җыю эше белән шөгыльләнергә исәп итте. Бу юлы шәхси көтебханә булдыру иде максаты. Шәт, Шәехгали дә каршы килмәс. Шулай да ниятен аңа чишкәләгәнче, Кодаш сәед белән аңлашырга кирәк дигән карарга килде. Ул аны күреп белә иде инде. Юка гәүдәле, озынча йөзле бу имам читтән караганда мәдрәсә шәкертен хәтерләтә иде. Шуңа күрә әллә ни ышаныч та уятмый. Ләкин бу ялган тәэсир генә иде. Сәед искиткеч укымышлы, белекле, менә дигән әңгәмәдәш икән. Сөенбикә аны тәүге җөмләсеннән үк төшенеп алды. Бу шигъри җөмлә иде.

Дөнья беркем өчен дә дәвамлы түгел,
Рәсулулла да анда мәңгелек түгел иде.

Сөенбикә үзе дә шигырь белән җавап кылды:

Йахшылык кыйл, йахшылыкда бар мәза,
Кем йахшылык кыйлса, ул табагай җәза.

—Таныдым, мелла Хаҗи бине Әл-Мәхмүд,—диде сәед,—бик оста телмәр вә чичән, диләр. Шагыйрьнең сез галиҗәнапка багышлап чыгарылган газәле дә хәтеремдә:

Йармөхәммәд, сәна бирмеш хак теле,—
Бу фәләк багыстанынын былбылы.

—Рәхмәт, сәед, сынык күңелемә канат куйдың,—диде Сөенбикә,—шагыйрь Мөхәммәдъяр бик олпат шәхес иде. Шактый фикерләребез тәнгәл килә иде. Мин аны дәүләт эшләренә тарымак итеп күп көч сарыф итсәм дә, остазы вә дусты Мөхәммәдәмин хан рухыннан читләшмәде. Ә көтебханә мисалында булышлыгы зур булды. Ходай исәнлек-саулык бирсен.

—Ханбикәнең «Кыйссаи Хөбби хуҗа» дастанына мөнәсәбәте ничек?

Әлеге сораудан Сөенбикәнең йөзенә күләгә ятты, әллә бер-бер килешмәс сүз әйттеме дип, сәед борчылып та куйды.

—Ошбу дастанны чыгарган Колшәриф сәед башымны ашаган адәмнәрнең берсе,—диде Сөенбикә теш арасыннан гына,—түбәнлек Бибарс бәк белән мине, улым Үтәмешгәрәйне Мәскәүгә әсир итеп бирәчәкләре хакында Иоанн патшага рәсми хәбәрне алар җиткерде. Алыш-бирешне дә алар башкарды. Фу, исемә төшсә, каным кайный башлый, бу антларын бозган хыянәтчеләр турында сөйләшмик, сәед.

—Баш өсте, ханбикә.

Сүз үзеннән-үзе китап тарафына борылды.

—Ханбикәне нинди китаплар кызыксындыра соң?—дип сорады сәед.

—Казаннан мине итәкләренә ут капкандай ашыга-кабалана алып чыгып киттеләр ич,—диде Сөенбикә,—китап мирасыннан кесә Коръәненнән ары бер җыентык та алырга рөхсәт итмәделәр. Хәзерендә Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф»ы, вә дә «Бакырган»нан башлау хәерлерәк булырдыр, мөгаен. «Котадгу Билиг», «Куман мәҗмугасы» күңелемә якын. Әлбәттә, көтебханәмдә Фирдәүсинең «Шаһнамә»се, Сәйф Сараиның «Сөһәйл вә Гөлдерсен»е дә булырга тиеш дип саныйм...

Кодаш сәед аны очлы ияген алга сузып тыңлады.

—Ханбикә, мин үземнең гыйлем дәрьясында үтә дә сай йөзгәнемне әле генә аңладым,—диде ул,—оятыма каршы, син санап киткән китапларның яртысын уку түгел, кулыма да тотып караганым юк. Бездәге китапчы «Бакырган»ны гына таба алса иде.

—Бик хуп, сәед, калганнарын сәүдәгәрләр аша юнәтергә тырышырмын.

Әңгәмә әле озак дәвам итте. Ни турында гына гәпләшмәделәр: тормыш-көнкүреш, гомер-яшәеш, тәрбия, гыйлем... Сөенбикә күңелен тырнап торган шәхси борчуларын да уртага салды хәтта.

—Горбәт[30] адәмне тәрбия итәр дигән гыйбарәне ничек шәрехләргә кирәк?—дип сорады.

Сәед әңгәмәдәшенең тел төбен бик тиз аңлап алды.

—Синең өлешеңә, ханбикә, бу дөньяда бик күп тетрәнүләр туры килгән,—диде уйчан гына,—Ходай...

—Аллаһы яраткан бәндәсен күп авырлыклар белән сыный димәкче

[30] Горбәт—җәфа.

буласызмы?—дип үзе ялгап китте Сөенбикә.

—Сабыр иткән генә морадына җитәр, ханбикә.

—Ярый ла, гомерең ул сабырлык кысасына сыйса?..

Сөенбикәнең тавышы калтыранып китте. Сәед аңа йомшарырга ирек бирмәде, сүзен кыстырырга ашыкты.

—Өмет сүнмәсен, ханбикә, адәмне өмет белән ышаныч яшәтә,—диде.—Сиңа вәсвәсәләнү бөтенләй урынсыз, никахың дәрәҗәле, улың бар...

Сөенбикәнең күзләренә нур инде.

—Дөрес әйтәсең, сәед, бала—бәгырь җимеше, күңелләрнең сәүмеше. Улым яшәтә дә инде мине.

Саубуллашканда сәед ханбикәгә кайгылы хәбәр җиткерде.

—Ханбикә, шагыйрь Мөхәммәдъяр да, Колшәриф сәед тә Казан орышында урыслар кулыннан һәлак булган,—диде.

—Көтебханәбезне ут төртеп яндыруларыннан хәбәрдар идем, ә бу мөхтәрәм ил агаларының фаҗигасе турында беренче синнән ишеттем,—диде Сөенбикә,—урыннары оҗмахта булсын.

—Амин!

***

Төштән соң Шаехгалидән йомышчы килде. Минем дә кирәгем бар икән, кояш кире яктан чыкмаса ярар иде дип уйлап куйды Сөенбикә. Ул моны яхшыга юрады. Бирәм дигән колына, чыгарып куяр юлына, ди. Көтебханә турында сүз кузгатырга менә дигән форсат лабаса.

Шаехгали, чыннан да, хатынын үзенә бер ихтирам вә олылау белән каршы алды. Түрдән йомшак урын тәкъдим итте, шәхсән үзе касәгә ширбәт агызды.

—Авыз ит, искиткеч татлы...

—Рәхмәт игътибарыңа, хан.

—Тәм-томга да үрел, әнә, баурсак, кош теле, кәләвә...

Сөенбикә каш астыннан гына иренә карап алды. Ул бүген борчулы күренә иде.

—Ханның күңеле урынында түгел ахры, бер-бер хафаң бармы әллә?—дип сорарга мәҗбүр булды Сөенбикә.

—Бар шул, бар,—диде Шаехгали өзгәләнгәндәй,—тик әлегә бу хәбәр имеш-мимешкә корылган... Мәскәүгә атчабар җибәрдем инде, ул төп-төгәл белеп кайтыр... мин барыбер әйтергә тиеш...

Сөенбикәнең йөрәге сызылып китте.

—Үтәмешгәрәйгә кагылмыйдыр бит?

Шаехгали бүлмә буйлап арлы-бирле йөрештереп алды да, тәрәзә каршысына килеп басты. Сарай мәйданында хәрби атлар белән күнегү үткәрәләр иде. Шуларны күзәтеп торды.

—Җанымны көйдермә, Шаехгали, әйт, ни булган... зинһар,—дип ялварды Сөенбикә.

—Улың вафат.

Сөенбикә таш булып катты. Шаехгали исә янә бүлмә иңендә киләп сарырга керешге. Аны атлар белән күнегү үткәрүчеләр чыгырыннан чыгарган иде. Көн үтсенгә генә эшлиләр, хөрәсәннәр, дип ярсыды. Шуңа күрә бу күнелсез очрашуга нокта куеп, тизрәк өйрәтү мәйданына чыгасы, гаепләләрне камчылыйсы килә иде.

—Миңа соң җеназага җитешергә кирәк ләбаса,—дип Сөенбикә дә урыныннан купты,—тиешле кешеләргә боерыгынны җиткер, Шаехгали...

—Александр Сафакиреевич христиан динендә, матәмдә мөселманнарны катнаштырмыйлар.

***

Ошбу кайгылы хәбәрдән соң Сөенбикә шактый вакыт игә килә алмыйча йөрде. Шул ярымгафил чагында аңа ниндидер кәгазьгә имза салдырып, мөһер суктырдылар. Анда үз теләге белән алтын-көмешләреннән, асыл ташларыннан, барча мөлкәтеннән, Казаннан үзе белән килгән кешеләреннән баш тартуы, аларны ире Шаехгалигә мирас итеп бирүе турында теркәлгән иде.

Ул кыл бөртек әйберсез калды. Хәер, әйберләрнең кирәге дә юк иде инде. Чөнки дөнья мәшәкатьләреннән бөтенләй читләште, үзгә тормыш белән яши башлады. Яше кипте, зиһене тарайды, күңеле хәтер вә тәкъвалеккә чорналды. Үтәмешгәрәйнең үлемен дә Аллаһының мөбәррат[31] гамәле сыйфатында кабул итә иде инде. Аллаһы Газраилен җибәреп, Үтәмешгәрәйне изелү-мыскыллаулардан, кимсетелү вә түбәнсетүләрдән, һәм дә муенына тавык тәпие асудан коткарган лабаса! Аның ялваруларын ишеткән!

Гарип балам Үтәмеш дә алты яшенә житте,
Фани дөньядан үтте, андан бер кайгум бетте.

Сөенбикә башы-аягы белән Хәтер дөньясына чумды. Бу дөнья ябык мәгарәне хәтерләтә иде. Анда үзеннән һәм бакыйга күчкән иң якын кешеләреннән башка берәүгә дә урын юк. Ул алар белән аралаша, гәпләшә, сөйләшә...

Җан өрелгән вакыйгаларның күбесе, билгеле, улы Үтәмешгәрәй белән бәйле иде. Әле дә зур калын келәм өстендә мәрткә киткәндәй оеп утыра. Сыны коры курадай үрә каткан, хәтта сулыш алуы да беленми. Ә күз алдында бәхетле көннәре...

—Әнкәсе, Үтәшне уйнату өчен кырык эшемне кырык якка ташлап кайттым,—дип, Сафагәрәй ишектән керә-керешкә улына үрелде.

—Кулга өйрәтеп бетердең инде баланы,—диде Сөенбикә ирен шелтәләгәндәй,—миңа Үтәш кушаматы тагуың да ошамый, кара халык түгел лә ул, булачак хан!

—Җә, әнкәсе, юкка чәпчемә әле, зинһар, яратып кына ич инде...

Үтәмешгәрәй үз хәл-халәтен, бу ике олы кешене үз кубызына биетә алуын бик яхшы аңлый иде, әлбәттә. Әнә, хәйләле күзләре ничек уйнаклый. Атасына каш астыннан гына карап алды да, кылтыкланып кулын алга сузды. Бу—барысына да мәгълүм бахбай бул дигән әмер. Сафагәрәй бер каршылыксыз дүрт аяклап мөкәйләде дә, ат шикелле кешнәп тә җибәрде.

—Их-ха-ха...

—На, бахбай!

Бахбай бүлмә буйлап чабып китте. «Баланы ега күрмә»,—дип аның артыннан тотам да калмый Сөенбикә йөгерде.

—Йөздәге яра эзе егет кешене бизи генә ул, әнкәсе, борчылма,—дип көлде Сафагәрәй,—үзең дә мине кылыч сызган җөй эзе өчен яратасың бит әле. Аннан соң, ханбикәм, дөньяны иләккә төяп кенә яшәп булмый, ул бик тиз рәвешен алыштыра.

—Әйттең сүз, Үтәмешгәрәй минем бердәнберем, кояштай күтәреп алган балам,—диде Сөенбикә,—утыз яшьтә күп хатыннар оныкларын сөя инде. Аның өчен җанымны фида кылырга да әзер мин. Ә дөньяга килгәндә, дөнья кешесенә карап йөзен ача.

—Шулай дигәннән, бер риваять-вакыйга исемә төште, шуны сөйлим әле,—диде Сафагәрәй,—тыңла.

Авылда мәет бар дип ишеткәч, ерак җиңги дә килеп җиткән. Караса, агай-

[31] Мөбәррат—изгелек гамәле.

энеләренең баласы вафат икән. Җингинең йөзе ачылып китмәсенме.

—Аллага шөкер.

Туганнары аптырап калган.

—Бу ни дип әйтүең, җинги, шөкер итә торган чакмы соң?—дип, ризасызлыкларын белдергәннәр.

—Шөкер итмичә, мин анасы үлгән дип торам тагы, улы гына икән ич. Анасы исән булгач, баласын тагын табар әле, Аллаһы боерса,—дип тынычландырган тегеләрне фәйләсүф җинги.

Шуңа күрә, ханбикәм...

Сөенбикәнең чырае сытылып чыкты, әмма аңлашырга өлгерә алмыйча калдылар—Үтәмешгәрәй көйсезләнеп, өстәл өстендәге уенчыкларны идәнгә чәчте, янәсе, булачак ханга игътибарыгыз кимеде, хөрмәтле әти-әниләр.

—Үтәш, чорсызланма,—дип бармак янады Сафагәрәй.

—Түгел Үтәс!—диде малай иреннәрен бүлтәйтеп.

—Кем соң?

—Мамыс!

—Нинди килешле исем,—дип хуплады Сөенбикә, Үтәш-Мамыш.

—Үтәш-Мамышгәрәй,—дип өстәде Сафагәрәй,—шулай инде, балага өч яшь тулганда, бөтен өй эче сөйләшергә өйрәнә.

Шуннан соң алар улларын үзләре тапкан исем белән Үтәш-Мамышгәрәй дип йөртә башладылар.

...Сөенбикә гәүдә торышын үзгәртмичә генә көндәлек догасын укый башлады: «Йә Аллаһы! Ул баланың җәннәткә керүен ата-анасыннан алдарак кылсаң иде. Үзеңнең рәхмәтең белән аны тәмуг газабыннан коткар, аның өеннән яхшырак өй бир, аның гаиләсеннән яхшырак гаилә бир. Йә Аллаһы, безнең ата-аналарыбызны, балаларыбызны һәм дә бездән алдарак иман китергәннәрне ярлыкасаң иде.

Йә, Аллаһы! Улыбызны бездән алда җибәрелгәнгә бер савап кыл, бездән алда үткәннәрдән һәм безгә әҗер-савап ит.»

Хәдичә табын җыйды. Кара-каршы утырып чәй эчтеләр.

—«Батырган», «Кыйссаи Йосыф» китаплары турында белештем, бер айдан өлгертергә сүз бирделәр,—дип хадимә шатлыгын бүлеште. Бу күңелле хәбәр, аның гөманы буенча, ханбикәнең күңелен үстереп җибәрергә бер зур сәбәп булырга тиеш иде. Тик фаразы акланмады.

—Әйт, кирәкми, мәшәкатьләнмәсеннәр,—дип, сүзне тамырыннан ук өзде.

—Үткәндәге истәлекләр белән генә юану алда өмет бетүне аңлата бит ул, ханбикәм,—диде Хәдичә еларга җитешеп,—калган кешегә яшәү фарыз, иҗтиһад итү фарыз. Синең бит әле алма кебек чагың...

Сөенбикә хадимәсен кочаклап алды.

—И, Хәдичә матурым, авызыңа бал да май,—диде,—син минем иң мәрхәмәтле, иң турылыклы сердәшем. Син игелек иясе генә түгел, игелекнең чын үзе. Иншаллаһ, гомерең мөмтаз[32] булыр. Минем булышлыгымны да тоярсың, чараларын күреп куйдым инде. Шәхсән миңа килгәндә исә, хәзерендә өметләрем дә, киләчәгем дә бакыйдагы якыннарым тарафында, Аллаһы хозурында. Җаннарыбыз күптән бергә инде безнең.

***

Үктәбернең шушы томанлы тәүге якшәмбе кичендә Мәскәү Кремленең интим гамәлләр залында Иоанн патша белән Шаехгали хан аулакта гына хәмер хозурында кәеф-сафа корып утыралар иде.

Хәмер сүзне тарта бит ул, ни турында гына сайрашмадылар, дәүләт

[32] Мөмтаз—өстен.

эшләре дә калмады, орыш-сугыш та, гыйшык-мыйшык хәлләре дә...

—Сөенбикә ханбикәнең кикриге шиндеме инде, ни хәрәкәттә йөри?—дип белеште Иоанн мәҗлес соңында.

—Исән-сау улына җеназа намазы укып саташа, хи-хи-хи...

—Алдауч җимне йоткан алайса, бик хуш—диде Иоанн зур канәгатьләнү белән,—рәхмәт, синең ярдәмең белән ул киребеткән патшабикәне олы сәясәттән алып ташладык. Югыйсә төркиләрнең әләмчесенә әверелә иде. Ул вакытта Рәсәй өчен Казанның да, Әстерханның да, Сибириянен дә капкасы ябыла иде.

—Ханбикә хәзерендә тере мәет.

***

«Әлвидаг» китабын тәкъдир итү Санкт-Петербургта яшәүче татар зыялыларын дәррәү күтәрде. Юсуповлар театры шыгрым тулды. Мәскәү, Казан, Касыйм, Әстерхан калаларыннан да кунаклар чакырылган иде. Татли оештыручы-менеджерларын да тапкан, финанс ягын да көйләгән.

Кичәнең беренче бүлеге тулысынча мәҗмуганың эчтәлеген шәрехләүгә багышланды. Ул Марсельнең нотыгы белән башланып китте. Әңгәмә-сөйләшүне Татли үзе алып барды. Әсәрнең язылу тарихы, композициясе, хикаяти тасвир үзенчәлеге укучыларда зур кызыксыну уятты. Беренче булып:

—Әсәр аерым-аерым тәгәлләнгән кыйссалардан гыйбарәт, бу бөтенлеккә зыян китермиме?—дигән сорау яңгырады.

—Автор тарафыннан ул шулай тәгаенләнгән, мин шәхсән үзем бу алымны уңыш дип бәялим,—диде Татли,—аннан соң, әлеге кыйссаларны Сөембикә образы бер җепкә терки. Тулаем бу ике юнәлешле, катнаш сюжетлы, заманча рухта язылган әсәр. Шуңа күрә хронология дә бер җепкә тезелеп кенә бармый, атылып алга да чыга, чигенеп тә куйгалый. Әлеге алым дөнья әдәбиятында хәзер бик киң кулланыла.

Шунда ук икенче сорау очты:

—Белүемчә, әсәрнең күп өлешен сез үзегез язгансыз, ә авторы бер әү генә—Тәфкил морза.—Гаделсезлек түгелме бу?

—Әгәр дә мин автор сыйфатында үземне күрсәтсәм, менә монысы гаделсезлек булыр иде,—дип җаваплады Татли,—әсәр бабам Тәфкил морза башында туган. Мин фәкать аның васыятен генә үтәдем.

—Китапның географиясен ничек күзаллыйсыз?

—Ул рус телендә язылды, татар, француз телләренә тәрҗемә ителде. Инглизлар да кызыксына...

Зал кул чапты.

Кичәнең икенче бүлегендә ни-нәрсәләр буласын Татли хәтта Марсельгә дә чишмәде, сер итеп саклады. Башта Сөембикә ханбикәгә багышланган җырларга конкурс узды. Анда консерваториядә укучы талибәләр көч сынашты. Кара чәч толымнарын күкрәгенә сузып салган чын татарча күркәм йөзле Галия исемле Арча кызы барысыннан да өстен чыкты. Тавышы шагыйранә моңлы иде, лирик җырларны үзәк өзгеч аһәң белән башкара.

Ай моңлана зәңгәр күктә,
Казан һаман сине көтә.
Язмышыма хуҗа булып
Кайтчы, зинһар, Сөембикә!

Бу юксыну белән тулы илаһи моң тыңлаучылар күнеленә сагыну хисләре булып иңде. Күпләрнең күзләре яшьләнде.

Шуннан соң ут сүнде. Ул янә кабынганда манзара бөтенләй үзгә иде инде, халык аһ итте.

Ян-якларында түшәмнән идәнгә кадәр яшел пәрдәләр дулкынланып җилфердәшкән сәхнәнең нәкъ уртасында әкияти купшы тәхет. Тәхеттә—ханбикә!

Тавыш көчәйткечтән тантаналы тәкъдир яңгырады:

—Казан ханлыгының мәшһүр мәликәсе Сөенбикә ханбикә!

Зал дәррәү торып басты. Бина эче алкышлардан дер селкенеп торды.

—Без мәңге синең белән Сөембикә!

Ханбикә, әйтерсең лә, рәссам Ильяс Фәйзулланың Татарстан президенты сараена куелган «Сөембикә илчеләр кабул итә» картинасыннан гына төшеп утырган. Татли-Сөембикә сәнгати образга тулысынча тәңгәл килә иде.

Өстендә итәкләре укалы челтәр белән бизәлгән алтынсу төстәге озын атлас күлмәк. Сөттәй ап-ак камзул. Уң җилкәсеннән дәрәҗә тасмасы сузылып төшкән.

Ханбикә кием-салымының һәр җөеннән, һәр җыерчыгыннан гүзәл затларга гына хас көязлек, назлылык, тәкәбберлек бөркелә.

Тавыш көчәйткеч янә телгә килде:

—Игътибар, игътибар, Сөембикә ханбикәнең матбугат конференциясе башлана. Сораулар алдан ук язмача кабул ителде.

Беренче сорау: ханбикә, кайбер кешеләр сине әхлакый тотнаксызлыкта гаепли. Аерым алганда, Кәшһәк угланны сөяркә урынына тоткансың дигән сүз йөри. Бу хакмы?

—Кәшһәк углан Сафагәрәй ханның иң ышанычлы кешесе, күренекле дәүләт эшлеклесе иде. Иремнең вафатыннан соң ул миңа да шундый ук тугрылык белән хезмәт итте. Казанлылар миннән ваз кичеп, өстемнән урыс патшасына баш орып йөргәндә дә Кәшһәк углан бердәнбер таянычым булып калды. Без гел бергә идек, ханлыкның мөстәкыйльлеген саклап калырга җан атып тырыштык. Ләкин көчләр тигез түгел иде, тора-бара без икәүдән-икәү генә калдык. Ә көннәрдән бер көнне углан да, ялгызымны калдырып, Казаннан качып китте. Мәгъшук бу юлга басар идеме? Юк, ул үлемне дә яраткан кешесе янында кабул иткән булыр иде.

—Рәхмәт, ханбикә, инде түбәндәге сорауга шундый ук ихлас җавап көтәбез.

—Вәгъдә!

—Ханбикә, синең язмышың мәшһүр француз көрәшче кызы Жанна Д Арк язмышы белән охшаш. Тик француженканың исеме бөтен дөньяга мәгълүм, ә Сөембикә үз кавеме эчендә генә калды. Моның сәбәбен ничек аңлатыр идең?

—Теге яки бу шәхеснең даны аны тудырган халык даны белән бәйле. Без бөек дип күкрәк кагып кына бөеклек килми. Әйтик, әгәр мин инглизләр яки сез әйткән французлар кавеменә караган булсам, исемем, һичшиксез, бар гавамга таралыр иде. Барыгызга да мәгълүм, мин әлеге популярлыгым белән дә урысларга, урыс зыялыларына бурычлы. Үз халкыма мин урыслар аша кайттым. Шуның белән бергә, урысларның абруе да мине җиһан мөнбәренә күтәрергә җитешмәде. Чөнки дөнья масштабында ул бик түбән. Шулай да, христианлык минем ыруымны бүгенгә кадәр саклап китереп җиткергән. Карамзин, Кутузов, Суворов, Державин, Тургенев, Кельдыш кебек олпат шәхесләрне дә христианлык күтәргән.

—Болай булгач, татарны, Гаяз Исхакый фаразлаганча, инкыйраз көтә түгелме?

—Бу сорауга княгиня Тәфкил сыйфатында җавап бирү отышлырак булырдыр, мөгаен,—диде Татли—ханбикә бераз уйланып торганнан

сон.—Шушы көннәрдә генә бер аксакалыбызның фикере белән танышырга туры килгән иде. Ул саклану мәсьәләсен төрки телләрнең берләшү мөмкинлегенә бәйләп карый. Ә төркиләр шактый: казахлар, төрекләр, үзбәкләр, кыргызлар... Бу яраклашу, билгеле, дип саный аксакал, тик юк булганчы, бар булу күпкә отышлырак лабаса!

Әлеге фараз, минемчә, инкыйразны гына якынайтыр иде. Икенче куркыныч—глобализация. Глобализация күп халыкларга, күп телләргә яный. Ассимиляция инде бүген үк бугаздан алды. Тик өметсез шайтан гына, ди. Татар зур тарихлы халык. Милләт агачының үзәге таза, тамырлары тирәндә. Шуна күрә ул яфраклары саргаеп, ботаклары зәгыйфьләнеп киткән очракта да шытым бирергә сәләтле. Әлбәттә, табигатьтәгечә тәрбияләү, ашлау, сугару зарур. Монысы инде субъектив фактор: һәр буын өстенә бердәй дәрәҗәдә төшә торган гомум бурыч кына түгел, көндәлек вазифа. Татар кебек дәүләтчелеген югалткан этнос өчен субъектив фактор аеруча мөһим.

Иртәгәсен төш вакытында Татли аэропортта иде инде.

—Мин шундый бәхетле, мсьё Марсель,—диде ул шатлык тулы күзләрен мөлдерәтеп,—сезнең ярдәмнән башка бу кадәр четерекле эшне, ай-һай, башкарып чыга алыр идемме икән? Зур рәхмәт.

—Рәхмәт ишетүе рәхәт анысы,—диде Марсель,—кызганыч, уртак эшебез күз ачып йомганчы төгәлләнде, мин аның гомер буена дәвам итүен теләр идем.

—Нишләмәк кирәк, һәр гамәлнең кайчан да булса ахыры килеп житә шул...

Марсель Татлине үзенә табарак тартып китерде дә:

—Мин сине яратам,—дип пышылдады.

—Мин үземне яратканны бик яратам, мсьё.

Татли ирен чите белән генә Марсельнең бит очыннан үбеп алды.

Ул арада пассажирларны очкычка утырта башладылар.

—Түзгән тимерне өзгән, өметегезне җуймагыз,—диде Татли,—мин бабамның тагын берәр васыятен чокып чыгарырмын әле...

—Хуш, Татли! Әлвидаг!

*2009-2010 еллар.*



Нәҗибә
Сафина

# ЯҢА ҖЫР АЛЫП КИЛӘМ

## Китмибез!

*Без җуләрме,үзебезне утка илтеп ник терик?*
*Бу кызу җирдән чыгып,тагы сәкарьгә ник керик?*
Г.Тукай

**Исәнме, саумы, кадерлем!**
**Кадерлем—кояшкаем!**
**Син генә күтәрә аласың**
**Иелгән бу башкаем.**

**Ничекләр иелмәсен баш,—**
**Оят милләт каршында,—**
**Табигать бүләге булган**
**Телең бетә барсын да...**

**Кояшкаем, синең янда**
**Мин тузаннан да кече.**
**Тик милләтнең телен саклау**
**Барыбер, шагыйрь эше.**

**«Тузаннар» тупланалмады,—**
**Көчсез чыктымыни җыр?**
**Синең хозурыңа илтеп**
**Җиткерә алмадымы җир?**

**Баш иелгән, китек күңел,**
**Кара төн лә җаннарда...**
**Юкса ата-баба каны**
**Ага бит тамырларда.**

Нәҗибә САФИНА—*шагыйрә, публицист; «Әгәр дә уйлагaнда», «Без—шигырь, тормыш—проза», «Кан хәтере» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Исәнме, саумы, кадерлем,
Әй, газиз милләткенәм!
Күтәр башың, ач җаныңны ,-
Яңа җыр алып киләм.

Җаным белән бергә бирәм,
Алыгыз, ал җырымны!
Киләчәгенә тарихның
Бәйләү кирәк чорымны!

Сайлаганнар сай булганнар,—
Бар өмет—үзебездә!
Җаннарда кояш кабызыр
Ялкынлы сүзебездә!

Китмибез тарихтан!—диеп,
Кылыйк һәрбер гамәлне!
Мәгърур милләт торып бассын,
Сокландырып галәмне!

Шагыйрьле милләт телле ул,
Тел—рух, дәүләт нигезе!
Чит халыкка йортка керү—
Шул коллыкның игезе.

Китмибез! Телсез, дәүләтсез
Яшәү нилеген белдек...
Без җиргә үзебез булып,
Яшьнәп яшәргә килдек!

## Тарихта юк

Ял көне—
гавам йокыда,—
эндәшүче юк миңа.
Җылы сүз көтәм, ә ансыз
нәзберек җаным туңа...

Ял көне—
әйтерсең, аны
биргәннәр йокы өчен.
Ял итәр өчен хезмәттә
бирергә кирәк көчең.

Ял көне—
юк ул тарихта,
милләт җаны көйгәндә,
милләт өстенә гел нахак
гаеп-гайбәт өйгәндә.

Ял көне—
инде бишенче
гасыр «ял итә» татар.
Алҗыган, әмма җаннары
көтә—кайчан таң атыр?

Ял көне—
шулкадәр озын,—
биш гасыр дәвам итә.
Торыгыз, әй, милләттәшләр!—
Озак йоклаган затларны
Иманы ташлап китә...

Ял көне—
бетте, торыгыз!
Торыгыз кояш белән!
Сәбәп иткәнгә кояшның
Насыйп итәсен беләм...

Ял көне—
намаз мәле ул
мөселман җаннар өчен.
Күрсәтегез бар дөньяга
шушы хикмәтнең көчен!

Ял көне—
юк табигатьтә,
ул һәрчак хәрәкәттә.
Ялган ял көне китермәс
Милләтне бәрәкәткә.

«Ял көне»—
озак йоклатты
гафләт йокысы белән.
Исән булсагыз торыгыз!—
хөррият быргысын өреп,
чаң суга-суга киләм.

Ял көне—
юк ул тарихта!—
йокламагыз үлгәнче!
Тарихтан йоклап калдылар
диеп, дөнья көлгәнче!

## Күренми...ме?

Дөнья ыгы-зыгы килә,—
Сәхнәләрдә шоу гына.
Урамнарда тракторлар,—
Ак карлардан тау гына.

Сәясмәннәр берөзлексез
Үз-үзләрен сайлауда.
Бизнесменнарның сәмәнен
Кесәләргә җайлауда.

Сукбай эт, сукбай мәчеләр,
Хуҗалары да шундый.
Яшәргә тырышучылар
Җир казый, тиен саный.

Яшәү мәгънәсен югалтып,
Элмәкләргә керәләр.
«Бездә халык рәхәт яши»—
Дип сөйлиләр түрәләр.

Зәңгәр экран, радиодан
Җыр—үткәнне сагыну,

Хыялында гына исән
Нигезенә табыну.

Бар да үтә, бар да китә,
Яшәп калырга, диләр.
Дөньядан алырга булган
Барсын алырга, диләр.

Ала, ала, ала, ала,—
Күмеләләр алтынга.
Адашып йөри бәхетем
Алтын таулар артында.

Тереләй тәмуг утында
Яна әдәм баласы.
Уйлый һаман бу дөньядан
Калды, диеп, аласы.

Дөнья ыгы-зыгысында
Сулар болганган чакта,
Күренми агы карада,
Кара күренми акта...

## Яшьлек күлмәге

Күбәләк керде күңелгә,
Канатлары леп тә леп.
Әллә ни булды йөрәккә,
Бәреп тора дөп тә дөп.

«Ярату!»—дип, типте йөрәк,
«Алдама!»—диде акыл.
Яшькә карап йөремәгән
Мәхәббәт гомер-бакый...

Акылга буйсынмадылар,
Аяклар китте биеп.
Җан белән бергә ачылды
Сандыклар киерелеп.

Яшьлек киемнәрен салып,
Китеп барган кайларга?
Абайламыйча яшемне,
Әй, керештем сайларга...

Яшьлек күлмәге иңемдә,—
Күбәләк канат—җиңе.

**Сөйгәннәрнең буладыр да,**
**Яшьлекнең булмый тиңе...**

**Күлмәгем иңемдә килеш**
**Утырганмын чүгәләп.**
**Күлмәк җиңендә талпына**
**Җан җылысы—күбәләк...**

**Әй, яшьлегемнең сандыгы,**
**Япмаң төшкән өстеңнән.**
**Кермәскә яшьлек илемә**
**Килмәде шул көчемнән...**

**Күбәләк җан, ярсу йөрәк,—**
**Элеккечә алары...**
**Картлыкны капларга гына**
**Теләми күлмәк бары...**

## Бүләк даулаучыларга

**Кояш бер дә сүнми яна,**
**Ялга да тукталмый ул.**
**Бәһа алырга һичкемнән**
**Ялгыш та укталмый ул.**

**Төнлә генә күрәсез дип**
**Үпкәләми ае да.**
**Качмый болыт арасына,**
**Юкса чыга җае да.**

**Чәчәк ата да коела**
**Йә өзеләләр гөлләр.**
**Бәхет мизгелләрен коеп,**
**Узып китәләр көннәр.**

**Һәм...берсе дә үпкәләми,**
**Бәя дә сорамыйлар.**
**Кешеләрнең гамәлләрен**
**Кирегә юрамыйлар.**

**Шагыйрь күңеле—кояш-ай.**
**Шагыйрь күңеле—Вакыт.**
**Вак-төякне өмет итмә,**
**Олы җаныңны ватып.**

**Кайнар кояшны кочып ян,**
**Айны керет өеңә.**
**Ваклама Вакыт-хәкимне,**
**Торсын дисәң көеңә.**

**Шулай яшәгән җаннарга**
**Дөнья куя бәһасен,—**
**Тарихның янмас битенә**
**Шагыйрь булып басасың!**

Габдрахман
Әпсәләмов

## ОНЫТЫРЛЫК ТҮГЕЛ

Бүген, бер дә уйламаганда, Хәбибулла абзыйны военкоматка чакырдылар. Алтынчы дистәнең актыккы көннәрен берәмтекләп чүпләп барган бу картка нинди йомышлары төште икән? Аны бит, хәрби хезмәткә ярамый дип, сугыш елларында да борчымадылар.

Эшкә киткән чакта Хәбибулла абзый карчыгы Гөлсемгә дә борчылмаска кушты.

—Син, анасы, алай өзгәләнмә әле,—диде ул.—Хаталык белән чакырганнары әллә кайдан күренеп тора. Эштән кайтышлый кәгазьләрен кертеп бирермен дә эше бетәр.

Ирләрнең шул инде! Борчылма, дип әйтәләр дә, шуның белән кеше күңеле тынычлана дип уйлыйлар. Бу язу өйгә килеп кергән минуттан бирле ана йөрәген нинди каушау өзгәләвен күрәләрмени соң алар!

«Бәлки, күз нурым турында бер-бер хәбәр килгәндер. Бәлки, исәндер, карлыгачым. Шуны әйтергә картны чакырганнардыр. Бишбалтада шундый хәл булган ди бит. Бөтенләй үлгәнгә саналган кеше үзе кайтып төшкән, ди».

Ана йөрәгендә яңа бер көч белән өмет чаткысы кабынды. Ул әле һаман да сугышта һәлак булган бердәнбер кызының кайтуын көтә иде.

Галимә фронтка кырык беренче елда ук китте.

Вокзалда актык тапкыр саубуллашканда, Гөлсем апа аңа:

—Кызым, берүк сакланып йөри күр,—диде. Галимә елмайды.

—Врач кешегә андый сүзне әйтмиләр, әнкәй.

Бу Галимәнең үз авызыннан әйткән соңгы сүзләре булды. Шуннан соң алар хат язышып кына сөйләштеләр инде. Кечкенә генә кәгазь кисәге ничәмә-ничә мең километр җирләрдән, салкын кар-бураннар, ут-давыллар аша шулкадәр күңел җылысын түкмичә-чәчмичә саклап китерә алыр дип кем уйлар? Галимәнең хатлары ярату, иркәләү сүзләре белән тулы була иде. Бичара Гөлсем апа аларны укыганда май кебек эреп китә торган иде. Өй салкын, тәрәзәләрдә бармак калынлыгы боз, урамда ачы җил дулый, ә Гөлсем апага гүя суыгы да, җиле дә тими, иртә таңнан торып, өстенә җинелчә генә киенә дә, заводка, кунарга да кайтмый эшләгән карты янына сөенечле хәбәр илтергә чаба. Ул шулай көн саен, айлар, еллар буе чабарга әзер иде, тик кызыннан-бәгыреннән исәнлеген белдергән куанычлы хатлар гына килеп торсын!

Ләкин бервакыт Галимәнең хатлары өзелде. Ана никадәр генә тилмереп көтсә дә, хат ташучы аларга керми уза башлады. Яз иде, ә ананың күзенә көн яктысы күренмәс булды. Ут йотып йөрде мескен, картайды, ябыкты,

яфрак төсле саргайды. Шулай да өметен өзмәде. «Эше бик тыгыздыр, хат язарга вакыты юктыр. Бераз бушасын гына, хәзер утырып әнкәсенә хат язар»,—дип сабыр итте, мең төрле сәбәпләр табып, үзен юатты. Тик йөрәге генә ул кадәр озак көтәргә теләмәде, көннән-көн көчлерәк сыкрап, көннән-көн ныграк түземсезләнде. Әгәр инде аларга таба борылган хат ташучы тәрәзәдән күренсә, үзен-үзе онытып, яшерен өмет һәм курку белән аңа каршы йөгерә иде, тәрәзә капкачын шакысалар яки ишек дөбердәтсәләр: «Галимәм түгелме?»—дип, йөрәге кабынып, җылы түшәгеннән сикереп тора, яланбаш, яланөс ишек ачарга ашыга иде.

Кеше йөрәген янып торган утка охшаталар. Һай, шулай гына булсачы! Сүнми торган ут юк бит. Янар, янар иде дә, бер сүнәр иде, газабы да туктар иде. Юк шул, ана йөрәге андый түгел, ул мәңгелек утлы хәсрәттә яна.

Гөлсем апа, иңбашына мамык шәлен салып, кызының язу өстәле янына килеп утырды. Өстәл тартмасын ачты, аннан төрлесе төрле кәгазьгә язылган, вакыт үтүдән инде саргая да башлаган хатлар төргәген тартып чыгарды. Болар Галимәнең хатлары иде.

Ун елдан артык инде—һай бу гомерләр, су кебек ага бит.—Гөлсем апа бу хатларны күңеле боеккан саен алып укый, барысын да диярлек яттан белә иде. Ләкин бүген тагын бер тапкыр укырга әзерләнде. Әмма бераздан анын кайчандыр чем-кара булган, хәзер инде үз төсләрен җуя башлаган күзләре җылымса көндәге тәрәзә пыяласыдай томанланып киттеләр. Кәкре-бөкре хәрефләр, боздай эреп юкка чыктылар. Ана бик тирән итеп көрсенеп куйды. Ләкин еламады, чөнки елый-елый анын күз яшьләре кибеп беткән иде инде.

Анын бөтен гомере хезмәттә үтте. Яшь чагында Казан сәүдәгәрләренә аш пешерде, кер юды. Исәпсез-хисапсыз кимсетелүләргә, кагылу-сугылуларга түзде, коточкыч вакчыл, карун, көнче бай хатыннары анын саф йөрәген этләр кебек таладылар. Аннары ул тормышка чыкты, дөресрәге, аны кияүгә бирделәр. Ире ул чакта пыяла заводында эшли иде. Бераздан Гөлсемне дә үз янына алды. Бу инде революциядән соң булды. Заводта эш җиңел түгел иде. Ләкин монда анын кешелеген таптамадылар. «Әрәмтамак, хәерче»,—дип мыскылламадылар. Иптәшләре барысы да аны тиң күрделәр. Гөлсем апа бөтенләй үзгәреп, канатланып китте. Янгыр суын эчкән чәчәк кебек янадан савыкты.

Шушы заводта ул, кере-чыга, егерме биш ел чамасы эшләде. Сугыштан соң, ревматизм бик җәфалый башлагач кына, картынын кинәшен тотып, «домохозяйкалыкка» чыкты.

Хәзер анын көннәре күбрәк ялгызлыкта үтә иде,—балалары берсе дә гомерле булмадылар.

Ялгызнын юлдашы—кайгы белән сагыш ди. Гөлсем апа моны бик яхшы татыды. Халык белән бергә чакта ничектер җиңелрәк була торган иде. Ул хәтта Галимәнең үлү хәбәрен алган көннәрдә дә артык бирешмәде. Өендә дә, эштә дә кайгыларын уртаклашучы дус-ишләре бар иде, гүя алар бу зур хәсрәтнең бик дәү өлешен үзләре белән алып китә тордылар.

Ул чагында Галимәнең бергә үскән, бергә укыган дус кызлары да килгәләп йөриләр иде. Карт белән карчыкнын хәсрәтен таратып, Галимәне искә ала-ала, бик озак сөйләшеп утыралар иде алар. Соңыннан кызлар төрлесе төрле җиргә таралышып беттеләр. Бары тик Салих исемле бер егет кенә килеп йөрүдән туктамады.

Галимә беркайчан да анын турында әнисенә сер ачмады. Ләкин сизгер күңелле анага кызынын йөрәк тибешен аңлар өчен бер күз карашы да җитә бит.

Аксыл чәчле, ябык йөзле бу оялчан егет килсә, Галимә, куанычыннан

кая басарга белмичә, күбәләк кебек очып йөри торган иде. Ана кеше моны ничек күрмәсен ди! Салихы да аны җаныннан артык ярата иде, ахрысы. Сугыш бетеп, армиядән кайткач та, үз өенә кермәстән, туп-туры Гөлсем апаларга кагылды. Фаҗигале хәбәрне ул фронтта чакта ук инде ишеткән булган, ләкин ышана алмаган.

Өч ел буе көн саен диярлек килеп йөрде Салих. Килгән саен Галимәнең стенадагы рәсеменнән күзен ала алмый, гел аңа карап утыра, ә кайчагында күзләрендә яшь бөртекләре дә ялтырый иде.

Мондый минутларда ананың йөрәге телгәләнә: «Нинди керсез, нинди көчле мәхәббәтне көйдерделәр бит бу каһәр суккан явыз фашистлар!»—дип әрни-әрни уйлый иде ул.

Беркөнне Гөлсем апа, үз баласыдай якын күрә башлаган Салихны тәмам кызганып:

—Салих улым, әллә бу рәсемне үзеңә генә биреп җибәримме?—диде.—Бер дә күзеңне алмыйсың бит.

Егет сискәнеп куйды:

—Миндә бар ул, Гөлсем апа...

Бу сүзләрне ул шундый кайгылы тавыш белән әйтте, Гөлсем апаның күзеннән яшьләре бәреп чыкты, ул үзе дә сизмәстән:

—Кайтмас инде ул, ахрысы, Салихҗан балам, юкка гына көтәсең,—дип әйтеп ташлады.

Һай, ник әйтте икән ул бу сүзләрне! Салих бик каты рәнҗеп:

—Дөрес түгел! Әйтмә бу сүзләреңне, Гөлсем апа, әйтмә!—диде. Аның төсе киткән, кәгазь кебек ап-ак иреннәре калтырый, ә эчкә баткан күзләрендә исә ут яна иде.

Көннәр үтте. Салих килми башлады. Аны каядыр икенче бер шәһәргә күчеп киткән дип сөйләделәр. Бу хәл ана күңеленә аерата авыр тоелды.

Җитмәсә, шундый көннәрнең берсендә карты да аны рәнҗетте. Галимәнең туган көне иде. Гөлсем апа, аш-су хәзерләп, иренең эштән кайтуын көтте. Ләкин карты ул көнне бик соң кайтты. Эш белән дә йөрмәгән үзе, бер дусына кереп шашка уйнап утырган.

—Кара син аны, бөтенләй истән дә чыккан бит, анасы,—диде Хәбибулла абзый, хатынының зарын ишеткәч.

Бу кадәр дә ваемсызлыкны Гөлсем апа күтәрә алмады. Сыгылып төшеп, елап җибәрде:

—Барыгыз да, барыгыз да оныттыгыз, таш бәгырьләр!—диде ул, өзгәләнеп.

Хәбибулла абзый, аптырап, баскан урынында таптанды.

—Чү, анасы, чү. Ни сөйлисең... Кем оныткан... Онытырлыкмыни...

—Куйсана, сөйләмә, ичмасам!—дип бүлдерде аны карчык.—Сина ни... Син бит аны тугыз ай йөрәк астында йөртмәгән...

Елый-елый Гөлсем апаның күз яшьләре кибеп бетте. «Дусларың да, сөйгән ярың да, хәтта атаң бәгырең дә оныттылар сине, кызым. Бары тик әнкәң генә сине күңеленнән чыгармый. Актык сулышын алганда да аның телендә син булырсың».

Бүген, Галимәнең хатларын укыганда, бу рәнҗүле уйлар Гөлсем апаның йөрәген янадан җәрәхәтләп киттеләр. Ул, тоныкланган күз карашы белән хатларга текәлеп, озак кына хәрәкәтсез утырды да, өстәл тартмасын ябып, урыныннан торды. Аннары зур урамга караган тәрәзә янына килеп сөялде. Якынлашып килгән кичнең зәгыйфь яктысы аның җыерчыклы йөзенә тагын да тирәнрәк моң салды.

Урамнан машиналар уза. Халык агыла. Тәрәзә турысыннан гына бер егет белән бер кыз көлешә-көлешә үтеп киттеләр. Аларга ни? Алар бит

кайчандыр шушы йортта Галимә исемле бер кыз яшәгәнлеген дә, аның Ватан сугышында үлеп калганлыгын да, карт анасының хәзер хәсрәт йотып, монланып тәрәзәдән карап торуын да белмиләр.

Тышта тәңкә-тәңкә кар ява. Күрче, быел кыш нинди иртә килә. Әле октябрь дә бетеп җитмәгән, инде кар-бураннар уйный башлады. Хәер, бу ятып кала торган кар түгел әле. Иртәгә булмаса берсекөнгә кояш чыгар да аның эзе дә калмас. Нигә ана кайгысы да шул кар кебек кенә эреми икән?

Картының кайтыр сәгате якынлашкач, Гөлсем апаның борчылулары бермә-бер артты. Хәзер инде ул утырып та, басып та тора алмый башлады. Аякларының авыртуына карамастан, алгы як бүлмә белән кухня арасында, киләп саргандай, бертуктаусыз йөреп торды. Кыңгырау тавышы ишетелмәс дип куркып, барлык бүлмәләрнең ишекләрен каерып ачып чыкты, радионы туктатты. Аннары кыңгырауның төзеклегеннән шикләнеп,—кайчагында ул бер дә шалтырамый, каһәр,—ишегалдына чыгып карады. Ишегалдында кеше-кара булмагач, урамга ук атлады. Ләкин Хәбибулла абзый урамда да күренмәде. Мөгаен, тагын шашка уйнарга кергәндер, карт юләр!

Гөлсем апа, ни өчен икәнен үзе дә белмичә, буфетка үрелгән чакта гына, ниһаять, кыңгырау шалтырады. Тын бүлмәдә ул шундый каты булып ишетелде, Гөлсем апа хәтта, сискәнеп китеп, кулындагы чынаягын төшереп җибәрде.

Колакчын бүрегенә, пальто якасына кар бөртекләре кунган Хәбибулла абзый ишек төбендә басып тора иде. Үзе аптыраган да, курыккан да кебек. Күзләре, түгәрәкләнеп, туп-туры карыйлар. Керфекләре белән мыек чылгыйларында әллә эрегән кар тамчысы, әллә яшь бөртеге җемелди.

—Атасы, ни булды? Авырып кайттыңмы әллә?—дип сорады Гөлсем апа, көч-хәл белән.

Карт эндәшмәде. Ничектер бик сәер атлап түргәрәк үтте дә, акылын башына жыя алмагандай, урындыкка утырды, кулы белән күзләрен каплады.

Гөлсем апаның иңендәге шәленең бер очы аркасы буйлап салынып төште, шәленең икенче почмагын йомарлап, атылып чыгардай типкән йөрәге өстенә бастырды.

Хәбибулла абзый кесәсеннән кулъяулыгына төрелгән бер әйбер чыгарды да өстәлгә куйды, калтыранган куллары белән төргәкне чишә башлады.

—Менә, анасы... истәлек итеп... кызыбызның... орденын...—диде ул, әкрен генә.—Ил онытмаган. Унике ел үткәч эзләп табып бирделәр. Үзе исән чакта ала алмый калган булган, наный.

Гөлсем апа бу минутта теләсә нинди авыр хәбәрне ишетергә дә әзер иде, әмма ләкин мондый сүзләрне ул бөтенләй-бөтенләй көтмәгән иде. Кайчандыр бала тудыру йортында шәфкать туташыннан нәниен беренче тапкыр үрелеп алган кебек, калтырап торган ике кулы белән өстәл кырыендагы орденны алды да күзләренә якын китерде.

—Кызым төсе,—дип пышылдады аның агарынган иреннәре. Ике бөртек күз яше, карт ананың жыерчыклы яңаклары буйлап тәгәрәп төшеп, орденның якты нурлары өстенә тамды.

*1954*



Лилия
Сәгыйдуллина

## ЧИКСЕЗЛЕК ЧИКЛӘРЕНДӘ

***

**Язылмаган шигырьләрем дәшә:**
**«Язып кал син, диләр, язып ал!**
**Ничек килсәк, шулай ук китәрбез,**
**Аерылса уртак язмышлар.»**

**Язылмаган шигырьләрем кѳтә:**
**Иң-иң яхшылары—алтыннар!**
**Кѳмешләргә әйләнмәсләр микән?—**
**Шул килешме әллә калсыннар?**

**Язылмаган шигырьләрем кайчак**
**Тѳшләремә кереп йѳдәтә.**
**Ният тә дә юкны бар итә дә,**
**Уйлаганны йѳзгә үзгәртә.**

**Язылмаган шигырьләрем кинәт**
**Әйләнәләр тере күмергә:**
**Кемнең ымы кайсы суфлер аша**
**Кайтавазлый минем күңелдә?**

**Язылмаган шигырьләрем миңа**
**Хат ташучы эшен тапшыра.**
**Хатны яздыручы, алучы бар—**
**Ике якны бәйләп мин торам...**

### Тамырдашлар

**Ата һәм ат—тамырдашлар микән?**
**Безнең ѳчен генә шулаймы?**
**Атлар күргән саен йѳрәк шуңа**
**Тибешен онытып, уйга чумамы?**

---

Лилия СӘГЫЙДУЛЛИНА—*шагыйрә, Башкорт дәүләт университеты доценты; "Абага чәчәге", "Мизгелләр йолдызлыгы" исемле китаплар авторы. Уфада яши.*

Әткәй һәм ат—аерылгысыз иде.
Булгандырмы шулай тиеш тә?
Икесе дә бер-бер артлы китте.
Уйлар җитмәс җиргә—биеккә.

Атсызлык та атасызлык бит ул
Өй-йорт өчен. Ил-йорт өчен дә!..
Дөнья йөге ишелеп өскә төшә
Ат-атасыз һәркем, һәр илгә.

Атлы гына алалгандыр исем
Һәм булгандыр атлы—атаклы...
Атсыз оныкэзләп табалырмы
Бабалары җиккән туратны?

...Хыял аты ялларына ябышып,
Байкап йөрим кайчак тарихны,
Хәтер яланының тибененнән
Алып кайтмак булып шул атны.

***

Сөю чорым үтте.
Килде сагышым...

...Ярдан күзәтәмен
Елга агышын:
Бер үк елга бит ул
Җәен һәм кышын,
Үзгәртсә дә бераз
Йөзен-рәвешен...

## Болгарга бару хатирәсе

Су өстендә
Ак пароход.
Ярлар—ага.

Ярлар калган
Ярлар ага
Артка таба.

Елга—алга
Берөзлексез
Йөгерә, чаба...

Пароход та,
Елга ертып,
Алга бара.

Шул ярадан
Идел каны—
Дулкын бәрә...

Ник бу дулкын
Гел йөз тота
Ярга таба?

Күр, чал башын
Соңгы төяк—
Ярга сала...

...Мәңгелекне
Ера-яра
Вакыт ага.

Дулкыннардан
Биек-биек
Ярлар сала.

—Ә пароход?..
—Вак йомычка...
Тик шулай да

«Елга кала,
Ярлар ага»,—
Дияр өчен

Пароход та
Кирәк, ахры,
Сиңа, кешем..

***

Кабер өсте—кипкән яфрак:
Тазартамын.
Еллар күмгән хәтеремне
Яңартамын...

Ел агачы койган яфрак
Катлам-катлам:
Узган гомер өзелгән дә—
Җиргә кайткан.

Һәм җир аны какмый-сукмый
Кабул иткән.

Җир үзе дә шул катламнар
Эзе икән.

Күрше каен ача әнә
Бөреләрен,
Белсә дә ул көзге, кышкы
Яфрак хәлен...

...Орлык сибәм, яңа эзләр
Калсын диеп,
Китмәс борын чәчәкләнеп
Алсын диеп.

## Парадокс

*«Умом Россию не понять...»*
Ф.Тютчев

Гаҗәеп ил Рәсәй, гаҗәеп ил!..
Акыл җитми аңлап бетәргә.
Монда сарык үзе бүре сайлый
Сарык көтүләрен көтәргә.

Гаҗәеп ил Рәсәй, гаҗәеп ил!..
Уртак аршын монда нәрсәгә?!.
Балаларын башта үстерә дә—
Утырта йә чәчә иртәгә.

Гаҗәеп ил Рәсәй, гаҗәеп ил!..
Үзенә гел үзгә юл сала.
Шуңа, ахры, юллар һәм юләрләр—
Кол-карактан кала—төп бәла.

Гаҗәеп ил, Рәсәй, гаҗәеп ил!..
Могҗизага кирәк ышану;
Могҗизалар кыры уртасына
Табышларны күмеп, бушану...

***

Иң беренче югалтуым минем!
Беренчесе... Шуңа—ачысы.
Хушлашулар иле Колумбы—син.
Ә синнән соң?!. Җиңел—кайсысы?!.

Һәрбер табыш—югалтуга барыш
Икәнлеген алдан белсәмме?!.

Язмышларга язылганны алдан
Күңел күзе белән күрсәмме?!.

Офык якынайгач, серен тойдым
Югалтулар дигән бу фәннең:
Син ачкан ил берөзлексез үсә—
Шулкадәр күп таба белгәнмен!..

## Диогенлык

Кешелеклелек эзләп йөрим
Мин кешеләр илендә.
Дәверләр үтеп торса да—
Мин Диоген[1] хәлендә.

Оран салам!.. Бер кайтаваз
Юк көнемдә, төнемдә.
Аңлау кая?! Сөйләшми ич
Бабил[2] йөрәк телендә!

Бер мин генә түгелдер лә
Җандаш эзләп йөрүче?..

Йөрәк утым—моң ялкыны:
Булыр, бәлки, күрүче?

Бәлки, бу эш—юк эштер ул?..
Яндырсаң да, янсаң да—
Нәтиҗә бер, әгәр җаннар
Калса кузы—калканда.

Канатлану—буп-буш хыял
Җанлы-җансыз дөньяда!
...Күбәләк артыннан йөгерә
Кеп-кечкенә бер бала...

[1] Диоген – философ
[2] Бабил – Вавилон



Рәмилә
Майорова

# ШУНЫ ТЕЛИ ЙӨРӘК

***

**«Сөймәвемне әйтсәм, рәнҗер,**
**Сөйләшмәс тә»,—дисеңме?**
**Ялгышасың!.. Болай түбән**
**Бәяләмә хисемне.**
**Үпкәләтмә мине. Аңла—**
**Синсез көн итә алам.**
**Рәнҗемим. Сөюне шулай**
**Саф килеш саклап калам.**
**...Күңелемә моң утырды.**
**Үзгәрдем... Тоймыйсыңмы?**
**Синсез синле яшәп була.**
**Шул ягын уйлыйсыңмы?**

***

**«Чибәр түгел» дисәгез дә,**
**Бәхәсләшмим сезнең белән.**
**Үз—үземне алдый алмыйм—**
**Матурлыгын күреп беләм.**
**Үкенмәм кук, эресәм дә**
**Җылысыннан сүзләренең.**
**Газизлеген исбатлый бит**
**Танышлыгы күзләренең...**
**«Нәрсә таптың анда?» димә!**
**Куырылып хистән көям.**
**Бәхәсләсләшеп торыр чакмы?!**
**Мин бәхетле—Аны сөям!..**

***

**... Сүзсез генә мине кире какты—**
**Исәнләшми үтте янымнан.**
**Нидер сынды шулчак йөрәгемдә,**
**Нидер чыгып очты җанымнан...**

Рәмилә МАЙОРОВА—*яшь шагыйрә, КФУ аспиранты. Шигырьләре көндәлек матбугатта даими күренеп килә. Казанда яши.*

...Туктатмагыз! Барыр җире булса
Оча бирсен әйдә, эзләмәм...
Үзе килсә—кабул итәм, ләкин
Аннан ары берни эшләмәм...

***

Кара җирнең үзәгенә,
Бар исән күзәнәгенә
Сеңгән мыштым салкын.
Өшеп агарынган кышта,
Ыгы-зыгылы тормышта
Җанда—сүнмәс ялкын...
Янып бетеп киләм эчтән:
Ут җанымнан тәнгә күчкән
Мин яртылаш исән.
...Кайнар маңгаемда тоям:
Фәрештәме диеп торам.
Күзем ачыйм дисәм—
Синең учың икән!
Бөтенләйгә микән?..

## Мизгел

Синең сорау—
Карашыңа уралган да,
Кереп бара аңга.
Минем җавап—
Бәйле телләремне чишеп,
Атыла синең янга.
Бик-бик тиздән
Шаян керфекләрең миннән
Яшерерләр сине.
Аңа кадәр
Бер туйганчы йөзләреңне
Күреп калыйм инде.
Ашык, хәтер!
Җавап көткән ул күзләрне
Истә калдыр тизрәк!
Ашык, күңел!
Бу мизгелдән ләззәтләнеп
Калсын гашыйк йөрәк.
...Үтте мизгел.
Мин җавапны бирдем.
Кузгалырга кирәк.
Хәерле юл!
Син бары тик яшә, сөю!
Бик тә гади теләк—
Шуны тели йөрәк.

***

Үлем көтәм...
Үз-үземнән ераккарак
Качу өчен,
Үзем генә белгән күкләремә
Юлны табып, тизрәк
Ачу өчен...
...Үлем көтәм
Үз эчемдә яңабаштан
Туар өчен,
Янып көйгән йөрәгемне...
Комнар белән ышкып
Юар өчен...
...Аллам, кичер!
Үләр идем:
Башка булып туар өчен,—
«Үлем» төшенчәсен зиһенемнән
Бөтенләйгә
Куар өчен.

Печән Базары

*Сатирик әсәрләр конкурсы*

Рөстәм Галиуллин

# ДАН

хикәя

Рәдиф—тарихи шәхес.

1953 елның 6 мартында ана төп-төгәл алты яшь иде. Малайның әнисе Фәнүзә укытучы булып эшли. Өйдә бала караучы кеше булмагач, ул аны эшенә ияртеп килә. Шулай итеп, Рәдифнең көннәре мәктәптә, укытучылар өчен ясалган бүлмәдә уза. Укытучылар сөйләшкән һәр сүз Рәдиф колагына кереп бара, башкаларга тиз тарала. Шуңа да бу мәктәптә ниндидер серле, яшерен хәбәрләр сакланмый иде.

Шук малай сирәгәя башлаган чәчле, саллы гәүдәле мәктәп директоры Хәкимҗан абыйсы белән дуслашып китте. Малайга аның кып-кызыл бәрхет ябылган өстәле бик ошый иде.

Ул көнне Рәдиф укытучылар бүлмәсендә беркем дә булмаудан файдаланып, теге матур өстәл артындагы урындыкка утырды. Үзен дөнья хакиме итеп хис иткән малай Хәкимҗан абыйсының җыелышларда кулларын болгап-болгап сөйләгән хәрәкәтләрен кабатлады һәм өстәл уртасында торган язу карасына кагылганын сизми дә калды. Шешәдәге язу карасы кып-кызыл өстәл буйлап агып китте...

Рәдиф бу эшенең юньлегә итмәсен чамалады. Мыштым гына урындыктан шуып төште. Ишекне ачып, бүлмәдән шылдым дигәндә генә, аны кинәт килеп кергән әнисе тотып алды. Әнисенең күзләре никтер яшьле иде. Ул Рәдифнең «гөнаһ»ын күрде дә тирги-тирги «арт сабагын» укытты.

—Шундый көнне... дуңгыз малай... шундый кайгылы көнне...

Әнисе, елый-елый, «тәрбия эшләрен» тәмамлауга, ашыга-ашыга бүлмәдән чыгып китте. Рәнҗетелгән Рәдиф үзе генә калгач, үкереп елап җибәрде...

...Ә бу вакытта ишегалдында бөтен мәктәп җыелган. Укытучылар күз яшьләрен яулык очы белән сөртә-сөртә, артык «хисле»ләре кычкырып ук елый-елый, мәктәп укучыларын сыйныфларга аерып, сафка тезә. Ишегалдындагы сафта балалардан «П» хәрефе хасил булган иде.

Бүген бик кайгылы көн икән... Милләтләр атасы Сталин вафат булган... Кызлар мышык-мышык елаша, ә шук малайлар исә күз яшьләрен чыгаралмый интегә иде. Менә шул вакытта сыйныф укытучылары арасында яшерен ярыш башланды: кайсы сыйныф ныграк елый, кайгыра?!

Укытучылар рәт арасыннан балаларның елауларын тикшереп йөри. Көлеп басып торган малай-шалай булса, шундук янына йөгереп килеп җитәләр.

—Син ник еламыйсың?! Кайгырмыйсыңмыни, оятсыз?!

—Кайгырам...

—Әйт әле, сиңа ипине кем ашата?

—Әни-и...

—Ах, җүнсез! Нинди анаң булсын, иптәш Сталин ашатты сиңа ипине, белдеңме?

—Ие...

—Кем сиңа фашистны җиңеп, тыныч тормыш бүләк итте?

—Эти-и...

—Надан! Безгә җиңүне олы атабыз Сталин алып бирде. Ул бүген үлгән. Син шуңа кайгырмыйсыңмыни?

—Кайгыра-ам...

...Мәктәпнең шушы кайгылы митингка әзерләнеп мәш килеп яткан мәле иде. Кинәт мәктәпнең зур ишеге шыгырдап ачылып китте. Аннан иләмсез тавышлар белән үкереп елап, әнисе тарафыннан кыйналган Рәдиф килеп чыкты... Рәдифнең бите буйлап яшь чишмәсе ага да үпкәсе күренерлек итеп ачылган авызына чума, күп елаудан күзләре кызарган. Малайның гәүдәсе калтырана, ул «ыы-гы, ыы-гы» тавышлары чыгарып өйләренә таба юнәлде.

Митингны башлап җибәрергә әзерләнгән директор Хәкимҗаннның, малайны күрүгә, чын күз яшьләре бәреп чыкты... Моңарчы кульяулыгын төкереге белән чылатып азапланган иде... Ул малайның артыннан йөгереп барып, кочагына алып күтәрде. Аннары, саф алдына басып, дулкынланудан сүзләрен йота-йота, сөйли башлады:

—Менә, иптәшләр, укучылар...Үзенә алты гына яшь булуга карамастан... Рәдиф... иптәш Сталинны югалтуның нинди кайгы... фаҗига икәнен аңлаган... Ул сезнең барыгызга да үрнәк булырлык итеп елый...

...Үзенә яклаучы тапкан, язу карасы өчен Хәкимҗан абыйсыннан эләкмәсен аңлаган Рәдиф, инде акырып елаудан туктады. Ул, тыныч кына сулкылдап, директор абыйсының киң эшләпәсе читеннән сафка баскан балаларны күзәтте. Митинг «П» хәрефе сыман тезелгән... «С» хәрефенә дә ошаган үзе... Көн саен мәктәпкә ияреп килә торгач, Әлифбаны яттан белә иде инде ул.

---

## БАТТАЛИЗМНАР

● *«Айлык пенсияң түзәрлекме?» дип сорамагыз. Түзәрлек! Соңгы егерме тугыз көне генә бик авыр уза...*

● *Аның ишегеннән чыкканда аягыгызны сөртергә онытмагыз!*

● *Без яшь чакта: «Минем хакта нәрсә уйлыйлар икән?» дип сагаябыз. Олыгайгач, нәрсә уйласалар да барыбер сыман. Картайгач ачыкланып бетә: безнең хакта бернәрсә дә уйламыйлар икән.*

● *Иксез-чиксез зур илдә яшәүнең файдасы да бар: качар урын күбрәк.*

● *Кайбер патшаның сәясәте үз шамакаен да көлдерә.*

● *Телевизор—кинотеатрлар каберлеге.*

● *Тешләреңне саклыйм дисәң... телеңне кыска тот.*

● *Уянган милләткә бишек җыры җырлаучылар күбәеп китте.*

● *Фәкыйрь илнең—гимны, начар товарның рекламасы шәп була.*

● *Ходай хатын-кызны—ирләр өчен, ирләрне хатын-кызлар өчен оҗмах итеп яраткан. Ике арадагы тәмугны алар үзләре тудыра.*

● *Чыбык яшь чакта яхшырак бөгелә—дидек тә, яшь буынны бөкре итеп үстердек.*

**Фәнзаман БАТТАЛ**

Алсу
Шәмсутова

# «АЛДЫМДА—ЧИКЛЕ ЧИКСЕЗЛЕК...»

## РӘМИС АЙМӘТНЕҢ ИҖАТ ПОРТРЕТЫНА ШТРИХЛАР

Хәзерге фәлсәфи поэзиядә үзенчәлекле тасвирлау стиле белән аерылып торган шагыйрьләрнең берсе—Рәмис Аймәт. Аның лирикасы, әйтерсең, яшәешне аңыкүңеле аша үткәреп, кайгы-сызлану аһын сеңдергән сыктау һәм... хөрлек лирикасы. «Айның аръягында» дип исемләнгән шигырьләр җыентыгына (2004) кергән фәлсәфи әсәрләренең төп темасын билгеләп, шуны әйтергә була: анда Инсанның рухи бәйсезлеге алга сөрелә. Илаһи бу бәйсезлек Яшәешнең фаҗигалелеген аңлаган мәлдә генә таныла. Мондый фәлсәфә шагыйрь иҗатында Илаһият кануннарына буйсынмаучы гыйсъянчылык кебек кабул ителә.

Р.Аймәтнең лирик герое ике дөнья арасында калган: «Әллә соң мин күкләр канунына, Җирләрнекенәме буйсынам?». Яшәешне шулай югарыдан, биектән күзәтү аның «мин»енә язмышны богау итеп кабул итүдән арынуга ярдәм итми. Киресенчә, лирик герой кичеп чыга алмаслык экзистенциаль ситуациядә—яшәешнең һәм җанының метафизик проблемалары алдында ялгыз кала.

*Дөньяларның кайсы читендә мин,*
*Вакытларның кайсы чигендә,*
*Гомеремнең кайсы мизгелендә,*
*Хыялымның кайсы күгендә*
*Яшим икән?*

(«Икән?»)

Р.Аймәтнең лирик герое белән танышу соңгысының эчке дөньясында гармония юклыкны да ачарга ярдәм итә. Гармония юк, чөнки герой Җирдәге тормыштан канәгать түгел, күп очракта ул үзен Яшәешкә каршы куя. Бу, үз чиратында, ялгызлык хисенә, кешенең Галәм-Җиһан алдында кечкенәлеген аңлауга, бу уйдан туган күңел сыктауларына китерә.

*Мин Җирләргә төштем. Озаккамы?..*
*Яшәп туйгач җирдә яшәүләре*
*Авыр булмас микән?...*
*Ни кылыйм?...*

(«Мин Җирләргә төштем»)

Р.Аймәтнең сурәтләү алымы гади түгел: образлары «челтәрле», шул ук вакытта тирән эчтәлекле һәм күпмәгънәле. Бу стиль без бүген күреп белгән башка

шагыйрьләр стиленнән күпкә аерылып тора һәм аны «гыйсъянчы экзистенциалист стиле» дип атарга мөмкинлек бирә. Р.Аймәт лирикасы һәр кешенең хыяллары, шатлык-кайгылары, хәл ителәсе мәсьәләләре белән тулы үз дөньясын тудыруы идеясен матур гәүдәләндерә. Шул ук вакытта кеше тышкы дөнья —яшәеш, җәмгыять белән көрәш алып бара: яшәү өчен, тапталмыйча исән калу өчен.

*Төн—кабер. Аh, монда никләргә*
*Хакимлек итә соң Төн генә?*
(«Мин монда!»)

Мондый көрәш шәхесне яшәү максаты һәм вазифасы турында тирән уйларга этәрә.

*Бу дөнья—гарасат мәйданы.*
*Әллә соң яшәү дә—бер җәза?!*

Р.Аймәт иҗатында Х.Такташның хөр һәм бунтарь иҗат рухы чалымнары үзен сиздерә. Шул ук вакытта интеллектуаль шагыйрь буларак танылган Р.Фәйзуллинның шигъри хөрлек билгеләре дә төсмерләнә.

*Очыш көтәм...*
*Соңгы әверелеш...*
*Күзләремдә тамчы-тамчы шигырь*
*Яна, яна...*
*Яңа шигырь булып*
*Кабынырга тора дөрләп бәгырь.*

Рәмис Аймәт—дөньяга үзенчә карарга ярата торган шагыйрь. Ул тудырган шигъри мифологемаларның кабатланмас үз йөзе бар, укучының фантазиясе, яшәеш турындагы белемнәре һәм, иң әһәмиятлесе, әдәби архетиплар җыелмасы тирән булганда, аның шигырьләре бөтен матурлыгында ачыла.

Әсәрләренең композициясе нигезендә чиксез пространстволы һәм ачык вакыт категорияле, каршылыклы һәм күп вариантлы лейтмотивлар системасы ята. Аның лирик герое җир тормышына мөкиббән китмәсә дә, язмыштан рухи азат түгел. Язмышка бәйле булу, тәкъдирдән уза алмау лирик геройның һәр аһәңендә сизелә.

«Алдымда— чикле чиксезлек!» шигыре гомуми Яшәешнең акрынлап чишелеше кебек янгырый.

*Алдымда—*
*ЧИКле ЧИКСЕЗЛЕК!*
*ИРЕКсез ИРЕК!*
*Тирбәлә дә мираж булып,*
*Югала эреп.*

Яшәештә Кеше ялгызы торып калгач, үзен кодрәтле итеп тоя. Әмма теләгән нәрсәләргә ия була алмаганын аңлаудан адәм баласына бирелгән ирекнең чикләнгәнлегенә инана. Шуны тану ноктасында «ирексез ирек»кә ия булудан туган хис экзистенциаль хисчәнлеккә алышына.

Җир кысаларындагы яшәештә инсанга тыелган һәм тыелмаган кануннар бар. Эш-гамәлләрнең әнә шулай чикләнгән булуы үзен яшәештә кодрәтле итеп тоярга теләгән адәм баласы өчен газаплы тартышка әйләнә: тыелган гамәлләрдән баш тартыргамы, әллә алар иркенә бирелергәме? Йөрәк-күңел кинлегендә барган бу тартыш җанны әрнетә, бимазалап тора, көчне ала.

*Гүләп тора җир һәм күкләр*
*Вакыт чигендә.*

*Кемдер дәшә: «Кич чикләрне,*
*Кич син, чигенмә!»*

Җиһанда адәм баласы акыл белән аңлап, күреп бетерә алмаган дистәләрчә «чикләр» бар: реаль һәм ирреаль тормыш чикләре, яшәү һәм үлем чиге, еллар чиге, җаннарның рухи үсеш кичерү чиге, үткән-бүгенге-киләчәк чиге, акыл белән акылсызлык чиге, гөнаһ белән гөнаһсызлык чиге... Ниһаять, без акылга да сыйдыра алмый торган параллель яссылыклар чиге! Җир кешесе булган лирик герой яки теләсә кайсыбыз мондый чикләрне үтеп чыга аламы, кодрәтлеме аңа адәм баласы? Үз теләге белән куркусызлыкны әләм итеп, җаваплылыкны тоеп, Инсан теләсә кайсы чикне үтеп чыга ала! Әмма моның өчен аның рухы саф һәм чикләрне үтәрлек үзгәрешләргә әзер дәрәҗәдә булырга тиеш: «Кич чикләрне, / Кич син, чигенмә!» Лирик герой аңында әнә шундый өндәү уяна. Шул ноктада үзенең яшәештәге урыны хакындагы хакыйкатьне ачарга теләгән лирик герой Җиһанның экзистенциаль бөтенлеген һәм онтологик чиклелеген аңлый. Җирдәге Яшәеш аңа Үксез (ятим, беркемгә дә кирәкми торган) булып тоела. Әлеге сыйфат Р.Аймәтнең яшәеш концепциясендә еш кына төп мотивка әверелеп китә.



*Яулап алган бар тарафны*
*Бөек Үксезлек.*
*Алдымда—*
*ИРЕКсез ИРЕК!*
*ЧИКле ЧИКСЕЗЛЕК!*

Беренче карашка, шагыйрь иҗаты шәхси кичерешләр, эмоциональ сөземтәләрдән генә торган тәэсир калдырса да, лирик геройның автор «мин»е белән тәңгәл килмәвен, аның мөстәкыйль фикерләү сәләтенә ия булуын аңлыйбыз. Лирик герой Яшәешнең чиксезлеге, бөеклеге алдында үзенең көчсезлеген ача, шуңа да кире Күккә —Илаһияткә омтыла. Бу теләк Илаһиятне «сагыну моңы»н барлыкка китерә.

*Җаным ашар, Күк капкасын ачып,*
*Мәңгелеккә—тынлык иленә...*
*Мин китәрмен...*
*Мәтәм гөсләсендә*
*Үкси-үкси соңгы кыл елар.*
*Баш очымда үксез күкчәчәк тә*
*Кайтуымны көтеп сулкылдар...*
(«Мин китәсе көн»)

Автор җанының киеренкелеге шигырь юлларының өзеклегендә, аларның күпнокталар белән тәмамлануында, мәгънәви басымга ия сүзләрнең еш кабатлануында да чагыла. Татар шигъриятенә Х.Туфан кабат кайтарган «Хафиз стиле»н куллану да (беренче һәм соңгы юлларның кабатланып килүе) яшәешне кабул итүдән, үз миссиясен аңлаудан туган эчке киеренкелекнең зураюын күрсәтә.

*Бәллүр кебек садә иртәләрдә,*
*Ак биләүдә чакта бар җиһан,*
*Иңнәремә килеп кунар кебек,*
*Канатларын җәеп ак илһам.*

*Уйларыма һич юк киртәләр дә,*
*Бәллүр кебек садә иртәләрдә.*

Кайбер тәнкыйтьчеләр Р.Аймәтнең сурәтләү теленә хас «сүз уенын» аңлап бетермиләр, аны формализм кебек кабул итәләр. Асылда ул шагыйрьнең сәнгатьчә эзләнүләрен, яна образлар, төзелмәләр табуны максат итүен дәлилли. Р.Аймәтнең Инсан концепциясендә кеше үзендә Күк һәм Жир яссылыгын йөртүче буларак күзаллана. Күкләрдә туган илаһи, чиста, горур, бәйсез Жан Жиргә инәргә мәжбүр ителеп, үзен тоткынлыкка эләккәндәй хис итә. Жир тормышы аның өчен читлек. Рухи жан анда жилкенә алмый, тормыш аны үз кысасына утырта һәм «үз кубызына биетә».

*Киләчәк? Юк!!!*
*Үткән—кара урман.*
*Жан талпына тимер читлектә.*
*Сур быргысын өрә фәрештәләр—*
*Вакыт килеп житкән соң чиккә.*

Инсанга Жир тормышында өч төрле илаһи юл бирелә: белемнән түбән юл, белем эчендә инанып яшәү һәм белемнән югары инану белән яши торган юл. Бу өч юл кешенең нинди рухи яссылыкта яшәвен, нинди процесслар кичерәчәген күрсәтә. Р.Аймәтнен фәлсәфи концепциясендә күбрәк «белем эчендәге инану» сиземләнә. Мондый принцип татар шагыйрьләренең күпчелегенә хас. Бары тик «белемнән өстен инану»га ия булган шәхесләр генә Жиһан турындагы белемнәреннән канәгать булмыйча, аны тирәнәйтү уе белән яналар. Бу Илаһи утка омтылышта, аның нурына тартылуда чагыла.

Шагыйрь ижатында еш кулланылган Жан һәм Тән мотивлары турында сөйләгәндә, без лирик геройның Жан образы формасындамы, әллә Тән образы рәвешендәме чыгыш ясавын аңлап бетерә алмыйбыз. Без Тән белән Жан арасында нинди бәйләнеш барлыгын, бу ике төшенчәнең бербөтенме, әллә ике мөстәкыйль башлангычмы икәнен күзәтергә әзер торырга тиешбез. Шагыйрь әлеге ике төшенчә белән бик кыю, житез эш итә, ягъни алар бер үк әсәр кысаларында да бер-берсенә әверелешкә (метаморфозага) дучар булалар. Вакыт-вакыт укучыга тән һәм жан үрелешеннән азат ниндидер икенче бер чынбарлык та күзаллана башлый.

«Мин әле тумаган» шигырендә туу һәм үлем категорияләре урынына, шагыйрь Илаһилык һәм Туу яссылыгына мөрәҗәгать итә: «Мин әле тумаган, мин әле / Үрелеп бакмаган дөньяга». Ана каршы яшәешнең туасы жаннардан гамьсез рәвештә гүләве китерелә.

Яшәеш турында сөйләгәндә аның нинди булуын, ничек тормышка ашуын дәлилләү өчен нык, тирән тәжрибәле булу сорала. Яшәеш фәлсәфәсе шагыйрьдән яки философ булуны, яки «тормыш турындагы тирән белемнәр»не таләп итә. Югарыда әйткәннәр Р.Аймәт фәлсәфи концепциясенең чишмә башын табуны сорый: шагыйрь мондый белемнәрне кайдан алган икән, ана бу фикри образлар ничек килә?

Жан һәм Тән теориясендә башкаларга бәхет бирү дигән өлеш бар. Нәрсә дигән сүз бу? Бу альтруистик сыйфат, ягъни нәфес кебек жанның түбән катлавыннан, эгоизм сыйфатыннан югарыга күтәрелү, башкаларга ярдәмгә килү кебек үк, аларга рухи жылылыкны бирү. Жанның нигезендә әлеге сыйфат бармы-юкмы икәнен билгеләү өчен ярата белү, синең тормышка мөнәсәбәтең, башкаларга мөгамәләң төп күрсәткеч булып тора. Рухи үлчәнеш, рухи халәт — инануны дөнья турындагы белемнәрдән югары куеп, шуна омтылган Жан өчен үзмаксатка әйләнгән юл. Шагыйрьнең «мин»е үзен Яшәеш эчендә таба, бу аны куркуга сала. Яшәешне ул эмпирик сыйфатлар жыелмасы итеп күрә, чөнки андагы һәрбер күренешне, предметны танып, белеп, тотып карап була.

«Мәгънә эзлим» шигырендә лирик герой яшәешнең асылын гына түгел, анда

чынга ашырылган үзенең дә асылын—яшәргә тудырылуының мәгънәсен табарга омтыла. Әсәр, гүя, борынгы грек фәлсәфәләренең «Үз-үзеңне танып бел» дигән карарын шигъри дәлилләгән кебек, «Үз-үземне эзлим үземнән» дигән төп идеягә беркетелә.

*Мәгънәсезгә узган еллармы бу?*
*Мәгънә эзлим һәрбер мизгелдән.*
*Мин үземне эзлим башын иеп*
*Тирән уйга талган һәр гөлдән...*

«Читләтелү» шигыре асылына илаһи нур салынган кеше образының дөньядан «сөрелергә» омтылышын ассызыклый. Яшәешнең бөтенлеген ачарга омтылган Инсан әсәрдә үз асылының бөтенлеген саклап калырга тырышучы буларак кабул ителә. Әмма гармонияле, камил дөнья урынына «читлек», «чонгыл», «киртә-читән» кебек каршылыкларга эләгеп, яшәештән читләшә, үзен маргиналь итеп тоя башлый.

*ЧИТәннән ЧИК-кирТә үреп,*
*ЧИТләшәм дөньясыннан.*
*Мин—дөньяга, дөнья—миңа*
*Әйтерсең сыймый сыман.*

Соңгы ике юлда лирик геройның дөнья белән каршылыгы куерганлыгы чагыла. Үзенең Җиһанга матурлык өләшү өчен түгел, сыналу өчен китерелгәнен аңлый ул.

Р.Аймәт укучыга әзер җавапларны такмый, ә лирик уй-кичерешләр процессын тасвирлауны өстен куя. Шуңа да аның лирик герое һәрвакыт 1 затта, «мин» исеменнән сөйли, чынбарлыкның күренешләре авторның «мин»ендә чагылыш таба. Әсәрләренең күпчелегендә кулланылган монологик фикерләү шагыйрьнең яшәешне актив рәвештә танып-белергә омтылуына ныклы дәлил.

Шагыйрьнең «Автопортрет» әсәре аның үзе турында мәгълүмат бирүдән битәр, Яшәешнең нинди формалар, образлар аша чагылышына тулы характеристика кебек кабул ителә. Шигырь тирән фәлсәфи эчтәлекле. Монда шагыйрь образлы чагыштырулар, милли мотивларны янача шәрехнамәләр белән тутыру аша ирешкән: «ялгыз нур», «сынга әверелгән» моң, учакның «күзгә күренмәгән ялкыны», «кайтып житалмаган кайтаваз», ниһаять, әсәрнең үзәгенә бастырып куярлык «давыл эчендәге тынлык» һәм «тынлык эчендәге зилзилә» гыйбарәләре!

*Җиһан тулып аккан ак Моңның мин*
*Сынга әверелгән халәте...*
*Давыл эчендәге бер Тынлык мин,*
*Тынлык эчендәге Зилзилә.*

Антиномияләргә корылган бу шигырьнең төп мәгънәсе бу хәяттә «мин»нең яшәп калырга мөмкинлеге тумау булып аңлаңыла, чөнки ул хәят яссылыгына житәргә аз гына калганда «өзелә дә кала»: йә сынык нур булып, йә тумый онытылган жыр, йә булмаса, «язылмыйча калган аять» рәвешендә. Нәтиҗәдә, янәшәдә генә дөнья барлыгын күреп, аңа житеп булмавын лирик герой таный: «Мин, гасырлар буе кайта-кайта, кайтып житалмаган кайтаваз».

Шагыйрь давыл һәм тынлык, тынлык һәм зилзилә кебек каршылыклы эчтәлекле төшенчәләрне бергә бәйли, нәтиҗәдә, алардан яңа мәгънә, яңа тәэсир туа. Галәм хаосы (давыл) эчендә бөтен барлыгы белән тотрыклылык үрнәге булган Тынлык, гүя, мәңгелек йортны—Илаһиятне ассоциацияләштерә, ә зилзилә исә шул Илаһияттә бәргәләнә торган һәм автор иҗатының үзәк лейтмотивын билгеләгән «тынгысыз җан»га ишарәли.

Үлем яки Яшәү төшенчәләре Р.Аймәттә ачыктан-ачык кулланылмый, ул аларны «урап-урап», төрле ишарәләр, чагыштырулар, метафоралар аша атый. «Мин китәсе көн» әсәре дә шундыйлардан. Моның кебек бәхилләшү эчтәлеге белән сугарылган әсәрләр татар фәлсәфи лирикасында аз түгел. Әмма шагыйрь куркынычлыктан битәр яшәүнең дәлиле булып калган хатирә идеясенә нигезләнә. Хатирәнең эчтәлеге исә үткән хәятны киләчәктә сагыну хисе белән тулылана. Шагыйрь иҗатының буеннан-буена кызыл җеп булып уралып барган Хәтер төшенчәсе киләчәктән бүгенгә карап аңа бәя бирү рәвешен ала.

*Мин китәрмен...*
*Мәтәм гөсләсендә*
*Үкси-үкси соңгы кыл елар.*
*Баш очымда үксез кукчәчәк тә*
*Кайтуымны көтеп сулкылдар...*

Шагыйрь әсәрләрендә гәүдәләнгән Инсан—Җиһанның бер өлеше, «күнел күгенә» Җир хәятын сеңдергән һәм Җир тормышында «күзгә күренә торган сынга әверелгән» илаһи форма, Илаһиятнең уйлый торган бер нуры. Ул, Адәм Җиргә иңдерелгәч тә, куркып һәм сокланып Җирне кабул иткән кебек, хәяттан алган кичерешләрен чагылдыра. Адәм Җирдәге күренешләрне беренче тапкыр исемнәре белән атаган шикелле, Р.Аймәтнең лирик каһарманы да аларны үзенчә, кабатланмас рәвештә атый.

Аның Илаһият чигендә торган лирик герое, Илаһияттәге башка затлардан аермалы буларак, Яшәешнең серен аңлый торган итеп бирелә. Дөрестән дә, Инсанга Тудыручы тарафыннан бирелгән рухи хөрлек, дөньялыкта үзе теләгән рәвештә хәрәкәт итәргә мөмкинлек бирелү, аның яшәештәге роле һәм вазифасының җаваплылыгын билгели. Шуның белән Адәм баласы илаһилыктан башка дөньяда яшәп карый алмаган фәрештә кебек затлардан аерыла. Шагыйрьдә «дөнья һәм мин» яссылыгы формалаша. Яфрак, чык, янгыр, томан кебек татар әдәбиятында еш кулланыла торган образлар анарда лирик герой белән турыдан-туры бәйләнешле, алар герой белән каршылыклы бәйләнештә торган «макрокосм»ны ачыкларга ярдәм итәләр. Бу җәһәттән аның әсәрләренең эстетик төшендә Х.Туфанның һәм рус шагыйре А.Тарковскийның фәлсәфи карашларына аваздашлык сизелә.

*Я человек, я посредине мира,*
*За мною мириады инфузорий,*
*Передо мною мириады звезд.*
*Я между ними лег во весь рост—*
*Два берега связующее море,*
*Два космоса соединивший мост.*
(А.Тарковский)

Шагыйрьнең тормыш һәм дөнья картинасы фламанд рәссамнары кебек гротесклы, образлы, куе буяулы. Мәсәлән, «Эзләмәгез мине...» әсәрендә дистәләрчә мең йөзләрдән тукылган тормышка лирик герой куе ярсу буяулар белән әрнү һәм үкенеч тулы хисләрен сызып уза.

*Беркайдан да эзләмәгез мине!*
*Сез эзләгән җирдә мин булмам.*
*Эзегезгә кар суы да түгел,*
*Зар суы да булып мин тулмам.*

Экзистенциаль хисчәнлек сыйфатына ия булган лирик геройның җаны чынбарлыктагы яшәешкә, кешеләргә үпкә саклый. Лирик герой бер үк вакытта үпкә катыш чәнчеп әйтелгән сүзенең яралый алуыннан тантана итә төсле. Ике

дөнья чигенә күтәрелгән, гүя, кешеләргә үпкә саклый торган яраланган фәрештәне хәтерләткән лирик герой вакытны алдан күрү сәләтенә ия кебек аңланыла: «Әле китәргә дә өлгермәдем,—/ Сагындыгызмыни шулчаклы?» Әлеге шигырьдә жир гамьнәреннән ваз кичәргә теләү темасы алга чыга. Бары шунда гына лирик герой тынычлык таба алачагына ышана.

Тормыш ваклыклары белән мәңгелек яшәеш хакында онытқан адәм балаларының кемнендер дөньяга тууында һәм соңгы юлга җыенуында гаме юк. Кешенең кадере килгән мәлдә түгел, соңгы сулышы өзелгәч кенә аңланыла.

*Сагындыгызмыни?.. Сагынырсыз!*
*Мин башка шул, башка оядан.*

Әлеге юллар исән чагында кадерләре беленмәгән Г.Тукай, Г.Исхакый, Һ.Такташ кебек талант ияләренең кайтавазы кебек яңгырый.

*...Эзләмәгез мине беркайчан да,*
*Кайтмаска (!) дип киттем Дөньядан!..*

Шигырьдә кулланылган каршылыклар бер-берсен көчәйтеп, лирик геройдагы фаҗигалелек хисен арттыра. Шигырьнең буеннан-буена сузылган сагыш хисеннән автор хәят мәгънәсен эзләү дигән катлаулы һәм борчулы темага күчә. Вакытны туктатып калып булмаслыгын аңлап, хәяттә үз урынын табарга омтыла.

*Айлар, еллар буе җавап көтеп,*
*Күзләремә баккан бар галәм.*
*Үз күчәрем тирәсендә үзем*
*Сәгать угы сыман әйләнәм...*
(«Икән!?»)

Р.Аймәт лирикасының төп мотивларыннан берсе—илаһилык дәрәҗәсендә карала торган рухи азатлык турында уйланулар. Исеменнән үк яшәеш белән метафорик каршылыкны күрсәтә торган «Мин әле тумаган» шигырендә илаһи иҗатның ни рәвешле тормышка ашырылуына шаһит булабыз.

*Мин әле тумаган, мин әле*
*Үрелеп бакмаган дөньяга.*
*Мин әле Мәңгелек иренендә*
*Бөрегә төйнәлгән бер Дога.*

Автор тарафыннан туасы җаннарның ике параллель дөнья арасында—Илаһият белән Хәят чигендәге чагы тотып алынган. Шагыйрь аны образлы итеп, «Айның арьягында» дип атый. Әлеге шигырьдә Илаһи яшәешнең һәр мизгеле кадерен белеп калырга омтылу белән бергә, Дөньяда яшәү эчтәлегенең тирәнлеген тою сизелә.

*Мин әле тумаган, ә инде,*
*Ә инде... арылган яшәп тә...*

Җир тормышын тасвирлау монда да метафизик планда бара. Гүя лирик герой, үзеннән алда ингән миллион җаннарның хәятын өйрәнеп, гомер һәм тормыш дигән күренешләрнең ни өчен бирелгәнен белә сикилә. Аныңча, Мәңгелек түгел, ә җир тормышы—танып белеп бетермәслек бер күренеш. Шуңа да ул акыл белән аны аңларга омтылганнарны куркыта. Шул рәвешле, яшәеш тоталь куркыныч кебек кабул ителә. Нәкъ шушы ноктада авторның яшәеш турындагы карашлары башка татар шагыйрьләренең карашларыннан аерыла.

Р.Аймәтнең шигырь корудагы осталыгы яшәешнең һәм чиксезлекнең рухи

бушлыгыннан арынырга ярдәм итә, гүя шагыйрь, җир белән күк арасында калып, бөек сәнгать хакында уйлана. Башкалар беркарусыз язмыш гозерен үтәгәндә, аның лирик герое шул рәвешле үзенә игътибарны беркетә, яшәештә һәм күкләрдә «үзе турында үзе сүз ала». Лирик минен югары сәнгать дәрәҗәсенә этәреп, әйтелгән һәр сүзнең, янгыраган һәр гыйбарәнең шагыйрь җанын, «күңел нурын» «түгү» өчен кирәклеген анлый. Шуңа да ул, шәхси кичерешләр яссылыгына күчеп, яшәештән бөтенлек эзли. Гармония, бөтенлек, камиллек эзләү аны бер Аллага, бер тормышка омтылышта күрсәтә.

*Кичер, Тәңрем!*
*Безнең инде күптән*
*Күкләр белән ара өзелгән.*
*Әллә шуңа безне бер Илаһым*
*Мәхрүм иткән күңел күзеннән.*
(«Сукыр»)

Җирдә яшәүнең тәмен татыган лирик герой сагыш аһәңе яктысында дөньялык белән бакыйлык чикләрен күңеле яссылыгында үлчи, ул хәзер Җиргә иңәргәме-юкмы дип түгел, ә аннан китәргәме-юкмы дигән сорау белән газаплана.

*Китәргәме?*
*Калыргамы бу дөньяда?*
*Китсәң, бар да кала.*
*Калсаң,*
*Китәр кебек...*
*каласылары да.*

Р.Аймәтнең лирик герое—Абсолюттан иңгән Хакыйкать буларак күзаллана. Вакыт булып та, чынга ашырылган хәят булып та чагылыш тапкан, кирәк икән адәм баласы сурәтенә керә алган Хакыйкать!

*Мин—Вакыт...*
*Мин—бер мизгел, үткән киләчәк тә.*
*Мин—кыямәт, олуг Нух көймәсе.*
*Мин—тәү аваз, хәтта, соңгы чик тә.*
(«Вакыт монологы»)

Бары тик Хакыйкатьнең Җир йөзеннән югалуы гына хәятның җимерелүенә китерүгә «Тәүбә котәм!» шигырендә ишарә ясала:

*Ай тотылган диеп уфтанмагыз,*
*Мин тотылдым бүген Ай булып.*
*Дөм караңгы. Гүя җирләр—күккә,*
*Күкләр җиргә төште убылып.*

Ай тотылу монда Хакыйкатьнең юкка чыгуы, иманның югалуы булып аңланыла. Тоталь фаҗигалелеккә китерә торган мондый күренешнең сәбәбе итеп, шагыйрь Хакыйкатьне ассоциацияләштергән Илаһидан йөз чөерүне саный.

*Күпме яктыртсам да дөньягызны,*
*Серле нурларымны аямый.*
*Белмәдегез кадерем!*
*Нурым харам!!*
*Җирдә—золым. Барыйм кая мин?*

Тәүбәгә килә белмәгән адәм балаларына соңгы кисәтү булып «Беркайчан

да эзләмәгез мине! / Сез эзләгән жирдә мин булмам»,—дигән соңгы аккорд яңгырый.

Р.Аймәт лирикасында хәр жан, сагыш мотивларына уралган герой белән янәшә атлаган Хакыйкать, аннан ваз кичү яки аны югалту мотивы XX гасыр башының кайнар хисле, хәр рухлы шагыйре Һади Такташның «Жир уллары трагедиясе» әсәренең сюжет сызыгын тоемларга булышлык итә. Гүя, Р.Аймәт Һ.Такташның әлеге әсәрендәге катлаулы вакыйгаларны, төп геройның кичерешләрен ижатының буеннан-буена сәйләндәй чәчкән. Р.Аймәттә очрый торган Жанның Жиргә инүе, Күккә кайтырга омтылу, дөньяның инсанны кабул итмәве, рухи бәргәләнү—болар барысы да Һ.Такташның әлеге әсәренә потенциаль реминисценцияләр һәм аллюзияләр булып кабул ителә.

Шулай да, экзистенциаль рухта ижат иткән башка татар шагыйрьләреннән аермалы буларак, Р.Аймәт шигырьләрендә бөреләнгән тормышны адәм баласының рухы сынала торган көрәш итеп тою хисе көчәергә өлгерми кала.

Бүгенге татар шагыйрьләренең күбесендә кабатлана торган уртак мотивларның берсе—ул Ялгызлык мотивы. Кеше дөньяга туган мәлдә һәм киткән чакта ялгыз, дип ялгызлыкны якты буяулар ярдәмендә тасвирлаган Зөлфәт белән рәттән Р.Аймәт тә ялгызлыкны күңелне, жанны чистарта, дөнья гамьнәреннән сафландыра торган бер халәт дип таный.

*Мин Сиңа сусадым...*
*Син—соңгы утравым.*
*Синнән дә*
*Туг(ы)ры, чын дустым соң юкмы?!*
(«Ялгызлык»)

Ялгыз калу—шәхеснең «мин»ен танырга, яшәештә эшләнгән эшләрне барларга, үз-үзенә хөкем чыгарырга һәм тәүбә итәргә булыша.

*Сиңа кайттым исә, мин—Ирекле.*
*Үзем—әсир, үзем —хөкемдар...*

Р.Аймәтнең яңа гасыр башында язылган шигырьләре ижатының икенче этабы булып күзаллана. Аларда шагыйрь Жир хәятының исәпсез-сансыз вакыйга-сурәтләренә игътибарын арттыра төшә. Монда инде ул Күкләрдән иңеп, дөньялыкта яшәргә дигән карарны таныган, аңа буйсынган зат буларак чыгыш ясый. Шулай да Мәңгелекнең серен йөрткән күңеленең иң түрендә ул Күкләр белән хушлашып бетермәгән, аңа кайту өметен сүндермәгән.

*Көтәр идем—*
*Көтәр кешем дә юк.*
*Барыр идем—*
*Каршы кем алыр?*
*Бу дөньяның сурәте дә беркөн*
*Күзләремдә эреп югалыр.*
(«Юк»)

Үз-үзе алдында үзен аклау кебек яңгыраган «Көтәм хәзер бары Үземне мин, / Кайтам хәзер бары Үземә», дигән юлларда Инсан туганчы ук рухына сеңдерелгән асылын саклап калырга тиеш дигән ислам дине тәгълиматларының берсе чагылыш тапкан. Шул җәһәттән Р.Аймәт ижатында Яшәеш сурәте белән янәшә мөстәкыйль атлый торган Инсан сурәте дигән төшенчә барлыкка килә. Монда яшәешне кеше образы аша ачуга караганда, күбрәк Инсанны каршылыклы яссылыклар яктылыгында тасвирларга омтылу көчле. Төп яссылыкларның берсе—ул Кешенең чиксезлек һәм мәңгелек кинлекләре белән тоташкан эчке үлчәме. Саф һәм эчкерсез Инсан гүя Жиргә төшеп бозыклык, ялган, мәкер маскасын кия.

*Сюжет —ялган.*
*Уен —фальш.*
*Минме*
*Режиссерның тере курчагы?..*
*Җитәр! Җитәр!!*
*Мин масканы салам*
*Һәм мәңгегә чыгам уеннан.*
(«Җитәр»)

Р.Аймәтнең Жиргә төшмәс өчен интуитив бер көч белән карышкан лирик каһарманы, ниһаять, тормышның «мәрхәмәтсез уен» икәнен таный. Инсан монда исән калыр өчен төрле битлек киеп яшәргә мәҗбүр ителгән мәхлук бер бәндәгә әверелә. Платоннар, Сократлар заманында ук ясалган бу ачыш, шагыйрь иҗатында тәкърарлау табып, Инсан дигән бөек исем белән яшәешкә күчкән җаннарның ваклануын, үз асылын җуюын дәлилли.

*Мин масканы салам...*
*Аһ, сагындым,*
*Кайтыйм инде, җитәр, үземә.*
*Минме соң бу?*
*Аптырашта калды,*
*Танымыйча тора күзгә дә.*

Космогоник мәгънәдә аңланыла торган Инсан образы Р.Аймәт иҗатының буеннан-буена аның илаһи асылын яктырту өчен кулланыла. Монда кешенең Жиргә җибәрелүенең төп вазифасын раслау максаты куелмый. Биредә Кеше аеруча бер киеренкелектә ачылган һәм тыгызланган образ буларак чыгыш ясый.

Йомгаклап әйткәндә, көйләп укыгандай укыла торган, тантаналы метафоралар белән сугарылган һәм «югары иҗадилык»ка нисбәт иткән бу поэзия тормышны раслаудан бигрәк, кешенең Илаһият белән Жир тормышы арасындагы халәтен ачуны өстен куя. Р.Аймәт шигърияте экзистенциаль һәм гыйсъянчылык хисчәнлеге белән сугарылган, ул—хис һәм фикер шигърияте. Кичерешләр анда уйланыла, уйлар нәтиҗәгә илтә. Шагыйрь тудырган фәлсәфи концепциядә ислам дине кануннары ачыктан-ачык чагылмаса да, милли архетип дәрәҗәсендә сакланып калган образлар һәм мотивлар ярдәмендә мифологемалар тудыру, аның татар-мөселман мәдәниятенә нигезләнүен дәлилли. Аллаһны тану—Р.Аймәтнең эчке инануы, ул шагыйрьнең сүз белән ясалган сурәтләреннән кинрәк.

# КАЗАН ТАТАРЛАРЫ ИЖАТЫНДА КИТАБИ ДАСТАН

Фарсы әдәбияты һәм фольклорының тирән йогынтысын кичергән төрки халыкларда, шул исәптән татарларда халык эпосын «дастан» дип атау да кулланылышка кергән. Әмма Идел буе татарларында «дастан» жанры бу төшенчәнең гомум кабул ителгән мәгънәсеннән кайбер яклары белән аерылып тора. Халыкның тормыш-яшәү рәвеше йогынтысында әкренләп формалашкан бу үзенчәлекләр чын мәгънәсендә милли характерда булуы белән кызыклы.

«Дастан»—борынгы фарсы сүзе, «хикәяләү» дигәнне анлата, героик бәян, тарих, поэма, легенда, музыка төшенчәләрен үз эченә ала. Төрки телләрдә «тарих», «хикәя», «үткән эшләр хикәясе» дигән мәгънәләрдә йөри[1]. Ул күп халыкларда жырау-чичән белән бергә күздә тотыла торган, ягъни текст һәм шул текстны көйләп-сөйләп башкаручы берлегеннән гыйбарәт синкретик жанр. Биредә шулай ук жырчы-бәянчы башкарган дастанның билгеле бер аудитория тарафыннан кабул ителүе дә әһәмияткә ия. Эпосны халыкка житкерүче жырау-чичән ижаты—язмасыз мәдәниятнең бер чагылышы, ә инде дастан әйтүче авызыннан кем тарафыннан да булса язып алынган эпик фольклорның безнең көннәргә килеп житкән тексты исә—шуның язуга теркәлеп калган гүзәл кайтавазы. Башкорт, казакъ, үзбәк, әзәрбайжан, кыргыз, төрекмән, кырым татарлары, якут, алтай, хакас, бурят һ.б. халыклар эпосы нигездә шундый. Боларда атаклы чичәннәр булып, алар тарафыннан эпос әйтү хәтта берничә айларга сузыла торган булган[2].

Көньяк халыкларының күпчелегендә, шулай ук Себердә яшәүчеләрдә бу традиция әле бүгенге көнгәчә яшәп килә, ягъни «дастан» жанры жырау-чичән белән күләмле фольклор тексты бөтенлеге традициясенә тугры кала. Эпосның телдән башкарыла торган мондый формасы күчмә тормыш шартларында озаграк яшәгән халыкларда ныграк сакланган.

Безнең халыкның иң зур этник төркемен тәшкил итә торган казан татарлары ижатында дастаннар күпчелек очракта үзләренең китаби булулары белән аерылып тора. Халык дастаны икән, беренчел чыганак, әлбәттә, һәрвакыт бар. Әмма хикмәт шунда: бездә дастанны халыкка житкерүче—телдән дастан әйтүче жырау-чичән түгел, ул күбрәк—текстны язып таратучы ролен башкаручы ижат кешесе һәм бу вазифаны, гадәттә, укымышлы кеше үти торган булган. Бу—татар китаби дастаннарының иң характерлы билгеләреннән берсе.

Урта Идел буе татарлары халык ижатына караган эпик әсәрләрдә чичән-шагыйрьнең текстны халык алдына чыгып башкару өлешенә игътибар шактый кимегән, эпосның фольклор әсәре булуын раслаучы барлык сыйфатлар текстның эченә сыеп беткән. Икенче төрле, Идел буе татарларында таралган дастаннарда төп игътибар жырчы-бәян итүченең әсәрне музыкаль башкаруына түгел, ә турыдан-туры текстның үзенә, шигъри сүзгә бирелгән.

1 Будагов Л. Сравнительный словарь турецко-татарских наречий. – СПб:тип. Императорский Акад. наук,1869. – С.547.
2 Курманбек. Жаныш,Байыш (эпос). – Фрунзе: Кыргызстан,1970. –Б. 5.

Әлбәттә, төрки һәм төрки булмаган халыкларга хас чичәнлек тә бөтенләй үк ят түгел мондый әсәрләргә. Бездә кайбер дастаннарның шигъри өлешен дутар, думбра белән көйләп әйтү традициясе дә булган[3]. Шулай да безнең халыкның дастан жанрында китабилыкка, язма иҗат белән шөгыльләнүгә омтылыш үзен сиздерә. Идел буе татарларына дастаннарның кыргыз, үзбәк, башкорт һ.б. халыклардагы кебек жырау-чичән тарафыннан башкарыла торган сөйләмә формадагысына караганда китаби характердагылары якынрак булган. Мәгълүм сюжетлы дастаннар, үзебезнең җирлектә китаби формага күчеп, янә бер төрле яшәү рәвеше кичергәннәр. Ә жыручы таланты ташып торган татар чичәннәренең (Сабирҗан акын, Байчыгави, Кәшшәфетдин Минзәләви, Хөсәен Нугай һ.б.) халык җырлары, афоризмнар, әкиятләргә гаять бай репертуарында дастаннар урын алмаган.

Китабилык ул—дастанның туу, таралу үзенчәлекләрен үз эченә алган, фольклор традицияләре һәм халыкның рухи ихтыяҗы белән тыгыз бәйләнгән күпкырлы күренеш. Татарлар элек-электән Һиндстан, Урта һәм Кече Азия, Иран, шулай ук Якын Көнчыгыш белән сәяси, дипломатик һәм мәдәни бәйләнешләр тотып яшәгәннәр. Әлеге халыклардан язма чыганаклар аша үтеп кереп, бездә язма формалы халык иҗаты булып таралган сюжетларның күплеге дә шушы мөнәсәбәтләргә турыдан-туры бәйле. Урта Идел татарлары—борынгы төрки бабаларынын язма иҗат традицияләрен алга таба үз мәдәнияте җирлегенә күчергән, шул традицияләрне үзенеке итеп кабул итә һәм үстерә алган, язма мәдәнияткә ихтирамы һәм ихтыяҗы зур халык. Халкыбызның дәүләт корып яши белүе, язмачылыкка бик иртә ия булуы, утрак тормыш рәвеше, шәһәр мәдәниятенең тиешле дәрәҗәдә формалашып өлгерүе һәм, әлбәттә, исламга бәйле рәвештә ныгыган китап культурасы йогынтысы китаби дастаннарның халык тормышында киң урын алуына китергән.

Язулы һәм дәүләтле халыклар эпосының язмышына мөнәсәбәттә Х.К.Короглы түбәндәгечә яза: «Язулы борынгы халыкларның (фарсы, һинд һ.б.) күбесендә эпос, язуга күчерелү белән үк, сөйләмә формада яшәүдән туктаган, чөнки дастан әйтүчене (сказитель) кыйссахан (чтец) алыштырган һәм ул авыл яки шәһәрнең озын кичләрендә шул ук эпосны үзе «канунлаштырган» формада халыкка укып бирә торган булган. Шәһәр һәм авыл культурасы югары утрак тормышлы иран, һинд, грек халыклары, тарихи үсешнең билгеле бер чорында, телдән башкарыла торган эпоска караганда язма эпосны кулайрак күреп, тулысынча язма эпоска күчкәннәр»[4].

Чыннан да, китабилык—гаять борынгы күренеш. Дөнья фольклорында китаби эпос формалашу урта гасырларга ук туры килә. Татар китаби дастаннары да, бүгенге рәвешендә безнең көннәргә килеп ирешкәнче, озын-озак тарихи юл үткәннәр. Халык иҗатын язмача бирү тәҗрибәсе әле китаби дастаннар формалашканга кадәрге чордан ук килә дип санарга нигез бар.

Рун язма истәлекләре булган Орхон-Енисей ядкәрләрендә үк инде төрки эпоска хас алым чагылыш тапкан[5]. VI—VIII гасырларга караган әлеге истәлекләрдә тасвир тарихи чынбарлыкка нигезләнә, аларда аерым бер образ эпик каһарман биеклегенә күтәрелә, идеаллаштырыла, вакыйгаларны сурәтләү эпос стилендә башкарыла. Төрки дастаннарның да нигезен нәкъ шулар—реаль вакыйга, тарихи шәхес гәүдәләнү һәм сурәтле эпик тел тәшкил итүне искә төшерик. Әйтик, Күлтәгин хан хөрмәтенә куелган Зур язмада идеаллаштырылган тарихи герой образы, геройның сугышчан атын тасвирлау («Алып Шалчының ак аты», «Азманның ак аты», «Очсызның ак аты», «Тадыка-чураның бүз аты» һ.б.) каһарманның эш-гамәлләрен, батырлыгын, җиңү тантанасын эпик стильгә хас арттырып-күпертеп күрсәтү, кабатлаулар, эпитет-чагыштырулар, батыр үлү сәбәпле сыктау—барысы да әлеге ядкәрнең фольклор әсәрләре белән аваздашлыгы турында сөйли. Орхон-Енисей ташларындагы эпос

[3] Урманче Ф. Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек. 3 томда. II том. – Казан, 2009. – Б.6.

[4] Короглы Х.Г. Огузский героический эпос. – М.: Наука,1976. – С. 114.

[5] Короглы Х.Г. Древнетюркская письменность // Средневековая татарская литература (VIII–XVIII вв. / – Казань: Фән,1999. – С. 11–40.

стильле язмалар сонрак татар китаби дастаны булып формалашкан жанрның шактый борынгы чаткысы, дисәк, хата булмас.

Татар китаби дастаннарының тамырын тагын да тирәнрәк катламнардан да эзләргә мөмкин. Алардагы мотив, сюжет, идеяләрнең борынгы Шәрык дастаннарында чагылуын күрәбез. Элек-электән язма мәдәниятле Урта Идел татарларында борынгы һәм урта гасыр Шәрык әдәбиятына һәм фольклорына хас күләмле шигъри поэма-дастаннарга ихтыяҗ гаҗәеп зур булган, шуңа да күп кенә язма эпос-дастаннар үзебезнең жирлеккә яраклаштырып кабул ителгәннәр. Ә борынгы Шәрык дастаннары—язма дастаннар, ягъни китаби эпос үрнәкләре.


Разсказъ о Нарекѣ и Чурѣ-батырѣ.
LE CONTE SUR LE NAREKK-BATYR ET LE TSHOURA-BATYR.
(По рукописи, принадлежащей издателю. *)

نارونك چوراننك حكايتى بودور
داعستان يورطنده قاضى بى ديكان بر اولوغ ميرزا بار ايرمش آننك بر
قان ميرزا ديكان بر اوسيه بار ايرمش كونلارده بر كون قاضى بى
عسكرى برلان آطلانب آو آولاماغه چقب بارا جوركان زماننده يولنده بر
قريه بار ايكان اول قريه غه قاضى بى كلسه بولار كلمسدين a) بوررون
جاو كلب شاوب آلوب كتكان بر يلش بالا قاشب قالينك اورمان اشنه
كرب قالغان ايكان اول قاضى بى كلكانده اول بالا بولارنى كوروب
اورماندان چقب قاضى بيكه كلدى اول قاضى بى بالادان صورادى
آولنكزغه نه بولدى ديب صورادى اول بالا ايتدى آولمزنى جاو شاوب
آلوب كتدى من قاشوب بو اورمانغه كروب باشنب قالديم ديدى

*) Для показанія діалектическихъ уклоненій удержано по возможности правописаніе подлинника. Другой списокъ этого разсказа имѣется въ Одесскомъ Обществѣ Исторіи и Древностей (Отчетъ этого общест. съ 1850 по 1851 годъ, стр. 6).
a) Въ подл. كلسدان

*«Чура батыр» дастаныннан фрагмент (татар версиясе). Чыганак: Березин И. Турецкая хрестоматия.–Т.П.–Казань: Тип. ун-та, 1862.—Б.41.*

Татар китаби дастаннары еш кына шумер-аккад, борынгы грек, борынгы һинд, борынгы Мисыр эпик истәлекләрендәге сюжет, мотивлар белән кисешә. Әйтик, китаби дастаннарда популяр теге һәм бу дөнья сюжеты (сандыкка салып суга агызу—теге дөнья белән очрашу мотивы буларак; кое образы—теге дөньяга үтеп керүнең бер юлы буларак; билгеле бер яшькә житкәч, сынау-инициация йоласын үтәү—янадан туу мотивы буларак) б.э.к. берничә меңъеллыклар элек яшәп киткән цивилизацияләрнең китаби эпосына ук барып тоташа.

Вакыйгаларны бәян итү ысулына, поэтик үзенчәлекләренә, эчтәлегенә һәм күбрәк кайсы темага багышланган булуына мөнәсәбәттә татар китаби дастаннарын ике төркемдә карарга мөмкин: романик китаби дастаннар һәм героик китаби дастаннар. Безнең халык мавыктыргыч сюжетлы әсәрләрне үз иткән. Мондый дастаннарның төп темасы—ике гашыйкның тетрәндергеч-эмоциональ мәхәббәт тарихы яки тарихи вакыйгаларга бәйләнешле каһарманлык бәяны. Китаби дастанның характерын билгели торган шушы ике зур тема төрки һәм Көнчыгыш эпосына хас күпләгән тема-мотивларны, типологик үзенчәлекләрне колачлый.

Романик китаби дастаннарыбыз билгеле бер тарихи чорда әдәбиятка якынаю кичерсәләр, героик китаби дастаннарның тарихи җыр, социаль эчтәлекле бәет яисә тарихи елъязмага әверелә бару күренешен дә искәртү мөһим. Романик китаби дастаннар рәтендә урта гасырлардан килгән романтик традицияләр өстенлек иткән халык дастаннары урын ала. Болар—лирик-фәлсәфи характердагы, төп каһарманның эчке кичерешләрен тәэсирле бәян итүгә, аның үзен җир йөзендәге иң камил зат буларак тасвирлауга корылган, геройның рухи тормышын тетрәндергеч итеп сурәтләргә омтылган, эмоциональлеккә үтә бай дастаннар. Мисал рәвешендә «Таһир белән Зөһрә», «Буз егет», «Ләйлә белән Мәҗнүн», «Йосыф китабы», «Шаһсәнәм һәм Гариб», «Хурлуга белән Һәмра», «Сәйфелмөлек», «Мактым-сылу» һ.б. әсәрләрне китерергә мөмкин.

Героик китаби дастаннарда батыр яисә пәһлеван образы үзәктә торып, төрки фольклорга хас батырлык сыйфатлары киң чагылыш таба. Мондый дастаннарның характерын реаль чынбарлыкка якынлык, тарихилык һәм каһарманлык дәрәҗәсе билгели. Кайбер дастаннарда каһарманлык идеясе дини-мистик карашлар белән сугарылган була. Халкыбызның «Түләк», «Гыйсә углы Амәт», «Чыңгыз хан», «Аксак Тимер», «Кыйссаи Сәкам», «Кисекбаш», «Каһарман Катил», «Нарык һәм Чураның хикәяте», «Күр углы Солтан» һ.б. дастаннары шушы төркемгә нисбәт ителә. 1919 елда Нигъмәт Хәким, 1940 елда Нәкый Исәнбәт төзегән җыйнама-тәнкыйди «Идегәй» дә, әлбәттә, героик китаби дастан хокукын дәгъвалый.

Халкыбызның китаби дастаннары—әдәбият, ягъни индивидуаль иҗат белән тирән керешкән язма эпик әсәрләр. Борынгы һәм Урта гасыр гомум төрки әдәбиятында мәгълүм сюжетка әсәрләр иҗат итү киң таралыш алган булган. Әйтик, Низаминың «Ләйлә белән Мәҗнүн», Мәҗлисинең «Сәйфелмөлек» кебек мәшһүр поэмалары билгеле сюжетка нигезләнгән, әмма фольклор башлангыч белән чагыштырганда индивидуаль иҗат күпкә өстенлек алган әдәби әсәрләр булып формалашканнар. Халыкның күпчелеге тарафыннан яратып кабул ителә торган мавыктыргыч дастаннарны энциклопедияләрдә фольклорга да, әдәбиятка да нисбәтле жанр дип аңлатуның[6] сәбәпләре нәкъ менә шуна—бер үк сюжетка халык вариантлары белән янәшә оригиналь әсәрләр дә иҗат ителгән булуга бәйле булса кирәк. Дастан ул—элитар жанр, тиешле югарылыкка күтәрелеп җитү өчен аңа күп вакыт талантлы шагыйрьнең әдәби осталыгы таләп ителгән, ягъни жанр оешуда индивидуаль башлангыч та шактый роль уйнаган. Әмма халыкның китаби дастаннарында авторлык мифик дәрәҗәдә генә калып, әсәрдә фольклор кануннары хакимлек итә, мондый дастаннар дөньяга уртак социаль-типик караш белән сугарылган булалар. Шуна күрә аларны оригиналь әсәр дип кабул итү дә, әдәби әсәр критерийларын кулланып тикшерү дә объектив була алмый. Ә фольклор сюжетының кайчандыр әдәбиләшкән формасы тәэсирендә янадан халык иҗатына кайткан, халык иҗатыннан янадан әдәби әсәр язуга илһам биргән сюжетлар бездә бар һәм мондый процесс татар фольклорында һәм әдәбиятында XX йөз башынача күзәтелә.

Казан татарларында «Түләк», »Кыйссаи Сәкам», «Гыйсә углы Амәт», «Каһарман Катил» кебек дастаннар фәкать кульязмалар яки басма китап булып кына көн күрсәләр (боларның телдән таралган вариантлары Идел буе татарлары иҗатында гомумән юк), «Таһир-Зөһрә» сюжетлы татар китаби дастанының безгә өч төрле яшәеш формасы мәгълүм: алар бүгенге көнгә кульязмада һәм сөйләм телендә, шулай ук җыйнама вариантлары аерым китап рәвешендә килеп ирешкән. Яисә «Сәйфелмөлек»—безнең халыкта кульязма булып та, китап рәвешендә дә, шулай ук сөйләмә формада һәм хәтта эпик җыр рәвешендә дә күпләп таралган, яратып укылган әсәр. Шулай ук «Бүз егет» бездә, күпчелек китаби дастаннарга хас булганча, төрле формада көн күргән. Татар халкы аны кульязмадан да, басма китаптан да укыган. Язма «Бүз егет» тәэсиреннән кабат халыклашканмы, йә булмаса элгәреләребез телендә актив яшәгән булганмы, халык арасында аның кыска сөйләмә вариантлары да очрый. Ә «Кыйссаи Йосыф»ның исә халыкта күбрәк китаптан уку, китап эчтәлеген сөйләп чыгу, билгеле сюжетка ияреп, яңа вариантта сөйләү кебек формалары киң таралган булган.

Шулай итеп, бездә бер үк төрле сюжетка корылган әсәрнең кульязмада, басма китапта сакланганнары белән бергә бүгенге көнгә халык сөйләмендә килеп җиткән вариантлары да очрап куя. Бу күбрәк үзенең тамыры белән китаби чыгышлы сюжетка барып тоташа торган дастаннарга карый. Әмма Идел буе татарларындагы сөйләмә характерлы дастаннарны җырау-чичән иҗаты булган «тере» эпос белән чагыштыру үзен акламый. Беренчедән, кагыйдә буларак, мондый вариантларның һәрвакыт язма параллельләре дә була һәм соңгылары үзләренең күләмлерәк һәм камилрәк булуы белән аерылып тора. Икенчедән, сөйләмә характерда булсалар да, безнең халыктагы мондый төр вариантлар чын чичән әйткән күләмле эпик текст булудан шактый ерак. Алар күп очракта мәгълүм язма дастанның эчтәлеген сөйләп чыгуга, бер өлешен көйләп әйтүгә яисә көйләп укуга кайтып кала. Өченчедән, сөйләмә вариантта очрый торган мондый әсәрләр Казан татарларына нисбәтле кайбер дастаннарга бәйле генә таралган (әйтик, «Йосыф кыйссасы», «Таһир белән Зөһрә» яисә «Бүз егет»тән эпик җыр) һәм таралыш географиясе ягыннан да, популярлыгы җәһәтеннән дә шактый чикләнгән.

Бездә дастан вариантын көйләп уку җырау-чичәннең үз әсәрен музыкаль башкаруыннан тамырдан аерыла. Дастаннарны көйләп әйтү Идел буе татарларында

[6] Краткая литературная энциклопедия. – М.:Советская энциклопедия,1964. – С. 530.; Новый энциклопедический словарь. – М.: Большая Российская энциклопедия,2001. - С. 314; һ.б.

язмасыз культура чагылышы булудан бигрәк ислам культурасы белән кергән күренешкә күбрәк охшаган. Коръәнне көйләп әйтү һәм китапка изгеләштереп карау традициясе бездә язуга теркәлгән күләмле эпик әсәрне дә көйләп укуга яисә яттан көйләүгә сәбәп булган.

Шулай итеп, гасырлар буе халык күнеленә тәэсир итеп килгән татар китаби дастанының өч тибын аерып күрсәтергә мөмкин: беренчесе—халыкта башлангыч формасы белән үк нигездә язма булып, безгә күбесенчә язма нөсхәләрдә килеп житкән, күчерелеп һәм укылып йөргән дастаннар. Мәсәлән, «Түләк», «Бүз егет», «Кыйссаи авык», «Кыйссаи Сәкам», «Гыйсә углы Амәт», «Шаһсәнәм һәм Гариб», «Хурлуга белән Һәмра», «Каһарман Катил», «Кисекбаш кыйссасы», «Чура батыр хикәяте», «Күр углы Солтан» кульязмалары яисә басмалары шундый дастаннар рәтенә керә.

Икенчесе—популярлыгы белән аерылып торган, язмада да, сөйләмдә дә бик актив таралган китаби дастаннар: «Таһир белән Зөһрә», «Йосыф китабы», «Сәйфелмөлек», «Ләйлә белән Мәҗнүн». Гадәттә мондый дастаннарның индивидуаль ижатка әверелгән версияләре дә мәгълүм була. Әйтик, һәркемгә мәгълүм Кол Гали поэмасы, Мәҗлеси, Низами ижат иткән әсәрләр. Шул ук сюжетка халык вариантлары да бихисап булып, алар һәм язмача, һәм телдән төрле вариантта таралсалар да, татар әдәбиятында мондый тип дастаннарга игътибар әдәби әсәр буларак бирелә килде. Популяр сюжетлы мондый ядкәрләр—бик борынгы риваятьләрдән зур поэмалар булып оешып, гасырлар дәвамында әдәбияттан янә халык ижатына һәм киресенчә күчеп яшәгән әсәрләр.

Өченче тип китаби дастаннар—иң элек авыз-тел ижатының эпик үрнәге булып, аннары билгеле бер автор тарафыннан аңлы рәвештә китабигә әвереллдерелгән, махсус барлыкка китерелгән китаби дастаннар. Татар халкында моның ачык мисалын без «Идегәй»нең жыйнама-тәнкыйди текстында күрәбез. Әмма китаби «Идегәй» башлангыч формасы белән телдән башкарылуга нигезләнгән дастан кыйпылчыкларыннан үсеп чыгуы белән үзенчәлекле. Жыйнама версияләреннән тыш, «Идегәй»нең себер татарларыннан язып алынган, жырау-чәчәннәр башкаруында теркәлгән вариантларының берничә дистәдә мәгълүм булуы әлеге дастанның татарларда әүвәл сөйләмә формада яшәгәнлеген раслый. Себер жирлеге, себер татарлары биргән дастаннар китаби дастаннардан бөтенләй аерылып тора. Бу аерма аларның башкарылу рәвешендә, поэтикасында, тулысынча синкретик ижат булуында һ.б.да чагыла.

Татар халкында китаби дастан күчермәләренең әллә ничә вариантта табылган булуы һәм әле дә табылып торуы—мәгълүм факт. Китаби дастаннар татар халкы тормышында бик зур урын алып торганнар, бу—фольклорның кин колач алып үскән тулы канлы жанры. Телдән башкарылган һәм теркәлми калган дастаннар белән чагыштырганда китаби дастаннарыбызның язмышы куанычлырак та, чөнки алар, бихисап кульязмалар булып, әле һаман яшиләр.

Шулай итеп, Урта Идел буенда яшәүче татарлар өчен китаби дастан чор таләбе, халыкның рухи ихтыяжы булган. Татар халкының дастани мирасын бөтен тулылыгы белән барлаганда бу атаманы урап узу, аңа игътибар итми калу мөмкин түгел. Китаби дастаннар—фольклорга хас төп үзенчәлекләрдән вариантлылыкны—тулысынча, синкретик һәм күмәк ижат булуны өлешчә саклап, телдән ижат итәлү һәм халык алдында башкарылу кадәресеннән (ягъни авыз ижаты булудан) тайпыла төшкән үзенчәлекле ижат, халкыбызның затлы эпик мирасы. Аларның һәркайсы киләчәктә махсус өйрәнү таләп итә.

**Лилия МӨХӘММӘТҖАНОВА,**
*филология фәннәре кандидаты*

# МУЗЫКАЛЬ ДРАМА ЖАНРЫНА НИГЕЗ САЛУЧЫ

## МИРХӘЙДӘР ФӘЙЗИНЕҢ ТУУЫНА 120 ЕЛ

Татар драматургиясе һәм театрының үсеш-үзгәреш тарихында җуелмас эз калдырып, иҗатлары белән халыкның рухи дөньясын баеткан, көч-ышаныч биргән, матурлыкка мәхәббәт, начарлыкка нәфрәт тәрбияләгән, тормыштан гамь һәм тәм табып яшәргә чакырган әдипләр арасында Мирхәйдәр Фәйзи исеме аерым бер урын алып тора. Аның бай иҗаты, бигрәк тә атаклы «Галиябану» музыкаль драмасы, дистә еллар дәвамында укылып, сәхнәләрдә куелып-каралып, гуманистик табигате, милли эчтәлек-сурәтләре, халыкчан җыр-моңы белән берничә буын укучы-тамашачының күнелен биләде, күпләрне әдәбият-сәнгать дигән олы, серле дөньяга алып керде. Тормыш-яшәештәге иҗтимагый, социаль-мәдәни шартлар йогынтысында рухи кыйммәтләргә караш-мөнәсәбәтләр үзгәрүе мәгълүм. М.Фәйзи иҗатының әдәби-эстетик кыйммәте нәрсәдә? Әлеге бай мирас, чор сынауларын үтеп, бүген дә заманча яңгырыймы? Әдипнең туууына 120 ел тулуны билгеләп үткәндә әлеге сораулар аеруча актуаль яңгырый. Бу урында шуны да билгеләп үтү мәслихәт булыр: М.Фәйзи иҗаты үзе исән вакытта ук зур кызыксыну уятып, XX гасыр дәвамында әдәбият-сәнгать белгечләренең, укучы-тамашачыларның игътибарын даими җәлеп итеп килә. М.Фәйзуллин, М.Мөлеков, А.Әхмәдуллин, Н.Ханзафаров, Б.Камалов, Л.Хәмидуллин, Ф.Фәтхи, Д.Фәйзуллин, Д.Абдуллина, Р.Шәрәфиев һ.б. хезмәтләре олы иҗатчының сәнгати уйлануларын, бу өлкәдәге табыш-яңалыкларын чор-заман рухына нисбәтле ачуның матур үрнәге булып тора.

Мирхәйдәр Мостафа улы Фәйзи (Фәйзуллин) 1891 елның 1 ноябрендә элекке Оренбург губернасы Орск өязенең Күкшел авылында туып-үсә. Әтисе Мостафа бертуган Хөсәеновларның Күкшел авылындагы җәйге утарында баш идарәче булып эшли. 1902-1904 елларда Мирхәйдәр Орск шәһәрендәге Габдулла хәзрәт Мәгазый мәдрәсәсендә, аннан соң ике ел Оренбургтагы «Хөсәения» мәдрәсәсендә белем ала. Шул елларда матур әдәбиятка тартыла. XIX гасыр мәгърифәтчелек әдәбияты, төрек һәм фарсы сүз сәнгате үрнәкләре белән таныша, рус драматургиясе һәм театры белән кызыксына. Вакытлы матбугат битләрендә иҗтимагый-милли тормыш, милли мәгарифнең актуаль мәсьәләләрен яктырткан язмалар белән чыгыш ясый башлый. 1914-1916 елларда Орск шәһәрендә мануфактура кибетендә кассир, соңыннан китапханәче булып эшли. Халык тормышы, аның яшәү рәвеше, гореф-гадәтләре белән таныша, яшьләр белән аралаша, халык авыз иҗатын өйрәнә, халык җырларын туплый һәм бастырып чыгара. 1919-1921 елларда Башкортстанның Бөрҗән-Тангаур кантоны Юлык авылында культура-агарту эшләрен алып бара, кантон үзәге Тимәстә үзешчән театрга җитәкчелек итә. «Кызыл Урал» газетасының хезмәткәре булып эшли, әдәби түгәрәкләр оештыра. 1923 елның җәен Татарстанның Балтач районы Шода авылында үткәрә. Аннары Казандагы Г.Тукай урамында урнашкан элеккеге Үзәк Шәрык китапханәсенә эшкә керә. Сәламәтлеге начараю сәбәпле, Башкортстанга китеп, Түбә руднигында һәм Баймак приискасында китапханә мөдире вазифасын

башкара, әдәби-мәдәни чаралар оештыруда актив катнаша. Әдип 1928 елның 9 июлендә Баймак шәһәрендә вафат була.

М.Фәйзинең башлангыч чор иҗаты татар әдәбиятында чынбарлыкны һәм кеше психологиясен сәнгатьчә тасвирлауда яңа сыйфатлар барлыкка килгән 1910 елларга туры килә. Ул башта «Татар туе» (1905), «Ике Хәсән» (1909) кебек бер пәрдәлек өйрәнчек пьесалар язып караса да, шигырьләр һәм бәетләр язуга күчә. «Шура», «Ан», «Вакыт», «Идел», «Акмулла» h.б. газета-журнал битләрендәге шигырьләрен туплап, «Минем шигырьләрем» (1912), «Яшь күңел» (1913) җыентыкларын нәшер итә. М.Фәйзи үз шигъриятендә, беръяктан, Г.Тукай, С.Рәмиев, М.Гафурилар буыны тудырган тормышчан һәм халыкчан традицияләргә тугры булып калса, икенче яктан, анда XX гасыр шагыйрьләренең икенче буыны Ш.Бабич, С.Сүнчәләй, З.Бурнашева, Г.Харис, З.Сагыйдә һ.б.лар иҗатының идея-эстетик үзенчәлекләре дә чагыла. Аның лирикасы тема-мотивлар байлыгы һәм жанрлар төрлелеге белән характерлана. «Табигать манзарасы» (1912), «Хәйран булам» (1912), «Чәчәкләр җыры» (1912), «Халыкча» (1912), «Җәйге төн» (1915) һ.б. шигырьләрендә табигать, мәхәббәт, хатын-кыз, музыка культы кебек романтик мотивлар, «Фәрештә» (1912), «Мөнбәр вә мендәр» (1912) дә иҗтимагый-социаль контрастлар гәүдәләнә. «Габдулла әфәнде Тукаев намена» (1912) әсәрендә халык шагыйре Г.Тукайның татар халкының рухи-мәдәни тормышында тоткан урыны һәм шәхесе традицион-шәркый һәм шартлы-романтик образлар аша тасвирлана. Шагыйрь поэзиясенең үзәген тәшкил иткән авыл темасы «Илем» (1915), «Юлык» (1919), «Юлык моңнары» (1919) һ.б. шигырьләрендә чагыштыру, сынландыру алымнары, гади халыкның көнкүрешеннән һәм авыл яшьләренең тормышыннан алынган детальләр ярдәмендә лирик геройның туган төбәгенә мәхәббәте, күңел байлыгы, хис-кичерешләре чагыла. М.Фәйзинең бер төркем шигырьләрендә яшәү һәм үлем, тәкъдир, язмыш, гомернең фанилыгы кебек фәлсәфи мотивлар гәүдәләнә. Мондый эчтәлектәге әсәрләрдә лирик геройның сызланулы күңел дөньясы, зарланулы халәте Ислам мәдәнияте, Коръән тәгълиматы традицияләрендә һәм XIX-XX гасыр чикләрендә Аурупа-рус әдәбиятларында формалашкан импрессионизм, экзистенциализм агымнарының алымнары, тасвирый чаралары ярдәмендә тасвирланыш ала («Үз иркемә куй» (1912), ; «Үткән вакыт», 1910; «Рәхәт кайда», 1912; «Бәхет», 1912; «Соңгы теләк», 1912 һ.б.)



М.Фәйзи иҗатының икенче бер зур тармагы драматургия тәрәнә карый. Язучының романтик шигъриятендә гәүдәләнгән тема-мотивлар һәм художество үзенчәлекләре аның драматургиясендә иҗади үстерелә һәм баетыла. Әдипнең мәзәк, комик хәл-ситуацияләргә корылган «Яшьләр алдатмыйлар» (1912) комедиясендә искелек, наданлык һәм азгынлык кире кагылып, укымышлылык, әхлаклылык, зирәк акыллылык яклана. Мөгаллим Шакир, Мәгъруфәләр Гали мулланы көлке хәлендә калдырып, искелек һәм яңалык тартышында җиңеп чыгалар. М.Фәйзинең бу еллар иҗаты чор әдәбияты, аеруча драматургиядәге сәнгати эзләнүләр белән тыгыз бәйләнештә үсә. Кеше яшәешен һәм аның күңел дөньясын тасвирлауда сентиментализм методының аерым сыйфатларын нигез иткән «Кызганыч» (1913) мелодрамасы романтик эчтәлеге белән җәлеп итә. Белемле, хисси җанлы Заһиднең мөгаллимә Гәүһәргә өйләнү теләге атасы Сөләйман байда зур каршылык тудыра. Традицион «аталар» һәм «балалар» көрәше милләткә хезмәт итү юлындагы яшьләрнең үлеме белән тәмамланса да, ул үлем яшьләрнең рухи җиңүе, гомумкешелек кыйммәтләренең яклануы булып аңлашыла. Мәхәббәт кешенең акыл үлчәүләренә, акча, матди байлыкка, берниндн киртәләргә буйсынмый торган серле көч, рух эше буларак тәкъдим ителә. Шул чорда әлеге пьесага проблематикасы белән якын булган, сызлану фәлсәфәсенә нигезләнгән «Тәкъдирнең шаяруы» (1913) языла. Әсәрдә гаилә, ир-хатын мөнәсәбәтләре, ана һәм бала хакы, мәхәббәт мәсьәләләре

төп каһарманнарның тирән кичерешләре, күңел бәргәләнүләре аша сурәтләнә.

М.Фәйзинең 1913-1916 еллар драматургиясе идея эчтәлеге, сәнгати эшләнеше ягыннан яңа сыйфатлар белән байый. Әдип «Авыл бәйрәме» (1915) музыкаль комедиясендә гади халык тормышын, авыл яшьләрен, аларның теләк-омтылышларын сурәтләүгә алына. Авторның эстетик идеалын гәүдәләндергән укымышлы, әхлаклы һәм тәрбияле шәһәр егете Заһит тирәсендә тупланган авыл яшьләре белән искелек сагында торучы дин әһелләре, олы буын арасында каршылык оеша. Романтик эстетика атрибутларыннан кешенең табигыйлегенә, авыл кешеләренең әхлакый сафлыгына, үзара мөнәсәбәтләрнең матурлыгына дан җырлана. Комедиядә татар халкының этнографиясе, гореф-гадәтләре, йолалары, гади сөйләм байлыгы, җырлы-биюле уеннары чагыла. Драматург вакыйгаларны халык көйләре, шаян җырлар белән бәйләнештә сурәтләү тәҗрибәсен ясый, бу сыйфат, үз нәүбәтендә, пьесаның жанр табигатенә тәэсир итә. Әсәрнең идея эчтәлеге белән тыгыз бәйләнгән шартлы-романтик образлар, аның мәгънәви кисәкләрен бер үзәккә туплаган «бәйрәм» әдәби детале дә художество яңарышын билгели. «Авыл бәйрәме» музыкаль комедиясе драматургның сәнгатьчә алымнарын төрләндерә һәм камилләштерә баруы турында сөйли. Бу әсәрдә башлангыч, яралгы хәлендәге сыйфатлар «Галиябану» («Сәгадәтбану», 1916) музыкаль классик драмасында тагын да үстерелә. Пьесаның сюжеты традицион мәхәббәт өчпочмагы мотивына корылса да, ул әдип иҗатында сәнгатьчә эшләнеше ягыннан иң камил әсәр булып тора. Тышкы кыяфәтләре һәм характер сыйфатлары арттырылып бирелгән Хәлил белән Галиябануның сөю-сөелү хисләренә авылның бай егете миһербансыз, мәкерле һәм гайрәтле Исмәгыйль каршы төшә. Үзәк конфликт Бәдринең мал-мөлкәткә, зур акчага омтылышы тудырган иҗтимагый характердагы ярдәмче каршылык белән тирәнәйтелә. Тигезсез көрәш Хәлилнең үлеме белән тәмамлана. Драматург яшьләр арасындагы, гаилә эчендәге киеренке мөнәсәбәтләрне, драматик һәм фаҗигале вакыйгаларны җыр-музыка белән тыгыз үреп сурәтли. Реализм һәм романтизм синтезы рәвешендә язылган «Галиябану» драмасында музыка очраклы бизәк төсендә генә түгел, ә пьеса эчтәлегенең тукымасын хасил итә. Әсәрнең шушы үзенчәлеген истә тотып, Г.Ибраһимов болай дип яза: «Менә шундый хасиятләре белән «Галиябану» бездә ялгыз урында тора, яңа бер баб, яки зуррак тәгъбир булса да, әйтик, драмалар галәмендә яңа мәктәп ача һәм, шулар аркасында бик хаклы буларак, гаммә алдында иң кадерле урыннарның берсен ала». Галиябану үз мәхәббәте, шәхси бәхете хакына аңсыз рәвештә милли чынбарлыкта хөкем сөргән патриархаль тәртипләргә каршы чыга. Драматург мәхәббәт, сөю-сөелү хисләренә дан җырлау аша, кеше бәхете мәсьәләсен җитди проблема итеп күтәрә. Пьесада барлык кешеләр омтылган бу кыйммәт, мәхәббәт, үзара матур мөнәсәбәтләр яклауга һәм саклауга мохтаҗ дигән фикер үткәрелә.

1917 елгы Октябрь революциясеннән соң М.Фәйзинең икенче чор иҗаты башлана. Илдәге иҗтимагый-сәяси вәзгыять, гражданнар сугышы, социалистик төзелеш, авылда күмәк хуҗалык төзү вакыйгалары әдипнең дөньяга карашына һәм сәнгатьчә фикерләвенә йогынты ясый. Бу елларда ул бик актив, нәтиҗәле эшләп, төрле жанрда дистәгә якын драма әсәре иҗат итә, шигырьләр, хикәяләр яза һәм көндәлек алып бара. М.Фәйзинең 1920 еллар драматургиясендә ике тематик юнәлеш аерымлана. Беренче тармакка караган «Урал суы буенда» (1917), «Асылъяр» (1918-1920), «Ак калфак» (1922-1923) драмаларында авылда яңа тормышның беренче яралгылары һәм шул чор кешеләренең күңел дөньясындагы үзгәрешләрне тасвирлау сызыгы белән төрле сыйныф, социаль катлау яшьләре арасындагы сөю хисләре, мәхәббәт темасы янәшә сурәтләнә. Драматургның катлаулы, тарихи һәм социаль катаклизмнар чорында беренче тәҗрибәсе булган «Урал суы буенда» (1917) драмасында социаль гаделлеккә, шәхси азатлыкка, кеше бәхетенә каршы торган киртәләрне җимерергә сәләтле, романтик рухлы актив геройлар тудырыла. Әсәрдә фән-техника казанышлары нигезендә авыл тормышын яңарту, мәдәниләштерү идеясе үткәрелә. «Асылъяр» драмасы иҗтимагый-социаль хәлләре төрле булган бай кызы Ләлә белән ятим Шәрәфнең мәхәббәт тарихын сурәтли. Әсәрдә шәркый әдәби традицияләр белән заман әдәбияты үсешендә күзәтелгән яңа тенденцияләр тыгыз үрелгән. Драманың

төп каһарманнары романтик эстетика кануннарына буйсындырылып, холык-сыйфатлары идеаллаштырылып тасвирланган. Хезмәтчеләргә, түбән катлау вәкилләренә кимсетеп караган Искәндәр байның каршылыгына карамастан, көрәштә яшьләр җиңеп чыга, аларның мәхәббәт хисләре тантана итә. Пьесаның исеменә чыгарылып, символик яңгырашка ия булган «Асылъяр» җыры әсәрнең композицион бөтенлегенә, төзеклегенә ирешүдә, вакыйгалар үстерелешен тәэмин итүдә, геройларның психологик кичерешләрен тирәнәйтүдә зур эстетик вазифа башкара. Алдагы әсәр белән жанр, сюжет, конфликт һәм коллизияләр, детальләр охшашлыгы күзәтелсә дә, морзалар тормышыннан алынган хәл-вакыйгаларны гәүдәләндерүе белән «Ак калфак» мелодрамасы аерылып тора. Теманы сыйнфый-социаль принцип ноктасыннан яктырту омтылышы, авторны морзалар яшәешен, характерларын бозып күрсәтүгә китергән. Сатирик планда иҗат ителгән Сәлим морзаның дуамаллыгы, гади халык вәкилләренә рәхимсез мөнәсәбәте максатлы рәвештә арттырылып күрсәтелгән. Шушы алым аша автор социаль каршылыкларны тирәнәйтүгә ирешкән. Ләкин шулай да мәхәббәт темасын сурәтләгән сызык үзенең камиллеге, җыр-музыкага байлыгы, романтик рухы белән укучының һәм тамашачының күңелен били.



*Башкортстанның Баймак районы Юлык авылында М. Фәйзи эшләгән китапханә бинасы.*

М.Фәйзи икенче юнәлеш әсәрләрендә («Кызыл йолдыз», 1923; «Адашкан күңел», 1923; «Кәкре каен», 1923; «Коммунага», 1924 һ.б.) иҗтимагый-социаль, сыйнфый көрәш мәсьәләләрен калку гәүдәләндерсә дә, дөньяга гуманистик карашын, кешегә олы ихтирамын саклый. Исеменә көчле мәгънәви йөк салынып, заман рухын чагылдырган «Кызыл йолдыз» (1923) пьесасы авылда беренче комсомол оешмасы төзү вакыйгасын сурәтли. Драманың төп конфликты китапханәче Хәй янына тупланган авыл яшьләре белән совет органнарына кереп оялаган кулак һәм аларның иярченнәре арасында туа. Каршылык, характерлар бәрелеше яңа иҗтимагый күренешләргә мөнәсәбәтнең, идеологик-сәяси карашларның төрлелегенә нигезләнгән. Социалистик үзгәрешләрнең беренче үрентеләрен, яңа идеология һәм әдәби-мәдәни чараларның авыл кешесенең психологиясенә тәэсирен күрсәтүдә драматург уңышларга ирешсә дә, сыйнфый көрәш вакыйгаларын тасвирлаган сюжет сызыгы тирән ачылган типлар белән аерылып тормый, аларның ышандыру көче түбән. М.Фәйзи «Кызыл йолдыз»да да авыл тормышын, этнографиясен, йолагадәтләрен чагылдыруга зур урын бирә.

«Адашкан күңел» мелодрамасында сурәтләнгән мәхәббәт сызыгы һәм вакыйгалар үстерелеше үзенең тормышчанлыгы белән аерылып тора. Шәһәрдән авылга мөгаллимә булып килгән Мавия әчке шөбһәләнү, күңел бәргәләнүләреннән соң крестьян егете Саматны ташлап, шәһәргә китеп бара һәм шул адымы белән зур тормыш сынавына дучар ителә. Автор вакыйгалар барышын реаль детальләрдә тасвирлап, буржуаз җәмгыятьнең кешелексез, кыргый тәртипләрен тәнкыйтьләүгә, Мавиянең характер көчен, рухи-әхлакый ныклыгын күрсәтүгә ирешә. «Адашкан күңел» пьесасындагы аерым күренешләр, мәсәлән, тормыш төбендәге зимагурлар яшәеше рус әдәбияты йогынтысында язылган. Автор тормышта, күңел дөньясында адашкан каһарманнарның ачы, михнәтле язмышларын тасвирлап, аерым эш-

гамәлләрне аек акыл белән үлчәргә, үз мәхәббәтенне сакларга кирәк дигән фикер үткәрә.

М.Фәйзи иҗатын XX йөз башы һәм 1920 еллар әдәби хәрәкәте үзенчәлекләреннән аерып карап булмый. Драматург үзенең остазлары булган Г.Исхакый, Г.Камал, С.Рәмиев, Ф.Әмирхан, И.Богданов һ.б. тәҗрибәсенә таянып әдәби иҗатка килә һәм сәхнә әдәбиятын яңа тема-мотивлар, үзенчәлекле геройлар, күптөсмерле, бай сурәт чаралары белән баета. М.Фәйзи сәхнә әдәбиятында беренчеләрдән булып авыл тормышын, көнкүрешен, кешеләрен тасвирлауга алына һәм үзе яхшы белгән әлеге материалны халыкның этнографиясе, фольклоры, уеннары һ.б. белән гаҗәеп уңышлы кушып-үреп баруга ирешә. Ә инде әсәрләре тукымасына көй-моңны кертеп җибәрүе белән яңа жанрга нигез сала. Әлеге «шытым» гаять уңышлы үсентеләр бирә. М.Фәйзи әсәре беренче тапкыр сәхнәгә куелуга ук халыкның кайнар мәхәббәтен яулаган музыкаль драма алдагы чорларда К.Тинчурин, Н.Исәнбәт, М.Әмир, Х.Вахит, И.Юзеев, Ә.Баян һ.б. иҗатында яңа сыйфатлар, төсмерләр белән байый. Бүген без татар сәхнә әдәбиятын музыкаль жанрдан башка күз алдына да китерә алмыйбыз. Тамашачы тарафыннан яратып кабул ителә торган «мелодрама» жанры да М.Фәйзи башлап җибәргән традицияләрнең уңай йогынтысында үсеп-үзгәреп тора. «Галиябану» драмасының сәнгати камиллеге, халыкчан рухы, автор яклаган идеалларның эстетик көче бүген дә сокландыра, илһам-көч бирә. М.Фәйзинең милли рухы белән аерылып торган геройлары, беренче чиратта, Галиябану белән Хәлил, күптән инде саф мәхәббәт символына әверелеп, дөнья әдәбиятындагы Ләйлә һәм Мәҗнүн, Таһир һәм Зөһрә, Фәрһад һәм Ширин, Ромео һәм Джульетта кебек мәхәббәт каһарманнары рәтендә тора.

Чор-заман үзгәрешләренә бәйле, М.Фәйзи иҗатын, аерым алганда, «Галиябану»ын бәяләүдә каршылыклы, бәхәсле карашлар да очрый. Шуның бер чагылышы буларак 1994 елны «Галиябану»ның режиссер Ә.Зарипов тарафыннан телевизион спектакль итеп эшләнгән яңа варианты дөнья күрде. Әмма режиссер концепциясе, бигрәк тә М.Фәйзинең татар хатын-кызларына хас иң матур сыйфатларны үзенә туплаган героинясын «ялангачландыру» җәмәгатьчелектә яклау тапмады. Спектакль күрсәтелү уңае белән язылган мәкаләләрдән күренгәнчә, физик һәм рухи матурлык, әхлакый сафлык, чисталык һәм олы мәхәббәт символы булган Галиябану бернинди үзгәртүләргә дә мохтаҗ түгел. Безнең әдәбият-сәнгать тарихында талантлы иҗат нәтиҗәсе буларак «Галиябану» бер генә. Бәхеткә, Финляндиядә яшәүче милләттәшләребездән бер төркем һәвәскәрләр тарафыннан күрсәтелгән «Галиябану» спектакле ихласлыгы, милли төсмерләрне калкытып куюы һәм, иң мөһиме, М.Фәйзи яклаган идеалларны дөрес чагылдыруы белән Казанның әдәбият-сәнгать дөньясын сафландырып җибәргән иде. Әлеге тамашаны безнең режиссерлар күргән булса, югарыда әйтелгән «мөгез чыгару», бәлки, булмас иде. Хәер, ялгышабыз бугай. 2002 елда «Идел» журналы «Ша-Ярыш-2» рубрикасында «XXI гасыр «Галиябану»ы» дигән конкурс игълан итеп, күпсанлы язмалар урнаштырды. Редакция, әлеге адымга баруны аңлатып, болай дип язды: «Бөек драматургыбыз рухы бу гамәлгә рәнҗемәс дип уйлыйбыз. Киресенчә, әлеге шаян иҗади өмә—аны яд итү, олылавыбыз билгесе ул». Әмма ул җәмәгатьчелектә бертөрле генә кабул ителмәде. «Ша-Ярыш»ка килгән текстларның күпчелегендә Галиябану җилбәзәк, акчага гына кызыгучы, милли сыйфатларның эзе дә калмаган, егетләр аздыручы кыз рәвешендә; Хәлил йә исерек, йә мескен, аракы өчен Галиябануны теләсә кемгә биреп җибәрергә әзер егет төсендә; Исмәгыйль исә йә «мафиозник», йә исерек, йә кызларны перчатка кебек алыштыручы авыл бае буларак сурәтләнә. Язмаларның берсендә дә Галиябану белән Хәлилнең яхшылык, матурлык, сафлык, чын мәхәббәт үрнәге буларак тәкъдим ителмәвен ничек аңларга? М.Фәйзи әсәренә капма-каршы төсмерләрдә биреп, укучыларда көлү-елмаю тудыру теләгеме, әллә инде хәзерге заман яшьләрендә кара-караңгы сыйфатлар гына күрү чагылышымы? Дөрес, авторлар теләге изгедә булып, заман яшьләрендә әхлакый сафлык, матурлык сыйфатлары бетеп бара бит дип, чаң кагулары яисә М.Фәйзи пьесасы геройларына хас милли сыйфатлар юк бит, дип, бу мәсьәләгә җәмәгатьчелекнең игътибарын җәлеп итүләредер. Әмма... Өлкән һәм урта буын кешеләр генә түгел, яшьләр дә М.Фәйзи геройларын, аеруча

Галиябануны яшьлек, гүзәллек, әдәп-әхлак, матурлык төшенчәләре белән бәйләп карый. Ә инде журналда урын алган пьеса-скетчлар күнелдә урнашкан образ-сурәтләрне юкка чыгара. Алай гына да түгел, күпләр моны М.Фәйзидән һәм анын якты геройларыннан көлү, аларны кимсетү дип кабул итте.

Әлеге урынсыз шаяруларга җавап йөзеннән Г.Камал исемендәге театр сәхнәсендә Т.Миннуллинның «Галиябану, сылуым-иркәм» (2006) драмасы куелды. Сәнгать әһелләренең катлаулы, гыйбрәтле тормышын шактый кин планда ачуны максат иткән әсәрдә, җитди мәсьәләләрнең берсе булып, М.Фәйзи «Галиябану»ының татар театры тарихындагы урынын билгеләү омтылышы да тора. Артист халкының театрдагы тормышын һәм шәхси теләкләрен, хис-кичерешләрен төрле яссылыкта сурәтләү аша, Т.Миннуллин һәркем күнелендә Галиябану яисә Хәлил образында уйнауның табигый һәм җан-рух теләге булуын ача. Ул исә М.Фәйзи «Галиябану»ының популярлыгы сәбәпләрен тагын бер кат калкытып куюга китерә: һәркем күнелендәге хис-кичерешләрне кузгатуы, янартуы белән укучы-тамашачыны сафландыра, җанын иркәли, күңелендә матурлыкка, мәхәббәткә омтылу, тартылу теләге тудыра.

Әйе, М.Фәйзинең бай иҗаты, атаклы «Галиябану»ы саф хисләргә нигезләнгән мәхәббәткә мәдхия укуы, гуманистик асылы белән алдагы буын укучыларда да зур кызыксыну уятачагына шикләнмәскә мөмкин. Драматургның самими-ихласлыклары белән башкалардан аерылып торган геройлары, аларның гаҗәеп шатлык-омтылышлар, кайгы-хәсрәтләр белән тулы хис-кичерешләрдә сурәтләнүе, шулай ук халыкның яшәү рәвешен, сыйфат-билгеләрен, өмет-юанычларын иҗатында тирән сугаруы бүген дә гаять заманча янгырый.

**Таһир ГЫЙЛАҖЕВ,**
**Әлфәт ЗАКИРҖАНОВ**

---

## Электрон почта да төпсез түгел

Редакциягә әсәрләр, мәкаләләрнең фәкать машинкада басылган яки компьютердан чыккан кульязмалары гына кабул ителә. Бер биттә 30 юл (компьютер текстында да!), бер юлда (сүз араларын да исәпләп) 60 тамга булырга тиеш. Кәгазьнең бер ягы буш кала. Машинка текстының беренче нөсхәсе генә кабул ителә. Компьютер текстының дискеты да булу кулай.

Хатлар исә, җинел танылырлык итеп, кулдан да язылырга мөмкин.

Редакциянең электрон адресына фәкать кечкенә күләмдәге язмалар (хатлар, документлар, фикерләр һ.б.) гына кабул ителә.

Электрон адреска күләме 5 биттән арткан язмалар җибәрелгән очракта, почта аша анын оригиналын (кәгазьгә басылган вариантын) алгач кына әсәр кабул ителгән санала.

# «МИН КАЗАННАН КИТМӘДЕМ»

РАВИЛ БОХАРАЙГА 60 ЯШЬ

*Равил Бохарайның нәсел чыгышы Себер ягыннан, Томск шәһәреннән. Аның бабалары танылган сәүдәгәрләр булган. Фамилиясе исә Себер белән Урта Азия арасында кәрван сәүдәсен йөртүчеләрдән— бохарайлардан килә. Равил Бохарай да нәсел юлыннан читкә тайпылмаган. Ул да, бохарайлар кебек үк, кыйтгалар, илләр арасындагы бәйләнешләрне арттыруга, мөнәсәбәтләрне көйләүгә үзеннән зур өлеш кертә. Дөрес, аның йөге сәүдәгәр бабаларыныкы кебек мал белән шыплап тулмаган. Ул җиһанга рухи байлык тарата. Безнең өчен тагын да мөһимрәге шул: дөньякүләм танылу алган шәхес инде ике дистә ел Җир шарының «аҗаган кайнаган шәһәре»ндә—Лондонда яшәсә дә, үзен тудырган татар милләтен, тәпи басып киткән Казанын бер генә мизгелгә дә исеннән чыгармый. Моңа инану өчен Равил Бохарайның әдәби әсәрләренең, фәнни хезмәтләренең исемнәренә күз салу да җитә. Туган җирен һәм туган халкын олылау аның үзен дә билгеле шәхес итте.*

**—Әтиегез Рәис Гата улы—Казан кибернетиклар мәктәбенә нигез салучы галим-математик, профессор. Әниегез—Наирә Халитова—физика-математика фәннәре кандидаты, шулай ук университетта озак еллар эшләгән педагог. Наил абыегыз физика-математика фәннәре кандидаты, Казан дәүләт университеты доценты. Шундый гаиләдә туып һәм фән юлында үсәргә ышанычлы перспектива була торып, сезнең башка юлны сайлавыгыз гаҗәпләндерә.**

—Мин дә олы тормышка беренче адымнарымны әти-әнием салган юлдан атладым: 1968-74 елларда Казан университетының механика-математика факультетында укыдым. Аны кызыл диплом белән тәмамлагач, укуны Мәскәү университетында теоретик кибернетика буенча аспирантурада дәвам иттердем.

Әмма мине әдәбият дөньясы һәрчак ымсындырып торды. 1969 елның мартында «Комсомолец Татарии» газетасында беренче шигырем басылып чыккач, мин тагын да канатланып иҗат итә башладым. 1977 елда «Яблоко, привязанное к ветке» дип исемләнгән шигъри китабым дөнья күрде. Бер елдан СССР Язучылар берлегенә кабул ителдем. Шул чакта мин фәнни һәм әдәби эшчәнлекне бергә үреп барып булмаячагын аңладым. Үземне гүя ике юл чатында басып торган кешедәй тойдым. Ул чакта төп иҗат мәйданы итеп әдәбиятны сайлавыма һич үкенмим.

**—Фәнни юнәлешне калдырырга туры килсә дә, сез башкарган хезмәтләр бер институт эшчәнлегенә тиң торырлык. Татар рухын, татар тормышын дөньякүләм таныткан әсәрләрегез турында әйтүем.**

—Мин татар халкының тарихи язмышы һәм фән буларак ислам фәлсәфәсе белән тирәнтен кызыксынам. Унынчы гасырдан башлап Явыз Иванның Казанны яулап алуына кадәр булган чорны өйрәнеп, инглиз телендә махсус китап яздым. 1992 елда «Azan» исеме белән борынгы татар дини-рухани поэзиясе үрнәкләренең

оригиналлары һәм инглизчәгә тәрҗемәләре тупланган аерым җыентык бастырдым, махсус кереш сүз язып, Лондон университеты профессоры-лингвисты Дэвид Мэтьюс белән берлектә инглиз телендә «Татар шигъриятенең тарихи антологиясе»н әзерләдем (Лондон, 2000), Англия, Канада, Һиндстан, Германия, Венгрия, Италия, Төркия матбугатында Татарстанга багышланган тарихи-публицистик хезмәтләр белән катнаштым. «Казан: искитмәле башкала» (1994), «Татарстан моделе һәм Президент Минтимер Шәймиев» (2000), «Гасырлар аша балкыган Казан Кремле» ( 2001), «Казан турында хикәят» ( 2005) китаплары дөнья күрде...



**—Соңгысына иркенләп тукталыйк әле.**

—«Казан турында хикәят»не меңъеллык татар мәркәзе хакында әдәби телдә язылган энциклопедия дип тә атарга була. Бу хезмәт мәдәни-тарихи өлкәләрне генә колачламый, анда сәясәткә дә, икътисадка да киң урын бирелгән. Лондонда яши башлаганнан бирле мин төп иҗатымны әнә шундый хезмәтләргә—рус һәм чит ил укучыларын Татарстан Республикасының тарихы һәм бүгенгесе белән таныштыруга багышладым. «Казан турында хикәят»— татар цивилизациясе турында хикәят ул. Казан борынгы болгар-татар язма мәдәниятенең символы гына түгел, ул Европа белән Азияне тоташтыручы үзәк тә. Китапның беренче бүлекләрендә—мин аларны җырлар дип атадым—Казанның эре мәдәни, сәнгать һәм мәгърифәт үзәгенә әверелүе турында сүз бара.

Әлеге хезмәтне башта рус, аннан инглиз телендә яздым. Минем фикеремчә, тарихи дөреслекне, димәк, татар халкы турындагы чынбарлыкны Россиянең һәр төбәгендә һәм татар турында уйлап чыгарылган, милләтебезне кимсеткән уйдырмалар таралган бөтен җирдә белергә тиешләр. Хәзер дә Татарстандагы гамәлләр иләк күзе аша үткәрелә. Хәтерлим әле, Татарстан латин графикасына күчәргә теләгәч, нинди кара тавыш купкан иде. Бу китапта мин шул хакта да яздым. Үз гомерендә кириллицадан татар телендә бер сүз дә укып карамаган кешеләр дә бу адымны хуплаучыларны ватанпәрвәрлек хисе булмауда гаепләп кычкырындылар! Шул ук вакытта герой шагыйрь Муса Җәлилнең Моабит төрмәсендә язылган һәм ватанпәрвәрлек хисе белән сугарылган шигырьләренең латин графикасында кәгазьгә төшерелгәнлеге турында уйлап та карамадылар!

Казан—минем тарихи-сәяси һәм икътисади хезмәтләремнең чыганагы гына түгел, ул шигырь һәм поэмаларымның, проза әсәрләремнең, пьесаларымның илһамчысы да. Мин бу шәһәрдә тудым. Соңгы дистә елларда ул чит ил кешеләре өчен ябык шәһәрдән кунакларны ачык йөз белән каршылый торган заманча башкалага әверелде. Мөгаен, бүген Идел буенда ана тиң калалар юктыр. Казан турында шундый китап язу минем күптәнге хыялым булса, яши-яши мин аны мөһим бурычым итеп кабул иттем.

*«...Ерак юлның тузаны*
*Иңемә салды тунын...»—*
*Бу бит тарихның үзе,—*
*Борынгы маҗар сүзе!*

*Ә минем*
*Олы юлым, «тузаным»,*
*Сүнмәс назым,—*
*Казаным!*

**—Берничә ел элек сез Казанда үзегезнең иң яхшы шигырь һәм поэмалар кергән**

**«Отпусти мою душу на волю» исемле җыентыкны тәкъдир иткән идегез...**

—Исеменә килгәндә, ул Тукайның «очты күңлем читлегеннән...» дигән сүзләреннән чыгып кушылды. Анда яңа шигырьләр дә бар, әмма күпчелекне сайланма шигырь һәм поэмалар тәшкил итә. Алар Мәскәүдә «Шигъри китапханә» дип аталган сериядә русча чыкты. Бу китап Казанда Сынлы сәнгать музеенда тәкъдим ителде.

Әйткәнемчә, мин Казанда туып-үстем. Рухи рәвештә мин аннан беркайчан да китмәдем. Казанда яңа китабымны күрсәтмәсәм, мин аны чыкмаган дип саныйм. Минем өчен Казан һәрвакыт беренче урында. Ул Мәскәү дә, Лондон да түгел.

**—«Равил Бохараев татарның шигъри диңгезен дөньяның шигъри диңгезе белән тоташтыра торган ерганак ясады. Моның никадәр олуг эш икәнен без яши-яши генә аңларбыз әле»,—дип язган иде күренекле шагыйрь Зөлфәт. Мин бу очракта татарның бөек шагыйре Тукайны дөньяда танытудагы абруйлы эшчәнлегегезгә тукталасым килә.**

—Тукай һәрбер татар баласын балачактан бирле озатып йөри. Балачагыбыз Тукай әкиятләреннән һәм «Туган тел» шигыреннән башлана. Туган тел ул—безнең өчен Тукай. Ул—туган телнең нинди югарылыкка күтәрелә алуын күрсәтүчебез. Без әлегә кадәр Тукайны аңлап җиткермибез, талантының колачын күзаллап бетерә алмыйбыз. Аны һаман үзебез корган кысалар чикләрендә, хакыйкатьне ничек кабул итүебездән чыгып кына аңларга тырышабыз. Тукайның даһилыгы аның безнең өмет, ышанычларыбызга туры килүендә генә түгел, аның булуы һәм мәңгегә безнең әхлак символы булып калуында. Әйләнә-тирәдә тормыш ничек кенә үзгәрмәсен, Тукай ул тыярга, кагылырга йә булмаса бетерергә ярамый торган символ булып кала бирә. Ул һәрвакыт халкының әхлакый идеалы, хакыйкать чагылышы булачак. Татар халкы өчен генә түгел, дөнья халыклары өчен дә. Шуна күрә дә ул бөек.

Габдулла Тукайның иҗаты һәм шәхесе мине һәрчак кызыксындырды. 1986 елда Тукай тормышы-язмышы турында «Тукай тирәсендә» дигән драматик повесть яздым. Курчак театры өчен язылган пьеса да бу теманың бер гәүдәләнеше булды: «Апушның тылсымлы төшләре» («Волшебные сны Апуша», 1986) пьесасы зур уңыш белән куелды. Заманында Тукайның «Су анасы», «Кәҗә белән Сарык әкияте» һәм башка поэмаларын русчага тәрҗемә итеп, аерым китап итеп бастырган идем. Г. Тукай сайланма әсәрләренең өч русча басмасын төзүдә катнаштым. Инде Тукайның бөтен шигырьләре дә инглизчәгә тәрҗемә итеп бетерелде. Алга таба алар Лондонда китап булып басылып чыгарлар.

**—Дөнья татарны белә башласын өчен чыннан да әдәби әсәрләрне халыкара телләргә күбрәк тәрҗемә итәргә, дөньяга күбрәк таратырга кирәктер шул...**

—Татарча бөек әсәрләр язарга кирәк, аннан соң тәрҗемә ителер ул. Классик әсәрләргә килгәндә, аларны да тиз генә турыдан-туры инглиз теленә тәрҗемә итеп булмый. Татар фикерен, моңын, яшәеш даирәсен инглиз телен аңлаучы тойсын өчен эшкә башка җирдән тотынырга кирәк. Мин үземнең шигъриятемнең инглиз телендә басылуын кирәксенмим. Дөньяны татарчадан тәрҗемә әсәрләр укыр өчен әзерлисе бар әле. Иң әүвәле аларга гадел тарихны, мәдәни казанышларыбызны җиткерәсе, бүгенге көн белән таныштырасы иде.

*Туган телнең «үги улы» булып,*
*русча яшим, язам, уйланам ла...*
*Туган телне белү—«һөнәр» түгел;*
*кичермәс ул онытсаң...*
*Әнә, кара:*
*чит көймәне эчкә куалый җил,*
*өзелгән чылбыры суны яра...*
*Чирәмнәрдә ишкәк—хәрәкәтсез,*
*Әсәрендем... балык исеннәме?!*

*Мин «Әллуки» көен көйлим, сузсез...*
*Күз яшьләрем ага...төтеннәнме?!*

**—Сез—урыс телле татар язучыларының берсе. Әгәр шул офык белән генә чикләнеп калсагыз, бәлки, сез татар халкы алдында бу кадәр абруй һәм дәрәҗәләр (Равил Бохарайга 1986 елда Муса Җәлил һәм Габдулла Тукай шигырьләренең тәрҗемәләре өчен Татарстанның Муса Җәлил исемендәге Республика бүләге бирелде. 2001 елда ул «Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем алды. 2006 елда ул «Очсыз-кырыйсыз поезд» («Бесконечный поезд», Мәгариф, 2001), «Казан карлары» («Казанские снега», Мәгариф, 2004) китаплары өчен Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булды) казана алмас та идегез. Күп телләрне белү һәм әлеге сәләтне татар халкын танытуда файдалану сезне безнең өчен кадерле дә, шул ук вакытта буй җитмәслек тә шәхес итә...**

—Рус телендә язсам да, шигырьләрем татарча минем. Нәфесемдә, кальбемдә татар каны ага.

Ә инде эшчәнлеккә килгәндә... Бүген мин дүрт телдә—татар, рус, инглиз һәм мажар телләрендә язылган кырыкка якын китап авторы. Испан, немец, төрек телләрендә иркен сөйләшәм һәм укыйм. 1986-87 елларда Будапешттта мажар телен өйрәндем. Шуннан соң мажар теленнән тәрҗемәләр белән мавыктым һәм шул телдә шигырьләр яза башладым. 1989 елда мине Венгриянең Язучылар берлегенә кабул иттеләр.

Үз гомеремдә миңа өч оешмада гына хезмәт итәргә туры килде. 1979-80 елларда РСФСР Язучылар берлегендә төрки телле әдәбиятлар, калмык һәм Себер халыклары әдәбиятлары буенча консультант булып эшләдем. 1988-89 елларда Мәскәүдәге М. Горький исемендәге Әдәби институтта татар теленнән тәрҗемәләр буенча семинар житәкчесе вазифасын башкардым. 1992-2009 елларда Лондондагы «Би-би-си» радиосының Россия бүлегендә штаттагы хезмәткәр булып эшләдем. БДБ илләренә, шул җөмләдән Татарстанга кагылышлы вакыйгаларны, яңалыкларны шәрехләүче диктор-күзәтче сыйфатында көн саен «Радиус» дигән махсус программа алып бардым. Хәзерге вакытта БМО Балалар Фондының Төрекмәнстандагы, Филиппиндагы һәм башка илләрдәге штаттан тыш консультанты булып торам.

**—Ел саен сезнең берничә китабыгыз дөнья күрә. Аларның һәммәсе тәҗрибә, белем һәм күп вакыт таләп итә торган саллы җыентыклар. Әле сез Татарстан белән дә тыгыз элемтәдә торасыз, әдәби процесста катнашасыз. Әйтик, «Яңа татар пьесасы» конкурсында катнашып лауреат булдыгыз һәм «Тимер борчак» («Железная горошина») пьесасы 2005 елда Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында куелды. Боларның барысына да ничек өлгерәсез?**

—Лондонга килеп эләгү белән язмышның үз милләтемә хезмәт итәр өчен нинди зур мөмкинлек бирүен аңлап алдым. Мин инде ничә еллар ялсыз эшлим. Моңа татар мәдәниятенә кечкенәдән булган мәхәббәтем этәрә. Китаплар бер көн яисә бер ел өчен язылмый. Иң мөһиме, алар җирдә калсын һәм һәр гасырда да үз укучысын тапсын. Шөкер, бу яктан үземне бәхетле саныйм. Бигрәк тә Казанда—туган җиремдә даими укучыларым булу мине сөендерә һәм тагын да канатланып иҗат итәргә рухландыра.

*Әңгәмәдәш*—**Рөстәм ГАЛИУЛЛИН**

# БӨЕКЛЕК ҺӘМ КҮҢЕЛДӘГЕ ЯРАЛАР

АЧЫК ХАТ

Галиҗәнап Вакыт... Аның галәмдә һич гаме юк: көн кояшлымы, яки болытлымы, дәрьяда караб батамы, күктә самолет янамы, җирнең кайсыдыр бер кыйтгасында сугыш бара һәм җаннар кыеламы—ул битараф. Әйе, вакыт үз «эшен» генә белә: ул сиздерми генә уза да уза. Көнне—төн, төнне көн куган кебек, җәйне кыш алыштыра тора. Баксаң, безнең күрешмәгәнгә дә, хәл-әхвәл белешмәгәнгә дә, София ханым, бер дистә ел икән ич инде.



Хәл-әхвәл дигәннән... Юк-юк та Сезнең хәлләр бертуган апагыз Ида Гобәйдуллина аша да, сабакташыгыз Валентина Холопова аша да ирешкәләп торды. Мин үзем дә... юбилеегызга (70 яшь) багышлап Казанда һәм Мәскәүдә узган Халыкара музыка фестиваленнән соң (ул 2001 елның 20-31 октябрендә узды), Сезгә озын-озын хатлар язып маташкан идем. Әмма җибәрми калдым шул.

Сиксән яшегез якынлашкан ошбу көннәрдә аларны янә укып, җибәрмәвемнең, дөресрәге, җибәрә алмавымның сәбәпләрен эзлим. Һәм күз алдында ун ел элек булган манзаралар янара.

Иң әүвәл—Сабан туйларыбыз кебек шаулап узган Казан фестивале.

И ул көннәр!.. Афиша-плакатлар белән бизәлгән Казан урамнары!.. Үзегезне күрү, музыкагызны тыңлау өчен халыкның ташкындай С.Сәйдәшев исемендәге Зур концерт залына агылуы... Өч көн дәвамында Сезне зурлау: чәчәкләргә, алкышларга күмү... һәм—Сезнең бәхетле йөзегез...

И ул бәйрәм рухы!..

Шулай да мин аны Сезнең «Юбиляция» әсәрегездә тасвирланган коллар тантанасына охшаттым.

Ни өченме?

Үзегезне чорнап алган протоколлы чиновниклар боҗрасыннан чыга алмавыгызга, Яңа Бистә татар зиратына, әти-әниегез каберенә баш иярга дә баралмыйча китүегезгә—күңел риза булмагандыр, мөгаен.

Инде фестивальнең Мәскәү көннәрен хәтерлик.

Җир һәм күкләр «сөйләшүен» Казанда тыңлаганлыктан (Мәскәү фестивале дә шул әсәрегез—дин проблемаларына, кешелек дөньясы һәм галәм язмышына багышланган «Страсти по Иоанну»ыгыз белән ачылды), мин Мәскәүгә Сезнең белән үк түгел, ә бераз соңрак килдем. Һәм... һәм, Сезнең монда үги булуыгызны күреп, гаҗиз калдым.

Әйе, әйе, юбилеегызга багышланган Халыкара фестиваль турында бөтен Мәскәвендә бернинди дә белдерү-афишаның булмавы, музыкагызның исә консерваториянең яртылаш буш Кече залында яңгыравы—аптыраш калдырды. Мондый хәл йөрәгегезгә яра салгандыр, күрәсең—Сез үзегез дә бик боек идегез. (Ярый әле һәр кичәдә яныгызда кызыгыз Надежда булды һәм үзегезгә булышып йөрде.)

Сезне мондый мохиттә күрү күңеленә ятышмагандыр, ахры, «Казань» журналының баш редакторы Юрий Балашов та (ул—журналының бер санын Сезгә

багышлаган, «Международный фестиваль музыки Софии Губайдулиной» дигән 110 битле затлы буклет чыгарган һәм фестивальнең һәр көненә (аерым-аерым!) гаҗәеп бизәлешле чакыру билетлары бастырган кеше!), консерваториянең кече залында бер генә көн таптанып йөрде дә, үз калабызга кайтып китте.

Мине исә монда музыкагызны тыңлыйсы килү генә түгел, рухи мәсләгегезне дә аңлыйсы килү теләге тота. Һәм—Сезгә затлы бер журнал өчен гаиләгез турында язарга теләвемне әйтәм.

Иркенләбрәк сөйләшү өчен уңай дип Сез (26 октябрьдә сәгать 11гә) үзегез тукталган «Ширатон палас» кунакханәсенә чакырдыгыз. Менә әйбәт булды, әтиегез турында да бәйнә-бәйнә сөйләрмен, бәйрәмегезгә бер бүләк булыр ичмасам дип сөендем мин. (Том-том романнар герое булырлык әтиегез Әсгать ага хакында бик аз беләсез чөнки. Хәтерегез калмасын берүк, гаепләп әйтүем түгел. Без бит сөйләшми торган чор, «телсез-сүзсез» буын балалары. Үзем дә, мәсәлән, әткәм турында берни дә диярлек белмим.)

Әйе, әйе, әтиегез турында... Бәйрәкә авылы тирәли (Татарстанның Ютазы районы) 262 дисәтинә (ягъни 286 гектар!) җир биләгән морза-хәзрәтләр нәселеннән булган Әсгать Мәсгут улы Гобәйдуллинның кечкенә чагы турында да, уку еллары, мәхәббәт яралары турында да һәм, әлбәттә инде, яшәү рәвеше—титаник хезмәте хакында да сөйләрмен дип фараз кылдым. Һәм кунакханә номерыгызның бусагасын да шундый ният белән атлап үттем.

Күңелегезне күтәрергә теләптер инде, сүземне янә юбилей бәйрәмегез белән тәбрикләүдән башладым. Ә Сез:

—Минем өчен бәйрәм—музыка белән очрашу ул,—дисез дә, урындыгыгыз артына килеп баскан ирегез Петр Мещаниновка карап алып:—Минем кызым, бер дигән апаларым бар, әмма минем өчен музыка бар нәрсәдән дә кадерлерәк,—дип өстисез. Һәм... рас әйттемме, шулай әйтергә ярый идеме дигәндәй, тагын ирегезгә карап аласыз.

Кеше ирене, иҗат ирене бәрабәренә хәтта туган илне калдырып китәргә дә үзендә көч тапкан шәхеснең ошбу халәте сискәндереп ала. «Сезме соң бу —күкләрнең җиденче катына менеп галәм белән сөйләшүче ханым?!» дип әйтүдән көчкә тыелып, шәхси тормышыгыз, яшәү рәвешегез, кыскасы, гаиләгез хакында сөйләвегезне үтенәм.

—Кечкенә чагымда әти мине кырларга-болыннарга алып чыга иде. Ул дәшми. Һәм без тып-тын гына кыр-басулар, елгалар буйлап бик озак барабыз. Табигать белән әти һәм мин!.. Бала чагымның иң бәхетле мизгелләре бу. Германиядә яшәгән соңгы елларымны да мин әнә шул бәхетле елларга тиңлим. Йортым каршында әти образын искәртеп торучы имән бар, ә янәшә-тирәли әти яраткан сиреньнәр утырттым. Әти... ул намус феномены!

Менә каян килә икән ул музыкагыздагы сагыш-юксыну аһәңнәре дип уйларга да өлгермим... ирегезнең тамак кыруы Сезне сүзсез калдыра. Минем дә түземлегем сынды, господин Мещаниновтан гафу үтенеп, үзебезне генә калдыруын сорарга мәҗбүр булдым.

Әмма Сез «бикләнгән» идегез инде. Ирегез йокы бүлмәсенә, икенче катка менеп китсә дә, Сез барыбер ачыла алмадыгыз. Иҗатыгызга илһам бирүче мәхәббәт хакында соравыма да, яшь вакыттагы гөнаһларымны искә аласым килми дию белән чикләнеп, үзегезгә рухи таяныч булган музыка осталары турында сөйләүгә күчтегез.

...Әтиегез турында сөйләргә теләвемне «онытып», китәргә җыендым. Сез каушый төштегез. Нindидер бик мөһим сер әйтергә җыенгандай ашыгып-каударланып кулымнан тоттыгыз.

Нәкъ шул мәлдә яныбызда ирегезнең пәйда булуы Сезне янә «айнытып» җибәрде.

Дилбегәне шундук ирегез үз кулына алды. Һәм аның: «Без Татарстанга бик рәхмәтле, бу турыда господин Президентка житкерсәгез иде», дию—ошбу очрашуның аккорды булып яңгырады.

Петр әфәндегә бу очрашу да шул сүзләрне әйтү өчен генә кирәк булган икән

дигән уй белән, ишеккә юнәлдем.

...Менә, ниһаять, фестивальнең соңгы көне—ябылу кичәсе.

Бу кичәнең Мәскәү консерваториясенең Зур залында узуы да җаныгызны җылыта алмаган иде.

Минем үз хәлем дә—шул чама. Янәшәмдә пәйда булган якташым Фәрит Гобәевнең «София ханымга ни булган, нигә бик боек ул», «Нишләп залда буш урыннар күп», «Ник бер түрә дә күренми», «Фестиваль хакында урамнарда нишләп бер реклама да юк» кебек дистәләгән соравының берсенә дә җавап таба алмыйча азапланып утырам.

Фотокүргәзмәнең ябылуын да көтеп тормыйча, юбилей бәйрәмегезне күрү, музыкагызны тыңлау өчен әле генә Франциядән кайтып төшкән фотохудожникны Сезнең мондагы хәл-халәтегез нык борчыды булса кирәк, ул озак кына пошынып-уфтанып утырды да, дөньякүләм бөекләрне күп күргән Мәскәүнең беркемгә дә исе китми бугай дигән нәтиҗә ясап, үзен тынычландырды. Тик мин генә тынычлана алмадым.

Казаныма кайткач та Сез күңелемнән китмәдегез. Мәскәү фестивале көннәрендәге арыган-йончыган кыяфәтегезне кысрыклап, безнең тәүге очрашуда туган образыгыз (ул очрашу 1990 елның декабрендә булды)—«Азат хатын» журналының «Сөембикә» булып үзгәрүенә чиксез сөенеп фатиха бирүегез дә, үзегезгә бүләк итеп алып килгән «Кыйссаи Йосыф» китабын күкрәгегезгә кысып: «Шушындый зур бүләк—миңамы?!» дип, бәләкәй бала кебек куануыгыз да—күз алдына килә. (Хәтерлисездер, 1991 елда яңадан туган «Сөембикә» журналының беренче санында Сезнең фатихагыз да бар. Ә икенче (февраль) санында Сезнең белән очрашу тасвирлана.) Шуннан соңгы (1992, 1993, 1996 елларда) очрашуларыбыз исә ихлас табигыйлеге белән әнә шул җылы, якты образны тагы да баеткан иде.

... Һәм менә: үзгә мохит, үзгә халәт, үзгә моң!

Кеше шушылай да үзгәрә ала икән—йә Хода! Гүя ике кеше, ике образ. Берсе—якын, үз. Икенчесе—ят. Берсен оныта алмыйм, чөнки ул йөрәк түрендә урын алган, ә икенчесен... анлый да алмыйм, күңел дә кабул итми. Һәм бу «икәүне» бербөтен итеп күрү—мөмкин түгел.

Шул сәбәпле, яраткан журналымда фестиваль турында да, гаиләгез хакында да бер хәбәр дә чыкмады. Язу теләге үзе үк, бөтенләй булмаган да кебек, юкка чыккан иде инде. Әмма минем үземә бушанырга кирәк иде. Шул нисбәттән Сезгә хатлар язарга тотынганмын да. Һәм «Ни-нәрсә булды Сезгә?» дип битәрләп башлаган ул хатларга тулышкан күңелемне түгеп бушанганмын да—җибәрмәгәнмен бит менә. Ә җибәрмәвемнең сәбәбе инде аңлашыла булса кирәк.

Әйе, әйе, болай да яралы җаныгызга җәрәхәт өстисе килмәгәндер. Шуңа күрә моңлы күңелегезнең нечкә кылларын аяганмын, димәк.

Ни генә дисәк тә, әлеге музыка фестивале—адәм күтәрә алмаслык иҗади хезмәтегез белән яулап алган бәйрәмегез иде бит. Аннары... Сез үзегез дә татар исемен бөтен дөньяга танытучы бөек композитор гына түгел, үз иле Татарстан өчен титаник хезмәт башкарган шәхес—Әсгать ага Гобәйдуллинның кызы да бит әле.

Ә ул миңа да «кызым» дип дәшә иде. Һәм аның турында мин шушы ук журналга олылап язачакмын әле.

**P.S.** Сиксән яшегез тулу уңаеннан, юбилей фестивален бу юлы Амстердам шәһәре башлый дип ишеттем. Мөбарәк булсын—музыка бәйрәмегез!

**Рәйсә ЮСУПОВА**
*Сентябрь, 2011.*

# КАНАТЛЫ ЛӘБИБ

ЛӘБИБ ЛЕРОНГА 50 ЯШЬ

Балалар өчен дә, өлкәннәр өчен дә язучы шагыйрь, прозаик, драматург, әкиятче, пародияче, эпиграммачы, сатира-юмор остасы... Саный китсәң, әдәби жанрларның һәммәсендә дә үз канаты бар икән ләбаса Ләбиб Леронның! Өлкәнрәк язучы агайларның: «Энем, пакусны киң алдырасың, болай чәчелүең сыйфатка сукмыймы соң?»—дип искәртүләренә ул үзе: «Ни телим—шуны язам. Халыкка кайсы ярыйдыр—үзе сайласын, мина барысы да ярый...»—дип шаяртып җавап бирә.



Халыкка кайсы ярыйдыр, дигәннән... Моннан нәкъ егерме бер ел элек Ләбиб Леронның «Күрше тавыгы» дип аталган эпиграммалар һәм пародияләр китабы дөнья күрде. Балалар һәм үсмерләр өчен инде берничә җыентык чыгарырга өлгергән язучының чын мәгънәсендә халыкка танылуы иде бу. «Бездәге әдәби вакыйгаларны колачлый алган—бу бик тә кызыклы күренеш!»—дип, әлеге китапка карата Фәрваз Миннуллин да үз фикерен белдергән иде. Инде килеп, шәхсән үзем дә шаһит: «Күрше тавыгы», студентлар тулай торагында кулдан-кулга йөри торгач, тәмам юкка чыкты—китапны миңа кире кайтармадылар. Соңгы күргәндә ул шактый тетелгән, таушалган һәм... калынайган иде. Игътибар итсәгез, фәкать күп укылган, битләре кат-кат актарылган китап кына калыная.

Үткен вә җор телле, урыны белән шактый ук усал төрттергән бу пародия-эпиграммалар, гыйбарәләр тәнкыйть вазифасын да үтиләр иде. Ни генә булса да, телгә алынган әсәргә, яисә язучыга бик шәп реклама да бит әле бу. Укучылар арасында гына түгел, язучылар мохитендә дә әдәби битарафлык хөкем сөргән заманда шушы ваемсызлыктан автор үз ысулы белән сискәндерергә, уятырга тырыша...

Тәнкыйть дигәннән, Гарифҗан Мөхәммәтшинның эпиграммасы искә төште:

*Төшкә керде Ләбиб Лерон—*
*Тәмәкесе көйри иде.*
*Шигърият басуларыннан*
*Чүп-чар утап йөри иде.*

Берничә ел элек, язучы, шушы «чүп-чарны утау» ниятеннән, «Сәхнә» журналында махсус сәхифә дә ачып җибәрде. «Мин дә җырлыйм шырдыйны...» дип атала ул. Биредә дә Ләбиб Лерон үзенә тугры булып калды: кемлегенә карамастан, мәгънәсез вә тозсыз, чүп-чар җыр авторларының, башкаручыларның тетмәсен-тетеп тәнкыйтьләде.

2008 елда дөнья күргән «Сөяксез тел» китабы инде узган гасырда калган «Күрше тавыгы»ның уңышлы дәвамы булып чыкты. Хәер, монысы хакында—соңрак.

Иҗатның, шигъриятнең символы—канатлы ат. Без исә бүген әдәбиятыбызның канатлары парә-парә киселгән вә йолкынган заманда яшибез. Татар әдипләренең

дә бик азлары гына «канатларын» саклап кала алды. Ләбибнең соңгы елларда язылган лирик шигырьләре—бу канатларының исән-сау, нык икәнлегенә дәлил. Гаяз Исхакый, Кәрим Тинчурин, Һади Такташ, Хәсән Туфан, Мөхәммәт Мәһдиев, Мөдәррис Әгъләмов кебек әдипләр хакындагы «Багышлаулар бабы»нда автор шагыйрь буларак та, шәхес буларак та тәгәл ачыла, минемчә. Бу җөмләдән янә шунысын да әйтү урынлы булыр: инде менә дистә ел дәвамында Ләбиб Лерон татарның олуг шәхесләренә багышланган әдәби-музыкаль кичәләргә сценарийлар яза. Бу затларның фикерен-кыйбласын, язмышын анык күзаллау, аңлау өчен язу халәтендә автор алар дөньясына, алар заманына чума, алар булып яшәп ала һәм бу аның лирик-фәлсәфи шигырьләрендә дә чагыла билгеле.

Ләбиб Леронның янә бер канаты—драматургия, балалар өчен дә, өлкәннәр өчен дә бердәй актив яза ул. «Чәпәләй белән Тәпәләй», «Аңгыра сарык җүләре» пьесалары Әлмәт театрында, ә «Урмандагы тамаша», «Без барабыз бәйрәмгә» пьесалары Татарстан телевидениесеннән күрсәтелә, радиодан да тапшырыла. Соңгы елларда аның Буа һәм Түбән Камадагы Татар дәүләт театрларында өлкәннәр өчен язылган яңа пьесалары сәхнәләштерелеп, уңыш казанды.

Балалар өчен шаян-шук шигырь яза икән, ул үзе дә бераз тиктормас-җор малайга әверелә, ә инде лирик-фәлсәфи шигырьләрендә, хикәя-бәяннарында Ләбиб Лерон ил агасын хәтерләтә. Нәкъ менә шушы әверелешләр аңа иҗат күгендә табигыйиркен рәвештә канат җилпеп очарга мөмкинлек тудыра да инде. Бер җөмләгә сыйдырып әйткәндә: Ләбиб Леронның иҗаты яшь аралаш көлә белү кодрәте белән көчле, үзенчәлекле. Аның спектакльләрен тамаша кылганда да, шигырь-хикәяләрен укыганда да мин шуны тойдым.

Төрле елларда Нажар Нәҗми, Шәүкәт Галиев, Илдар Юзеев, Батулла, Фәнзаман Баттал, Зөлфәт кебек күренекле каләмдәшләребез Ләбиб Леронның талантын зурлап үз сүзләрен әйттеләр.

Исем кую остасы—монысы да әдипнең янә бер канаты. Лемон Лерон улы Лероновның үзенә дә Ләбиб дигән әдәби тәхәллүсне әллә Ркаил Зәйдулла, әллә Туфан Миңнуллин кушкан анысы. Вәләкин әдәби әсәрләргә, сәхифәләргә шәп исем уйлап табу җәһәтеннән аңа тиңнәр аз. Үземнең дә беренче хикәяләремә исемне Ләбиб белән бергә кушкан идек. Бактың исә, Фәиз Зөлкарнәйнең «Әверелеш», Ркаил Зәйдулланың «Ил», Газинур Моратның «Мин дөньяны тыңлыйм» китапларының да исем авторы—Ләбиб Лерон икән.

«Идел» журналының күп кенә сәхифәләре исеме («Һәйбәт-гайбәт», «Ша-Ярыш», мәсәлән), «Салават күпере»ндәге «Шалтмылтфильм»—аның иҗат җимеше. Әле дә хәтердә—моннан ун-унбиш еллар элек «Шалтмылтфильм» әкият-комиксларын (авторы—Л.Лерон) күренекле язучыбыз Батулланың малайлары зар-интизар булып көтеп алалар иде. Инде алар да милләтебезгә хезмәт итүче гаярь егетләр булып үсеп җиттеләр.

Ләбиб Леронның төп канаты, әлбәттә—балалар өчен иҗат итү! Мөдәррис Әгъләм 1988 елда: «Безгә Ләбиб кебек егетләргә таянырга кирәк. Кайсы редакциядән генә мөрәҗәгать итмәсеннәр, ул эшли. Халыкка кирәк, балаларга кирәк дигән гаме бар!»—дип язган булса, 1989 елда исә Мөхәммәт Мәһдиев болай дигән иде: «Балалар өчен язу өлкәннәр өчен язуга караганда да кыенрак дип беләм. Бу җәһәттән Ләбиб талантлы егет, язачак егет». Күренекле каләмдәшләренең ышанычын вә өметен аклады әдип: «Яңгырның ял көне», «Транзистор үч ала», «Тәгәрмәчле чана», «Таһир маҗаралары», «Кояшны кочкан малай», «Борчак шыттырам»—бу китапларга тупланган шигырьләр, хикәяләр, әкиятләр, пьесалар—инде менә чирек гасыр дәвамында ничә буын татар баласын үз дөньясында яшәтә, тәрбия кыла!

Быел әдипкә 50 яшь тула. Тәрҗемәи хәлен кыскача гына бәян итәм: Ләбиб Лерон (Лемон Лерон улы Леронов) 1961 елның 11 ноябрендә Татарстан Республикасының Мөслим районы Түреш авылында дөньяга килә. Балачагы Актаныш районының Олы Имән авылында уза.

1969-1979 елларда Олы Имәннең башлангыч, Югары Яхшыйның сигезьеллык мәктәпләрендә, Киров авылының урта мәктәбендә белем ала. 1979 елда Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетына укырга керә. Аның журналистика

бүлегеп 1984 елда тәмамлый. Университетта укыган елларында ук «Яшь ленинчы» (хәзерге «Сабантуй») газетасы редакциясендә эшли башлый. 1986-1988 елларда Татарстан Язучылар берлегендә СССР Әдәби фондынын Татарстан бүлеге директоры вазифасын башкара.

Берара янә «Яшь ленинчы» газетасы редакциясендә әдәбият-сәнгать бүлеге мөдире, Татарстан телевидениесенең балалар өчен тапшырулар редакциясендә мөхәррир булып эшләп ала. 1989 елдан бирле ул - «Салават күпере» журналында әдәбият-сәнгать бүлеге мөхәррире хезмәтендә.

Ләбиб Лерон—Татарстан Язучылар берлегенең Шәйхи Маннур (1994), Абдулла Алиш (2000) һәм Фатих Хөсни (2006) исемендәге премияләре лауреаты. Татар әдәбиятын һәм сәнгатен үстерүдәге иҗади хезмәтләре өчен 2002 елда аңа Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исем бирелде. 2007 елда шагыйрь Республиканың Муса Җәлил исемендәге премиясенә лаек булды. Ул—1990 елдан СССР (Татарстан) Язучылар берлеге әгъзасы.

Җан дусты Ркаил Зәйдулланың аңа багышланган шигыре болай башланып китә:

*Без сабыйлар иленнән бит, дустым!—*
*Ап-ак болытларга тиенеп,*
*Яшьле керфек кебек янәшәдә*
*Еллар канат җилпи, күк биек!*

*Ак карларда җиләк тамчысыдай*
*Безнең гомер... Яз да, яз, сабый,—*
*Бу чуалган куллар хушлашуның*
*Эндәшүе сыман гасаби.*

Мин дә, аңа кушылып, дәвам итеп, болай дим: бүгенге залиманә дәвердә сабыйлар иленә хыянәт итмичә яшәвең—үзе бәхет бит ул, фәрештәдән ингән канатларың исән-сау булсын, үз Ватаныңда озын-озак яшәргә насыйп әйләсен!

**P.S.**Быел август-сентябрь айларында Кытай карамагындагы Шәркый Төркестан якларында булдым. Андагы татарлар белән аралаштым. Байтак дуслар табып кайттым мин аннан. Шуларның берсе—Мәхмүт. Ул үз машинасында туристларга Тянь-Шань тауларын күрсәтеп йөри. Шундый сәфәрләрнең берсендә юл буе мин аңа Ләбиб Леронның үзем белән алып килгән «Сөяксез тел» китабыннан пародия-эпиграммалар укып, көлдереп бардым. Мәхмүт үзе дә Ләбибкә охшаган, мыеклы да, хәтта аның яшьтие дә, иң мөһиме—юморны аңлый.

Интернет заманы бит—саубуллашканда без аның белән электрон адресларны алыштык.

Әле кичә генә Мәхмүттән хат килеп төште.

«Сөяксез тел»не укып чыктым. Ачуланма, кире кайтара алмыйм—миннән дә кемдер чәлдергән... Тиздән Казанга җиенам—яшьтинең үзен күреп, яңа китабын табарга иде!»—диелгән иде анда.

**Марат ЗАКИР**

Фирдәвес
Гарипова

# АВЫЛЛАРЫБЫЗ ТАРИХЫ

## Апас

Апас атамасы тарихи чыганакларда искә алына. Д.А.Корсаков җыеп бастырып чыгарган белешмәдә (XVIII гасыр) Апас авылында 163 йомышлы, 2 керәшен татары яшәгәнлеге әйтелә. Авыл Табар суы буена утырган. 1859 ел мәгълүматларын эченә алган белешмәдә күрсәтелгәнчә, исемсез күл янына утырган Апас авылының 177 хуҗалыгында ислам динендәге 492 ир-ат һәм 466 хатын-кыз яшәгән, мәчет эшләгән. 1898 елгы белешмәдә Апас авылында Колсәет выселогы белән бергә, татарлар яши дип искә алына, К.П.Берстель белешмәсеннән Апаста 1812 татар кешесе көн иткәнлеге күренә.

Район 1964 елның 4 мартында оешкан. Ул республикабызның көньяк-көнбатышында урнашкан. Районның мәйданы 1047,5 кв км, халкы 22,6 мең кеше. 1991 елны Апас районыннан Кайбыч районы аерылып чыга. Районда 22 җирле үзидарә советы, 72 торак пункт, 1 шәһәр тибындагы бистә бар.

Район аша Зөя—Ульян (Каратун станциясе) тимер юлы, Югары Ослан—Буа автомобиль юлы үтә.

Өлкәннәр сөйләвенә караганда, Апас элек тау итәгендә, хәзерге урыннан биш чакрым ераклыкта, Зөя елгасы янындагы Авыл күле янында нигезләнгән була. Авыл янында гына кара урман үскән. Бу урманда качкыннар да яшәгән дип сөйлиләр. Яз көне Зөя елгасы ташып су баса торган булганга, халык хәзерге урынга, Табар елгасы буена килеп утыра.

Беренче булып Апаска нигез салучы кеше Габбас исемле була. Тора-бара авыл исеме Апас булып кала.

Авыл уртасыннан бормаланып Табар елгасы ага. Моннан башка тагын Апас янында Каз күле, Озын күл, Кәкре күл, Зеркальный сазы, Торналар сазы һ.б. сулыклар очрый.

Бу район Тау ягына керә. Апас янында гына Укысын тавы бар. 1996 елның җәендә көннәр эсселәнеп китеп, янгырлар яумагач, авыл картлары шушы тауга менеп дога укыганнар, янгыр сораганнар.

Апас халкының күбесе кәсепле булган, чүлмәк, орчык, каба ясау һәм кирпеч сугу белән шөгыльләнгәннәр. Кирпечләрне аерым йортларда сукканнар. Халык тагын матур итеп һәм бизәкләп сыбызгылар һәм курайлар ясаган. Элек Апаста базар үткәрелгән, ә базарның иң данлыклысы Каратунда булган.

Апаска күп кенә шигырьләр, мәдхияләр багышланган, аның турында җырлар да бар: «Апас вальсы» (Шәриф Мостафин шигыре, Азат Биктаһиров көе), «Апас ягы—тау ягы» (Марсель Галиев шигыре, Алмаз Хәмзин көе), «Сагындырды Апас, сагындырды» (Әхмәт Рәшит шигыре, Фәрит Хатипов көе).

---

*Дәвамы. Башы 2006 елның 6нчы санында.*

«Сагындырды Апас, сагындырды» жырының сүзләре Апасны болай тасвирлый:

*Җилләр хәбәр итәр ераклардан*
*Туган якка минем кайтасымны.*
*Сагындым мин гүзәл Апасымны,*
*Сагындым мин моңсу каеннарны—*
*Алар көтә минем кайтасымны...*

## Болын–Балыкчы

Болын-Балыкчы авылы Апас районында, район үзәге Апас авылыннан 8 чакрымда, Каратун тимер юл станциясеннән—6, Тәтештән 44 чакрым ераклыкта урнашкан.

Авыл тарихи белешмәләрдә искә алына.

Д.А.Корсаков белешмәсендә (XVIII йөз) күрсәтелгәнчә, авылда 21 бер хуҗалыклы (однодворцы), 112 йомышлы, 4 керәшен татары көн күргән. Авыл күл буена урнашкан. 1898 елгы белешмәдә Болын-Балыкчы авылында 1180 татар һәм рус кешесе яши дип искәртелә. Нажия Борһанова мәгълүматларына караганда, Болын-Балыкчы авылы халкы күршедәге Югары Ындырчы, Шәм-Балыкчы, Кормаш, Үтәмеш, Түбән Биябаш авыллары белән бергәләшеп, июнь ахырында Кызыл яр җыенын бәйрәм иткән.

Олылар Болын-Балыкчы авылы оешуын болай сөйли. Авыл оешасы урында күл, аның янында болынлык булган. Шул болынлыкка балыкчы бабай килеп утырган.

Авыл уртасындагы күл хәзер нык саеккан, хәтта бетү алдында. Кар суы күп булган елларда ул Зөя суы белән тоташа. Элек ул һәр елны яз көне Зөя белән бергә тулып аккан һәм ана Зөядән төрле балыклар кереп калган. 1970 елларда күлне казып һәм чистартып та караганнар. Чишмәсен тапмаганнармы, каплаганнармы, күлнең суы бөтенләй бетәр кебек. Хәзерге вакытта аның тирә-ягына тоташ тал агачлары үскән.

Авыл янында елга, чишмә, сазлыклар җитәрлек: Әбүбәкер бабай ермагы, Мәрҗән чишмәсе, Сәгыйть сазы, Олы саз һ.б.

Авылның тирә-ягын төрле яктан урманнар чолгап алган. Авыл янында гына нарат урманы. Моннан тыш тагын Шомбыт, Зөя урманын атарга мөмкин.

## Дәвеш

Дәвеш авылы Апас районында, район үзәге Апас авылыннан 12 чакрымда, Кильдураз тимер юл станциясеннән—4, Тәтештән 45 чакрым ераклыкта урнашкан.

Дәвеш тарихи белешмәләрдә, халык авыз иҗаты әсәрләрендә телгә алына. Дәвеш авылы янында элек борынгы шәһәрлек хәрабәләре булуын С.М.Шпилевский билгеләп калдырган (1877, 495—496). XVIII йөз мәгълүматларын эченә алган Д.А.Корсаков белешмәсендә Дәвеш авылы да теркәлгән. Анда барлыгы 60 йомышлы һәм 14 керәшен татары көн иткән. К.П.Берстель белешмәсендә күрсәтелгәнчә, Дәвеш авылында 807 татар кешесе яшәгән.

Нажия апа Борһанова мәгълүматларына караганда, Дәвеш авылы халкы июнь башында Колгына, Коштавыл һәм Кара Борнаш белән бергә Юа, Юалык җыенын бәйрәм иткән Дәвешнең өч ягында урманнар сузылган. Якында гына бормалана-бормалана Зөя елгасы ага. Зөянең уң як ярында бер-бер артлы калкулыклар, кечкенә генә таулар тезелеп киткән. Авылның көнчыгыш өлешендә Бола суы Зөягә кушыла. Авыл янында Үле Бола елгасы бар. Бу елга 1940 елларда тимер юл салынганнан соң, Бола суының агышы үзгәргәч барлыкка килгән.

Заманасында авыл урынында урман булганлыкны ышна атамалары раслый. Ышна басулары бабаларыбыз тарафыннан урманнан чистартылып ясалган: Сәйдәш ышнасы, Шаһи бабай ышнасы.

Кыр уртасында Мәмәт чардуганы бар. Ул изге урыннардан санала. Анда Мәмәт исемле кеше күмелгән. Яңгыр озак яумый торса, өлкәннәр шунда барып яңгыр сорый, дога укыйлар.

Республикабыз авыллары яннарында «Кыз тавы», «Кызлар уйный торган җир», «Кыз каласы», «Кала тау» дип йөртелә торган урыннар байтак. Шактый еракларга билгеле булган, барлыкка килүе турында халык телендә төрлечә сөйләнә торган «Кыз тавы»ның берсе Дәвеш кырыендагы калкулыкта урнашкан. Әлеге атаманың легендасы бар. Аның турында «Гыйса улы Әмәт» дип аталган риваятьтә сөйләнә. Аның кыскача эчтәлеге болай. Җанибәк ханның тугыз ир баласы була. Унынчы баласын да ул ир бала дип көтә. Кыз туса, хатыны Тайдулла ханымга баланы үтерергә әмер биреп, ауга китә. Унынчы бала булып кыз бала дөньяга килә. Хан хатыны бу баланы үтерми, ә олы улына тәрбиягә җибәрә. Кыз үсеп җиткәч аны Гыйса улы Әмәт алып кача. «Зөя тамагына барып, Идел якасында торды. Имди аны «Кыз тавы» диләр»,—дип языла бу риваятьтә.

## Дәүләки

Дәүләки авылы Апас районында, район үзәге Апас авылыннан 15 чакрымда, җирле үзидарә советы үзәге Биештән—4, Каратун тимер юл станциясеннән—3, Тәтештән 51 чакрым ераклыкта урнашкан.

Казан ханлыгы чорындагы авылларны исәпкә алган исемлектә Дәүләки авылы да теркәлгән. Д.А.Корсаков бастырып чыгарган белешмәдән күренгәнчә, Дәүләки авылында 3 дворовый татар кешесе, Иске Дәүләкидә йомышлы 33 татар, 2 керәшен татары, Яңа Дәүләкидә йомышлы 42 татар, 11керәшен татары көн иткән. А.Артемьев бастырып чыгарган, 1859 ел мәгълүматларын эченә алган белешмәдә күрсәтелгәнчә, Чирмешән ярына утырган Иске Дәүләки авылының 74 хуҗалыгында 221 ир-ат һәм 243 хатын-кыз көн иткән, мәчет эшләгән. Яңа Дәүләкинең 17 хуҗалыгында 77 ир-ат, 69 хатын-кыз яшәгән. К.П.Берстель белешмәсендә Дәүләки авылында 1003 татар яшәгәнлеге әйтелә. Дәүләки авылы янында археологлар соңгы Болгар—Алтын Урда чорына нисбәтле табылдык әйберләр билгеләгәннәр.

Олылар авыл оешу турында болай сөйли.

Авыл башта тау башына утырган булган. Ләкин тора-бара монда яшәү кыенлашкан. Авылга зур урман якын булган. Мал-туарны бүреләр буып киткәләгән. Өстәвенә, авыл янында су булмаган, бер-ике чишмә генә чыккан. Кинәшләшкәннәр дә, су буена килеп утырганнар. Чирмешән елгасы буена иң беренче Дәүләки исемле бай кеше йорт сала һәм көн итә башлый. Аның артыннан башка кешеләр дә килеп нигез коралар. Иске авыл урынында бары тик зират кына торып калган. Халык яңа урынны ярата һәм монда рәхәтләнеп көн итә башлый. Дәүләки исеменә нисбәтле рәвештә авылга Дәүләки исеме бирелгән.

Авылның элекке урынын халык Югары авыл дип йөртә. Андагы борынгы зират койма белән уратып алынган. Борынгы ташлары да бар. Халык бу зиратны Изгеләр зираты дип йөртә.

1943 елның декабрендә авыл халкы фронтка җибәрү өчен 83 пар оекбаш, 97 пар бияләй һ.б. киемнәрне район комиссиясенә тапшыра.

Дәүләки авылы Апас районының матур табигатьле кочагына утырган. Аны төрле яктан урманнар, кырлар, елгалар, калкулыклар уратып алган. Авылның нәкъ уртасыннан текә ярлы, мул сулы Чирмешән елгасы агып үтә.

Авылның көньягында Бола суы колхоз басуларын «Ялкын» колхозы басуларыннан аерып тора. Бола суы Зөягә килеп кушыла. Авылның төньягыннан көньяк-көнбатышка таба ике яклап яшеллеккә төренгән тимер юл сузылып китә. Бу юлдан беренче тапкыр 1943 елның 1 сентябрендә поездлар йөри башлаган.

*Дәвамы киләсе саннарда.*

# М

**МИҢНУЛЛИН** Фәрваз Мөхәммәдулла улы (5.8.1934, Арча р-ны Ишнарат а.—11.12.1994, Казан, туган авылында күмелә), әдәби тәнкыйтьче, ТАССР атказ. мәдәният хезмәткәре (1984). 1959 да Казан ун-тын тәмамлый. 1959-61, 1965-76 елларда «Казан утлары» ж-лында бүлек мөхәррире, 1977-84 елларда ТАССР Язучылар берлегендә, 1984тән Татар китап нәшриятендә матур әдәбият бүлеге мөдире, баш мөхәррир (1992-94) булып эшли. «Якты юллар» (1975), «Прозаның гражданлык йөзе» (1983), «Затлылык» (1989), «Балта явызлар кулында» (1994) исемле җыентыкларда агымдагы әдәби процесска анализ, Ә.Еники, Ф.Хөсни, Г.Әпсәләмов, А.Гыйләҗев, М.Мәһдиев, Р.Төхфәтуллин һ.б. язучыларның иҗади портреты бирелгән. М. иҗатына гражданлык хисе, язучы осталыгы үзенчәлеген күрсәтә белү хас. Русчадан татарчага Г.Уэллсның «Человек-невидимка» («Күренмәс кеше», 1979), Дж.Лондонның «Мартин Иден» (1982) һ.б. тәрҗемә итә.

Әдәб.: Галиуллин Т.Н. Тәнкыйть күгендәге йолдыз // Казан утлары. 2004. № 5; Әдипләребез: Биобиблиографик белешмәлек. К., 2009. Т.2.

*Т.Н.Галиуллин.*

**МИРЗАНОВ** Бәхтияр Гомәр улы (10.11.1892, Уфа губернасы Эстәрлетамак өязе Юрактау а.—17.7.1941, Уфа ш.), шагыйрь. 1910-14 елларда «Галия» мәдрәсәсендә укый, 1935 тә Башкорт авыл хуҗалыгы ин-тын тәмамлый. 1914 тә Казанга килә, «Сөембикә» ж-лы редакциясендә эшли. 1915-17 елларда Оренбург ш. яши, 1917-18—Сәмәркандта татар-үзбәк мәктәбендә укыта. 1920 дә Оренбургта политработниклар курсларын тәмамлаганнан соң Эстәрлетамакта БАССРның белем бирү халык комиссариаты инспекторы булып эшли. 1922 дән туган авылында балалар укыта, җир үлчәүче, зоотехник булып эшли. 1937 дән Уфада яши. Беренче шигырьләр һәм тәрҗемәләрен 1914-17 елларда «Аң», «Шура», «Сөембикә» ж-лларында, «Вакыт», «Тормыш», «Кояш» г-таларында һ.б. бастыра. М. иҗатына романтик мотивлар хас, автор төрле социаль һәм фәлсәфи мәсьәләләр күтәрә («Бәйрәм таңы», 1914; «Хөррият көннәрендә», 1917). «Җен туе», «Илче», «Инкыйлаб», «Исмагил» исемле поэмаларында шагыйрь җәмгыять кимчелекләрен тәнкыйтьли, хатын-кыз хокукларын яклый. «Кызыл чәчәкләр» (Эстәрлебаш, 1921) исемле шигъри җыентык, балаларга багышланган «Ак патша» (1921), «Кечкенә революционер» китаплары авторы.

Әдәб.: Башкорт әзәбияте: XX быуат башы. Поэзия. Өфө, 1983. 1 кит.; Татар шигърияте: XX гасыр башы. К., 2004.

*З.З.Рәмиев.*

**МИРХӘЙДӘРОВ** Рауль Мирсәет улы (17.11.1941, Актүбә өлкәсе, Мартук а.), язучы, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1999). Рус телендә яза. Ташкент политехн. ин-тын тәмамлый (1968). 1961-80 елларда төзелеш оешмаларында прораб, инженер булып эшли. 1990 елдан Мәскәүдә яши. «Самсон кечкенә станциясе» («Полустанок Самсона») исемле беренче хикәясе «Родники» (М., 1971) альманахында басылып чыга. М. иҗатын икегә бүлергә була. 1970-85 елларда ул кечкенә (хикәя, повесть) формаларда яза: «Ут-кош» («Жар-птица», 1971; «Оренбург шәле» («Оренбургский платок», 1978); «Безне онытмагыз» («Не забывайте нас», 1980) һ.б. Мәскәүдә басылып чыккан җыентыклар. Алдагы елларда ул масштаблырак әсәрләр тудыра. М.—кискен сюжетка корылган, детектив интригага нигезләнгән соц.-сәяси романнар авторы. Әсәрләр геройлары—төрле дәрәҗәдәге сәясәтчеләр, хакимияткә менеп утырып, ришвәтчелеккә бирелгән чиновниклар, «күләгә»дә яшәүчеләр. Криминал структуралар турындагы күпкырлы фактик материалны анализлау нәтиҗәсендә язылган романнар: «Җәяүле сәйран» («Пешие прогулки», М, 1988), «Кытай императорының охшаш кешесе» («Двойник китайского императора», М., 1989), «Пик масте» («Масть пиковая», М., 1990), «Үзем хөкем итәчәкмен» («Судить буду я», М., 1992) совет елларыннан соңгы болганчык еллар хроникасын тәшкил иткән тетралогиягә әверелде. Мәхәб-

*Дәвамы. 2005 елның 4нче саныннан басылып килә.*

бәткә багышланган «Иртәләгән сагыш» («Ранняя печаль», Днепропетровск, 1991) исемле романында язучының башлангыч чор иҗатында урын алган темалар, образлар үстерелә. «Һәр нәрсәгә—акчалата» («За всё наличными», М., 1997) романы «яңа руслар» тормышын бәян итә, хәзерге көн зур афёралары турында сөйли. М. прозасына архитектониканың күпкатлылыгы, жанрлар синтезы хас. Әсәрләренең бөтенесе диярлек татар теленә, күбесе инглиз, немец, француз, испан, венгр, чех, польша, грузин, казах, үзбәк телләренә тәрҗемә ителгән. 1997 дә Мартук ш. язучының музее ачылды.

Әсәр.: Собрание сочинений: В 4 т. М., 1992-93; Собрание сочинений: В 4 т. Днепропетровск, 1996.

Әдәб.: Мустафин Ш.С. Культуру восстановить труднее, чем экономику (Беседы с писателем Раулем Мир-Хайдаровым). К., 2007.

*Р.Р.Мусабәкова.*

**МИФТАХЕТДИНОВ** Альберт Вәли улы (11.5.1937, Уфа ш.—9.11.1991, Мәскәү, Магадан ш. җирләнгән), язучы. Рус телендә яза. 1959 да Киев ун-тын тәмамлаганнан соң Чукоткага килә, 1966 тан Магадан ш. яши. Анда телевидение студиясендә, «Советская Чукотка», «Магаданская правда» г-талары редакциясендә эшли. 1973 дән Магадан язучылары оешмасының җаваплы сәркәтибе. «Чукотка белән очрашу» («Встреча с Чукоткой»), «Үткел» («Перевал»), «Дәшмәү яры» («Берег молчания») телефильмнар сценарие авторы. «Одиссей турында сөйлә» («Расскажи про Одиссея», Магадан, 1967), «Бик бәләкәй җир шары» («Очень маленький земной шар», М., 1972), «Кит турындагы серле бер эш» («Совершенно секретное дело о ките», Магадан, 1983), «Поляр сәяхәтләренең законы» («Закон полярных путешествий», Магадан, 1986), «Кит турында эш» («Дело о ките», М., 1994). М. Чукотка турында яза, аның геройлары—геологлар, каюрлар, сунарчылар. Хикәя һәм повестьларында язучы яшәүнең катлаулы мәсьәләләре турында уйлана: кем ул кеше, нәрсә ул яшәү, үлем? Аның китаплары эстон, поляк, болгар, испан, инглиз, француз телләренә тәрҗемә ителгән. «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

*Р.Р.Мусабәкова.*

**МОДЕРНИЗМ**, 20 йөз башы әдәбияты һәм сәнгатендәге «сул» агымнарның (кубизм, сюрреализм, футуризм, экспрессионизм, символизм, орфизм, фовизм, пуризм h.б.) барысын берләштергән иҗат юнәлеше. Киңрәк мәгънәдә—19 йөз—20 йөз уртасы чоры сәнгатенең тарихи чоры.

Әдәби М.нын төп үзенчәлекләре—классик сәнгатьнең гармониягә ия булган формаларына каршы чыгып, яңа формаларга тудырырга омтылу, ассызыкланган шартлылык, чынбарлыкны сәнгати дәрәҗәдә бозып үзгәртү, мәгънәләр б-н уйнау, дөнья һәм кеше турында төп, бәхәссез дөреслекнең (хакыйкать) юклыгын раслау. М.ның төп темалары—шәхеснең яшәештәге урынын идея һәм сәнгати чаралар ярдәмендә эзләү һәм бу мәсьәләне гаклый хәл итүгә ышанычның югалуы. М. агымнары сәнгатькә яшәешнең яшерен серләренә ишек ача торган гыйлем итеп карый. Тормышны кабул итү, матурлыкны изгеләштерү модернның төп сыйфатына әйләнә.

Модернистик сурәт тудыру омтылышлары татар әдәбиятына 20 йөз башында керә башлый. Модернистик тәҗрибәләрне үзләштерүгә һәм иҗади төшенүгә татар әдәбиятынын тамырлары шәрыкъка барып тоташу ярдәм итә. Ш.у. фәлсәфи-эстетик нигезләре символизмга һәм экзистенциаль фәлсәфәгә якын буларак суфичылык мәдәнияте традицияләре модернизм б-н аваздаш тоела. Модернистик стильләрнең реализм һәм романтизм б-н синтезлашуы аеруча Ф.Әмирхан, Ш.Камал, Н.Думави, Г.Ибраһимов, С.Рәмиев, Ш.Бабич h.б. иҗатында үзен нык сиздерә.

1906-08 елларда Дәрдемәнд, 1920-30 елларда Һ.Такташ иҗатында символизмның фәлсәфәсе һәм эстетикасы оеша башлый. 1910 елларда проза һәм лироэпикада реалистик һәм мифологик, романтик һәм мифологик, шартлы-лирик һәм тарихи катламнарның мәдәни синтезы барлыкка килә. Бу синтезның үзәген символ-идея, яки символ-проблема тәшкил итә (Ф.Әмирханның «Татар кызы», М.Хәнәфинең «Айсылу», Б.Мансурның «Татар егете», Г.Рәхимнең «Хан мәчетендә», М.Гафуриның «Бу кемнең кабере?», «Бер чәчәкнең наләсе» әсәрләре). Татар язучыларын аеруча экзистенциализм фәлсәфәсе (кеше табигатенең камил булмавы, төп мотив буларак, җир тормышының фанилыгын раслый) үзенә тарта. М.Гафуриның «Болгар кызы Айсылу», Ф.Әмирханның «Бер хәрабәдә», М.Хәнәфинең «Милләтем», «Тегеннән», «Гөл бакчасында», Г.Газизнең «Бер хыял» әсәрләрендә тормыш куркыныч һәм акылдан язган «кара көчләр патшалыгы» кебек тасвирлана. Г.Газизнең «Юлдаш эзләгәндә», М.Хәнәфинең «Кайдан? Кайда!», Г.Насрыйның «Мазарстанда» хикәяләрендә кеше тормышы бертуктаусыз көнкүреш ваклыкларыннан качу итеп аңлатыла. Саф импрессионистик характердагы хикәяләр дә языла (кара: Импрессионизм), мәсәлән, Г.Исхакыйның «Бер манзара», Ф. Вәли-

евнең «Көймәдә» һ.б. 20 йөз башында экспрессионизм С.Рәмиев, Н.Думави, Б.Мирзанов һ.б. лирикасы һәм лиро-эпикасында да күзәтелә башлый. 1920-30 елларда Һ.Такташ, К.Нәҗми, Г.Кутуй, Н.Исәнбәт һ.б. иҗатларында исә аеруча зур үсеш ала. Рус әдәбиятындагы кебек артык көчле тәэсир итәрлек сәнгать б-н мавыгу 1920 елларда футуризм (Г.Кутуй) һәм имажинизмны (К.Нәҗми) барлыкка китерде. 1930 елларда татар әдәбиятында М. үсеше озакка тоткарлана. 1980 нче еллардан башлап ул янадан активлаша, постмодернизм (Ф.Бәйрәмова, З.Хәким, Г.Гыйльманов, Н.Гыйматдинова, М.Гыйләжев һ.б.) элементлары б-н баетыла. Сынлы сәнгатьтә М. төп үзенчәлекләре— әсәрләрдә тормышны соңгы чиккә кадәр җиткереп каралту яки тормышны үзенә охшатып кабатлаудан тулысынча баш тарту. Аларда, гадәттәгечә, басым сәнгати формага ясала. Форма исә сәнгать әсәренен асылы итеп кабул ителә һәм аның эчтәлегенә тәнгәл була. Футуризм, конструктивизм, абстракт сәнгать стиль үзенчәлекләрен үз эченә алган авангард сәнгатьне модернистик сәнгать дип карап, М.ны еш кына авангардизмга тиңлиләр.


Татарстан сынлы сәнгатендә кайбер модернистик агымнарның (кубофутуризм, экспрессионизм, абстракционизм) сыйфатлары 1910 еллар ахырында—1920 еллар башында «Көнбагыш» («Подсолнечник») (К.К.Чеботарёв, А.Г.Платунова, И.А.Никитин, Д.П.Мощевитин, И.И.Алпатов, Василий Вера (В.Попов), Н.Диомиди (Н.И.Михайлов), П.М.Зотов, Г.И.Потапов, Г.П.Соловьёв-Озеров, Д.М.Фёдоров) төркеме рәссамнары һәм 1920-23 елларда эшләп килгән «Җайдак» («Всадник») графиклар төркеме иҗатларында барлыкка килә. Ике төркем дә 1920 нче елларда С.С.Фёдоров һәм П.А.Мансуров абстракцияле рәсем сәнгатен укыткан АРХУТЕМАСта (Казан архитектура-сәнгати һөнәрханәләр, 1918-25) оеша. Авангард сәнгатенең башында бу чорда ш.у. ТатЛЕФ (К.К.Чеботарёв, А.Г.Платунова, М.В.Барашов, С.Хромов, А.Н.Кашаев) рәссамнары да була. ТатЛЕВка татар мәдәнияте эшлеклеләреннән торган «Сулф» («Сул фронт») төркеме дә керә; оештыручыларның берсе—ТатЛЕФның президиум әгъзасы, татар полиграфикасына нигез салучы Ф.Ш.Таһиров була. Әсәрләрендә конструктивизм алымнарын (фотомонтаж) файдаланып, татар авангарды тарихында ул якты эз калдыра. Алга таба, 1960 еллар урталарына кадәр Татарстан сынлы сәнгатендә модернистик юнәлешләр үсми. 1960 елларда модернистик юнәлешне сынлы сәнгатьтә А.А.Аникеёнок, Р.А.Килдебәков дәвам иттерә. 1970 елларда экспрессионизм чалымнары В.П.Аршинов, Н.У.Әлмиев графикасында гәүдәләнеш таба; И.К.Зарипов иҗатында халык сәнгате традицияләренә модернистик рәвештә янадан төшенү (неопримитивизм) күзәтелә. 1990 елларда аерым модернистик агымнар киңрәк таралыш ала. Абстракционизм традицияләре эзлекле рәвештә З.М.Миннеәхмәтов (Алабуга ш.), Р.К.Нәфыйков (Казан), сюрреализм—В.Я.Акимов, Ю.Г.Свинин (Чаллы ш.) иҗатларында чагыла. Казан рәссамнары Е.Г.Голубцов, А.И.Дорофеев, А.М.Артамонов, И.А.Хәсәнов, И.В.Гыймранов, А.Р.Ильясова, Р.А.Салихов әсәрләрендә төрле модернистик агымнарның стиль үзенчәлекләре постмодернизм контекстында күзәтелә.

Әд.: Сарабьянов Д.В. Стиль модерн: Истоки. История. Проблемы. М., 1989; Саяпова А.М. Дардменд и проблема символизма в татарской литературе начала XX века. К., 1998; Теория литературы. Литературный процесс. М., 2001. Т.4; Нигматуллина Ю.Г. «Запоздалый модернизм» в татарской литературе и изобразительном искусстве. К., 2002; АРХУМАС: Казанский авангард 1920-х. М., 2005; Заһидуллина Д.Ф. Модернизм һәм XX йөз башы татар прозасы. К., 2003.

*Д.Ф.Заһидуллина,*
*Г.Р.Фәйзрахманова.*

*Дәвамы киләсе саннарда.*

# «Казан утлары» архивыннан



*Бу айда Корбан гаете бәйрәме булып узды. Хаҗ кылучылар намазда. Мәккә шәһәре.*



*Язучы һәм галим Эдуард Касыймов (1930-1986).*



*Быел күренекле режиссер һәм педагог Шириаздан Сарымсаковның тууына 100 ел тулды. Ш.Сарымсаков (уртада) Казан мәдәният институты (хәзерге Казан мәдәният һәм сәнгать академиясе) студентлары һәм хезмәткәрләре белән. 1984 ел.*



*Язучылар Тукайның һәйкәл-бюсты (Б.Урманче эше) янында. Уңнан сулга—Мөхәммәт Садри, Зәки Нури, Нәби Дәүли, Равил Фәйзуллин. Матбугат йорты (Бауман, 19) бинасы. 1974 ел.*



*Озак еллар "Казан утлары" журналында эшләгән каләмдәшебез, шагыйрь Рәдиф Гаташ.*



*Язучы Гомәр Бәширов һәм композитор Сара Садыйкова. "Җидегән чишмә" кичәсендә. Түбән Кама. 1984 ел.*

*Бәләкәйләр*

# БӘЛӘКӘЙ РӨСТӘМ

## Кайдадыр сугыш иде

Безнең балачак тормышыбыз бүгенге балалар тормышыннан бөтенләй үзгә иде. Чөнки ул сугыш елларына туры килде. Шәһәр тормышының үз кыенлыклары булгандыр. Ә авылларда, әйтик, мин яшәгән авылда, кешеләр дә ач, маллар да ач иде. Әтиләребез сугышта, әниләребез көне-төне эштә. Без балалар ни теләсәк шуны кыланып яшибез. Менә тамак ач булу гына жанны кыйный. Бодай басуы саргайгач, хәлебез жинеләя, басуга кереп утырабыз да башак уып итәкләребезгә бодай тутырабыз. Кырда учак ягып, аны табада кыздырып ашый башлыйбыз. Басуга керү куркыныч, колхоз бригадиры камчы тотып, атка атланып басу карап йөри. Безне күрсә, камчысы безнең аркага эләгә. Ул чакларда ашлык өлгергәч аны урып ындыр дигән урынга ташып сугалар иде. Әнкәйләр ашлык суга башлагач, безнең хәлләр тагы да яхшыра, алар учак ягып, бодайны мулданрак кыздырып безне ашаталар иде. Шунысы яман, бодайны кесәгә салып өйгә алып кайтырга ярамый, ә безнең өйдә дә ашыйсы килә.



## Безнең Наил башлы малай

Әнә Наилнең әнисе итәгенә бодай салып кайтырга чыккан да, юлда тикшереп, бодаен табып, үзен төрмәгә яптылар. Наил авыл карамагында калды. Торуын ул бездә торды, әнкәй аны безгә алып кайтты. Наил бик уңган малай, маллар караша, бакча эшләрендә дә булыша.

Минем әткәй ни өчендер чормага шактый күп мал тиресе элгән, озак торып хәзер алар калай кебек каткан. Килде бит Наилнең башына бер уй:

—Без аларны ашыйк!—ди.

—Ничек?

—Йоннарын утта өтик тә, тиресен пешерик,—ди. Без шулай эшләдек тә. Тиреләрне ваграк кисәкләргә турап, сындырып, йоннарын утта яндырып, тиресен пешерә башладык. Ул ашның тәмлелеге әле дә хәтеремдә. Бик күп кафеларда, рестораннарда ашаганым бар, андый да тәмле аш ашаганым булмады кебек.

Ул елларда кешеләр генә түгел, маллар да ач иде. Бигрәк тә колхоз фермасындагы сыерлар ашарга сорап туктаусыз мөгриләр. Ул чакта сыерлар арасына чиләк-чиләк

зурлыгындагы эре-эре тоз кисәкләре куялар иде.

Ни өчен куялар дигән сорауга җавапны да Наил уйлап тапты:

—Күп тоз ялагач, күп итеп су эчәләр. Эчләре тулгач, ашауны онытып торалар,—диде. Безгә дә тоз яларга кинәш итте. Без ул тозларны ялап карадык. Ләкин безнең алар арасында буталып, тозларын ялап йөрү сыерларга ошамады.

## Үгез мине куып җитә алмады

Бер юньсез үгез мине фермадан куып ук чыгарды. Әй куды, әй чаптым. Киртә өстенә мендем дә, ферма йортыннан урам якка сикердем. Алданган үгез киртәләрне җимереп, мөгезенә киртә элеп урам якка чыкканда мин инде еракта, урамдагы каз төркемнәрен туздырып өйгә элдертә идем. Мин бүтән тоз яларга керми башладым. Ул чакта кибеттә йомырка кабул итәләр иде. Бер йомырка бирсәң, кибетче Котдус абзый өстәлдә яткан иске китаптан бер бит ертып ала да, шуңа бер уч тозлы кильки төреп бирә. Без малайлар шулай кесәләргә кильки тутырып елга буендагы чишмәгә чабабыз. Монда табигать матур, саф һава, яшеллек. Килькие дә нинди бит! Ялтырашып торалар—аша да аша гына. Бу инде сыерлар аяк арасында буталып тоз ялау түгел. Чыннан да, тозлы кильки ашап, күп кенә су эчкәч, ашыйсы килү бераз басыла сыман икән.

## Ур–ра! Әткәйләр сугыштан кайта башлады

Беренче булып култык таягына таянып Равилнең әтисе Котдус абзый кайтты, кибетче булып эшли башлады. Икенче булып сул кулы кәкрәеп каткан Сәгыйть абзый кайтты, ул ферма мөдире булып эшли башлады. Өченче булып Туликның әтисе Колбин абзый кайтты. Кәтәм—минем әткәй юк та юк. Наилнең әтисе дә, әнисе дә кайтмыйлар. Ул да аларны бик көтә.



## Колбин абзый мукшы иде, күп татардан яхшы иде

Колбин абзый сау-сәламәт кайткан, авылда шофер булып эшли башлады. Ул ындырда безнең әнкәйләр суккан ашлыкны машинасы белән авыл амбарына ташый. Кыр юлында Колбин абзый, әлбәттә, безне очрата, машинасын туктата, көрәк хәтле куллары белән безне берәм-берәм күтәрә:

—Татар малай, батыр малай!—дип безнең арт якларга шап-шоп сугып, машина әрҗәсендәге бодай өстенә ташлый:

—Кесәләрегезгә бодай тутырыгыз, тизрәк тутырыгыз!—ди.—Инде, әйдә, кайсыгыз төшә?—ди. Берәм-берәм күтәреп безне кыр юлына бастыра. Үзе бер унайдан:

—Малай матур, күлмәк кыска, корсак зур!—дип, корсакларыбызга да шап-шоп суккалап ала.—Сез әнә тегендәрәк чокырда мине көтегез, монда авыл бик якын, председатель күрер!—ди. Без кесәләребезне өйдә бушатып, чокырга ашыгабыз. Тиздән Колбин абзыйның ындырдан авылга кайтып килүче яшел машинасы күренә. Тагын:

—Малай матур, күлмәк кыска, корсак зур!—Һәм шап-шоп башлана. Безнең янда кызлар булганда, Колбин абзый аларның яулыгына бераз бодай төреп бирә.

## Безнең дә ипи ашаган чак булды

Без хәзерге балалар кебек теләсә кайсы вакытта авыз тутырып ипи ашый алмый идек шул. Шулай да ипи ашаган чак булды. Җиләк-җимеш өлгергәч, йә җиләк, йә шомырт, йә карлыган җыеп, аны сатарга стансыга барабыз. Ул безнең авылдан

унбиш чакрым читтә. Анда барып житкәнче төш вакыты житә. Узучылар вагоннардан төшеп, безнең алып килгән җиләк-җимешләребезне сатып алып бетергәнче кич тә була. Җыелган акчаларыбызга һәркайсыбыз ипи сатып ала. Менә шуннан соң утырып, авыз тутырып ипи ашыйбыз. Инде унбиш чакрым араны кире кайтырга кирәк. Кайтыр юлыбыз—олы юл буенда, бераз куркабыз да. Безнең авыл аша узучы машиналар безне утыртмыйлар, һәр шофер мукшы Колбин абзый кебек яхшы түгел шул. Юлыбызның урман аша узасы урыннары да бар. Наил алдан бара, ул курыкмый: «Әтием дә юк, әнием дә юк, мине бүре ашаса да ярый,—ди.—Ипи тутырган капчыгымны гына асып китәрсез, кызларга бирерсез»,—ди.

Без кайтыр юлга кузгалуга караңгы төшә башлый. Төнлә юлыбыз мазарат кырыеннан да уза (урыс зиратын безнең якта ни өчендер «мазарат» диләр иде). Безнең якта, житмәсә, шундый риваять бар. Имеш кайчандыр бу юлда төнлә мазараттан чыгып бер абзыйны шунда сөйрәп кертеп җеннәр кыйнаганнар, абзый тангача кычкырып ярдәм сораган. Җеннәр абзыйга типкәлиләр, өстенә менеп бииләр дә: «Бүген төнлә учак ягып сине кыздырып ашыйбыз, без кеше итен яратабыз»,—диләр икән. Бервакыт абзый мазараттан чыгып кача алган, әмма җеннәр аны куып житкәннәр дә, кире мазаратка кертеп, чишендереп, тәре баганасына бәйләп куйганнар. Инде җен балалары абзыйга таяклары белән дә төрткәли, суккалый башлаганнар. Аны кемнедер күмәргә килүче урыслар гына коткарган. Авылына кайткач, абзыйны танымый торалар икән, чөнки чәче ап-ак, тәннәре күгәреп беткән... Тагын әле урманнан узучы өч кешене бүреләр ашаган, юл буенда аяк киемнәре генә торып калган дигән сүз дә бар. Кыскасы, куркырлык та шул.

Без урманны чыккач, мукшы авылы Пүләй башлана. Инде Касады елгасы аша салынган ике күперне узасы да, аннан безнең Йолдыз авылы. Арабызда Такый исемле малай бар иде, ул бик оста җырлый, матур тавышы әллә кайларга яңгырый. Пүләйне узуга Такый авыл көенә җырлап җибәрә:

*Сандугачлар да сайрамый, әллә инде көз микән?*
*Була диләр бәхетсезләр, әллә шулар без микән?*

Бу җыр безнең исән-сау кайтып житүне бөтен авылга хәбәр итә. Касады елгасы бу җирдә икегә тармакланып уза. Бер тармагы Пүләй ягыннан, икенче тармагы безнең авыл—«Йолдыз» ягыннан уза. Без кайтып килгәнне ишетеп өлгергән кызлар, Пүләт күперенә үк килеп, безне каршы ала. Авылда күпләр безне малай-шалайга санаса да, без үзебезне инде егетләргә санап йөри идек, чөнки колхоз эшләренә дә катнашабыз. Кичке клубны гөрләтеп без уйныйбыз. Уеннардан соң кызлар озаткалаган да бар. Бездәге кичке уеннарга хәтта Пүләйдән мукшы кызлары да килә. Пүләй безгә чакрым ярым ераклыкта. Әлбәттә инде, Пүләй кызларын да озатып куябыз.

Безне каршыларга килгән кызлар без алып кайткан ипиләрне алалар да, чыр-чу килеп Йолдыз күпере ягына—авылга йөгерәләр. Хәзер алар бер якты өйгә керәләр дә, бирегә килмәгән кызларга да өлеш чыгарып, ипиләрен тигезләп бүләләр инде.

Менә шулай үтте безнең балачак.

**Рөстәм МИНГАЛИМ**



*Таныш булыйк:*
*Хыялый кызларның берсе*
*Мин буламын, Флүзә.*
*Хыял канатлары мине*
*Әллә кайларда йөртә.*
*Кешеләрдә яратам мин*
*Ихласлык, гадилекне.*
*Күп нәрсәдән өстен күрәм*
*Чын дуслык, сабырлыкны.*
*Бер-береңне аңлап яшәү*
*Шундый рәхәт, күңелле,*
*Кешегә яхшылык эшләү*
*Үзе бәхет түгелме?!!*

Мин, Нәҗмиева Флүзә Рамил кызы, 1995 елның 31 маенда Апас районының Багыш авылында туганмын. Без гаиләдә алты кеше: дәү әтием, дәү әнием, әтием, әнием, энем. Әтием—игенче, әнием—укытучы. Энем Раил—Багыш башлангыч мәктәбенең 4нче сыйныфында, үзем—Чирмешән урта мәктәбенең 9нчы сыйныфында белем алабыз. Мин туган авылымны һәм мәктәбемне бик яратам. Дус һәм ярдәмчел гаиләм белән горурланам. Укытучыларымны хөрмәт итәм.

## Әниләрдә—әниләр дә

**Назлы караш—әниләрдә,**
**Җылы кочак—әниләрдә,**
**Тәмле сүзләр—әниләрдә,**
**Йомшак куллар—әниләрдә.**
**Чаптар йөрәк—әниләрдә,**
**Җылы сүзләр, назлы караш**
**Көтә бездән әниләр дә!**

## Сине көтәм...

**Тагын бер көн бушка узып китте.**
**Эзлим сине, ләкин таба алмыйм.**
**Айлы кичтә ярлар очраша,**
**Карлы юлдан ялгыз гына атлыйм.**

**Айның нуры—кояшныкы кебек,**
**Парлар саный күктән йолдызлар.**
**Йолдыз атылганда теләк телим,**
**Чынга ашсын иде бу хыял!**

## Нишләргә?..

**Көндезләрен сине өндә күрәм,**
**Ә төннәрен күрәм төшемдә.**
**Сине уйлап көнем, төнем үтә**
**Нишләргә дә белми... Нишләргә?**

**Төшләремдә, бәгърем, без гел бергә.**
**Ә өнемдә кайда йөрисең?**
**Сине күрер өчен яшим бит мин,**
**Тик син генә һаман килмисең.**

### Нигә шулай, Вакыт?

**Әйтерсең лә коләсең син, Вакыт:**
**Ашыкканда син гел—чабасың.**
**Ялгыз моңланганда, туктап калып,**
**Ник газапка мине саласың?**

---

*«Хикәя яза аласызмы?»*

***9нчы санда шундый бәйгегә йомгак ясап, аның яңа «сериясен» игълан иткән идек. Беренче хикәяләр килә башлады инде…***

## ОЧРАШУ

***Айратның бармаклары шуып китте һәм Фәридәгә дигән СМС ялгыш Миләүшәгә «очты»:*** «Мин бер сәгатьтән килеп житәм. Чәенне куя тор».

Аптырашка калган Миләүшә күзен дивар буйлап йөгертте. Карашы стена сәгатенә туры килгәч, ул дертләп куйды—Айрат ярты сәгатьтән килеп житәчәк бит! Кыз ашыга-ашыга бүлмәне жыештырырга кереште. Озын борынлы чәйнеге дә плитәгә кукраеп менеп утырды.

***

Айрат атлаган жиреннән шып туктап калды.

—Йә, Хода, нишләдем мин?—анын бармак очларына кадәр тирләп чыкты.

Ул кулындагы кызыл розаны күкрәгенә кыскан килеш тирән уйга батты.

Бүген ул Фәридәне мәхәббәт турындагы бик яхшы кинога чакырмакчы иде. Түш кесәсен сыйпап алды—аны Фәридә белән якынайтырга тиешле кәгазьләр көлешеп куйды. Кинодан чыккач, Айрат аны тулай торакка озатырга һәм үзенең гашыйк булуы турында әйтергә тиеш иде!

—Хәзер Фәриданә кисәтмичә килеп керәмме инде? Барып чыкмады бу!

Айрат күнелсезләнеп кулын селтәде. Кинәт туган уеннан түбән салынган башы күтәрелде:

—Башта Миләүшәгә кереп бер сәгать сөйләшеп утырам. Аннан Фәридә белән кинога барам!

Ул адымнарын тизләтеп тулай торакка таба атлады. Авыр ишекне елатып ачкан мизгелдә Фәридәгә СМС юллады: «Мин бер сәгатьтән килеп житәм. Чәенне куя тор». Бу юлы Айратның бармаклары уяу иде.

***

Фәридә, үзенә урын таба алмыйча, ялгызы бүлмәдә әрле-бирле йөренде. Бүген алар университеттан Айрат белән бергә чыктылар.

—Шундый матур апрель киченен кадерен белеп каласы иде,—Айратның үзалдына мыгырдангандай сөйләнүеннән Фәридәнең колаклары кызышты.

«Нәрсә әйтергә теләде икән Айрат?»—тулай торакка кайтканнан бирле Фәридә шул сүзләрне кат-кат хәтерендә яңартты. Инде тәрәзәләргә кичке энгер-менгернең авыр шәүләсе сарылды—Айраттан исә бернинди хәбәр-хәтер юк. Фәридә инде ничәнче тапкыр кулына лекция дәфтәрен алган иде—телефоны җырлап җибәрде. Кыз күнеленә тулган шатлыкны эченә сыйдыра алмый сөенеп кычкырды: Айраттан! Киләм дигән!

Әле генә борынын салындырып утырган кызны җен алыштырган диярсең: хәзер ул күңелле көй көйләп, аяк очларында бии-бии Айратны каршыларга әзерләнә.

— Ahh!—чәй пакетының бушлыгын күреп, Фәридәнең йөрәге ярыла язды.—Нишлим? Хурлыкка калам бит. Чәе генә дә юк икән дисә...

Менә ишек ачылыр да аннан Айрат килеп керер кебек тоелды. Фәридә күрше кызларга йөгерде. Тик бүлмәләре бикле иде. Төркемдәше Данияненң ишек тоткасын кат-кат тартты—ачылмады.

—Миләүшә!—баш миендә бу уй яралып өлгергән мизгелдә үк аның аяклары коридорның икенче башына йөгерә иде...

...Кара-каршы утырып, көлешә-көлешә чәй эчкән Айрат белән Миләүшәне күргәч, кыз үз күзенә ышанмады.

—Айрат?!

Әле генә канәгать елмаеп утырган егет Фәридәнең үзенә төбәлгән гаҗәпләнү катыш усал карашыннан кып-кызыл булып башын иде. Егет кулларына урын таба алмый угаланды: әле башын сыйпады, аягына суккалады, спорт кәчтүменең изүен чишеп җибәрде...

Шулчак Айратның спорт кәчтүме эченә яшеренгән роза баш калкытты. Розаның таҗлары оялудан комачтай кызарып, нидер әйтергә теләгәндәй Фәридәгә күз кысты. Тик кыз чәчкәнең ымын аңламады: кырт борылып бүлмәдән чыгып йөгерде. Ишек шапылдап ябылган мизгелдә Айратның кесәсендәге телефон көчле бармакларның кыскалавыннан авыр ыңгырашты һәм шулчак аның канлы яшьләре кебек идәнгә роза таҗлары коелды.

**Госман МИФТАХОВ,**
*Казан*

---

## «ЯШЬ РОЗОЧКА»

***Укытучы егет класска килеп керү белән унберенченең кызлары бердәм хихылдаша башладылар...***

Ә бер атна элек Алсу мәктәптән авызын бүлтәйтеп кайтып кергән иде. Керү белән аяк киемнәрен як-якка ыргытты да, диванга йөзтүбән бөкләнеп ятты. Кызының авыр холкына күнеккән әнисе сак кына янына килеп:

—Кызым, ашны җылыттым, әйдә, аша,—диде, аркасыннан сөеп.

Ә Алсу керпе кебек энәләрен чыгарды да:

—Мин тук, теләмим,—диде.

—И, хәзер мәктәптә шулай тамак туйдырып кайтарып җибәрәләрмени? Элек бер сарык ашап бетерерлек булып кайта идең, ә бүген тук дигән буласың.

Әнисе Алсуның сүзләрен гел шулай шаяртып, авырга алмаска тырыша. Алсу бу юлы да түзмәде, көлеп җибәрде.

—Әйтәсең дә инде, әни. Сарык, имеш... Алай түгел лә!

—Менә елмайдың да. Яле, сөйлә, ни булды?

—Эчем поша, Роза Минебаевна пенсиягә чыгам ди. Минем урынга яшь укытучы апагыз килер ди. Имеш, аның вакыты житкән.

—Кызым, өлкән бит инде ул,арыйдыр да, аннан, яшьләргә дә урын бирергә кирәк бит.

Алсуга бу сүзләр бер дә ошамады. Ул пыр тузынып урамга чыгып китте. Йөрәге шартларга җыенган вулкан сыман кайный иде. Ташып торган ачуны кая куярга белмәде. Ничек шулай инде?!! Ничек яраткан укытучысы аларны ташлап, хыянәт итә ала инде!?

Алсу авылга якын чишмә юлына китте.

Ярсып йөгереп килде ул чишмәгә. Анда чиләкләргә су тутырып торган егетне күргәч, сискәнеп китте. Егет тә сагайды, эндәшергә кыймыйча торды. Алсу нишләргә белмәде, кире борылыргамы? Юк, нәрсә, әллә егетләрдән куркып торамы? Бу Алсуның яраткан урыны, үзе китсен. Чиләкләре дә тулып килә инде. Әнә Алсу эндәшмичә генә читкә карап басты. Ә егет сак кына су тутыра. Алсу эчтән генә уйлады, хәзер үзе дәшәр, чибәр кыз нишләп йөри,син миңа ошыйсың, дияр һәм шуның ише әкиятләр сөйләр. Ләкин егет сүз башларга ашыкмады. Бигрәк чибәр, каһәр! Чәче кара, буй-сыны да килешеп тора. Әллә ничә кызның башын әйләндергәндер инде. Берәрсенә кунакка кайткандыр. Егет чиләкләрен тутырды да, тактадан сак кына чыгып:

—Иплә кенә керегез, такта черегән, ахры,—диде. Алсу дәшмәде. Ләкин чибәр егетнең аңа дәшүенә ул бик шатланды, хәтта, үзе дә сизмәстән, бик матур итеп елмаеп та куйды. Егет киткәч, туйганчы су эчте,чишмә челтерәвенә кушылып җырлады. Кояш та ничектер аеруча матур яктырта, җил дә назлап кына биттән сыйпый сыман иде. Беренче мәртәбә ул егет заты турында ачу белән түгел, ниндидер назлылык, татлылык белән уйлады.

Шул егетне күрмәмме диеп көн дә чишмәгә йөри башлады ул. Егет кенә нишләптер күренмәде. Тагын дөнья ничектер соры, усал, коры булып калды. Житмәсә, Роза апалары да бүген соңгы көн күрешүләрен хәбәр итте.

—Сезнең хәзер яшь Роза апагыз булыр,—диде ул шаяртып, күз яшьләрен күрсәтергә теләмичә.

Укучылар бик моңсу, теләр-теләмәс кенә саубуллашып, урамга чыктылар, әйтерсең, муеннарына таш элеп куйганнар. Алсу гына, кышкы усал буран кебек дулап, чәчрәп чыкты:

—Минем идея бар. Әйдәгез, иртәгә «яшь Розочканы» урынына утыртабыз. Дөресрәге, кнопкага.

—О-О-О, шәп идея. Әйдә, күрсәтик әле күрмәгәнен. Үзе теләп килгән бит. Менә карарбыз, безгә күпме чыдар икән.

Икенче көнне Алсу, ниндидер бик тәмле әйбер ашыйсы килгән кеше кебек, мәктәпкә иртүк китте. Дуслары да анда иде инде. Аны гына көтәләр икән. Кнопка да әзер, житмәсә, урындыкның бер тәпиен дә борып куйганнар. «Яшь Роза» апаны ныклы каршы алу көтә. Кыңгырау шылтырагач, сыйныф тын калды. Ишекләр сак кына ачылып китте һәм класска... укытучы егет килеп керде. Кызлар менә шунда хихылдаша башладылар инде ул. Егет исә, мөлаем гына елмаеп:

—Исәнмесез, балалар! Мин сезнең яна рус теле укытучыгыз Рамил Әнвәрович булам,—диде.

Бу сыйныф турында алдан барысын да белгән Рамил Әнвәрович бер урындыкка, бер Алсуга елмаеп карап торды. Яшь кыз, йөрәк ярсуын баса алмыйча, сыйныфтан көчле давыл булып очып чыгып китте...

**Ранилә ГЫЙЛЬМАНОВА,**
*Алабуга—Әгерҗе.*

# УЛ АНЫ ОЧРАТТЫ...

***Алар аерылышып, инде елыйсы еланып, бер-берсе турында яманы да, яхшысы да сөйләнеп, онытылып бетте дигәндә ул Аны янәдән очратты.***

Очратты да диеп булмас, дөресрәге, ул аны күреп алды.

Гадәттәгечә, эшенә бик иртә килде Илһам. Өстендәге киемнәрен тиз генә алыштырды да, аскы катка төште. Кызыксынып, үзе эшләгән кибетнең зур пыяла тәрәзәсе янына барып басты.

Иртәләрен кибет каршындагы тукталышны күзәтергә ярата ул. Кызык бит. Ниләр генә юк анда. Үрнәк алырлыгына сокланып, гыйбрәт алырлыгына рәнҗеп карый Илһам.

Ә бүген ул Аны күрде. Башта үз күзенә ышанмыйчарак торса да, егет аны шундук таныды. Йа, Ходам, бу ул бит, ул—аның Тансылуы. Бер ел элек югалткан мәхәббәте.

Кыз аңа арты белән тора иде. Ялгышмыймы соң егет? Юк, ничек ялгыша алсын ди. Ул аны мең, юк, миллион кыз арасыннан да танып алыр иде.

Тансылуның гына чәчләре шулай аеруча матур итеп дулкынланып тора.

Тансылу гына ак төсне ярата һәм һәрвакыт актан киенә.

Ә аның күзләре? Алар шундый жанлы. Кыз үзенең күңелдәгесен яшерә алмыйча азапланганын әле дә хәтерли егет. Шул коңгырт күзләр Илһамга сокланып та, шелтәләп тә, яратып та багалар иде бит. Их, бер генә тапкыр булса да карыйсы иде аларга.

Кыз, нәрсәдер сизенгәндәй, артына борылды. Карашын кибет тәрәзәсенә юнәлтте. Үз шәүләсенә сокланып, чәчен төзәткәннән соң, егетне күреп алды.

Илһам каушап калды. Әле генә кызның борылуын тели иде түгелме соң ул? Ә хәзер? Ник шулкадәр дулкынлана? Әллә һаман да ярата инде? Бәлки, яратадыр да...

Егет сизелер-сизелмәс кенә ияк кагып, кызга сәлам бирде. Тансылу да аны таныды бугай. Ихлас елмайды.

Ә хәзер нишләргә? Күптән күрергә хыялланып йөргән кешесен шулай җиңел генә җибәрә алмый бит инде ул. Әллә тынычлана башлаган җанны кабат яраламаска инде? Юк, ни булса да булыр, барыбер нидер эшләргә кирәк.

Шулвакыт Илһамның зиһенен бер уй яктыртып үтте. Тәрәзәнең парлана башлаган башына барып, егет пыялага чәчәк рәсеме ясады. Ишарә белән генә кызга, «бу сиңа,» диде.

Тансылу елмайды. Шундый матур итеп елмайды. Егетнең йөрәге сулкылдап куйды. Сагынган икән бит ул аны, бик сагынган! Ә кыз?. Ә ник Тансылуның күзләренә моңсулык йөгерде соң? Шуны күреп, Илһам ашыгып икенче рәсемне ясарга кереште.

Бер-берсенә ябышкан кар бөртекләрен пыялага төшергәннән соң, «хәтерлисеңме?» дигәндәй кызга төбәлде. Тансылу сизелер-сизелмәс кенә баш какты.

Илһам күзен йомды. Яңа ел алдыннан, икесе бергә кәгазьдән кар бөртекләре кисеп, аларны бергә беркетеп, аерылышмаска вәгъдә бирешкәннәр иде бит алар. И, ул самими, ихлас, бер-берсе өчен утка да, суга да керергә әзер чаклар... Үткәннәр үзләренә йоткан бит аларны. Шулай хатирәләр томанында эреп бетәрләр, югалырлармы икән алар?

Егет күзен ачты. Таңсылуны тукталыштан тапмады ул. Икенче тапкыр җуя түгелме соң инде ул мәхәббәтен? Юк, тагын нидер эшләргә кирәк.

Кибетнең ачылуын хәбәр итеп кыңгырау шалтырады. Халык эчкә агылды.

Ашыгып урамга чыгып барган Илһам, ике ишек арасында, кочагына бер кызның килеп керүен тойды.

Бик таныш иде ул ана. Кызның чәченнән килгән хуш истән егетнең башы әйләнеп китте.

Әйе, бу Ул бит, Ул. Аның Тансылуы.

—Сылуым, кичер мине...

Ничек кичермәсен инде? Мәхәббәт ул—олы йөрәкле!

Бер ел элек көтеп тә ишетә алмаган шушы сүзләрдән кызның иреннәренә елмаю кунды. Таңсылу Илһамының киң кочагына ныграк сыенды.

**Алмаз МАНСУРОВ**

---

**Биредә файдаланылганнардан тыш тагын дүрт башлам бар. Менә алар:**

*Кунакханәнең мин туктаган бүлмәсе кояш карый торган якта булып, төн уртасы якынлашуга карамастан, һаман бөркү иде. Йокыга китә алмаячагымны аңлап, диңгез ярына чыктым...*

***

*Халык агымына ияреп җир астына төшеп барганда Аяз сискәнеп китте: аның аяк очында—эскалаторның көмеш баскычында—ике нәни песи баласы утыра иде. «Карале син, әй, болар да Тукай мәйданында булачак пикетка ашыгалар, ахрысы!»—дип уйлады егет.*

***

*«Камил Сәлимович! Мин сине яратам!»—кара тактага шулай дип язылган иде! Яшь укытучы кулына акбур алды.*

***

*Яшь адвокат Нуриев кесә телефонының онытылып калганын вокзалга килеп җиткәч кенә сизеп алды. Такси тотып, тиз генә яңадан фатирга кайтып килергә кирәк иде.*

*Кайтса... Кыңгырау сүнгән, тимер ишек эчтән бикле.*

**Бу җиде башламның һәркайсын үзегезнеке итә аласыз. Ләкин хикәячекләрнең күләме бер журнал битеннән артмаска тиеш.**

---

*Халык әйтсә, хак әйтә*

## Мәкальләр

*Уналты яше тулган кыз энә өстендә бии.*

*Оялчан кыз—сөйкемле кыз.*

*Ахмак кызлар күрсә, кыза, тизрәк кулын суза.*

*Бакага гашыйк булсаң, күл буеннан кайтмассың.*

*Берәү бар—үзе яратыр, берәү бар—үзен яратканны яратыр.*

*Газапсыз гыйшык юк.*

*Гашыйкка Бохара да ерак түгел.*

*Гыйшык—төтенсез ут, ачкычсыз йозак.*

*Гыйшык үпкәсез булмый.*

## Бер планета—ике кояш

Планеталар хәрәкәте законнарын өйрәнеп И.Ньютонга бөтендөнья тартылыш законын ачыклау өчен нигез салган австрияле астроном һәм математик И.Кеплернын исеме белән аталган космик обсерватория 2009 елнын 6 мартында ясалма иярчен орбитасына чыгарылды. Андагы җиһазлар Кояш системасыннан читтәге, башка йолдызлар тирәсендә әйләнүче планеталарны эзләү һәм тикшерү өчен әзерләнде.

Мин фәкыйрегезгә шул ук 2009 елнын август аенда ЮНЕСКО тарафыннан оештырылган «Астрономия һәм дөнья мирасы» исемле халыкара фәнни конференциядә шундый тикшеренүләр башкаручы галимнәрнен берсе Зигфрид Франк белән очрашу да насыйп булган иде. Докладларыбыз төрле секцияләрдә булса да, анын чыгышын тынлый алдым. Ул, ерак йолдызларнын берсе тирәсендә берничә планета әйләнеп йөрүе, шулардан берсенен Җиргә бик охшаш булуы хакында сөйләп, аудиториянен дикъкатен җәлеп итте.

Бу очрашудан сон Интернеттагы астрономия яналыкларына багышланган язмалар арасыннан ерак йолдызлар системаларындагы планеталар турындагы мәгълүматларга игътибарлырак булдым. Һәм... ни гаҗәп, галимнәр тарафыннан күптән фаразланып та монарчы бары тик фантастик әсәрләрдә генә тасвирлана торган система турында укып, шаклар каттым. Кыскасы, Кеплер обсерваториясе аша космостан алынган электрон фотоларда ике йолдыз тирәсендә әйләнүче планета табылган.

«Ике кояш тирәсендә йөри» дигән сүз планета орбитасы үзәгендә ике кояш рәттән тора дигәнне анлатмый. Аларнын, бер-берсеннән билгеле бер ераклыкта булып, уртак масса үзәге тирәсендә ике орбита буенча хәрәкәт итүләре төп шарт. Ә планета шул уртак масса үзәге тирәсендә тагын да зуррак, шул үзәктән якынча йөз миллион километр ераклыктагы орбита дип атала торган йомык траектория буенча бер әйләнешен 229 тәүлек эчендә башкарып чыга. Кыскасы, ике кояш парлап вальс әйләнгәндә, алардан җылы алучы планета ерактарак аларнын тартымына сарылып йөри. Әти, әни һәм бала диярсен боларны! Планета орбитасы астрономия дәреслекләрендә һәм китапларда тасвирлана торган түгәрәккә яисә эллипсларга һич охшамаган булырга тиеш. Анда кирегә борылыш шикелле «элмәкләр»нен булуы да бик ихтимал.

Андагы «кояш»ларнын берсенен массасы безнен Кояшыбыз массасынын 69 процентын, икенчесенеке исә, Кояшыбыз массасынын биштән бер өлешен генә тәшкил итә. Ә планета үзе Сатурн шикелле газдан оешкан гигант күк җисеме. «Климат» дигәнен бик кырыс анда, температура минус йөздән минус җитмеш градуслар арасында үзгәреп тора. Ике кояш җылытунын да файдасы юк икән.

Үз «бердәнберебезгә»—Кояшыбызга рәхмәтле булып, үз җиребездә шөкрана кылып яши бирик, җәмәгать!

**Ким ШАКИРОВ**

---

*«Ак җилкән»гә хат язу өчен адрес:*
*420066, Казан, Декабристлар ур., 2, «Казан утлары», «Ак җилкән».*
*Электрон адрес E-mail: kazanutlari@yandex.ru*

# ЖУРНАЛГА ЯЗЫЛУ ДӘВАМ ИТӘ

Хөрмәтле укучыларыбыз!

1 сентябрьдән 2012 елның беренче яртысы өчен вакытлы матбугатка язылу башланды. «Казан утлары»ның индексы **73210** (физик затлар өчен), **16262** (юридик затлар өчен). Татарстанда ярты елга язылу бәясе физик затлар өчен **272 сум 94 тиен**, юридик затлар өчен **309 сум 30 тиен.**

Журналга язылуны җиңеләйтү максатыннан абонемент үрнәген тәкъдим итәбез. Шушы квитанцияне кисеп алып, анда үзегезнең тулы адресыгыз, исем-фамилиягез һәм язылырга теләгән айларны күрсәтеп, үзегез яшәгән җирдәге элемтә бүлегенә тапшырырга кирәк.

«Казан утлары»на язылырга онытмагыз!

**Ф.СП-1**

Почта России

**АБОНЕМЕНТ на** ~~газету~~ **журнал** **73210**

(индекс издания)

*«Казан утлары»*

(наименование издания) количество комплектов:

на 20 12 год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | |

Куда

(почтовый индекс) (адрес)

Кому

(фамилия, имя, отчество)

| ПВ | место | ли-тер |
|---|---|---|

**ДОСТАВОЧНАЯ КАРТОЧКА**

на ~~газету~~ журнал **73210**

(индекс издания)

*«Казан утлары»*

(наименование издания)

| Стои-мость | подписки | ____руб.____коп. | количество комплектов: |
|---|---|---|---|
| | пере-адресовки | ____руб____коп. | |

на 20 12 год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | |

Куда

(почтовый индекс) (адрес)

Кому

(фамилия, имя, отчество)

Фәнис
Яруллин

# ХӘТЕР ТӨПЛӘРЕНДӘ УТЛЫ КҮМЕР

КӨНДӘЛЕКЛӘР

## 1985

**9 сентябрь.** Бүген бер әйбәт төш күрдем. Имеш, минем ниндидер пьесаны Г.Камал театры куя икән. Үзем ул пьесаны язмаганмын да, имеш, бары тик уйланылган гына. Әкият тә кебек. Үзем ахырына кадәр тормадым бугай.

7 сентябрь көнне телевизордан «Яңа китаплар» дигән тапшыру булды. Фоат Галимуллин алып барды. Тапшыру китап кибетеннән алып барылды, әйбәт оештырылган иде. Язучылар Р.Харис, Г.Моратов, В.Нуруллин, Р.Кәрамиләр дә бар иде. Алып баручы Тукай, Әмирхан томнарын күрсәтте, хәзерге язучыларга күчте. Шунда күңелне бер нәрсә тырнап үтте. Р.Кәраминең өч кисәктән торган бер повестен Ф.Галимуллин әдәби вакыйга булырлык әсәр дип китте. Әйберләрне бәяләгәндә шундый тупас ялгышлык җибәрү бер дә килешә торган эш түгел инде. Автор үзе кырыйда басып тора дип кенә чама чиген онытырга ярамый бит. Ул әсәр әдәбиятыбызда начар язу үрнәге буенча вакыйга булса гына инде.

Бездә кызык кына тенденция яши: беренче булып эшчеләр темасына багышланган трилогия, хатын-кызның беренче романы, фәлән-фәсмәтән. Менә шушы нәрсә беренче булсам барлык йомшаклыклар да кичерелә дигән уй тудыра. Һәм начар булса да беренче дигән исемне алып калырга тырыша башлыйлар. КамАЗ турындагы әсәрләр моңа мисал. Күпме повесть-романнар языллы—барысы да үле тудылар. Әнә хәзер Газиз Кашаповның АЭС турындагы романы—шул тенденциянең тагын бер нәтиҗәсе. Роман түгел, начар мәкаләләр, репортажлар җыелмасы. Мөгаен, шуны берәр тәнкыйтьче: Г.Кашапов Татарстан АЭСы турында беренче булып роман язды дип күккә чөеп чыгар әле.

**20 сентябрь.** 11еннән 18енә хәтле Нурсөяләр авылында булдык. Көннәр бик шәп дип әйтерлек түгел иде. Зәкия апалар бәрәнге ала башлаган иде. Фәрит булгач, юлга чыгарга батырчылык иттек, юкса машина менә ватылам, менә таралам дип калтырый иде. Кайткач, машинаны Фәрит белән Шамил абый караган иде, ничек йөрде икән бу дип шаккаттылар. Шатунный вкладыш ашалып беткән ди. Әдип абый сәбәбен таба алмаган иде. Берәүнең иске вкладышларын алып торып, шуның белән юлга чыктык. Зеленодольскида газ педале сынды. Аны Фәрит салдырып алып, сварщик эзләп китте. 1 сәгатьтән вакытлыча эшләп торырлык итеп ясатып кайтты. Шуның белән кайтып җиттек. Хәзер Нурсөя белән Фәрит вкладыш дигән нәрсәсен эзләп чыгып киттеләр.

**24 сентябрь.** Бүген өйгә җылы бирә башладылар.

Режиссер Рөстәм Абдуллаев килде. «Бай эти»не эшлибез. 80 процент пьеса бар

*Дәвамы. Башы 1нче санда*

инде, ди. Калган 20 процентын эшләргә кирәк.

**29 сентябрь.** Беркөн «Казан утлары»ннан Р.Низамиев шалтыратты. «Каз кычкыра»ны бик ошаттым, диде. 86нчы елның икенче яртысына кертергә тырышырбыз диде. Нәшриятта да редакцияләнеп бетеп ята. Әгәр анда алдарак чыкса журналга бирмәсләр инде. Ә журналда чыкмаган әйберне безнең тәнкыйтьчеләр укымый да.

**1 октябрь.** «Бай эти»не тагын бер кат эшләп чыктым. Бусы режиссер белән икенче тапкыр эшләү. Аңынчы Туфан белән 3-4 эшләгән идек. Минем өчен пьеса иң авыр жанрдыр, мөгаен. Бәлки, башкалар да шулай кат-кат эшлиләрдер инде. Миңа килеп әйтмәгәч тә.

Кичә врачлар килеп чыкты. Чакыртмаган идек. Күрәсең, теге дежур врач язып куйган булгандыр. Флорина Сергеевна йөрәккә дип ниндидер таблетка язды. Нурсөя бүген аптекага китте. Эчүен дә эчмәм инде мин аларны. Биргәч аласы килә—шул гына. Сестра Әлфия: «Һаман язасызмы?»—дип сорады. Нурсөягә: «Нигә ул шушы хәлендә һаман эшләп үзен җәфалый инде?»—ди икән. Эшләмичә яшәүнең иң зур җәза икәнен белмидер әле ул.

Бу арада көннәр яңгырлы. 6-8 градуслар тирәсе. Өйдә 21-22. Минем өчен бу салкынчарак. Юрган ябынып ятарга туры килә. Ә калын әйбер астында тизрәк арыта. Кибетләрдә бик әйбәт йомшак дөя одеаллары булган, безгә очраганы юк.

Кичә телевизордан Минзәлә театры Гогольнең «Өйләнү»ен күрсәтте. Әйбәт уйнадылар. Материалы булганда бу театр артистлары да уйный ала икән.

Өченче көн Сафуан абый Муллагалиев килеп утырды. Язучылар союзының яңа күчәсе бинасында комендант булып эшли икән. Хәзер икенче китабын әзерләү турында сүз йөртә башлаган. Башта, әле яза башлаган чорда: «Мин әйберләремне бастырып чыгару өчен язмыйм, балаларга истәлек булып калыр дип кенә язам»,—дип тотынган иде. Аннары, бер китап чыгарсам, диде. Хәзер икенчесе үзеннән-үзе шулай булырга тиеш дигән кебек карый башлаган. Шулай шул ул: аппетит ашаганда килә. Әле бераздан Союзга член итеп алдырту турында сүз кузгатачак. Үзенең фикеренчә, ул инде хәзер шигырь язуның серләренә төшенеп җиткән, беребездән дә начар язмый. Хәтта күбебезне «орып ата».

**8 ноябрь.** Бәйрәм үтеп бара. Кеше-кара килмәде. Бәйрәм көннәре бик озын һәм бик күңелсез узалар. Кичә «Литературная газета» һәм «Новый мир» журналы укып яттым. «Новый мир»ның быелгы 10 санында өч повесть, өчесе дә профессионал язучыныкы түгел. Икесен укыдым инде. Башлап язучылар да хәзер профессионаллардан ким язмый. Тормышны, яза торган предметны белү ягыннан алар бездән өстенрәк тә. Журналның шушы ук санында—Есенин турында зур гына мәкалә. Вакытында иҗатына карата жылы сүз ишетмәгән икән. Үзенең шагыйрь икәнлеген раслар өчен үләргә мәҗбүр булган.

**18 ноябрь.** Өченче көн Миңлегөл ханым (М.Рафикова) килде. Ике бүлмәле квартир биргәннәр. Панель йорт дип барасылары килми. Мин 23 ел панель йортта яшим әле, үлгәнем юк. Хәзерге квартирларның планировкасы яхшы, кухнясы зур, бүлмәләре аерым. Ә безнең кухняга коляска белән кереп булмый, бүлмәсе берсе эченнән икенчесенә кермәле, лоджие түгел, балкон. Анда коляска белән чыгып утырып булмый.

## 1986

**13 февраль.** Кичә Хәдичә апа Җәлилова килде. Бик ачык, кеше белән тиз аралаша һәм рәхәтләнеп көлә ала торган, юморга бай хатын икән. Аңа карап Муса Җәлилне күз алдына китерергә тырышып утырдым. Ул да шундый бик тере күзле, ачык һәм ягымлы кеше булгандыр, мөгаен. Күп кенә сораулар бирермен дип уйлаган идем. М.Шабай күбрәк башка нәрсәләр турында сөйләп утырды да, шәхси сорауларга вакыт әз калды. Җәлилнең 80 еллыгын уздырырга дип чакырганнар. Әминәне бик яратып бетерми, ахры, Мусаны көтү (сугыштан кайтуын көтү турында сүз бара) турында сүз чыккач: «Аның кебек көткәнче, көтмәгәнең артыграк»,—дип куйды... Хәдичә апаның туры сүзле икәнлеге күренә. Җәлил дә, бәлки, шундый булгандыр.

Бездә ике сәгать утырды. Самолеттан килеп төшүгә үк: «Мине иң беренче Фәнис Яруллиннарга алып барыгыз»,—дип куйган. Минем шулай эшләмәгән куллар белән язу яза алуыма бик шаккатты. «Быел Мусаның юбилеен Оренбургта да бик зурлап уздырдылар»,—ди... Бер бүлмәле квартирда яши икән. Хәдичә апаның 23 яшендә ире сугышта үлгән. Үзе дә сугышта катнашкан. Хәзер берүзе яши. Аның белән безнең танышлык моннан бер-ике ел элек хат аша башланган иде. Ул минем «Төшә дә исемә» дигән шигырьне укыган. Дөресрәге, Оренбургта бер Мәйшәкәр исемле хатын (шигырьләр бик яратучы) минем «Танышлар арасында» дигән китапны аңа алып барган. Ул китап боларга бик ошаган. «Җәлил премиясенә иң лаеклы кеше син»,—дип мина хат язып салган иде. Шуннан язышкалап тордык.

**25 февраль.** 21 февраль көнне берничә язучы: Т.Миннуллин, И.Юзеев, Р.Хәмид, Р.Мингалимов һәм артистлардан Г.Сафиуллина белән Риф Гатауллиннар туган көн белән котларга килгәннәр иде. Кызык кына сөйләшеп, җырлашып утырдык.

23 февральдә университеттан бер төркем студентлар белән Флера Сафиуллина килгән иде. Озак итеп җырлашып утырдык, берничә тапкыр чәйләр эчтек. Аннары Мәдинә Маликова, Әхмәт Рәшитов, Рәшит Әхмәтҗановлар килеп керде. Гармунчы да бар иде, ләкин гармуны булмады. Соңыннан Әхтәм Сатыев баян да алып килгән иде, тик кызлар таралышкан иде инде. Бик күп чәчәкләр алып килгәннәр. Студентлар мин яраткан азалия чәчәге алып килгән, Әхтәм—тюльпаннар. Бу Әхтәмне һич аңлап бетерә алмыйм әле мин: әллә артык ярдәмчел, әллә артык йомшак күңелле. Гармун табар өчен генә дә башта такси белән күпме җирләрне урады, аннары транспортта җәфалана-җәфалана үз баянын алып килде. Минем сүзләргә язылган бер җырны җырлап күрсәтер өчен күпме расходлар, күпме интегүләр күрде. «Гел шулай керәсен төшемә» дигән шигырьгә энесе көй язган. Аның энесе—Сатыев Кирам Әлфия Афзалованың баянчысы икән. Болай матур гына көйгә ошаган үзе, Әхтәм үзе дә ярыйсы гына җырлый икән.

**2 март.** Кичә башкорт филармониясе артистлары Фән Вәлиәхмәтов белән Фәйрүзә Нуриевалар килде. Татарстан районнарында гастрольләрдә йөргәннәр. Казанның да кайбер клубларында концертлар куйганнар. «Сезнең «Җилкәннәр җилдә сынала» повестен укып үскән кешеләр бит без. Сезне бик күрәсе килә иде»,—диләр. Бик матур җырлыйлар икән икесе дә. Алар белән Риф Гатауллин да килгән иде. Барысын да җырлаттык. Озак гастрольләрдә йөреп арыганнар, кич белән әле Осиново поселогында концерт куясылары бар, төнге поезд белән китәселәре бар—шулай да ялындырып тормадылар, җырладылар. Фән баянда да уйный икән. Аларга үземнең китапларны бүләк иттем. Икесенә ике китапны күрсәттем дә: «Кайсыгызга кайсын бирим?»—дип сорадым. Фән әйтә, миңа калынрагын бир, үзем төслесен, ди. Аңа «Танышлар арасында»ны, Фәйрүзәгә «Табыну»ны бирдем. Фән бик таза. «Синең бу корсакка умарта сыярлык»,—дигән идем, бик рәхәтләнеп көлделәр. Пилмән ашагач җырларга авыр дип утырганнан әйтелде инде бу сүз. Күңелле кешеләр. Берничә сәгать эчендә якын дусларга әйләндек. Аракы куйган идек, эчмәделәр. Аракы эчкәч җырлап булмый ул диләр. Үз эшләренә җаваплы карыйлар икән.

**4 март.** Удмуртиядән ике хатын килгән иде, үзләренең тормышлары турында яздырасылары килә. Син безгә барып берәр ай яшәсәң, безнең тормыш турында китап яза алыр идең, диләр. Бу хатыннар апалы-сеңелле туганнар. Сеңлесенең ире бик әйбәт икән, шуны әдәбиятта күрсәтәсе иде, ди. Алар мине таза кеше дип күз алдына китергәннәр булса кирәк. Күргәч, аптырап калдылар. Яза алмыйм дигәч, бик кәефсезләнеп кайтып киттеләр. Үзләренең тормышлары турында яздырырга теләүчеләр көннән-көн күбәя башлады әле.

**9 март.** Кичә Әхтәмнәр семьясы белән килгәннәр иде. Роза чәчәкләре алып килгәннәр. Малае биеп тә, җырлап та, шигырь сөйләп тә күрсәтте. Әле алты гына яшьтә, кыю булып үсеп килә.

Бу арада көннәр җылы торды. Эретә. Түбәләрдә әле кар ярты метр калынлыкта.

Минем иҗат кичәсен уздырырга җыеналар.

**19 март.** Кичә Марс Ш. килде. Минем иҗат кичәсендә ул чыгыш ясаячак.

Нәрсәләр сөйлим икән синең турыда, ди. Үзең ни сөйләргә теләсәң—шуны сөйләрсең, дидем. Аннары телевидение редакторы Индус Сирматов килеп, сценарийны алып китте.

Иҗат кичәсе 21 мартта Актерлар йортында булачак. Каушап калмам микән инде. Хәзер халык бик кыю бит, әллә нинди сораулар биреп төп башына утыртып куюлары да бар. Белмәгән нәрсәләремне белмим дип кенә җавап бирермен инде. Артык белдекле булып кыланып булмас.

Марс: «Кичәңне уздырырга нигә риза булдың инде, үзеңне сакларга кирәк»,—ди. Үземне саклыйм дип үземне гел кочаклап кына утырырга микәнни?! Халык алдына да бер чыгасы килә бит. Юбилейларга әллә барып житеп була, әллә юк. Утыруы бик авыр булыр, әлбәттә. Ләкин куркып торсаң бер эш тә эшләп булмый. Үземне сакласам, миңа язмаскадыр да, бәлки. Бервакыт М.Мәһдиев тә: «Син разный кульъязмалар укып күзеңне бетермә»,—дигән иде. Ә миңа төрле кеше китерә, отказать итә алмыйм.

**23 март.** Иҗат кичәм беткәннән соң мине котлаучылар барысы да бик яхшы булды диделәр. Икенче көнне телефоннан шалтыратып әйтүчеләр дә шуны кабатладылар. Университет укытучым Флера Сафиуллина: «Бер генә кичәнең дә моның кадәр табигый булганын хәтерләмим. Җавапларың бик тапкыр чыкты һәм кыска булуы белән ошады»,—диде.

Клубта халык күп иде. Байтак кеше керә алмый киткән. Бөтен проходларда басып тордылар. Телевидение өчен эшләнгән өлеше генә бераз ясалмарак чыкты бугай. Телевидениене сүндереп куйгач, икенче сулыш белән башлап җибәрдек. Артистлардан ни өчендер Дания Нуруллина килмәгән иде. Бөтен лирик шигырьләр аңарда иде. Ул шигырьләр укылмыйча калдылар. Ирек Баһманов, Равил Шәрәфиев, Роберт Батулла, Гөлзадә Сафиуллиналар шигырьләрне укыдылар. Үзем биш шигырь укыдым. Сорауларга җаваплар бирдем. Миңгол Галиев өч җырны җырлады: «Чык юлларга», «Иң гүзәл кеше икәнсез», «Рәхмәт, илем»—Мансур Хәсәнов музыкасы.

Гөлзадә «Акчарлак» (Ганс Сайфуллин муз.), «Әйттең миңа» (Риф Гатауллин муз.), «Сөялдем сөяннәргә» (Риф Гатауллин муз.), «Бер-беребез өчен» (Риф Гатауллин муз.) җырларын башкарды. Соңгысын Риф белән бергәләп җырладылар. Халык бик ошатты бу җырны...

Кичәгә безнең авылдан Мәдинә Гыйлаҗева—татар теле укытучысы, Булат Галимуллин—унынчы класс укучысы (минем шигырьләрне бик яратып укучы) килгәннәр иде. Ул шигырьләр сөйләргә дип килгән, ләкин ана сүз бирмәделәр. Аннары Флорес, Зилә Шәйхетдиновлар Арчадан килгәннәр иде. Анда педучилищеда музыкадан укыталар...

**21 апрель.** Кичә бакчага барып кайттык. Көн бик үк җылы түгел иде. Шулай да көне буе урамда яттым. Әхтәм капка баганалары утыртты. Череп беткәннәр иде.

Мөхәммәт абыйларның алмагачларына саескан оялаган. Утыра инде. Баласын чыгара алыр микән. Мөхәммәт абыйлар үзләре килгәч куркып качмаса. Без бакчада йөргәнгә дә бик чырылдады. Соныннан гына күнегә башлады. Мөхәммәт абыйга шалтыратып сөенчесен алдым кайту белән.

**1 май.** Арчада очрашу уздырып кайттык. Шәп булды, диделәр. Райком, исполком, райкомол кешеләре дә бар иде. Дом культураларында басып торыр урын да юк иде. Ике сәгатьтән артыграк барды. Тын да алмый утырдылар. Педучилище укытучылары һәм укучылары минем берничә җырны башкардылар. Гөлзадә белән Риф тә бик тырыштылар. Менә алар сәнгатькә чын күңелдән гашыйк кешеләр инде. «Монда бушка эшләп йөрү безгә ни бирә»,—дияр иде башка берәү булса. Ә болар санаторийларын калдырып, поезд белән Арчага, минем очрашуны ясарга килделәр. Көн матур торды. Райкомның һәм райкомолның секретарьлары мактау грамоталары бирделәр. Ә педучилище бер ваза бүләк итте. Бик күп роза чәчәкләре бүләк иттеләр. Районда чәчәкне табуы да кыен булгандыр әле.

Очрашудан соң Флорес Шәйхетдиновларга кайттык. Анда бик әйбәт мәҗлес булды. Төнге өчкә кадәр утырдык. Бу очрашуны оештыручы Флореслар, Зиләләр булды инде.

Очрашуны педучилище укытучысы Дамир Каюмович Галимов алып барды. Очрашу буласын район газетасына язып чыкканнар иде, бер көн алдан. «Бездә Сибгат Хәкимнәр, Гариф Ахуновлар очрашу уздырды, ләкин алар, беренчедән, үз районыбызныкы, икенчедән, юбилей кичәләре үткәрделәр. Ләкин берсенә дә бу кадәр халык килмәгәндер»,—диделәр.

Райком секретарьлары: «Моның кадәр итеп тә халыкны җыеп була икән!»—дип сәхнәдән әйтеп төште.

Кайтканда Гөлзадәләр белән бергә кайттык. Күтәреп керергә Риф булды. Юкса Нурсөянең мине күтәреп менәрлек рәте калмаган иде. Ул Арчага баруга чирләде. Әллә аппендицит, әллә эчендә берәр нәрсә—бөгелде дә төште. Кичәгә дә бара алмас дип курыккан идем, анда көч-хәл белән булса да утырды инде. Рульдә дә көчкә кайтты. Һаман терелеп житә алмый. Аяктан егылмаса ярый инде. Дөресен әйткәндә, мин халыкның рәхмәтен җыеп йөрим, ә бит ул булмаса мин дә юк. Ул булганга гына мин бар.

**5 май.** Китап чыгып житте. Бүген авторскиларны алып кайттык. Тышлыгы бик матур түгел. Кәгазе 3 нче сорт. Ярый инде. Бу китапта минем иң шәп ике повесть. Эчтәлеккә кереп китсә, укучы башка ягының житешсезлеген күрмәячәк.

Бүген көне буе кар яуды. Бик әшәке жил. Өйгә әз генә жылы бирә башладылар. Май башыннан бирле көннәр шундый әшәке жилле. Шушы кардан соң бераз жылынып китсә генә. Шомыртлар, кайбер алмагачлар чәчәк ата башлагач, өр-янадан суытты да куйды.

**6 май.** Китап чыгып житкәнне кешеләргә әйтми торам әле. «Казан утлары»ның 8нче санына бирербез дип торалар иде. Китап чыгып житкәнне белсәләр, бирмәячәкләр.

Кичә бер әкият яздым. Әкиятләр 7 табак тирәсе җыелды инде. Тагын 3 табак язылса, 89нчы елга китапка бирергә була.

**8 май.** Берничә көн инде чирләп торам. Күңел болгана, эч авырта.

Эльмира Шәрифуллинаның «Мизгел» дигән китабын укып чыктым. Фаил турында язылган повесть-истәлек. Әгәр аларның тормышларын бер дә белмәсәм, бөтенесен чынга алып укыр идем, бәлки. Ләкин күп нәрсәнең андагыча түгел икәнлеген белгәч, әсәр артык төчелеге белән күңелгә тия. Фаилнең рухын зурлау түгел, ничектер кимсетү кебегрәк килеп чыккан. Һәрхәлдә, миңа шулай тоелды.

Әгәр минем турыда кемдер шундый төчелек белән язса, бер дә ошамас иде. Кеше бит кимчелексез була алмый. Нигә бер-берсенең йомшак якларын әйтүдән куркалар икән кешеләр. Кимчелек бит ул кешене кимсетми, яза белсәң, зурайта гына.

Бервакыт безнең авыл укытучысы Мәдинә: «Сине бик тәртипле, бик акыллы булган диләр, дөресме?»—ди. «Юк,—мин әйтәм,—яшь чакта бик юләр идем мин. Кыяр урларга кергән чаклар да булды, исереп (эшли башлагач) велосипед югалтырга да туры килде. Бик күп кызлар белән дә йөрдем. Мәхәббәткә дә бик үк тугры булмадым. Мине дә кемдер ташлады, мин дә кемнедер ташладым»,—дим. Шуларны сөйләгәч, аптырап тынлап утырды. Юләрлекләр күп булды инде. Әле дә мин чибәр кызларга гашыйк булып алгалыйм. Минем бу гадәтне Нурсөя дә белә һәм ул аны гаеп тә итми. Ул яктан ул бик алга киткән карашлы. Шагыйрь кешенең гашыйк булмый гына яши алмаганын аңлый.

Гомумән, минем характерым бик үк тотрыклы түгел. Кемнәрдер гел бертөсле кара белән, бертөсле кәгазьгә генә яза. Ә мин теләсә нинди кара белән, теләсә нинди кәгазьгә, теләсә нинди шартларда яза алам. Больницада да, дачада да, гомумән, теләсә кайда. Шулай булмаса, мин эшли дә алмас идем. Кайсы көннәрдә миңа тышка чыгу эшләрен башкару өчен генә дә 7-8 сәгать вакыт кирәк. Шуның белән җәфаланганда да башка шигырь килгән чаклар була. Гомумән, минем бер тышка чыгуым хатыннарның бала тудыруына тиң. Утыз елга якын вакыт эчендә күргән җәфаларны чагыштырсаң, бер полк бала тапкан хатынныкына тиң булыр, бәлки.

Нишләптер язып булмый башлаган, кул шуа да төшә кәгазьдән. Бүгенгә житеп торыр.

Арчада очрашу вакытында бер кыз: «Шигырьләрегезне генә түгел, үзегезне дә бик яратам, Нурсөя апа көнләшмиме?»—дип язган. Исемен язмаган, үзен «Таныш

түгел бер кыз» дип куйган. Исемен язса да артыннан барып булмас иде инде, әлбәттә. Шулай да яратулары әйбәт.

**11 май.** Бакчага барып ике кич (9-11) кунып кайттык. Көннәр коточкыч салкын. Төннәрен—5 ләр. Элеп куйган сөлгеләр шыкыраеп туңган иде. Чияләр, алмагачлар чәчкә ата алмый утыралар. Май бәйрәменә ничек булсалар—һаман шул килеш.

Бакчада бик каты гына чирләп алдым. Барган көнне тышта яткан идем, салкын бәргән, ахры. Ярый температура күтәрелмәде. Корсакны төрле дарулар белән дынгычлап тутырып котылып калдым бугай. Өйгә иртә-кич ягып та чыдар хәл юк. Калтырата.

Кырыйдагы күршеләр әйбәт кешеләр. Дачаларына сирәк киләләр. Кешеләр юк чакларда мин бөтенләй чишенеп ташлап кызынам. Кояшның файдасы күп. Җәй көне әйбәтрәк кызынып калсаң, кыш көне яралар ачылмый. Кызынырга туры килмәсә, кыш буе яраларынны ямап чыгасың инде. Тышта ята торган урыным әйбәт—чәчәкләр арасында. Аллеядан үткән кешеләр мине күрмиләр. Һавадан каргалар, саесканнар гына миңа карап: «Кайчан үләсең инде, бәлки, бер-ике кабарлык итең булыр иде»,—дип уйлап китә бугай.

Яңгырлар яумый. Тузан, суык, җил. Язга ошамаган. Өйгә җылы бирәләр. Кайтып керүгә өй җылы булгач күнелле үк. Сөякләр язылып китте.

**19 май.** Мөхәммәт Мәһдиевларның алмагачына оялаган саескан бала чыгарган. Якын тирәгә карга килеп кунганны күрсәләр, саесканнар парлашып теге карганы куалар. Шулхәтле агрессив нәрсәләр, карга куркып качарга мәҗбүр була. Сыерчыкларны да үз яннарына якын җибәрмиләр. Башка елны Мөхәммәт абыйларның сыерчык ояларына сыерчык оялый иде, быел саесканнар боларны куып җибәргән. Сыерчык оясы буш калган. Мөхәммәт абыйның абыйсы Рәшит абый боларның ояларын бик җентекләп карап йөрде: «Болар ояны ныклы нигезгә салганнар,—ди.—Аска кызыл балчык сылап калдырганнар, шул кызыл балчыкка чыбыклар салып, ояны өеп менгергәннәр. Безнең Мөхәммәттән уздырганнар. Мөхәммәт өен төзегәндә нигез салып маташмаган иде»,—ди.

Саескан оясының төбәсен дә яртылаш каплый икән. Үзе кереп йөрер өчен бер як кырыйдан (көнбатыш яктан) ачык ишек калдырган. Балаларын сыерчык кебек еш ашатмый. Бер алып кайтканда, бәлки, күбрәк алып кайтадыр. Ашарга эзләп урманга оча. Безнең тиреслектә генә берничә күкәй ята (бозылгандыр дип чыгарып ташлаган идек). Шуларны ни өчендер тишеп эчми. Хуҗаларныкына тимим ди микән әллә? Кошларның сәер яклары күп. Әле менә чыпчыклар да җирдән ипи-мазар ашамыйлар. Ничә көн инде җир өстендә макарон ята, пешкән ашны түккән идек, ашаучы юк.

Бакчада чияләр, сливалар чәчәктә. Алмагачларның 17сендә чәчәкләре юк иде әле, бәлки, ачыла башлаганнардыр. Тюльпаннар быел да начар булды.

Кичә Арчадан Флорес Шәйхетдиновтан хат килде. Теге шигырь кичәсен оештырган өчен миңа да рәхмәт әлакте, дигән. С занесением в трудовую книжку, дигән. Бик әйбәт.

17се көнне телевизордан теге Актерлар йортында булган очрашуны күрсәттеләр. Әйбәт чыккан.

**23 май.** Бакчаның бик матур чагы. Чияләр, алмагачлар ап-ак. Нурсөянең генә тазалыгы юк. Икенче этаждан мине күтәреп төшерү-менгерүләре кыенлашканнан кыенлаша. Ябык булсам да ир кеше бит мин. Тәки квартирны лифтлы йортка алыштырмыйлар. Туфанга ышанычым бик зур иде, ләкин ул да председатель булып алгач бүтәннәрнең борчулары турында бик уйламый башлады кебек. Беркөн шалтыраткан идем. «Син Мөсәгыйт Хәбибуллинга шалтырат әле»,—ди. Мөсәгыйтнең моннан ун ел элек ничек итеп безне төп башына утыртуы турында аңа берничә кат сөйләгән бар бит югыйсә. Мин алардан мөмкин булмастай нәрсә таләп итмим. Ике бүлмәле квартирамны лифтлы йорттан шундый ук квартирага алыштыруларын гына сорыйм. Моны язучы булмаган инвалидка да эшлиләр югыйсә...

Югарыга менсәләр, барсының да үзләренең унышларыннан башы әйләнә башлый, күрәсең. Бу квартир мәсьәләсен өч председательгә әйтәм бит инде. Башта Зәки Нури алдап йөртте, аннары Гариф Ахунов, инде Туфан да шулай булгач, кемгә

өмет итәргә соң?.. Юк, Туфаннан өметне өзеп бетермим әле.

Кайчагында квартирны шартлатып ташлыйсы килә. Бөтенләй булмаса бирми калмаслар иде. Минә булдыксызлыгым өчен Нурсөя алдында оят. Әшли алырдай җинеллекне дә эшли алмыйм бит мин ана. Ярый, минем чирне дәвалап булмасын ди. Квартирны гына алыштырырга мөмкин ләбаса. Монда бит минә карап утырыр урын да юк. Көн туса, дангыр-донгыр машина. Тузан. Барлык «ямь» шул. Шушы чүплек өемнәренә карап мин шигырь язарга тиеш. Әгәр Нурсөя чынлап чирләп китсә, гомергә бер мәртәбә дә урам күрмәячәк бит мин... Әлбәттә, Туфанның мина эшләгән яхшылыклары булмады түгел. «Автомобиль»не язганда да, «Бай әти»не язганда да ул кат-кат укып киңәшләр бирде. Ләкин бит андый киңәшләрне мин дә күпләргә бирәм. Мина да укырга повестьлар да, хикәяләр дә, шигырьләр дә җибәрәләр. Берсен дә җавапсыз калдырмыйм. Анализлап, булдыра алганча ярдәм итәм. Кайберләрен үзем эшләп матбугатка да тәкъдим итәм. Мондый нәрсәләрне эшләргә һәр язучы бурычлы дип уйлыйм. Чөнки безне дә кемнәрдер шулай үстергән, нинди генә талантлар да кемнәргәдер таянып үсә.

**24 май.** Иртәгә Нурсөяләр авылына китәбез. Зәкия апа бик каты чирләгән.

**2 июнь.** Бер атна Нурсөяләр авылында булдык. Зәкия апаны больницага илтеп салдык үзебезнең машина белән. Берни ашамый-эчми ун көн яткан булган инде. Өендә бер кешесе юк: җизни курортта. Без кайткан көнне җизни дә, Фәрит тә кайтып кына кергәннәр иде.

Әле нинди чир икәнен дә төгәл генә белә алмадылар. Температурасы 39ны узган иде. Больницаларында пеницилин да юк. Зәкия апа Нурсөянең иң әйбәт туганы. Ул үлә-нитә калса, аларга да кайтып булмый инде яңадан. Гомер буе ике кешелек эшләгән. Ире Фәйзерахман абый—сугыш инвалиды. Бер кулы, бер күзе юк. Тормыш арбасын Зәкия апа тартып бара. Без авылга кайткач, Нурсөя берничә көн кер уды. Тәзкирә (киленнәре—үзләре белән тормый)—сыер сауды, Фәрит (читтәге малайлары) көне буе су ташыды, мунча ягарга, кер уарга, бакчага сибәргә. Ә Зәкия апа шушы эшләрнең бөтенесен берүзе эшләгән бит. Ә монда өч кеше эшләп бетерә алмый. Нурсөя аяктан егылмаса ярар иде дип курка башладым. Иртән 5тән торып баса, кичке 10-11ләргә кадәр аяк өстендә. Мине дә карарга кирәк. Авылда тормыш һаман авыр шул әле. Шуна яшьләрнең анда каласы килми.

**8 июнь.** Кичә Туфан Миңнуллинның «Әниләр һәм бәбиләр»ен үзәк телевидение аша Г.Камал театры артистлары башкаруында күрсәттеләр. Шәп уйныйлар инде безнең артистлар, шайтан алгыры. Бу пьесада драматургик материал да юк диярлек бит. Пьеса өчен иң кирәкле нәрсә—конфликт юк. Ләкин артистларның осталыгы күп кенә кимчелекләрне каплый. Ни өчендер русча текстны бик начар эшләгәннәр. Тәрҗемә түгел, нindiдер схема килеп чыккан. Татарча белмәгән тамашачы өчен бу бер сүз боткасы булып кына аңлашылгандыр. Әсәрдә конфликт булмадымы, сүз күбәя инде ул. Безнең драматургларадан Хәй Вахит конфликтлар остасы иде. Хәзер менә Ризван Хәмит кискен конфликтларга корылган пьесалар яза. Ләкин аның геройлары артык кырыслар. Шуның аркасында тамашачыда симпатия уятасы вакытта да ахыры ни белән бетәр дигән кызыксыну гына туа. Туфанның әсәрләрендә нindiдер мелодрама элементлары була. Күздән яшь чыгара. Шуңа күрә тамашачы андый әсәрләрне хубрак күрә.

**25 июнь.** Һәркөн диярлек янгырлар явып киткәли. Кичә без бакчадан кайтырга җыена башлагач кына коярга тотынды. Сәгать ярымлап яуды. Житмәсә машинасы кабынмый азапланды. Нурсөя бичара көне буе эшләп арыганнан соң машинаны кул белән әйләндереп азапланды. Стартер алдыра алмый. Ир-атка да аны әйләндерү җиңел түгел.

Бүген автосервиска шалтыраткан идем, Идиятуллин дигән инженер: «Без мастерны өйгә җибәрә алмыйбыз, машинагызны монда китерегез»,—ди.

Мин. Эшләмәгән машинаны ничек алып килергә соң?

Ул. Буксировка белән.

Мин. Буксировка өчен машинаны каян табарга?

Ул. Ансы минем эш түгел.

Менә бездә хезмәт күрсәтү ничек «шәп» куелган. Кызык өчен язу машинкалары

төзәтә торган мастерскойга шалтыратам.

Мин. Минем язу машинкам ватылган иде, өйгә мастер җибәрә алмассызмы?

Тавыш. Юк, без өйгә йөрмибез. Машинкагызны монда алып килегез.

Мин. Мин инвалид кеше, анда алып барырга мөмкинлегем юк.

Тавыш. Ансы безне кызыксындырмый.

Мин. Ә мин кем белән сөйләштем?

Тавыш. Кабул итеп алучы белән.

Мин. Фамилиягезне әйтмәссезме?

Тавыш. Юк.—Һәм трубканы куя.

20 июньнән җиләкләрне ныклап ашыйбыз инде. Быел иртәрәк өлгерде. Бу арада яуган яңгырлардан соң юл буендагы үләннәр күзгә күренеп күтәрелде. Табигатькә чыгып, күккә карап ятсаң бөтен мәшәкатьләр онытыла. Мин җылы көннәрдә гел тышта ятарга тырышам. Кайвакыт зәңгәр күккә озак карап ятканнан соң күзне йомам. Шунда төрле «төсләр» күрә башлыйм. Ул төсләр бер-берләре белән кисешәләр. Үземне шушы төсләр челтәрен бер офыктан икенче офыкка җәеп йөрүче итеп тоя башлыйм. Гомумән, төсләр мине гомер буе озатып бара. Армиядә имгәнеп госпитальдә ятканда бер мәлне бик каты алма ашыйсым килә башлады. Күзне йөртеп, түшәмдә янган лампочка яктысы белән алма ясыйм. Күзне кысып йомуга мин күз хәрәкәте белән ясаган алма пәйда була. Ул башта аксыл, аннары кызыл төскә керә. Зурая һәм бераздан формасын югалтып төрле почмакларга таралып стеналарга сеңә.

Кайвакыт төсләр мине саташыр дәрәҗәгә җиткерә. Реаль тормыш чынбарлыгы минем шушы күз хәрәкәтләре белән ясаган сурәтләр бергә кушылып, ниндидер фантастик дөнья тудыра. Кайбер шигырь юлларын мин лампочканы каләм итеп түшәмгә «язам». Күзне йомгач, ул юллар берничә секунд ап-ачык булып күренеп тора, аннары тарала. Шунсы кызык, күз хәрәкәте белән язган язуларым кулларым сәламәт чакта язган почерк төсле була.

**5 июль.** Беркөн Ренат Хариска шалтыраттым. «Каз кычкыра» повесте китапта чыгып җитте бит, мин әйтәм. Нишлибез инде, «Казан утлары»на кертәбезме, юкмы? Озак кына сөйләштек. Повестеңны бик ошатып, махсус 8нче санга керттек, ди. Подписчиклар санын арттырыр өчен, син иң укыла торган автор, ди. Сөйләшә торгач, повестьны төшереп калдырмаска булды. Журналда чыгу, әлбәттә, әйбәт инде. Аның тиражы зур, тәнкыйтьчеләр дә китап укымый, укыса-нитсә, журнал гына.

**29 июль.** 25ендә Халидәләр, Илгизләр килде. Илгиз машинаны карады. Әхтәм глушительне сварить иттереп алып килгән иде. 26-27ендә дача өенең тышын буядык Халидәләр белән.

28ендә Рөстәм Абдуллаев белән Әлмәт театрының директоры Рөстәм Фатыйхов килде. Әйбәт кенә сөйләшеп утырдык. «Кызлар күңеле—тирән сер»не биреп җибәрдем. «Бай эти»не киләсе елның язына куябыз дип торабыз, ди.

Дөресен әйтергә кирәк: пьесалар авыр языла. Язудан да бигрәк куйдыру авыр. Режиссерга җайлашырга кирәк. Ул әйткәнчә эшләп бирәсең, аның башына тагын икенче фикер китереп суга. Драма әсәрләре—ымсындыра, ләкин сиңа тоттырмый торган кыз кебек. Тота алсаң, кочагыңа кысасың һәм шатлыктан бераз исереп йөрисең, ә бераздан кочагыңны ачып карасаң, анда бөтенләй ят кыз була.

**2 август.** Кечә Нурсөя авылларына кайтып китте, Зәкия апасының хәлен белергә. Зәкия апа берничә ай инде больницада ята. Минем янда Халидә калды (олы апам Вәсиләнең кызы). Халидә 2,5 яшьлек Альбинасын алып килгән. Бик кызык сөйләшә торган чагы. Кичә яңгыр ява башлагач: «Күкери бабай килә»,—ди. Еламаганда әйбәт. Диванда утырганда да: «Әни, кутәр»,—дип әнисенең кулына менеп утырырга гына тора. Үзе бик сөйкемле.

Кичә Фәиз Зөлкарнәевтан хат килде. «Тозлы тамчы»ны редакцияләргә ана биргәннәр, ахры. Сүз башы язабызмы китапка дип сораган. Сүз башы кирәктер инде ул. Ләкин кемнән яздырырга әле аны. 15 табак кереп китә алырмы инде. Янадан шигырь китаплары әллә чыгарып була, әллә юк. Соңгы вакытта шигырьләр бик язылмый да. Әзерләгән проза китаплары да чират көтеп ята.

**20 август.** Август урталарыннан көннәр салкынайды. Яңгырлы. Бакчадагы мичне икенче якка чыгартырбыз дип сүтеп ташлаган идек, һаман чыгартып булмый. 16 август көнне Сафуан Муллагалиев чыгара башлаган иде. Көне буе Нурсөя измә ташыды, кирпеч кертте. Рәшит белән Сафуан мич чыгардылар. Инде моржасына килеп җиткәннәр иде. Иртәгә чыгарып бетерербез дип кайтып киттеләр. Алар киткәч, Нурсөя мич авызын ачып караса, шаккатты. Мичнең авызына бер утын да көчкә генә сыярлык. Ул утынны мичкә тыгар өчен дә кулынны пешерә-пешерә эчкә үрелергә кирәк. Ә безгә бит анда чуен тыгып аш пешерергә дә туры килә. Калайлар тыгып җиләк тә киптерәбез. Икенче көнне Сафуан уникеләр тирәсенә генә килде. Килеп керү белән мичнең авызы турында әйттек. Аннары мич төбенә дә кирпеч җәймәгән, өеме белән щебенканы раствор белән бутап кына ыргыткан. Шуларны әйткәч, Сафуан дуларга тотынды... Ул киткәч, Нурсөя Сәлмән дигән миччегә барган иде, ул мичне сүтәргә кушты. Кеше эшләгән эшне рәтләп булмый инде аны, диде. Нурсөя икенче көнне тагын 11гә чаклы мичне сүтте. Кирпечләрен кырды. Иске мичне Нурсөя авылларында чакта Әхтәмнәрдән сүттергән идем. Бераз эшне Нурсөядән башка гына эшләп, аңа сюрприз ясамакчы идем, барыбер мич сүтәргә туры килде. Язмышыннан качып булмыйдыр инде, күрәсең.

**27 август.** Узган атнада мичне чыгарттык. Сәлмән оста кеше икән. Мич җыйнак, матур булды. Бакчада мич бик кирәк нәрсә икән. Чүп-чарларны ягарга, аш пешерергә, ә иң әһәмиятлесе—сине җылытырга. Кеше өчен җылылык, матурлык, иркенлек кирәк. Бакчалар алып берничә түтәл әйбер үстергәнче фатирыңда ятып ул җиләк-карлыганнарны сатып кына алсаң, күпкә очсызгарак төшә югыйсә. Ләкин бакча ул сине күпмедер вакытка шәһәр коллыгыннан коткара. Үзеңне монда ирекле сизәсең. Ә ирекне, саф һаваны, күкләр биеклеген сатып алып булмый.

**29 сентябрь.** Бу көннәрдә Драйзерны укып яттым. Шәп яза. Капиталистик илдә яшәсәң, баю юлларын анардан өйрәнергә була. Ләкин без әллә бәхеткә, әллә бәхетсезлегебезгә—социализмда яшибез. Кайчандыр мин Ф.Энгельсның «Деньги», К.Маркснын «Капитал»ын укып коммунизмга бару юлларын өйрәнгән кеше. Чынлап та, нинди система яхшырак икән? Социализмдыр, мөгаен.

**30 сентябрь.** Иртән бүрек-бүрек кар яуды. 0 градус иде. Буран булып алды. Сентябрьдә мондый буран күргән юк иде. Күңел кузгалып куйды. Тагын бер кышны күрергә язган икән.

## 1987

**3 февраль.** 27 гыйнвар көнне инвалидлар өчен спецмагазиннан 287 сумга бүрек алып кайткан идек. Кара төстә. Миңа ошамады.

Чөнки төсе кара. Бик каты. Колагын күтәргән килеш башка зур, колагын төшерсәң, башны кыса.

Бүрекнең шул кимчелекләрен әйтеп кибет директорына шалтыраттым. Кире тапшырырга мөмкинме, дидем. «Мөмкин, китерегез»,—диде директор. Нурсөя икенче көнне үк алып китте. Ләкин бүрекне кире алмаганнар. Берәр атна көтегез инде, бәлки икенче төрлеләре кайтыр дигәннәр. Бер атнадан соң Нурсөя янадан бүрекне күтәреп китте. Алмаганнар, директор үзе булмаган. Шул ук көнне төштән соң кибет директорына янадан шалтыраттым. «Китерегез»,—диде. 3 февраль төштән соң тагын бүрекне күтәреп китте Нурсөя. Сатучылар эт кебек ябыштылар, ди, бигрәк тә кассир әллә ниләр әйтеп бетерде, ди. Инвалидка нигә шундый кыйммәтле әйбер аласыз дип әйтә ди. Инвалид хәерче кебек йөрергә тиешме дип талашып киттек, ди Нурсөя. Көчкә тапшырып кайтты бүрекне. Ярый әле директоры әйбәт, юкса тапшырып булмый иде, ди.

**15 март.** Соңгы вакытта көндәлек язарга да вакыт җитми. «Бай эти»не Әлмәт апрельдә әзерли башлый. Аңа берничә бит эшләп бирәсе булды. Минзәлә театрына «Кызлар күңеле—тирән сер»не җибәргән идем. Ленар Садриев (режиссер) аны укып китерде. Бу пьесаны өр-яңадан диярлек эшләп

җибәрдем. Ул арада 15 битлек хикәя язып ташладым. («Йөз карасы»). Тагын бер олы эш йөкләделәр әле миңа. Фасил Әхмәтов беркөнне шалтырата: «Бер музыкаль комедия яза башлаган идек Муллануров Мөхәммәт дигән кеше белән. Худсоветта либреттоны үткәрмәделәр,—ди.—Шуны кара әле, бәлки, соавторлыкка алынырсың»,—ди. Либреттоны 11 мартта китерделәр, 2 кат укып чыктым. Драматургик материал юк, соавтор булырлык түгел. Яңаны язып карасам гына дип бер сюжет планы төзеп куйдым да 13 мартта Фасилне, опера театрының режиссерларын, Рәмзия Такташны чакырдым да планны сөйләп бирдем. Нигездә планны ошаттылар. Композитор Ринат Еникеев та бар иде. Режиссерларның татар кешесе булмавы гына әйбәт түгел. Әсәр теленең нечкәлекләренә төшендереп булмый бит инде аларны. Валерий Васильевич Раку—баш режиссер, Таубе Леонид Генрихович—постановщик. Болай үзләре миннән канәгать калдылар төсле. Хәзер менә 11енән бирле—бүген дүртенче көн—моны ничек язарга дип баш ватам. Бер әсәр турында да болай уйланган юк иде бугай. Язган кадәресе белән безне таныштыра барырсың дип киттеләр үзләре. Бер көндә бер картинаны язып та ташладым. Ләкин икенче көнне йөрәк авыртырга тотынды, каләмне кулга алырлык булмады.

**11 апрель.** Нәрсәгә дип тотындым инде мин бу либреттога?!. Йокы качты. Йокламагач, эшләп булмый. Шулай төрле яктан тарткалаулар булмаса хәзер бетерә идем инде мин аны. Режиссерлар үзләре дә үзләренә ни кирәген белмиләр. Йә поэтик формада яз дип башны катыралар. Алай язсаң, тегеләй кирәк. Яз көне болай да авыр эшләнә, өстәвенә ничә айлар инде пролеженьнар ябылмый. Көн саен бәйләү белән мәш киленә. Яңадан бу либреттога тотынмыйм дип атып бәрәм, ләкин баштан атып бәреп булмый.

Әлмәттәге пьесаны да режиссер репетиция ясый башлыйбыз дип торганда гына режиссерны эштән алдылар. Абдуллаев хәзер анда берүзе калды...

Бик арыдым!

**20 апрель.** Бу атнада эшләр бик күп булды. Минзәлә театры «Кызлар күңеле—тирән сер»не быелгы язгы репертуарга кертергә маташа. Режиссер Ленар Садриев белән эшлибез. Ул махсус командировка алып, шуны эшләтеп бетерергә дип килде. Кичә спектакльдә катнашырга тиешле биш артист та килде. Алар белән күңелле генә итеп чәй эчтек, Нурсөя гөбәдия пешергән иде. Бер шампан бар иде. Аның белән эшнең башын билгеләп куйдык. Бу пьесаны өч кат тулысы белән эшләдем, ә финалын биш кат эшләдем инде. Бүген менә Нурсөя машинкада язып бетерсә, иртәгә режиссер композиторга (М.Имашевка) алып китәчәк кульязманы. Художнигы Наилә Кумысникова булырга тиеш. Спектакльне май ахырларына чыгарырга уйлап торалар.

Әлмәттәге «Бай эти» турында хәбәр ишетелми. Алар да апрель урталарында репетициягә тотынырга тиешләр иде. Бу пьесаның бәхете булмады. Башта күчмә театр куярга җыенган иде, хәзер Әлмәт репертуар планына кергәнгә дә икенче ел. Һаман дөнья күрә алмый. 14 апрельдә репетиция башлыйбыз дигән иде режиссер, бер атнадан безне эштән алып аттылар бит, әсәренне башка кеше куяр инде дип киттеләр. Әлмәт театрының директоры Рөстәм Фатыйховны да очырдылар. Хәзер анда Абдуллаев үзе баш, үзе койрык. Минем пьесаны куярга берәр режиссер чакырмаса, үзе өлгерә алмас инде. Хәзергә шундый хәлләр. Март, апрель айлары минем өчен бик тыгыз булды.

**21 апрель.** Бүген Азат Аббасов белән Леонид Генрихович Таубе килде. Либреттоның язган кадәресен укыдым. А.Аббасовка бик ошады. Бу музыкаль комедия либреттосы түгел, настоящий опера либреттосы ди. Миңа бернигә карамый либреттоны язып бетерергә куштылар. Бу бит үзе бер зур нәрсә булачак, диделәр. Теле бик поэтичный, образлар бик лиричный диделәр.

**22 апрель.** Кичә «Кызлар күңеле—тирән сер»не режиссер «Булган инде бу!»—дип алып китте. Бүген ул Минзәләгә кайта, берсекөнгә репетициягә тотынырга исәпләре. Уйлары барып чыкса, май ахырларына спектакльне чыгарырга тиешләр.

**25 май.** Көннәр кызу. Берничә көн бакчада булып кайттык. Без бакчада вакытта

Туфан Миңнуллин горисполкомнан Гыйлаҗев Наил дигән кешене алып килгән. Кызганыч, без өйдә булмадык. Гыйлаҗевы бер хатын белән икенче көнне дә килгән. без кайтып кергәндә янарак китеп барган булганнар. Квартирны алмаштыру мәсьәләсен Туфан, ниһаять, кузгатып җибәргән. Боз бер кузгалгач китәр инде, ди Туфан.

Боз дигәннән, кичә бакчадан кайтканда «Залесный» поселогына җитәрәк коточкыч булып боз яуды. Машиналар йөри алмый торды. Бер ун минут туктап тордык. Фараларны яндырып та алдагы машинаны ун метр калмый күреп булмый иде. Бер машинага чак килеп бәрелмәдек. Язгы ташу да бу кадәр булмагандыр. Ә бер-ике км кайтуга бөтен дөнья коп-коры иде. Полоса-полоса булып кына яуган. Бәхет тә кемгә тия, кемгә юк. Шуның кебек табигатьтә дә кайда кояш, кайда яңгыр-боз.

**10 июнь.** 4 июньдә «Бай әти»не чыгардылар. «Әти килде» исеме белән. 5 июньнән Актаныш районына куярга алып чыгып киттеләр. Кабул итү вакытында ошатканнар үзен. Ләкин исемен алмаштырып әйбәт эшләмәгәннәр. Ш.Хөсәеновның «Әни килде»се бар иде бит инде.

3 июнь көнне «Минзәлә театры «Кызлар күңеле»н чыгарырга тиеш иде. Спектакльләрендә эшләнеп бетмәгән җирләр бар дип 8енә калдырганнар. Ләкин 8е көнне дә спектакльләрен чыгарырга туры килмәде. Сабантуйга кайтып киткән бер артистлары чирләгән. 9ына калды. Шулай итеп, 9 июньдә Бикбау дигән авылга барып куябыз дип шалтыратканнар иде. Бүген Ленар шалтыратырга тиеш. Куелганмы-юкмы?

Кичә Балтач Вагыйз килгән иде. Бу спектакльне Минзәләләр Балтачка алып барабыз дип торалар. Балтачка барсалар, без дә шунда барып карый алырбыз дип өметләнеп торабыз.

7есе көнне редактор килгән иде. Галимҗан Гыйльманов дигән егет. Шигырьләрне бик ошатканлыгын әйтте, әйбәт китап булачак дип тора. Ләкин беренче бүлек артык озын, аны икегә бүлсәк әйбәт булмасмы ди. Ул бүлекне бүлеп, бүлек башына дүрт юллык шигырь әзерләп куйдым.

Бу көннәрдә «Казан утлары»на шигырьләр әзерләдем. Машинкада бастырып илтәсе калды. Уйланылган хикәяне яза алганым юк әле. Төрле вак-төяк эш белән вакыт үтә.

Нурсөянең өр-янадан язвасы ачыла башлады. Җәйгә чыксаң ана эш күбәя. Төрле якка чабарга. Бакча. Машина. Мин. Язган әйберләрне басарга да кирәк. Безнең мондый ук эшле ел булганы юк иде бугай.

Нурсөянең бер чәчәк атмый торган кактусы чәчәк атты. Синең пьесаларың чыкканга ул дип йөри. Бәлки, шулайдыр да.

*Дәвамы киләсе саннарда*

## Ictimaği-mədəni tormışıbızdan
## Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

### БӨТЕНДӨНЬЯ ТАТАР ГАЛИМНӘРЕ ҖЫЕНЫ

30 сентябрь һәм 1 октябрь көннәрендә Татарстан Фәннәр академиясендә татар галимнәренен II Бөтендөнья форумы булып узды. Ул ТР Фәннәр академиясе оешуга 20 ел тулуга багышлап һәм шуңа махсус туры китереп үткәрелде.

Мәгълүм булганча, бүгенге көндә академиядә 39 хакыйкый әгъза, 75 әгъза-мөхбир, 32 шәрәфле әгъза (шуларның икесе безнең каләмдәшләребез—Туфан Миннуллин һәм Равил Фәйзуллин).

—Инде беренче очрашуыбызга, җыелган проблемаларны уртага салып сөйләшүебез, фикер алышуыбызга 4 ел вакыт узып киткән. Инде менә сезне кабат Казанга чакырдык. Очрашуыбыз кызыклы, нәтиҗәле булыр,—дип сәламләде дөньяның төрле илләреннән, РФ республикаларыннан һәм Татарстаннан җыелган галимнәрне ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин.

Форум барышында төрле илләрдә төрле фәнни юнәлештә хезмәт куючы 20дән артык галим чыгыш ясады, үзләренең тәкъдимнәрен җиткерде. Алар—ТР Фәннәр академиясе президенты Әхмәт Мазһаров, РФА академигы, РФ Дәүләт Думасы депутаты Михаил Залиханов, РФАның Себер бүлеге рәисенең беренче урынбасары Ренад Сәгъдиев, Башкортстан, Якутия-Саха республикалары академияләре рәисләре Рамил Бәхтизин һәм Игорь Колодезников, БТК башкарма комитеты рәисе Ринат Закиров, Татарстан тарих институты директоры Рафаил Хәкимов, РФАның Океонология институты директоры Роберт Нигъмәтуллин...

Пленар утырышта фәннең төрле тармакларындагы мөһим мәсьәләләр белән бергә бүгенге шартларда татар телен саклап калу, аның үсеше өчен ихтыяҗ булдыру проблемасы кузгатылды. Әйтик, татар телен ил күләмендә икенче дәүләт теле дип кабул итүне, бердәм дәүләт имтиханын рус һәм татар телләрендә тапшыру мөмкинлеген сорарга; Татарстанда һәм Россиядә милли мәктәпләрне, шул исәптән татар мәктәпләрен ябу процессын һәм илдә РФ Конституциясен бозуны туктатырга; Казан (Идел буе) федераль университеты кысаларында Милли институт булдыру хәстәрен күрергә. Форум йомгаклары буенча кабул ителгән резолюциядә болар да чагылыш тапты. «Милли телләрнең бетүе—кеше генофондының таркалу-җимерелүе ул»,—дип басым ясап әйтте ТР Фәннәр академиясе президенты Әхмәт Мазһаров бу уңайдан.

Форумда кабул ителгән резолюциядә шулай ук, татар галимнәре җитәкчелек иткән дөньякүләм дәрәҗәдәге фәнни мәктәпләр һәм үзәкләрне саклау, аларны үстерү проектын эшкәртүне оештырырга, гыйльми яшьләр белән эшләү тәҗрибәсен өйрәнеп, аны фәнни җәмәгатьчелеккә таратырга; татарның фән, мәгариф, мәдәният эшлеклеләренең фәнни һәм иҗади мирасы мультимедиа виртуаль музей-китапханәсен булдырырга; ТРда алга таба файдалану өчен, татар галимнәренең инновацион идеяләре банкын булдыруны дәвам итәргә; «Татарстан Республикасы өчен 50 инновацион идея» конкурсында татар галимнәрен актив катнашырга чакырырга, «2015 елга кадәр ТРда фәнни һәм инновацион эшчәнлек стратегиясе» кебек республика программалары һәм проектларын гамәлгә ашыру кысаларында бөтен дөньядагы татар галимнәрен бергә туплап ныгыту буенча адреслы эшне дәвам иттерергә, диелә.

Татар галимнәре форумының соңгы көнендә Татарстан Фәннәр академиясе президенты Әхмәт Мазһаров әлеге академиягә шәрәфле әгъза буларак кабул ителгән АКШның Висконсин университеты профессоры, тарих фәннәре докторы Юлай Шамилоглу белән Россия Фәннәр академиясе Космик тикшеренүләр институтының әйдәп баручы гыйльми хезмәткәре, Германиянең Макс Планк исемендәге Астрофизика җәмгыяте институты өлкән фәнни хезмәткәре, физика-математика фәннәре докторы Марат Гыйльфановка дипломнар тапшырды.

### БҮЛӘКЛӘҮЛӘР

Башкалабызда Башкортстан мәдәнияте көннәре узды. Кунаклар Чаллы, Түбән Кама шәһәрләрендә булдылар. М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет

академия театры каршында башкорт тирмәләре урнаштырылган иде. Анда халык башкортларның кул эшләреннән күргәзмә дә карый алды. Сәнгать осталары үзләренең жыр-биюләре белән сөендерде. Башкортстан Президенты Рөстәм Хәмитов Татарстандагы Башкорт корылтае рәисе Фирдәвес Бәшировага Халыклар дуслыгы орденын, Казан хореография училищесы балетмейстеры, профессор Нинель Юлтыевага Салават Юлаев орденын тапшырды. Татарстан Президенты Рөстәм Миннеханов халык рәссамы Абрек Абзгильдинны «Фидакарь хезмәте өчен» медале белән бүләкләде. Татарстанның һәм Башкортстанның халык артисты Гөлсем Исәнгулова һәм Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының баш балетмейстеры Сәлимә Габдрахманова Президентның Рәхмәт хатына лаек булды.

### АКТИВРАК БУЛЫРГА

Матбугат һәм гаммәви коммуникацияләр буенча республика агентлыгы житәкчесе Марат Моратов ТР басма һәм электрон гаммәви мәгълүмат чаралары житәкчеләре катнашында киңәйтелгән киңәшмә үткәрде. Киңәшмәдә Роскомнадзор идарәсенең ТР буенча житәкчесе Айрат Зарипов, РФ наркотиклар әйләнешен контрольдә тоту федераль хезмәте идарәсенең ТР буенча башлыгы Фаяз Шабаев, Татарстан Үзәк сайлау комиссиясе рәисе Анатолий Фомин катнашты.

Наркоконтроль хезмәте вәкилләре наркотик һәм психотроп матдәләрнең законсыз әйләнешен кисәтүдә гаммәви мәгълүмат чараларының роле турында сөйләде, журналистларны наркоманиягә каршы көрәшкә активрак кушылырга, наркотик матдәләрнең кеше организмына китергән зыяны турында күбрәк мәгълүмат бирергә өндәде. ТР Үзәк сайлау комиссиясе рәисе Анатолий Фомин РФ Дәүләт Думасына сайлауга әзерлекнең барышы белән таныштырды, гаммәви мәгълүмат чаралары житәкчеләрен сайлауга кагылышлы законнарның сакланышы өчен җаваплы булуы турында кисәтте. А.Фомин сайлау һәм референдумнарны мәгълүмати яктырту мәсьәләләре буенча курслар үткән журналистларга РФ Үзәк сайлау комиссиясе рәисе Владимир Чуров имзалаган махсус таныклыклар тапшырды.

### ХӘТЕРДӘ

15 октябрь көнне башкалада егерменче тапкыр «Хәтер көне»н билгеләп үттеләр. Казанның Явыз Иван гаскәрләре тарафыннан яулап алынуына багышланган чарада 500гә якын кеше катнашты, араларында Башкортстан һәм Мари Иленнән килүчеләр дә бар иде. Ирек мәйданында узган бер сәгатьлек митингтан соң халык Казан урамнары буенча Кремльгә таба юнәлде. Хәтер көне 1552 елда башкаланы саклаганда һәлак булган сугышчылар истәлегенә Коръән уку белән тәмамланды.

### ТАТАРЧА ДА ЯХШЫ БЕЛ

2013 елгы Универсиаданың «кайнар элемтә»се ачылды. Телефон элемтәсе якын арада татар һәм инглиз телләрендә эшли башлый.

Универсиаданың ярдәм телефон элемтәсе гамәлгә керде. 8-800-550-2013 телефон номеры белән шалтыратып, Россия буенча абонентлар Казанда XXVII Бөтендөнья җәйге Универсиадасы, «Казан-2013» волонтерлар программасы, Бөтендөнья жәйге студентлар уеннары кысаларында үткәрелә торган мәдәни-күңел ачу һәм спорт чаралары хакында мәгълүмат ала алалар.

«Казан-2013» волонтеры булырга теләгәннәр, ярдәм телефон элемтәсе буенча «Казан-2013» Башкарма дирекциясенең волонтерлар белән эшләү департаменты хезмәткәрләре белән хәбәрләшеп, Универсиаданың волонтерлар программасында катнашуга консультация ала алалар.

### ТУКАЙ ЕЛЫ ДӘВАМ ИТӘ

***

Күптән түгел Төркиянең Тарсус шәһәрендәге бер зур урамга Габдулла Тукай исеме бирелде. «Халыкара Каражаоглан шарлавык шигырь кичәләре» дигән чара кысаларында Тарсус мэры Борһанетдин Кожамаз һәм Татарстан Мәдәният министрлыгының ТЮРКСОЙ оешмасындагы вәкиле Лилия Саттарова урамга Г.Тукай исемен бирү тантанасында катнашып, урам башындагы кызыл тасманы кисте. Тантананы ТЮРКСОЙ һәм Тарсус мэриясе вәкилләре белән шәһәр халкы да тамаша кылды. Тарсус мэры сүзләренчә, якын көннәрдә биредә никах сарае ачылачак. Шулай ук сәүдә һәм күңел ачу мәркәзе төзү дә планлаштырылган. Киләчәктә Г.Тукай урамы халык яратып йөри торган күңел ачу бульварына әйләнәчәк. Ә моннан берничә ел элек каладагы яңа бер проспектка «Татарстан» исеме бирелгән иде.

Шунысын да әйтик, Тарсус белән Татарстанның Азнакай каласы—тугандаш шәһәрләр.

***

Ульян өлкәсенең Димитровград (Мәләкәс) шәһәрендәге 22нче татар мәктәбендә 260 укучы укый. Быел беренче сыйныфка 28 бала кергән. Милли мәктәптә укырга теләүчеләр саны арта бара. Киләчәктә Г.Тукай исемен йөртәчәк әлеге белем йортының дәрәҗәсе тагын да үсте. Чөнки мәктәп алдында халкыбызның бөек шагыйре Габдулла Тукайга бюст куелды. Аны ачу тантанасы Ульяновск өлкәсендә

яшәүче милләттәшләребезнең уртак бәйрәменә әверелде. Милли киемнәр кигән укучылар кунакларны чәкчәк, татар җырлары, татар биюләре белән каршы алды.

***

Төркия дәүләт «TRT AVAZ» каналы «Тукай» мәдәният һәм мәгърифәт үзәге турында махсус тапшыру күрсәтте. Тапшыруда, башлыча, «Тукай» үзәгенең эшчәнлеге, татар халкының гореф-гадәтләре турында сүз барды. Шул исәптән бөек шагыйрь Габдулла Тукай турында мәгълүмат бирелде. Аның «Милли моннар», «Ата белән бала» һәм «Туган авыл» шигырьләре сөйләнде. Тапшыруда шулай ук татарча көйләр дә уйналды. «Туган тел» дә яңгырады. Казан ханбикәсе Сөембикә язмышы белән таныштырып, «Сөембикә бәете» башкарылды. Программада татар халык аш-сулары да танытылды. Җырбиюләр белән үрелеп барган бу тапшыру бер сәгатькә якын дәвам итте. Киләчәктә әлеге тапшыру TRTнең башка телевидение каналларында да күрсәтеләчәк.

## ГАМИЛ АФЗАЛНЫ ОЛЫЛАУ

***

Әлмәт Татар дәүләт драма театры бинасында Татарстанның халык шагыйре Гамил Афзалның тууына 90 ел тулуга багышланган тантаналы кичә булды. Анда Татарстан Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов җитәкчелегендә Казаннан килгән бер төркем каләм әһелләре, шулай ук шагыйрьнең туган җире—Актаныш районыннан якташлары катнашты.

«Гамил Афзал—татар шигъриятендә кабатланмас шәхес,—диде Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов тантанада ясаган чыгышында.—Аның җәмгыяви лирикасы гражданлык намусын гәүдәләндерсә, йомшак вә самими юморы исә вәгазь укымыйча гына җәмгыятьтәге кимчелекләрне ачып сала».

Күп кенә кунаклар кичәгә шәхси китапханәләреннән автор култамгасы куелган шигъри җыентыклар алып килгән иде. Менә шушы багышламаларның залда яңгыравы шагыйрьнең рухи дөньясын тагын да киңрәк ачарга ярдәм итте. «Безнең әти намуслылык һәм рухилыкны бар нәрсәдән өстен саный иде»,—дип искәртте әдипнең кызы Рауза Колмәтова, искә алу кичәсендә әйтелгән сүзләрне раслап.

Юбилей кичәсе «Татнефть» ачык акционерлык җәмгыяте һәм Әлмәт шәһәре хакимияте булышлыгы белән оештырылды.

***

15-16 сентябрьдә Татарстанның халык язучысы Туфан Миңнуллин, ТР Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов, язучылар Марсель Галиев, Камил Кәримов, шагыйрә якташыбыз Фәйрүзә Мөслимова, драматург Данил Салихов, шулай ук Әлмәт, Чаллы шәһәрләреннән язучылар Татарстанның халык шагыйре, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе, Такталачык авылында туып-үскән күренекле шәхесебез Гамил Афзалның тууына 90 ел тулу уңаеннан Актаныш-та оештырылган чараларда катнашты.

Беренче көнне район мәдәният йортында Г.Афзалны искә алу кичәсе булды, ул районыбыз һәвәскәрләренең җыр-биюләре белән үрелеп барды. Кичәдә район башлыгы Энгель Фәттахов чыгыш ясап, Татарстан Язучылар берлеге һәм Актаныш муниципаль районы гамәлгә куйган Гамил Афзал исемендәге тәүге премияне беренче иясенә—«Минһаҗ маҗаралары» исемле китабы өчен Туфан ага Миңнуллинга тапшырды. Кичәдә Г.Афзалның җәмәгате Нәфисә ханым да катнашып, үзенең истәлекләре белән уртаклашты.

Икенче көнне исә язучылар гимназиядә белем алучы балалар белән очрашты, аларның сорауларына җавап бирде. Соңыннан кунаклар Такталачык авылына барып, Г.Афзал, М.Мутин истәлекләрен саклаган музей белән дә таныштылар.

## ШАГЫЙРЬ ИҖАТЫ АТНАЛЫГЫ

Татарстанның халык шагыйре, Россиянең Дәүләт премиясе, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Ренат Хариска 70 яшь тулу уңаеннан театр атналыгы булып узды. Ул М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрында шагыйрь либреттосы нигезендә иҗат ителгән «Йосыф кыйссасы» балеты (композитор Л.Любовский) белән ачылды.

Спектакль башланыр алдыннан Ренат Харисны Татарстан Премьер-министры Илдар Халиков тәбрикләде һәм аңа «Татарстан Республикасы каршындагы казанышлары өчен» орденын тапшырды. Аннары юбилярны Татарстан Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов, Россия Язучылар берлеге җаваплы секретаре Николай Переяслов, Дагыстан Язучылар берлеге рәисе Магомед Әхмәтов, Башкортстан Язучылар берлеге рәисе Азамат Юлдашбаев, Чуашстанның халык шагыйре Валерий Тургай котлады. Ренат Харис иҗатының байлыгын, масштаблылыгын билгеләп үтте, төрле республикалар халыклары арасында иҗади дуслыкны ныгытуга зур көч куюы өчен аңа ихлас рәхмәтләрен ирештерде.

Юбилярның иҗаты зур. Р.Харис—шигъри роман, кырыктан артык поэма, дистәгә якын шигъри цикл, йөзләрчә җыр, кантата авторы. Ул композитор М.Яруллин белән бергә «Кеше» ораториясен язып, М.Хәлил премиясенә лаек булды. Аның

либреттолары буенча «Шагыйрь мәхәббәте» (Р.Ахиярова) операсы, «Йосыф кыйссасы» (Л.Любовский) балеты куелды, телефильмнар эшләнде. Пьесалары Г.Кариев исемендәге Казан Татар дәүләт яшь тамашачы, «Әкият» Татар дәүләт курчак театрларында куелды.

Атна дәвамында тамашачы игътибарына Ренат Харис либреттосына язылган «Шагыйрь мәхәббәте» операсы (М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры), «Умырзая» драмасы (Г.Кариев исемендәге Казан Татар дәүләт яшь тамашачы театры), «Кәкрүшкә», «Абай-бабай аланы» («Әкият» Татар дәүләт курчак театры) тәкъдим ителде.

### АЛИШ БҮЛӘКЛӘРЕ ТАПШЫРЫЛДЫ

Һәр елны көз керү белән, патриот-шагыйрь Абдулла Алишны искә алу чаралары уздыру, аның исемендәге әдәби премияне тапшыру күркәм традициягә әйләнде. Быел да бу тантана Спас районында булды. Башта шагыйрьнең туган авылы Көектә А.Алиш бюстына чәчәкләр куелды. Шунда ук шигъри митинг үткәрелде. Аннары бәйрәм Болгар сәнгать мәктәбендә дәвам итте. Бу чараларда катнашучыларны Спас муниципаль районы башлыгы Камил Нагаев сәламләде. Алишның якташлары алдында Казаннан кайткан кунаклар, Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Вакыйф Нуриев, язучылар Ләбиб Лерон, Әнәс Хәсәнов, Йолдыз Шәрәпова, Дания Гайнетдинова (алар барысы да А.Алиш бүләге иясе) һәм Татарстан китап нәшрияты (бу коллектив та А.Алиш премиясе лауреаты) баш мөхәррире, шагыйрь Ленар Шәех чыгыш ясады.

Ин дулкынландыргыч мизгелләр тантана ахырында булды: Татарстан Мәдәният министрлыгы һәм Язучылар берлегенең Абдулла Алиш исемендәге премиясенең быелгы лауреатлары игълан ителде. Алар— Татарстанның халык шагыйре Фәнис Яруллин һәм шагыйрь, прозаик, галим Фарсель Зыятдинов. Ф.Яруллинга премия—Казанда, Ф. Зыятдиновка А.Алишнын туган җирендә тапшырылды.

### ЯШЬ ИҖАТЧЫЛАРГА— ӘДИП БҮЛӘКЛӘРЕ

Менә өченче ел инде яшь иҗатчыларга Арча муниципаль районы хакимиятенең Татарстанның халык язучысы Гариф Ахунов исемендәге премияләре тапшырыла. Сәнгать мәктәбендә үткәрелгән тантанага районның татар теле һәм әдәбияты укытучылары, китапханәчеләр, мәктәп укучылары чакырылган иде. Премияләр 6 номинациядә (проза, шигърият, публицистика, рәсем сәнгате, музыка, үзешчән сәнгать) бирелде. Бүләкне укучыларга Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Надия Мифтахетдинова, Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Вакыйф Нуриев, Татарстанның халык язучысы Мөсәгыйт Хәбибуллин, шагыйрь, драматург Рафис Корбан, яшь шагыйрә Йолдыз Миннуллина, шагыйрьләр Наилә Ахунова (Г.Ахуновның кызы), Борис Вайнер (Г.Ахуновның кияве), әдипнең оныгы, рәссам-дизайнер Аида Вайнер тапшырды.

### ИТАЛИЯЛЕЛӘР БЕЗДӘ КУНАКТА

Россиядә быел Италия мәдәнияте елы булганга күрә, бер төркем язучы-журналистлар: Себастьяно Грассо, Анджело Гульельми, Симоне Кальтабеллота, Марина Тереза Джавери, Лучана Кастеллина, Андреа Censored Кербакер, Луиджи Ла Спина, Антонио Ньоли, Роберто Паццы, Марио Сантагостини Россияне үз күзләре белән күрергә теләп, ерак юлга чыкканнар. Сәфәрләре— Мәскәү, Түбән Новгород, Екатеринбург, Томск, Красноярск, Иркутск, Улан-Удэ һәм, ниһаять, Казан...

Кунаклар ТР Милли китапханәсендә Татарстан язучылары, китапханәчеләр, студентлар белән очраштылар. Җырчыбыз Рөстәм Маликов халкыбызның моңлы көйләрен, итальян җырларын сузып, үзләрен тагын бер тапкыр шаккатырды.

Бөтен дөнья балаларына Чиполлинонь бүләк иткән Джанни Родари варислары безгә буш кул белән генә килмәгәннәр икән: очрашуда катнашкан һәркемгә рус һәм итальян телендә әсәрләре тупланган китап бүләк иттеләр. Кунак ашы—кара-каршы дигәндәй, Милли китапханә кунакларга истәлеккә быел олуг юбилее зурлап үткәрелгән Тукайның төрле телләргә тәрҗемә ителгән шигырьләр җыентыгын һәм Казан турында матур альбом тапшырды.

Кунаклар белән очрашулар Идел буе Федераль университетында һәм Тукай музеенда да узды.

### ЕРАКТАГЫ ЯКЫННАР

Көньяк Сахалинда 7 октябрьдә Ерак Көнчыгыш татарлары конгрессының өченче төбәкара фәнни-гамәли конференциясе узды. Бу мөһим чараны Сахалинның татар милли-мәдәни автономиясе оештырган. Чарада Бөтендөнья Татар конгрессы башкарма комитеты рәисенең урынбасары Ирек Шәрипов, өлкә һәм шәһәр хакимияте вәкилләре, Хабаровск, Амурдагы Комсомольск, Сахалин утравының Холмск, Корсаков һәм Ново-Александровка шәһәрләреннән килгән милли җәмгыять активистлары катнашты. Конференциягә килүчеләр Ерак Көнчыгыш татар һәм башкортларының бүгенге хәле, аларның киләчәк язмышы хакында фикер алышты, үзләрен борчыган мәсьәләләрне уртага салып сөйләште, тәҗрибә уртаклашты.

### «МӘКТӘПКӘ—КОМПЬЮТЕР»

Татарстанда 40 мең мәктәп укытучысы шәхси ноутбук белән тәэмин ителде. Узган елның апрелендә Татарстанда Укытучылар елы кысаларында Президент Р.Миннеханов тәкъдиме белән старт алган «Укытучыга—ноутбук» дигән проектны тормышка ашыру тәгәлләнде дигән сүз бу. Ә инде проектның икенчесе—«Мәктәпкә—компьютер» проекты кысаларында республикабыз мәктәпләренә 6 мең яңа компьютер җибәрелде. Әле тагын уку елы дәвамында 53 мәктәпкә (һәр районда—берәр мәктәпкә) башлангыч сыйныфлар өчен 212 мобиль класс (барлыгы 148 миллион сумлык) кайтарылачак. Быелның азагына кадәр Татарстанның барлык мәктәпләре дә мультимедиа җиһазлары белән тәэмин ителәчәк.

Татарстан Президенты алдан ук белдергәнчә, компьютерлар республикабыз мәктәпләрендә һәр дүрт ел саен алыштырылып торылачак.

### ХАҖИЛАР КҮБӘЯ

Россиядән хажга баручылар квотасы ике мең кешегә арттырылган.

Июль аенда Нальчикта Россия Президенты Дмитрий Медведевның илебездәге мөселман бергәлекләре лидерлары белән очрашуында хажга бару өчен квотаны арттыру турында тәкъдимнең җиткерелүен искә төшерик. Менә хәзер аның буенча тиешле карар кабул ителгән. Шулай итеп, быел Россиядән 22,5 мең кешегә хаж кылу мөмкинлеге ачыла дигән сүз. Татарстанның квотасы исә—2 мең кеше.

### ИЗГЕ ГАМӘЛ БУЛАЧАК

Татарстан Диния нәзарәтенең Ярдәм күрсәтү һәм хәйриячелек бүлеге республика мәчет-мәдрәсәләре өчен китап җыю чарасын башлап җибәрде. «Һәркемнең өйдәге китапханәсендә укылган китаплары бар. Аларны мәчетләргә бүләк итсәгез, башка мөселманнар да ислам турында белемнәрен тирәнәйтә алачак»,—дип хәбәр итәләр Диния нәзарәтенең матбугат бүлегендә. Китапларны җыю 16 ноябрьгә кадәр дәвам итәчәк. Барлык сораулар белән (843) 236-52-12 телефонына мөрәҗәгать итәргә мөмкин.

### УЛ ДА ВАФАТ

Кырым татарларының халыкара танылган язучысы Чыңгыз Дагҗы 92нче яшендә Лондонда вафат булды. Ул әсәрләрен төрекчә язган бердәнбер кырым язучысы буларак билгеле. Ч.Дагҗы—романнар, мемуарлар һәм хикәяләрдән торган 25 китап авторы. Араларында гарәпчә һәм русчага тәрҗемә ителгәннәре дә бар. Беренче ике романы 1956 елда Истанбулда басылган. Аның берсе—«Куркыныч еллар», икенчесе «Илен югалткан адәм» дип атала. Чыңгыз Дагҗының әсәрләре күбрәк үз тормышын, кырым татарларының михнәтле яшәешен чагылдыра.

### ХЕЗМӘТЕНӘ КҮРӘ ХӨРМӘТЕ

Татарстан Республикасы гаммәви мәгълүмат чараларын үстерүгә зур өлеш кертkәне өчен хезмәт ветераны **Зарипов Марсель Харис улы** Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләнде.

## ЭЛЕКТРОН АДРЕСЫБЫЗ ҮЗГӘРДЕ

Игътибар!

Журналыбызның *kazanutlari@telebit.ru.* электрон адресы ябылу сәбәпле, хатларыгызны, документларыгызны фәкать **kazanutlari@yandex.ru** адресына гына юллагыз.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Беренче биттә:* «Көзнең соңгы көннәре».

*Дүртенче биттә:* шагыйрә **Ләйсән Юнысова**.

# Яңа китаплар




**Рәис Даутов:** биобиблиографик белешмәләр, мәкалә һәм хатирәләр җыентыгы (төз. М.Госманов, Р.Рахмани). Казан: «Җыен», 2011.—368 бит. Тиражы—2000 данә.

«Шәхесләребез» сериясендә чыккан бу җыентык татар әдәбияты һәм мәдәнияте тарихының күренекле белгече, тәрҗемәче, редактор, Татарстан китап нәшриятында һәм татар энциклопедия институтында 40 елга якын эшләп, халкыбыз мирасын кайтаруда зур хезмәт күрсәткән Рәис Нәүширван улы Даутовның (1928-2007) тормыш юлына һәм иҗади эшчәнлеген яктырта.

Фотодокументлар белән бизәлгән бу китап мәдәни, иҗтимагый тарихыбыз белән кызыксынучы киң катлау укучылар өчен кызык булачак.




**Лена Шагыйрьҗан.** Хуш исләре җиһан гөлләренең: поэма, эссе, лирик-фәлсәфи миниатюралар, тәрҗемәләр, мәкаләләр.—Казан: Татар. кит. нәшр., 2011.—303 бит. Тиражы—2000 данә.

«Дөньядагы барлык-барлык сүзләр арасында минем дә үз серләрем бар...» дип әйтә шагыйрә үзенең «Сүз» дигән эссе-язмасында.

Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, шагыйрә Лена Шагыйрьҗанның бу китабына соңгы елларда әдәбият сөючеләр һәм киң җәмәгатьчелек арасында җитди кызыксыну уяткан әсәрләре һәм дөнья шигъриятеннән тәрҗемәләре тупланган.



Лəйсəн Юнысова

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)